# КАЗАН УТЛАРЫ

www.kazanutlary.ru

*ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ*

*1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА*


Бу санда


ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Илсөяр ИКСАНОВА. Таулар миңа – йөрәк ярасы... *Шигырьләр.* ...3
Миргазиян ЮНЫС. Кыпчак кызы Аксанә. *Роман.* ...8
Данис ХӘЙРУЛЛИН. Бер төзегән гомер бue төзер... *Шигырьләр.* ...47
Алмаз ХӘМЗИН. Шәрәфи – «хи-хи» түгел... *Кинаяле тамаша.* ...51
Шәфикъ ИМАТДИНОВ. Үкенерлек яшәмәдек бугай... *Шигырьләр.*
*(Ркаил Зәйдулланың кереш сүзе белән).* ...80
Лира ИБРАҺИМОВА. Айзидә. *Хикәя.* ...113

«ХӘЗИНӘ» ӘДӘБИ КОНКУРСЫ

Фәрит ЯХИН. Яз яме белән бергә. *Повесть.* ...84

ЯҢА ИСЕМНӘР

Нурлан ГАНИЕВ. Ил бетмәсә, бетмәс телем дә... *Шигырьләр.* ...107

*Җәһәт тәнкыйть:* сәхифәне Дания ЗАҺИДУЛЛИНА алып бара. ...111

ДӨНЬЯ ХАЛЫКЛАРЫ ӘДӘБИЯТЫ

Курт ВОННЕГУТ. Хикәяләр. *(Рүзәл Мөхәммәтша тәрҗемәсе.)* ...142

*Укучы фикере:* Руфина ФӘТТАХОВА. Әкиятсез балачак. ...155

ХУҖА БӘДИГЫЙНЫҢ ТУУЫНА 130 ЕЛ

Рәис ШАҺИЕВ, Нурулла ГАРИФ. Хуҗа Бәдигый һәм аның нәсел-нәсәбе турында
яңа табышлар. ...156

ШӘҮКӘТ БИКТИМЕРОВНЫҢ ТУУЫНА 90 ЕЛ

*Фотоархив:* Титаннар гасыры. *Рәйсә ЮСУПОВА әзерләде.* ...160

*Фикер:* Фәрит ХАТИПОВ. Милли яңгыраш. ...162

ЮБИЛЕЙЛАР

*Фотоархив:* Ринат Мөхәммәдиев тормышыннан мизгелләр. ...140
*Бәләкәйләр:* Ринат МӨХӘММӘДИЕВ. Прәникле төшләрем... ...164

ПЕЧӘН БАЗАРЫ

Зәет МОТАЛЛАПОВ. Туксанынчы еллар көндәлегеннән. ...175

*Шаян сәхифә:* Уены-чыны бергә. *Сәхифәне Марсель ГАЛИЕВ әзерләде.* ...179

2019 елда дини бәйрәмнәр һәм истәлекле көннәр. ...181
Хушлашу сүзе. ...183
2018 елда «Казан утлары» журналында басылган әсәрләр исемлеге. ...184
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. ...190

Гамәлгә куючы –
«Татмедиа»
акционерлык
җәмгыяте

*БАШ МӨХӘРРИР –*
**Рөстәм Госман улы**
**ГАЛИУЛЛИН**

*ИДАРӘ:*

**Ирада Әюпова**
**Рабит Батулла**
**Мөдәррис Вәлиев**
**Разил Вәлиев**
**Рәдиф Гаташ**
**Рәдиф Җамалетдинов**
**Айрат Зарипов**
**Дания Заһидуллина**
**Илфак Ибраһимов**
**Дамир Исхаков**
**Зиннур Мансуров**
**Хатыйп Миңнегулов**
**Вакыйф Нуриев**
*(җаваплы сәркатип)*
**Данил Салихов**
**Равил Фәйзуллин**
**Рамил Ханнанов**
*(баш мөхәррир урынбасары)*
**Илсур Һадиуллин**
**Рәфикъ Юныс**

---

*Мөхәррирләр:* **Айгөл Әхмәтгалиева, Фәнил Гыйләҗев, Фирүзә Җамалетдинова, Айсылу Имамиева, Камил Кәримов.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Лилия Гатауллина, Элеонора Җамалиева, Наил Кадыйров.**
*Сайт мөхәррире:* **Рәзилә Хәйретдинова.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Люция Сөләйманова** (баш бухгалтер).

---

✉✉: Редакция һәм нәшер адресы: *420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.*
☎☎: *Баш мөхәррир – 222-05-50 (өст. 1618).*
*Баш мөхәррир урынбасары – 222-09-83 (өст.1612).*
*Җаваплы сәркатип һәм проза бүлеге – 222-09-83 (өст. 1613)*
*Шигърият, сәнгать һәм хатлар бүлеге – 222-09-83 (өст.1616).*
*Исәп-хисап бүлеге – 222-09-80 (өст.1266), касса – 222-09-84 (өст.1874).*
➂: **Факс** – (843) *222-09-83 (өст.1612).*
💻: **E-mail:** kazanutlari@yandex.ru

---

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

---

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды. Айга бер тапкыр чыга.
Басарга кул куелды 30.11.2018, график буенча 30.11.2018.
Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70Х108 $^{1}/_{16}$.
Нәшер-хисап табагы 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ Е-3270. Тираж 4167.
Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләрне күзәтү буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы идарәсендә 2011 елның 23 мартында теркәлде.
Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС77-44362.
Индекслар: 73210 (Татарстаннан читтә яшәүче физик затлар өчен), П2365 (Татарстанда яшәүче физик затлар өчен), 16262 (Татарстаннан читтәге юридик затлар өчен), П2368 (Татарстандагы юридик затлар өчен). Бәясе ирекле.

---

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.
«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2018 ел



Илсөяр
Иксанова

# ТАУЛАР МИҢА – ЙӨРӘК ЯРАСЫ...

## Тагын бер ел үтте...

Тагын бер ел үтте.
Тагын бер ел
Китеп бара,
күчә тарихка –
Шатлык-көенечләр,
мәшәкатьләр,
Иске дуслар, яңа танышлар.

Бар да үтә…
Кала җанда Сөю
Һәм… соклану кала Дөньяга.
Күпме сулар эчмә,
гомер кичмә,
Бу дөнья бит көн дә өр-яңа.

Сокландыра,
Моңландыра кайчак.
Уйландыра,
Сала утларга.
Кабатлана еллар,
фасыл, айлар,
Тик… һәр көне аның өр-яңа.

Яңа еллар килә…
Яңа еллар
Нинди булыр,
Ниләр күрсәтер?
Яхшыга тик юрыйк,
Исән булыйк.
Өзелмәсен Өмет
һәм Хәтер!

---

Илсөяр ИКСАНОВА (1966) – *шагыйрә; «Ышанасы килә», «Кышкы канәферләр», «Кырык кыл» һ.б. китаплар авторы. С.Сөләйманова һәм Һ.Такташ исемендәге әдәби премияләр лауреаты. Казанда яши.*

## Татар көрәше

Сабантуйның төп бәйгесе – көрәш!
Кыл шикелле һава тартылган, –
Бөтен халык, бердәм өнсез калып,
Сулышын да ала бер тыннан.

Берләштергән,
укмаштырган көрәш, –
Монда бөтен мәйдан хөкемдар.
Бөек Гаделлекне саклый шулай, –
Уч төбендә кебек батырлар.

Хәрәмләшү, хәйлә коруларны
Бик тиз тотып ала ул халык.
Көрәшәсең икән, гадел көрәш! –
Милләтеңнең йөзен акларлык

Булсын синең һәрбер хәрәкәтең, –
Кыю, төгәл, матур, акыллы.
Бары шулай көрәшкәндә генә
Мәйдан таный асыл батырны.

Сабантуйның тажы – милли көрәш,
Бил алышу гына түгел ул.
Карурманнар кичкән чакларда да
Кара ягылмаган күңел ул!

***

Кылдан нечкә – кыз баланың язмышы,
Кыл өстендә – кыз баланың бармышы.
И Ходаем,
Насыйп иткәч тиң ярын,
Хәерле кыл,
Гомерлек ит никахын!

Ир-егетнең иңнәрендә – ил йөге.
Ир-егетнең иңнәрендә – тиң йөге:
Кыз баланың кылдан нечкә язмышы.
Тормыш дигән сират аша барышы.

Кылдан нечкә,
Кылычтан да үткен ул, –
Тормыш шундый –
Кырык сыртлы үткел ул!
Мең эченнән бердәнбереңал табып!
Үтү кирәк бер-береңә таянып!

## Ачы гамь

*Ркаил Зәйдуллага*

Ничә ел бер юлдан атлыйбыз,
Сулыйбыз шул бер үк гамьне без.
Баллана алмыйбыз,
Гамь ачы, –
Шуңа да гел балан тәмле без.

Язмышка язылган, күрәсең,
Гамьнәрнең ачысын йотарга.
Үтеңне сытардай ачыдан
Сискәнү
Күпвакыт коткара.

Йомылып
Йә оеп калудан
Коткара.
Һәм алга этәрә.
Бу җиргә, мөгаен, килгән без
Кышларны уятып китәргә!..

## Авыр сүз

*Авыр сүзләр ишетсәгез,*
*Үткәреп җибәрегез!*
Халык җыры

Үткәреп җибәрсәң дә...
Күңел кителеп кала.
Сытылган үт күк ачысы
Бәгырьне өтеп ала.

Авыр сүз ишеткән саен
Тетелә бара йөрәк.
...Фәрештәләр китә качып,
Кала тик шыксыз өрәк!

***

Күз алдымда тора көлеп, –
Шомыртларың ап-ак күбек.
Күңелеңне аңлый алган
Булыр микән минем кебек?!.
Ап-ак хисләр
Коелып кала,
Гомеркәйләр
Узып бара.
Чәчәкләрне
Өзә җилләр,
Кадерләрне
Белер кемнәр?

Язда ап-ак шомыртларның
Җимешләре кара икән.
Тик язларның яктылыгы
Күңелләрдә кала икән!
Ап-ак хисләр
Коелып кала,
Өметләрне
Еллар ала.
Чәчәкләрне
Өзә җилләр,
Кадерләрне
Белер кемнәр?

***

Киткәнеңә күпме вакыт үтте.
Үзгәрдеме дөнья?
Үзгәрде!
Шау чәчәкле җәй башында калдым,
Инде көтеп торам көзләрне.

Киткәнеңә күпме гомер үтте, –
Синле гасыр күчте тарихка.
Син китте дип, туктамады вакыт...
Бармас төсле иде карыш та!..

Киткәнеңә күпме еллар үтте,
Күпме еллар өтте бәгырьне!
Күзләремә карап басып торам.
...Син җәйләрдә калдың, кадерлем.

***

Мин кем сиңа?..
Шушы соравыма
Җавап табалмадым ничә еллар!
Бүген белдем.
Йоттым яшьләремне, –
Чит-ятларга рәнҗеп еламыйлар...

## Тауларны сагыну

**1**

Тау артында тагын таулар, –
Биегрәк һәм серлерәк...
Ап-ак түбәләрен күргәч,
Алгысынып тибә йөрәк.

Кул сузымы кебек кенә.
Җитим дисәң,
Ай-һай ерак!
Үткелләрне, бозлыкларны
Узу кирәк юллар урап.

Кичү кирәк тау елгасын –
Кайнап аккан бозлы суны.
Упкын-ярдан үтү кирәк –
Каласыңмы, егыласыңмы...

Үрмәлисең үҗәтләнеп,
Биеклек, һай, ашкындыра!
Түбәсенә җитсәң,
Алда
Яуланмаган таулар тора!

**2**

Күптән инде мин тауларга менмим!
Тик сагынам серле тауларны.
Тау сулышын тоймый яшәгәннәр
Минем халәтемне аңлармы?

Таулар миңа – сөю биеклеге,
Таулар миңа – йөрәк ярасы.
Үзәкләрне өзгән үткелләре –

Гомер белән гомер арасы.
Синле гомер биеклектә калды...
Мин ялгызым
Төштем үзәнгә.
Баш очында мәңге торган күкләр
Ишелер күк иде ул мәлдә...

Күкләр ишелмәде.
Таулар исән.
Чәлпәрәмә бары хыяллар...
Ымсындырып көтеп калды бары
Без яуларга тиеш кыялар.

Синнән ары тауга менгәнем юк!
Төшләремдә генә буталам, –
Биеклеккә мине өндәвеңме? –
Кул изисең кебек Ак таудан...

## Өрәм...

*Илдә көчек булсаң да бик ярый,*
*Тик ил өчен кирәк өрергә!*
Зөлфәт

Ил өчен бит!
Өрәм, өрәм...
Көчек кенә булсам да.
Ил, дип, өргән көчекләрнең
Түре бездә – бусага.
Өрәм, өрәм...
Ил өчен бит!
Илдәшләрем тыңлыйлар.
...Алабайлар, Карабайлар
Кочаклашып җырлыйлар!

***

Минем илем төнгә кереп бара,
Таң юлыннан киттек каерылып.
Төн кичүләр таныш, юкса, безгә
Дөнья яктысыннан аерылып.

Күрә торып төнгә керәбез без.
Хакимнәргә кулай төн карасы.
Язмышына битараф бу илне
Гафиллектән ничек коткарасы?!.

Ничек кичеп чыгарбыз соң төнне?
Табылырмы ут кабызыр чакма?
Кабат төнгә кереп барабыз бит,
Таңга чыктык кына дигән чакта.

Миргазиян
Юныс

# КЫПЧАК КЫЗЫ АКСАНӘ

РОМАН

**Сигезенче бүлек**

**1**

Оксанадан хәбәр булмау Габдрахманның эш арасында онытылып торып та, ялгыз калу белән кабат исенә килеп төшкән даими сызлау чыганагына әверелә башлады. Рахманкулов аңа инде биш тапкыр радиограмма җибәрде. Урта диңгезгә чыккач, Кызыл диңгездә барганда, Бабел Мандәб бугазын үтеп Һинд океанына кергәннән соң... Җавап һаман юк. Бер-бер хәл булмагандыр бит? Әллә онытырга хәл кылып, аңардан бөтенләй ваз кичүеме?.. Кыз белән егет арасындагы мөнәсәбәтләрне кем белеп бетергән... Бүген үләргә җитеп бер-берсенә омтылган ике гашыйкның, иртә таңга кадәр уйланып ятканнан соң, икенче көнне инде араларының кинәт суынып китүе бер дә булмаслык хәлмени? Нидер бар монда... Шушы көнгә кадәр сулкылдап торган йөрәге бу югалтуны ничек кичерер... Элеккечә үк ялкынланып яратырга язсын иде.

Төнге йокысыз ялгызлыкта Габдрахманга шушындый тынгысыз уйлар килеп хафаландыра иде.

Төшке аштан соң вахтага басарга рубкага менгәндә, Габдрахманга радист Суменко очрады:

– Сезгә радиограмма бар. Каютагызга кертергә җыенып тора идем, – диде ул һәм Рахманкуловка ярты стандарт бит зурлыгындагы бланк тоттырды. – Акчасы күп булса кирәк йөргән кызыңның, төгәл ярты литрга җитәрлек түләгән.

Озак көткән иде Рахманкулов бу радиограмманы. Алу белән укып чыкса, ләззәте тулы булмас, дип, кәгазьне, икегә бөкләп, кесәсенә салып куйды. Өченче штурман белән рубкага керделәр. Корабның маршруты сызылган карта өстендә һава торышын белгерткән НАВИП радиограммасы ята. Координатларын ачыклаганчы, Габдрахман радиограммага күз салды. Көнчыгыш Кытай диңгезеннән секундына ике йөз метр тизлек белән тайфун якынлашып килә иде.

***

Йөрәк ярсып тибә. Тән таш булып ката башлаган шикелле тоела. Күңелдә авыр, куркыныч шом. Бу инде тайфун алдыннан кузгалган инфраозын дулкыннарның һаваны чорнап алганын белгертә. Кайвакыт шушы

*Ахыры. Башы 10, 11 нче саннарда.*

дулкыннарның амплитудасы йөрәк тибүе белән тәңгәлләшә, резонанска керә дә канның ярсып агуы тамырларны тишеп тышка бәреп чыгардай була. Шушы очракта корабтагы кешеләр, куркудан нишләргә белмичә, суга сикереп төшеп котылырга телиләр булса кирәк. Кораб – кешесез кала. Диңгезчелек тарихында экипажсыз калган кораблар шактый еш очраган. Шушы хәл «Оча торган голланд» риваятен барлыкка китергән.

Вахтаны өченче штурманнан кабул итеп алуга, рубкага капитан килеп керде:

– Укыдыңмы? – Ул штурман рубкасының өстәлендә яткан радиограммага ымлап күрсәтте.

– Укыдым.

– Йөк шторм вакытында урыныннан кузгалмаслык итеп беркетелгәнме? Бигрәк тә прокат. Ул бит сәгать пружинасы шикелле. Чайкалганда, төргәкнең калае өзелеп китсә, трюм капкачын бәреп ачып ташлаячак.

– Төргәкләрне көчем җиткән кадәр ныклап беркетергә тырыштым инде. Йөк төяүчеләр ашыгып эшли бит. План. Ашыктылар. Гел ызгышып торырга туры килде.

– Әйдә, икәү карап, тикшереп чыгыйк әле.

Алар, кесә фонаре тотып, һәр трюмдагы йөкнең чайкалуга каршы тора алу-алмавын тикшерделәр.

– Портта торганда запас борыслар алып дөрес эшләгәнсең, – диде Анатолий Александрович. – Боцманны, өлкән матросны ал да, беренче һәм бишенче трюмдагы прокатлар арасына чайкалганда чыдарлык итеп терәкләр куеп чыгыгыз әле. Тайфунның исемен генә кара син – «Берта». Яһүд хатыннары үҗәт була. Аңа каршы тору ансат булмаячак.

Боцман белән өлкән матросны чакырыр алдыннан Габдрахман каютасына керде дә кесәсеннән радиограмманы алды.

Кичә кич сәгать унынчы яртыда җибәргән.

«Тренировки не радуют. Решила гимнастикой расстаться навсегда. Очень жду твоего возвращения. Скучаю. Хочется сказать еще одно для обоих очень важное слово. Скажу когда вернёшься. Целую. Оксана».

Һәр сүзнең эчендә сөйләп кенә аңлатып булмаслык тойгылар кайнарлыгы, өметләр, туачак мөнәсәбәтләр, кыскасы, киләчәкнең бәхетлеме, бәхетсезме булуы, эченә колач җитмәслек вакыйгалар тутырылган язмыш ята иде. Кесәгә салган кәгазь кисәге, җанлы нәрсә шикелле, Габдрахманның күңеленә кайнар хисләр, бары тик ярату гына бирә ала торган ниндидер яшәеш рәхәтлеге чәчеп тора иде.

***

Корабны төягәндә, докердардан ярты литр аракыга алган агач борысларның яртысын беренче трюмга, калганнарын бишенчегә алып төштеләр дә калай төргәкләре арасына кагып беркетеп куйдылар.

Трюм эченнән чыкканда, тайфун кузгаткан җил корабка килеп бәрелә башлаган иде инде. Көчле җил зур дулкын куптара. Шунлыктан, аның корабка килеп бәрелүе нык сизелми. Дулкын корабны салмак кына өскә күтәрә дә бераздан чоңгылга төшереп куя.

Әлеге вакытта капитан палубадагы мичкәләрне, спардектагы шлюпкаларны карап тикшереп йөри иде. Ул кабат рубкага, Рахманкулов янына килеп керде:

– Вахтадан соң ял итүчеләрне уятабыз инде, – диде ул. – Трансляциядән кисәтеп куй әле. Каютадагы әйберләрне ныклап беркетсеннәр.

Ярты сәгать үтүгә, тайфун җиле үкереп исә иде инде. Мачталар сынар

хәлгә җитеп сыгылалар. Җил диңгез өстен кубарып ала да корабка томыра. Суның палубадан астарак өлеше зур көч белән корабның кабыргасына килеп бәрелә. Шундый зур көч белән китереп бәргән дулкын корабны сытып, трюм капкачларын кубарып ыргытыр шикелле тоела. Калынлыгы ярты сантиметр булган калайның шушы акылдан шашып бәрелгән су көченә каршы тора алуына, никадәр тырышып карасаң да, ышанасы килми. Курку тоемлауны, тәннең һәр өлешен чорнап алган да, күңел түрендә нindidер сиңа ят, дошман бер көч: «Бу синең соңгы минутларың, кычкырып ела, Ходай Тәгаләдән газапсыз, теге дөньяга җиңелрәк алып китүен сора...» – дип әйтеп, өндәп тора.

Тайфун котырганда, ярга якынлашырга да куркыныч. Кораб Көньяк Кытай диңгезенең 16 градус 37 минут киңлегендә, 114 градус 26 минут меридианында иде. Төньякта Кытайның Хайнань утравы, корабның юлына каршы көнчыгышта Филиппин архипелагына кергән Лусон атавы. Тыныч диңгездә йөзгәндә, кораб тагы бер көннән Гонконгка барып җитәргә тиеш.

«Дөнья хәлен белеп булмый», – дигән картлар. Татар халкының язмышы диңгездәге кораб язмышына охшашлы булганга шулай әйткәннәрдер. Гонконгка кайчан барып җитәсен Аллаһы Тәгалә генә әйтә алыр иде. Бер көн урынына ике атна булуы да бар. Бәлки, ул портны күрергә язмагандыр да...

Җилнең һаман көчәюенә, дулкыннарның аяусызлана баруына карап, Габдрахман шул турыда уйлый иде. Аның авылдашлары нишли икән? Анда һаман шул очы-кырые булмаган мәҗбүри, хак түләмичә генә эшләтә торган колхоз эшедер инде. Одессада исә шәһәр тормышы, диңгез ярына урнашкан порт тормышы. Һәм анда Габдрахманның сөйгәне – кыпчак кызы Ак Санә...

## 2

Давыл басыла төшкәндәй итте. Сыртларын кабартып ургылган аяусыз дулкыннар да әкренләп тау-тау булып йөгерүләреннән туктала башлады. Диңгез исә тынычланасы урынга бөтерелеп кайный, чоңгылланып корабны җилтерәтә. Мондый хәлне Габдрахманның күргәне юк иде әле.

Рубкага капитан килеп керде. Барометрның басымы төшкәнен күргәч, аның пыяласына бармагы белән суккалап карады да Рахманкуловтан сорады:

– Ни булганын аңладыңмы? – диде, дер селкенеп торган палубадан рубканың уң як почмагына үтеп. Кулы белән тәрәзә төбенә беркетелгән тоткага ябышкач өстәде – Тайфун күзенә юлыктык. Диңгездә моннан да куркынычрак нәрсә бармы икән?

Карап торырга җил дә ярсып исми, дулкыннар да гөрселдәп корабны кыйнамый шикелле. Мачталар менә-менә сынып төшәргә җитеп дер селкенә. Корабның дер калтыравы шундый гайрәтле, берничә минуттан вак кисәкләргә ярылып, таралып төшәр шикелле тоела. Тайфун күзенә юлыкканда заклюпкаларның ычкынып, корабның таралып төшүе сирәк очрый торган хәл түгел иде. «Ярый әле теплоходка дүрт кенә ел. Әле ул нык, бу сынауны исән-имин үтәргә язсын, Ходаем», – дип, аңыштырмый Аллаһы Тәгаләгә ялваруы тышка бәреп чыкканын сизде Габдрахман.

– Гонконгка исән барып җитә алсак, чиркәүгә кереп шәм куярга кирәк булыр, – диде Анатолий Александрович, Рахманкуловның фикерен аңлагандай итеп. Аннан өстәп куйды. – Мин әле ул турыда уйламыйм да икән – син бит мөселмандыр?..

– Әйе, мин – мөселман. Дөрес, безне хәзер атеист итмәкчеләр. Сезнең атеизм турында итальяннар белән сөйләшкәнегез булдымы?

– Юк. Италия коммунистларының католик булып калулары турында әйтмәкчеме сез?

– Алар коммунист булуларына карап диннән ваз кичмиләр. Иң кызыгы шунда: «атеизм» сүзен ишетү белән, итальяннар андый кешене бандитка, җинаять эшләүдән курыкмый торган бәндәгә саныйлар. Дин тотмаучыларны алар «ля раджоне» – ирекле фикер йөртүче, дип атыйлар.

– Мин монда чакта корабны урап чык әле. Сак бул. Бортка якын барма. Калтыраганда палуба сине үзеннән-үзе диңгезгә алып томыруы бар. Палубага беркетелгән әйберләрне дә читтәнрәк урап уз. «Тайфун күзе» чиктән тыш мәкерле ул.

Габдрахман башта спардекны, аннан соң төп палубаны һәм аскы палубаны урап чыкты. Иң өстәге пеленгатор палубасына күтәрелергә курыкты.

Өскә менгән саен, корабның калтырануы көчәя бара иде. Пеленгатор палубасына илтә торган трапның беренче басмасына басуга, калтыранудан аягы ычкынып китте дә Габдрахман релингка ябышкан килеш һавада асылынып калды. Рубкага әйләнеп кайткач, капитанга хәлне сөйләп бирде:

– Шлюпкаларны тарттырып тоткан трослар бушый башлаган. Аларны ныгытасы бар. Боцманга үзегез әйтәсезме, әллә мин боерык биримме?

– Үзегез әйтегез. Спардектагы мичкәләр ычкынып китәрлек түгелме?

– Тарттырган бауларын чөйләп дөрес эшләгәнбез, аларның берсе дә урыныннан кузгалмаган.

– Мин каютама төшәм. Куркыныч туа башласа, шундук миңа хәбәр итегез.

Капитан аска төшеп киткәч, Габдрахман сул як күперчеккә чыгарга ишекне ача башлаган иде, нindидер кыргый көч шапылдатып кире япты. Ярый ишекне тоткан кулын тартып алырга өлгерде – авыр имән ишек ябылганда, бармакларын сытып чыгарасы иде...

Сәгать төнге дүрттә вахтага өлкән штурман менде. Штурманнар рубкасына кереп, корабның картадагы урынын тикшерделәр.

– Вахтага килер алдыннан мин корабны урап чыктым, – диде өлкән штурман Дюженко. – Тайфун күзеннән чыга алмасак, озакламый шлюпбалкаларны тотып торган корыч арканнар өзеләчәк, йә булмаса шлюпкалар сытылачак. Ишетәсеңме корабның ничек ыңгырашканын?

– Ә трюмнарга тутырылган прокатның, сүтелә башлап, трюм капкачын бәреп чыгуыннан курыкмыйсыңмы?

– «Тайфун күзе»нең читенә якынлаша башладык шикелле. Моннан дүрт сәгать элек гарасат көчлерәк иде.

– Вахтаңа иминлек телим, – диде Рахманкулов рубкадан чыгып китәр алдыннан һәм, трапның култыксасына бар көче белән ябышып, аска, каютасына төшә башлады.

Каютасын ачып керүгә, рундуктан бәреп чыккан киемнәре, үзе белән йөрткән язу машинкасы, сабын савыты, кырынгыч, тагын әллә нинди әйберләрнең каютаның палубасында тәгәрәшеп йөрүен күргәч, Габдрахманның кәефе кырылды. Каюта шкафы – рундукның бите каерылып чыккан. Тимер палубасына чәнчә бармак юанлыгы болт белән беркетелгән сейф, әрле-бирле селкенеп, каюта идәненең уртасында ята. Тимер болтларны, әйтерсең, үткен пычак белән кисеп ташлаганнар. Рундук астындагы тартмадан бау алып, иң башта сейфны диванга тарттырып беркетеп куйгач, палубада аунап яткан

әйберләрне караватастындагы иркен тартмага тәеп тутырды да, баш очындагы браны яндырып, ятагына менеп ятты һәм кесәсендәге радиограмманы чыгарды:

«Гимнастика белән хушлашам. Синең кайтуыңны зарыгып көтәм».

Яшәүнең тәме, кызыгы булмас иде сине беркем көтмәсә. Дөрес, Габдрахманны әнисе көтә, туганнары. Миллионлаган улларын, кызларын ГУЛАГ лагерьларында череткән илдә әниләр һәрвакыт аларның кайтканын әрнеп, күз яшьләренә тыгылып көтәләр. Күпмиллионлы армия тоткан илдә аларның көтүе дәвам итә. Тик аналарның дәүләт тартып алып олактырган балаларын көтү белән сөйгән кызыңның көтүе арасында аерма бар. Әниеңнең зарыгып көтүе искә төшкән чакларда үкереп елыйсы, балаларны аналарыннан аерган көчне каһәрлисе, шул көчкә каршы көрәшәсе килә. Габдрахман әнисе искә төшкән саен, аны кызгана, аның тәрбиясе, күз яшьләре, сагынулары өчен нәрсәдер эшлисе, ул игелекләрне ниндидер юл белән кайтарып бирәсе килгәнне тоеп интегә иде. Аны хәзер моннан ике генә ай бөтенләй таныш булмаган, хәтта аның дөньяда барлыгын Габдрахман белмичә яшәгән бер кыз зарыгып көтә. «Скучаю...» дигән. Кызның сагынуы ихлас икәнлегенә егетнең бернинди шик-шөбһәсе юк иде. Ул бит кызны үзе дә сагына. Ниндидер әрнүле рәхәтлек, күңелне җылытып торган якты өмет белән очрашу мизгелен көтә. Адәм баласының һәммәсе шикелле, Рахманкулов үзен белә-белгәннән бирле бәхеткә ымсынып яшәде. Оксана белән танышканнан соң, шул «бәхет» дип аталган билгесезлеккә төс керә, аның мәгънәсе барлыкка килә башлады.

«Икебез өчен дә бер бик мөһим сүзне әйтәсем килә. Кайткач әйтермен...» Нинди мөһим сүз икән ул? Оксана ул сүзне нигә радиограммага язмаган? Дөньяны буш сүз басты. Сүз – ялган, сүз – коткы, сүз – богау ул тоталитар дәүләт шартларында. Кешеләр бер-берсенең сүзенә ышанмый башладылар, чөнки хак сүз юкка чыгу дәрәҗәсенә килеп җитте. Оксананың әйтәсе сүзе ниндидер вәгъдә, Габдрахманны бәхетле итәсе зур, изге гамәл булып тоела иде. Биш җөмлә язылган кәгазь кисәге Габдрахманга шундый кадерле. Шул биш җөмлә вахтада торганда үлеп арыганны юкка чыгарды, корабның «тайфун күзе»нә юлыгуы, экипаж әгъзаларының, алар белән Габдрахманның да исән-иминлеге кыл өстендә торуы онытылды. Диңгез чиксезлегендә, тайфун белән көрәшеп, менә-менә батарга торган кораб шушы мизгелдә Габдрахман өчен икенче урында калгандай булды. Кәгазь кисәгенә язган сүзләр соңгы очрашудагы рәхәтлекне, яшәүнең мәгънәсен меңгә тапкырлап, егетне җиденче кат күкләргә күтәрде. Габдрахман тәнендә һәм җанында Оксана уяткан тылсымлы сөю ялкыны кабынуын тойды. Кызның тыгыз, ымсындыргыч күкрәкләре аңа килеп терәлгәннәр. Ул Оксана сулышының үз сулышына килеп кушылганын тоя. Нинди тылсымлы көч икән ул яраткан кызы кочагыннан кергән илаһи тәэсир? Күпме вакыт узды, аларның араларындагы бушлык ике мең ярым мильгә җитеп озынайды, ә шул соңгы кочаклашып үбешү әле һаман исән, һаман кечерәйми, тәэсире һич кимеми иде. Бәлки, чыннан да, ир-егет хатын-кыз заты белән кушылганчы, әле бербөтен түгелдер? Аллаһы Тәгалә тумыштан ир баланы да, кыз баланы да ярты өлештән торган итеп кенә яратадыр? Бергә кушылганнан соң гына бербөтенлек барлыкка килә булса кирәк... Кайберәүләр өйләнәләр, гаилә коралар, балалар үстерәләр, ә үзләре, арада шушы күкләрдән иңгән чын ярату булмаганлыктан, гомер буе яртылаш килеш яши бирәләр...

Кораб әкренләп «тайфун күзе»ннән чыга башлады бугай. Дерелдәү, калтырану күпмедер басыла төште. Әмма чайкалу һаман көчәя, аяусызлана гына бара иде. Радиограмманы мендәр астына салгач, Габдрахман утны

сүндерде. Тән арыган. Күңелдә җыр белән генә аңлатып булырлык рәхәтлек.

Кораб чайкалганда тәгәрәтеп стенага китереп бәрә, берничә мизгелдән, кире якка идәнгә алып ыргытырга тырыша. Рахманкулов диванга күчеп ятты. Башын диванның мендәренә, аякларын стенага терәде. Бу мизгелдәге кичерешләр аңа каяндыр таныш иде. Кайдан, кемнән ишеткәне булды икән аның ул хакта?.. Исенә төште – боларның барысы да халык җырларында булган икән... Сагынулар да, яратылу бәхете дә, һәр очрашуны зарыгып көтеп алу да. Йокыга талыр алдыннан Габдрахманның баш миендә киләчәккә җиңелчә бер өмет чаткысы кабынып китте:

«Оксананы туган телгә өйрәтергә кирәк. Телгә өйрәнгәннән соң – җырларны.

Гаилә тормышының көндәлек шатлыгының иң бөек, бәхетле мизгеле – икәүләшеп «Гөлҗамал» җырын җырлау булырга тиеш. Борынгы украин җырлары белән борынгы татар халык җырлары арасындагы уртаклык Габдрахманга таныш иде. Ике халыкта да кыпчаклар калдырган көчле мирас катламы ята».

Шул турыда уйлап ятканда, Габдрахманның арып алҗыган тәне йокы тылсымына кереп эреде. Астын өскә китерергә, сытып ташларга, тирәнлеккә йотып юкка чыгарырга тырышып, корабны кыйнаган тайфун куркынычыннан Рахманкуловны йокы, беркемнең дә көч-куәте җитми торган онытылу дөньясына алып китеп, тәмам тынычландырды.

**3**

Көндезге вахта алдыннан йокыдан уянганда, чайкалу шактый йомшара төшкән, корабның таралырга җитеп калтырануының эзе дә калмаган иде. «Димәк, без «тайфун күзе»ннән исән-имин чыга алганбыз», – дип сөенеп куйды Габдрахман.

Кают-компаниядә ашап чыгып, рубкага менгәндә, ул радист белән очрашты.

– Сиңа радиограмма бар, – диде Николай Суменко. Һәм, кире борылып, үзенең каютасына алып керде. – Мин аны кичә алган идем. Сине уятасым килмәде.

Рахманкулов спардекка төште дә каютасына керде. Күңелендә «Нишләп Оксана миңа көн саен радиограмма җибәрә башлады әле? Әллә берәр куркыныч нәрсә бармы?..» дигән шом кузгалып куйды. Текстның азагында Дадоновның фамилиясе язылган иде. Димәк, Юра җибәргән.

«Габдрахман, инде белгәнеңчә, Оксана олимпиада вакытында иңбашын авырттырган иде. Күнегүләрдән дә күңеле суынган, ахры. Ул зур өмет белән сине көтә. Аның белән ешрак хәбәрләшеп торсаң иде. Нинадан, Евгениядән, «Чолман» экипажыннан сиңа кайнар сәлам.

Юрий Дадонов».

Радиограммадагы сүзләргә ияреп, авырту Рахманкуловның үзенә дә килеп бәрелгән кебек булды. Ирексездән, ул иңбашын тотып карады. Юк, аның иңбашы авыртмый шикелле иде. Нигә соң алайса нindидер сызлауга охшаш аяусыз тынгысызлык кәгазьдәге сүзләрдән аның тәненә күчеп йөгерде?

Рубкага менгәндә, кораб горизонт читеннән калкып чыккан, үзара ярышып болытларга омтылган биек йортлар укмашкан җиргә таба шуыша иде. Башкалардан алда кереп, төшке ашны ашаганда, лоцман чакырганнар, корабтагы йөкне каршы алучыга хәбәр иткәннәр.

Исәнләшү белән, капитан Бородуля:

– Йөк кәгазьләрен таможенникларга күрсәтергә әзерләп куйдыңмы? – дип сорады.

– Әйе. Алар әзер.

– Каютаңнан штурманнар рубкасына алып мен әле. Карап чыгасым килә.

Аска төшкәндә, Рахманкулов кесәсенә радиограмманы салды. Каютасына кергәч, коносаментларны, каргопланны алганчы, Юрий Дадоновның сүзләрен тагын бер кат укып чыкты. Моңа кадәр хисләрдә һәм хәтердә генә яшәгән кыз аңа якын-үз кешегә әверелгән, әйтерсең лә алар үзләре генә белгән ниндидер җаваплы, вәгъдәдән дә җитдирәк мөнәсәбәт белән үзара тоташканнар иде. Кызның сәламәтләнүе өчен Габдрахман үзен җаваплы итеп сизә иде.

**4**

Моннан өч дистә ел элек Таулыга атлы арбага утырып сәяхәт кылып кайткан Бәкер һәм Фәриха малае бүген, Кытай җиренең бер кисәге булуына карамастан, инглизләр кулындагы иректле Гонконг шәһәрен күрәчәк. Тиздән Рахманкулов кытай телендә Сянгань, европалыларча Гонконг дип аталган шәһәр-дәүләтне үзенең туган Татарстаны белән чагыштырып карый алачак. Дәүләтчелеген югалткан туган җирне, туган халкыңның язмышын зур Кытай дәүләтеннән инглиз колонизаторлары тартып алган җиде юл чатындагы Гонконг белән чагыштыру аңарда нинди фикер уятыр?!

Әнә, корабны каршы алырга лоцман көймәсе килә. Диңгез дулкынының көчен, аның мәкерен үз корабыңа карап чамалавы читен. Басыла башлаган тайфунның тау биеклеге дулкыннары лоцман катерын күкләргә чөеп ыргыта да дулкын арасындагы тирән чокырларга илтеп ташлый.

– Безнең Одессада мондый чайкалу вакытында лоцман корабка якын да килми, – дип сүз башлады капитан.

– Шуңа без анда тышкы рейдта дулкын басылганын көтеп вакыт үткәрәбез дә инде, – диде Рахманкулов аңа. – Ә бу лоцбот, әнә, кечкенә бер бөҗәк сыман, кара, ничек кыю үрмәли.

– Монда инглизләр идарә итә. Алар диңгез белән бик күптәннән уртак тел таба белә торган милләт, – диде капитан.

Лоцбот кораб яныннан узгач, борылып, әкрен генә сулъяк бортка якынлаша башлады.

Рубкага килеп кергәч, лоцман корабтагы приборларга, гирокомпас репитерындагы курска күз сирпеп алды:

– Фул әһед!

– Полный вперёд! – дип кабатлады Бородуля лоцманның боерыгын.

Портны диңгездән аерып торган борынны үтүгә, зур, иркен һәм тыныч порт ачылды. Аркылыга-буйга әллә ничә чакрымга җәелгән портта йөзләгән корабның кайсылары причал көтеп, кайберләре ачык диңгезгә чыгар алдыннан ягулык, су һәм азык-төлек китергәнне көтеп тора иде. Корабларның күплегенә диңгездә тайфун котыруның да сәбәбе бар иде, әлбәттә. Советлар Союзындагыча дәүләтнеке саналган корабта эшләүче диңгезчеләрдән хуҗасына эшләүче диңгезчеләрне саклык һәм акылга таянып эш итү аера иде.

Габдрахман лоцманның инглиз икәнлеген шундук аңлап алды. Ак кыска чалбар, тезенә җитеп торган ап-ак гетр һәм ак кроссовка кигән. Нинди генә көчле җил дә очырып төшерә алмый торган ак чехол кигертелгән матур фуражка һәм кыска җиңле ак күлмәкнең җилкәләрендә капитан дәрәҗәсендәге

диңгезче икәнлекне белгерткән дүрт ука тасмалы погоннар. Джозеф Конрад әсәрләрен укып тәрбияләнгән Рахманкулов инглиз диңгезчеләрендә ихтирамга, үрнәк алырга лаек сыйфатларны күрергә өйрәнгән иде инде. Лоцманның үзен тыныч һәм ышанычлы тотуы рубкадагы урыс диңгезчеләренә дә тәэсир итте, швартовка вакытында Советлар Союзы портларындагы шикелле, кычкырыш, көчәнеп эшләү, тәртипсезлекнең монда эзе дә юк иде.

Якорьда торган кораблар арасындагы тарлыклардан тыныч кына узып, причалга якынлаштылар. Биредә урыс диңгезчеләре шикелле швартов бауларын, «бросательный конец» дип аталган нечкә бау – шкертикка тагып, ярга ыргытмыйлар иде. Туктыйсы урынга юнәлгәч, корабка кечкенә моторлы көймә якынлашты да швартовка эшен башкарырга чыккан матрослар кулыннан корабны ярга беркетә торган юан арканнарны алды, сөйрәп, ярдагы пушкаларга элеп куйды. Лоцманның корабка утыруына ярты сәгать уздымы икән, кораб причалга беркетелгән, таможенниклар, йөк хуҗасы, санитар врач һәм йөк бушатуны оештыручы стивидор кают-компанияда корабның документларын һәм конасаментларны тикшереп утыралар иде инде. Утыз-кырык минуттан алар да, саубуллашып, корабтан төшеп киттеләр. Матрослар трюм капкачларын ачты. Йөк бушатучылар килеп туктады.

– Стивидор[1] йөкне бушатып бетерергә ничә тәүлек кирәк диде?

– Ике тәүлек.

– Сталин чорында бу турыда әйтергә дә куркыр идем. Капиталистлар илендә рабочий классның ике ярым тапкыр тизрәк һәм сыйфатлырак эшләвен син ничек аңлата аласың?

Капитан Рахманкуловның фикер йөртү сәләтен һәм аның үзенә карата ихласлыгын сыный иде.

– Бу турыда КГБга җиткерсәгез дә, визамны яба алмаслар дип уйлыйм. Беренчедән, социалистик ярышның камчысы көчсез икәнлеген, икенчедән, капиталистларның эшчеләр сыйныфына тамагы тук, өсте бөтен булырлык, иркен фатир, әйбәт җиңел машина алырга җитәрлек акча түләүнең социалистик ярыштан көчлерәк икәнлеген аңлата. Сәбәбе шул булса кирәк.

– Рәхмәт миңа ышануыгызга. Куркакларны яратмыйм мин. Сталин-Берия чорындагы дер калтырап яшәү безнең каныбызга сеңгән. Шуннан котыла алмасак, без һаман колбиләүчеләр илендә хакыйкатьтән куркып яшәүне дәвам итәчәкбез, Сез күзәтә торгансыздыр бит? Әнә, капиталистлар гади халыкның сүзенә ничек колак сала белә. Бер якта – акча капчыклары – капиталистлар, икенче якта – гади халык. Һәр як үз мәнфәгатен ачык белгертеп, каршы як белән көрәш алып бара. Чынбарлыкны чагылдырган җәмгыять фикере барлыкка килмәгән очракта демократия дә була алмый. Демократия шартларында дистәләгән миллион бер гөнаһсыз кешеләрне ГУЛАГ лагерьларында үтереп тору мөмкин дә түгел.

Капитанның тугарылып сөйләшүеннән файдаланып:

– Портларда вахтада тәүлекләп торабыздыр бит? Бүген өлкән штурманның вахтасы,– диде Габдрахман.

– Беләм. Йөкне бушату җайга салындымы?

– Әлегә тоткарлыксыз бара.

– Өлкән штурман белән килеш тә ике-өч сәгатькә шәһәргә чыгып керә аласың. Миннән рөхсәт.

[1] Стивидор – чит илләрдә судно йөген төяү һәм бушату эшләре өчен җаваплы кеше.

## 5

Чит илдә совет диңгезчесе ялгызы шәһәргә чыга алмый иде. Һәр командирга помполит ике гади диңгезчене тага. Берсе, һичшиксез – стукач, икенчесе – активист. Башка ил моряклары чит ил портларында бергә укмашкан өч диңгезчене күрү белән, боларның совет иленнән икәнлеген шундук аңлап ала иде.

Помполит Габдрахманга буфетчы хатынны тагарга тырышып карады.

– Йөреп кайтсын инде. Әнә бит, кибетләрне карарга атлыгып тора, – диде, каютасын җыештырып йөрүче хатынга күрсәтеп.

– Мин бит бер генә сәгатькә чыгып керәм. Кибетләр карап йөрергә вакытым юк, – дип баш тартты Рахманкулов.

Помполит аңа үзе белән бер вахтада торган матрос Перебейносны һәм моторист Харченконы такты. Алар өчәүләп шәһәргә юнәлделәр.

Капиталистик илләрнең кибетләре, модадан чыккан кием-салымның арзанлыгы, Совет илендә шәм яндырып эзләсәң дә табып булмый торган әйберләрнең өелеп ятуы – Советлар Союзы дип аталган урыс иле флагы астында йөзүче диңгезчене айлар буе гаиләсен күрмичә, хәерчегә түләгән эш хакы өчен бил бөгәргә шул мәҗбүр итә иде.

Шәһәр аларның өчесенә дә таныш түгел иде. Бу очракта совет иленнән килгән башка кораб диңгезчеләренең тәҗрибәсенә таянып эш итәргә кирәк була. «Сергей Саблин» торган причалга янәшә пирстә Владивосток танкеры тора иде. Танкерга җитәрәк алар причалга төшеп килгән, «уяулык саклау» боерыгы белән бер-берсенә беркетелгән өч диңгезчене күреп алдылар.

Аларны куып җиткәч, сөйләшүне Харченко үз өстенә алды:

– Сез Владивостоктанмы? – диде ул.

– Әйе, – диде өчлекнең җитәкчесе. – Без Владивостоктан.

– Сезнең бу портка килгәнегез бармы?

– Сирәк булса да кергәләп йөрибез, – диде төркемнең җитәкчесе.

– Совет диңгезчеләре монда нәрсә сатып ала?

– Монда нәрсә алсаң да арзан, пошлинасыз яши торган портофранко шәһәре бит бу, – диде Ерак Көнчыгыш пароходчылыгы диңгезчесе.

– Комиссионкага тапшыру өчен кирәкле әйбер турында сүз бара. Совет диңгезчеләрен тәэмин итә торган кибет моннан еракмы?

– Без нәкъ шул кибет каршысында торабыз, – диде төркем җитәкчесе.

Әйбер сатып алып, аны, Одессага кайткач, комиссионкаларга тапшырырга, әйбер кыйммәт торган җирләргә җибәреп акча ясарга Харченко оста егет иде. Кибетне табу белән генә канәгатьләнмичә, сорауларын дәвам итте:

– «Мәктәпкә озату» өчен монда нәрсә алалар? Нәрсәләр арзан тора? Аңлатып бирегез әле шуны.

«Мәктәпкә озату» сүзенең барлыкка килү тарихы кызыклы иде.

Бер одессалы Италиядән бозавын имезеп торган болан сурәтле синтетик гобелен сатып алып кайткан да комиссион кибеткә тапшырган. Йөзүгә кабат чыкканда, хатынына әйтеп калдырган: «Әгәр товар сатылса, син миңа: «Балалар мәктәпкә киттеләр», – дип радиограмма җибәр. Сатылмаса: «Балалар мәктәпкә йөрмиләр, авырып яталар», – дип яз. Гобелен тиз сатылган булса кирәк. Берничә көннән диңгезче: «Балалар мәктәпкә киттеләр», дигән радиограмма алган. Радиограммага язылган сүзләргә әһәмият биреп тормаслар иде, радист стукач булган, күрәсең. Ул диңгезчедән сораган: «Кышкы каникул

вакыты бит. Нишләп синең балаларың мәктәпкә йөри?» Диңгезче, билгеле, аңлатырга мәҗбүр булган. Бу вакыйга тиз арада диңгезчеләр арасында таралып өлгерә. Шуннан соң сатар өчен алган әйберне «мәктәпкә озату өчен» дип алу гадәткә кереп китә.

– Нәрсә арзан? – диде Владивосток диңгезчесе. – Сез одессалымы?

– Әйе, без Кара диңгез пароходчылыгыннан, – диде Харченко.

– Сез бит сату итү өлкәсендә чемпионнар. Өйрәтеп торуның кирәге дә юктыр. Шул ук стенага элә торган келәмнәр, нейлон кофталар. Соңгы вакытта диңгезчеләр «болонья» плащ белән бизнес ясый башлады.

Шушы сүзләрне ишетүгә Харченко кибеткә чапты. Рәхмәт әйтергә дә онытты. Рәхмәт сүзен Рахманкуловка әйтергә туры килде.

Кибет эчендә, чыннан да, синтетик гобеленнар, нейлон кофталар, болонья плащлар һәм джинсы чалбарлар өелеп ята иде. Өч совет диңгезчесе, шул ук Ерак Көнчыгыш пароходчылыгы вәкилләре булса кирәк, прилавка каршында сатулашып торалар иде. Кибет хуҗасы, җәлпәк битле кытай, елмаеп каршы алды:

– Братишки! – диде ул урысча. – Давай-давай: кавёры, плащ-болонья, джинси, нейлоновые ковты. Всё дёшево. Забирай. – Урысча белгәне шуның белән тәмамланды, күрәсең, үзенең урысны яратканын исбатлар өчен, кибет хуҗасы урыс сүгенүенең иң кабахәт, иң популяр сүзләре белән сүгенеп алды.

Харченко шундук, кибет хуҗасы белән сатулаша-сатулаша, болан сурәте, тарантелла биюе һәм диңгезчеләр телендә «мадам карапчи», рәсем сәнгатендә «Похищение из сераля» дип аталган, ат менгән төрекнең кыз урлавын сурәтләгән өч келәм сайлап алды. Таможенниклар өчтән артыкны рөхсәт итмиләр иде.

Перебейнос та ике келәм, калган акчасына бер дистә нейлон косынка һәм чәйни торган резинка «сникерс» сатып алды. Тәҗрибәле диңгезчеләр өйрәткәннәр булса кирәк. Үзеңнең чит илләрдә йөреп кайтуыңны исбатлар өчен, Совет илендә, танышларыңа шул америка сагызын, авторучка һәм башка чүп-чар бүләк итү гадәте кергән иде.

Рахманкулов күптән инде ясалма күннән тегелгән куртка алырга хыялланып йөри иде. Европа портларында куртка алырга аның валютасы җитми иде. Монда исә джинсы чалбар да, куртка да чиктән тыш арзан иде. Ул валютасына куртка, чалбар һәм ике келәм сатып алды. Кибет хуҗасы алган әйберләрне целлофан пакетка тутырып, скотч белән ябыштырып куя барды.

– Сез кайсы пароходчылыктан? – дип сорады кибет хуҗасы инглизчә. – Бүген генә килдегезме, әллә күптән монда торасызмы?

– Бүген генә килдек. Одессадан без, Кара диңгездән.

– Дусларыгызга әйтегез. Гонконгтагы иң арзанлы кибет минеке. Мин махсус совет диңгезчеләренең күңелен күрү өчен эшлим. Сыра эчәсезме?..

***

Кытайның ярлы ил икәнлеге Габдрахманга мәгълүм иде. Ул университетта кытай студентлары белән бер тулай торакта яшәде. Алар, чыннан да, ярлы, һәр тиеннәрен санап, акчаларын бары тик ашауга, трамвайга гына тотып, бик тә кысынкы яшиләр иде. Хәтта җәйге каникул вакытында туган илләренә дә ике елга бер генә мәртәбә кайтып киләләр иде. Һәр көнне иртән физзарядка ясыйлар. Ашны үзләре пешереп ашыйлар. Хәтта студент ашханәсендәге арзанлык та аларга кыйммәт тоела иде. Һәр кичне диярлек җыелыш. Гел

«бишле»гә укыйлар. «Дүртле» алган студентны комсомол җыелышында үтереп тәнкыйтьлиләр иде. «Мао кушты». Артык тырышып укудан кайбер кытай студентлары дистрофиягә юлыгып, хастаханәгә эләксәләр, һәр көннең әзерләнәсе материалын аларга илтеп торалар иде. «Мао кушты» – бу кытайлар өчен закон гына түгел, яшәү кагыйдәсе генә дә түгел, әйтерсең, шул «Бөек җитәкче» кушканның бер генә катрә өлешен үтәмисең икән, сулыш алудан туктаган бәндә хәлендә шундук үләсең, юкка чыгасың иде.

Гонконгтан соң «Сергей Саблин» теплоходы Кытай порты Ксинангка барып, Европа портларына кайтару өчен йөк төяргә тиеш иде. Кытайның үзе белән, шул илдән тартып алып колония ясаган Гонконг белән чагыштырып карау мөмкинлеге булачак иде. Габдрахман инглизләрнең бер-бер артлы колонияләреннән баш тартып, аларга ирек бирүне күзәтеп йөрде. Франциянең колониясе саналган Алжирдан хәрби җитәкче генерал де Голль егерме миллион французны, пароходларга төяп, туган илләренә кайтаруның шаһиты булды. Алжирдагы француз армиясе, ирек өчен көрәшүче гарәпләр белән чагыштырганда, чиктән тыш көчле, һәр очракта алжирлыларны буйсындырып торырлык иде. Де Голль – генерал, ә генерал исә сугыш чукмары булырга тиеш. Нишләп соң ул шундый ымсындыргыч колониясенә үзе теләп ирек, азатлык биреп, корал ярдәмендә буйсындырудан баш тартты?

Кибет витриналарындагы затлы товарлар, энҗе-мәрҗән, алтын-көмеш, асыл ташлар, кием-салымның затлылыгы, күплеге шуларны гомерендә беренче тапкыр күргән матрос Перебейносны телсез калдырды. Витриналарның сихере аны туктата, аякларын җиргә, күзләрен пыяла артындагы могҗизаларга беркетеп куя иде. Шул ук вакытта егет капиталистик илләрнең мәкерле, һәр адымда синең социалистик уяулыгыңны җуеп төшерергә торган куркынычы турында һәм әлеге әшәке коткыга баш бирмәм, дип кәгазьгә язып имзасын куйган ант турында онытмаска тырыша иде. Көлке дә, кызганыч та иде матросның хәле. Харченко, инде дистә елга якын чит илләрне күреп йөргән моторист буларак, үзен ничек тотарга кирәклекне – җае чыкканда, капиталистик илләрдәге кимчелекләрне генә телгә алырга, шушы юл белән үзенең КГБ ачкан визасын сакларга кирәклекне – яхшы үзләштергән иде.

Алар бераз адашып, портка кайтырга юл эзләп йөргәннән соң, сатып алган әйберләрен калдырган кибет янына килеп чыктылар. Эчкә кергәч, кибет хуҗасы сорады:

– Шәһәр ошадымы?

– Ошадымы сиңа, Петро? – диде Рахманкулов.

Егет югалып калды. Ошады, дисәң – капиталистлар илендәге шәһәр. Ошамады, дисәң – ялган.

– Болай, начар түгел шикелле, – диде ул һәм кадрлар бүлегендә калдырган ант кәгазен аклар өчен өстәде. – Әмма шунысы начар: хезмәт ияләрен эксплуатациялиләр...

Габдрахман тәрҗемә итте.

– Кайда күреп өлгердегез хезмәт ияләрен эксплуатацияләүне? Совет диңгезчеләренә күпме түләгәннәре миңа мәгълүм. Сезнең айлык эш хакын портта эшләүче докерлар ике-өч көн эчендә ала.

– Нәрсә әйтә ул? – дип сорады Харченко. Тәҗрибәсе зур диңгезче буларак, сүзнең нәрсә турында барганын чамалый иде ул. Рахманкуловның аны кибетләргә кереп йөрүдән мәхрүм иткәне өчен үч алырлык фикер юкмы икән аларның сөйләшүендә дип кызыксына иде.

– Хуҗа безнең экипажны кибетенә чакыра, – диде Габдрахман. – Ул товарларын махсус совет диңгезчеләре өчен тотам, диде.

– Корабыгызга кайткач, диңгезчеләргә әйтегез, – диде хуҗа һәм кибетенең адресы, аның нинди товарлар белән сәүдә итүе язылган рекламаны учлап егетләргә сузды.

Ике тәүлектән йөкне бушатып бетерделәр. Әшли белә иде Гонконгның докерлары. Стивидор йөк бушатуны оештыруда даһи иде. Һәм техниканың да иң соңгы сүзе – һәр операция автоматикага, электроникага көйләнгән. Бу – Кытай җиренә урнашкан инглизләр төзегән порт.

**6**

Ксинанг порты Сары диңгезгә урнашкан, әле тулысынча төзелеп тә бетмәгән яңа порт. Анда моннан бер генә гасыр элек диңгез суының дулкыннары уйнап йөргәндер. Хуанхе елгасы диңгезгә туктаусыз ләм ташып тора. Диңгезгә койган җирендә елга саега, әкренләп елга тамагында яңа тармаклар, ясалма сазлыклы утраулар барлыкка килә. Утраулар диңгез чигенгән чакта гына су өстенә калкып чыгалар, диңгез күтәрелгәндә, алар су астында калып күренмиләр. Кичә монда килеп җитеп, якорь салган чакта Габдрахман бинокльдән күзәтте. Кытайлар шул елга агызып китергән ләм өстенә земснаряд белән төптәге ләмне суырып өяләр дә, шуның өстенә баржаларга төяп, ком китереп аударалар. Диңгез өстеннән күтәрелеп чыккан ясалма утрауларга пароходларга төяп Аргентинадан кайтарылган, акчага сатып алган кара туфракны җәяләр. Кара туфрак җәелгәннән соң, җирне, ызан ясап, вак кисәкләргә бүлгәлиләр дә җирсез игенчеләргә әҗәткә саталар. Кытай лоцманы мактанып сөйләде: егерме биш ел эчендә хакын түләп бетерергә вәгъдә биреп алган җирнең хакын тырыш кытайлар алты-җиде елда түләп бетерә икән. Шул сүзләрне ишеткәч, капитан Бородуляның патриотик тойгылары тышка бәреп чыкты:

– Ә без Советлар Союзында миллионлаган гектар яшел тугайлардагы чабып бетерә алмаслык болыннарны, уңдырышлы яланнарны тигезлектә агып яткан елгаларның суы астында калдырып, гидроэлектростанцияләр төзибез...

***

Габдрахман, киенеп, авралга чыкты. Швартовка вакытында ул корабның койрыгында матрослар белән җитәкчелек итә, теплоходның ярга йомшак килеп терәлүе аның җаваплылыгында иде.

«Сергей Саблин», дулкынваткычның очына утыртылган маяк яныннан узып, порт эченә кереп килә. Портта инде күптән металлоломга тапшырасы иске баржалардан, ике карсак буксирдан тыш бер генә кораб та юк. Кытайларның чит илләр белән сәүдәсе оештырылмаган микәнни? Тукта әле, монда бит йөк бушата торган краннар да күренми. Яңа төзелгән причал янында гына земснаряд су төбеннән ләм суырып, киләчәктә пирс буласы урынга бушата. Димәк, портны төзи генә башлаганнар.

Әнә, причалда швартов бауларын корабтан алып, ярга каккан пушкаларга беркетергә әзер торган швартовщиклар. Йа Хода, өсләрендәге киемнәре... Аларның ябыклыгы... Юан, авыр арканнарны сөйрәргә көчләре җитәрме икән мескеннәрнең? Әллә швартов баулары үзләрен диңгезгә сөйрәп төшерерме?

Өлкән матрос Кириенко йомгак итеп уралган нечкә бау – шкертикны ярга ыргытты. Очып барган җиреннән авыр йомгак сүтелә, һаман оча. Ниһаять, йомгак ярда көтеп торган ябык бәндәләрнең янына барып төште. Эләктереп

алдылар һәм берьюлы өч кеше суга төшерелгән юан арканны сөйрәргә тотынды. Тешләре, тырнаклары белән ябышып сөйриләр мескеннәр. Юк, болар көчләре җитмичә җиргә егылсалар да, сөйрәүләрен дәвам итәчәкләр.

Ниһаять, «Сергей Саблин»ны причалга беркетеп бәйләп куйдылар. Корабка комиссия – таможенниклар, чик саклаучылар, тагын әллә кемнәр – өсләренә гади яшел тукымадан тегелгән френч кигән бәндәләр кереп тулды. Тикшерү, тентү башланды. Йөзләрендә елмаю. Үзләре ашыгалар. Гадәттә, нинди генә портка кермә, кайсы гына илдә булма, урысча «формальность» дип аталган документларны тикшерү, йөк төяү хакында сөйләшү инглиз телендә бара. Комиссияне җитәкләгән таможенник, чик саклаучы һәм йөк төяүне оештыручы стивидор – өчесе дә саф урыс телендә сөйләшәләр иде. Менә бит кытайларның Советлар Союзында белем алулары нәтиҗәсе?!

Йөк төяү белән җитәкчелек итәргә тиешле стивидор йөкне өч тәүлек эчендә төяп бетерәбез дип вәгъдә итте. Комиссия эшен бетереп чыгып киткәч, Рахманкулов капитан янына керде.

– Өч тәүлек эчендә йөкне төяп бетерәбез дигәнгә сез ышандыгызмы? – дип сорады ул капитаннан.

– Әкият сөйли стивидор. Ничек инде техника кулланмыйча унҗиде мең тонна йөкне төяп бетереп булсын. Стивидор мин мореходкада укыган елларны Одессаның порт инженерлары әзерли торган институтында Михаил Жванецкий белән бер курста укыган. Шунда шыттырырга өйрәнгән, күрәсең... Син инде күз-колак булып тор. Бу Европа иле түгел. Урлашу да бездәгедән ким түгелдер. Тальманнарны тәҗрибәле матрослардан сайладыңмы? Монда бит биш трюмга да берьюлы төйибез, диделәр.

– Матрослар җитмәде. Мин докторны да, икенче радистны да тальман итеп билгеләдем. Баш тартмакчы булганнар иде. Капитанның боерыгы, дип, сезнең исемегезне файдаландым.

– Дөрес эшләгәнсең, – диде Бородуля. – Вак-төяк җаваплылыкны өстенә алырга курыккан штурманнарны яратмыйм мин.

***

Рахманкулов причалга күз салды. Терсәкләре тишек күлмәктән, шәрә тезләре ертык чалбардан чыгып торган бәләкәй буйлы, ябык докерлар, унар кешедән торган төркемгә тупланган сафларга тезелеп, корабка якынлашып килә иде. Алдагы төркем башындагыларның кулында күчмә кызыл байрак. Гадәттә, һәр трюмга өч-дүрт докер туры килә. Болар исә бер дистә, һәммәсенең йөзендә бу милләт вәкилләрендә генә очрый торган тәвәккәллек һәм Чкалов заманында чыккан: «Мы рождены, чтобы сказку сделать былью...» омтылышы сурәтләнгән. Шуларны күргәч, Габдрахманның исенә үзе белән бергә Мәскәү университетында ярым ач, ярым ялангач яшәп, гел «бишле»гә генә укыган кытай студентлары, Караяр картларының капка төбендә ләчтит сатып утырганда: «Кытай басар дөньяны», дип еш кына искә алулары килеп төште.

Һәр трюм янына капчык төягән машина килеп туктый башлады. Күз ачып йомганчы, капчыкларны парашют дип аталган баудан үргән җайланмага тутырып, машина өстенә килеп туктаган, кран урынына кулланылган укның ыргагына эләләр дә, икенче мизгелдә ул капчык төялгән парашютны күтәреп трюм капкачы өстенә илтеп куя. Капчыкны ике докер түбеннән күтәреп тота, өченче йөкче капчык авызын теккән юан җепне үткен пычак белән аркылыга кисеп ташлый. Капчык эчендәге мамык төбе – шрот трюм эченә коела. Трюм

эченнән күтәрелгән куе сасы тузан корабны чорнап алды. Докерлар исә тузанның иң куе җирендә эшләсәләр дә түзәләр иде.

Ике тәүлектән соң кытай докерларының йөкне өч тәүлек эчендә төяп бетерәчәкләре тулысынча ачыкланды. «Нинди халык бу?» – дип хәйран калды Габдрахман. Ул колхоз эшендә кемнең эшчән, кемнең ялкау икәнлеген аңлап булмаганны белә иде. Бик тырыш, эшчән кешенең дә колхоз эшендә көн үткәрү өчен генә кыймылдап йөрүе мөмкин иде. Совет илендә кешенең тырышлыгын, эшчәнлеген аңлар өчен, аның үз эшен башкаруын күрергә кирәк иде. Ә менә кытайлар... Нинди халык соң бу? Габдрахман белән Мәскәү университетында укыган кытайлар һәр иртәне, урыслар йоклаган арада, торып физзарядка ясыйлар һәм иртәнге ашны пешереп ашарга да өлгерәләр иде. Һәр Кытай студенты гел «бишле»гә генә укый иде. Сәләтле булганнан түгел, Мао кушты, дип, «бишле»гә укый иде азиатлар. Менә хәзер Габдрахман кытайларның докерларын күрде. Аларга эш хакын чиктән тыш аз түләгәннәре көн кебек ачык иде югыйсә.

***

Кытай докерлары йөкне төгәл ике тәүлек ярым төяделәр. Үз күзе белән күрмәгән кешегә бу ябык, алама киенгән, йончуның чигенә җиткән бәндәләрнең шундый эш башкаруларын сөйләп аңлатырлык түгел иде. Корабка йөк төяүнең нәрсә икәнлеген белгән кеше: «ялганла, әмма чамаңны онытма», дип сөйләүдән туктатыр иде.

Габдрахман стивидордан сорамый булдыра алмады:

– Миңа бер нәрсә аңлашылып җитми, – диде ул.– Сез менә, социализм төзибез, дип көчәнәсез. Шәһәрдә без аяк атлаган саен бизнеска, алыпсатарларга, төрле зурлыктагы капиталистларга юлыгып йөрдек. Озакламый баеган кытайларның тәхеттә утыручы коммунистларны бәреп төшерүеннән курыкмыйсызмыни?

– Коммунистлар үзләре бизнес белән шөгыльләнегез, баегыз, Кытай бай булырга тиеш, дип пропаганда алып бара.

– Байлар белән хезмәт ияләре арасында гауга чыгып, революция барлыкка килүдән курыкмыйсызмы?

– Кытай кешесе беркайчан да кытай кешесенә каршы сугыш игълан итмәячәк. Әнә, Тайвань атавында гоминьданчылар капитализмда яши. Сугыш ачсак, без аларны күптән инде җиңгән булыр идек. Утрауда кытайлар бай яши. Әгәр без дә шундый байлыкка ирешә алсак, бернинди сугышсыз, кушылып, бер дәүләт булып яши алачакбыз, дип аңлата безнең галимнәр. Сез, урыслар, Тайваньны Кытай Халык Республикасына кушу өчен, бер минут та икеләнеп тормыйча, сугыш ачар идегез... Чынбарлыкта кытай үз милләте өчен җанын бирергә риза булып яши.

– Кытайда яһүдләр бармы?

– Бездә юк алар.

– Нишләп юк?

– Белмим. Кытай кешесе башын иеп, нәрсә кушсалар, шуны башкарып йөргән булып кыланса да, өстә аның белән идарә итеп утыручы башка милләт вәкилен өнәми. Әнә бит, татарлар Кытайны яулап алганнан соң, император итеп үз милләте вәкилләрен утыртканнар. Гасырлар үтү белән, татарлар кытайга әверелгән.

«Рәсәйдә революцияне яһүдләр ясаган. Әгәр социализмнан капитализмга кире кайту өчен революция булса, аны да яһүдләр оештырачак һәм, урыслар

исеменнән алар идарә итәчәк. Байлык та алар кулына кереп эләгәчәк. Ә мин фәкыйрь, Ксинанг шәһәрендә яшәүчеләрне күрү белән, Андерсенның «Сандугач» исемле әкиятендәге беренче җөмләсен исемә төшердем: «Кытайда кытайлар яши. Аларның императорлары да – кытай кешесе». Менә сиңа әкият...»

Җирле вакыт белән сәгать бердә йөкне төяп бетерделәр. Биш трюмда эшләгән биш бригада арасында социалистик ярыш барган икән. Күчмә кызыл байракны икенче трюмда эшләүче бригада күтәреп килгән иде. Йөк төялеп бетүгә, докерлар причалга тантаналы җыелыш үткәрергә төште. Портның җитәкчесе, партия оешмасы секретаре һәм профком рәисе шул җыелышта чыгыш ясап, күчмә кызыл байракны өченче трюмда эшләгән бригадага тантаналы итеп тапшырып китте. Кызыл байракны яулап алуга кытайлар сабый балалар ихласлыгы белән шатланалар иде. Советлар иленең шаулы утызынчы еллары рухы монда күчкән диярсең.

**7**

Габдрахман Бәкер улы Рахманкулов өч ай ярым гомерен кораб артыннан сузылып калган кильватер агымына агызып җибәргәннән соң, Одессага әйләнеп кайтты. Кайда хәзер Гонконг? Кытай порты Ксинанг кайда? Ә Роттердам, Плимут, Гавр, ниһаять, күпме еллар, яныннан узганда, Бәкер малаен ымсындырып, үзенә якын җибәрмичә торган һәм Одессага әйләнеп кайтыр алдыннан гына керелгән Тахо елгасы тамагына урнашкан Португалия порты Лиссабон кайда? Соңгы рейста узган өч ай ярым вакытның да Рахманкулов кая китеп югалганын аңлый алмый иде. Шул өч ай ярымның һәр көнен, сәгатен, минутын ул күңеленнән кичереп, үзенең картаюга җитәкләп алып барган гомере аша уздырып җибәрде. Кайда ул хәзер айлар, атналар, көннәр, мизгелләр? Менә бит ул яшәү дигән нәрсә... Аны аңлап та, аңлатып та булмый.

«Сергей Саблин» теплоходы ике көннән тагын юлга чыгачак. Габдрахманны корабның штаттагы икенче штурманы алыштырды. Ул хәзер үз корабы – «Чолман»ны көтә. «Чолман» бер ай, ай ярымнан Одессага кайтып җитәчәк. Пароход юлда йөргән арада Габдрахманга чираттагы ялын бирделәр. Ялга китәр алдыннан ул, Чистые Криницы авылына шалтыратып, үзенең Ак Санәсе белән сөйләшеп алды. Оксана берничә атнадан Одессага килергә тиеш иде.

– Кайттым менә. Бер айга ял бирделәр. Син генә юк Одессада. Синсез монда бушлык. Бер кызыгы да юк ялгыз селкенеп йөрүнең... – диде Габдрахман, уфтанып.

## Тугызынчы бүлек

**1**

Ялгызлыктан шактый йончып, олы, тирән мәхәббәткә сусап кайткан Габдрахманны Одесса һич көтелмәгән сюрпризы – моннан соң аның киләчәк яшәешенә үзгә бер юнәлеш биреп, гомер агышын бөтенләй икенче эздән борып җибәрердәй олы вакыйга-бүләге белән каршылады. Почта бүлегенә кереп, ул үз исеменә аталган бандероль һәм бер хат алып чыкты. Бандерольне энесе Варис җибәргән, хат «Совет әдәбияты» журналыннан иде. Габдрахман тыкрыктан диңгез ягына чыгып, скверлагы буш эскәмиягә барып утырды һәм зур кызыксыну белән, ашыга-ашыга, бандерольне ачты. Кәгазь төргәк эченнән «Совет әдәбияты» журналының өч ай элек басылган дүртенче саны килеп

чыкты. Аның беренче битенә, эре хәрефләр белән, энесе Варис: «Уңышың белән ихлас котлыйм!» дип язып куйган иде. Габдрахман зур кызыксыну катыш, журналның эчтәлегенә күз ташлады – басма хәрефләр белән аның исем-фамилиясе, ярты ел элек Казанга җибәргән хикәясенең исеме һәм кайсы биттә басылганы күрсәтелгән иде. Ул, бөтен дөньясын онытып, йотлыгып, үзенең беренче кат татар телендә язган яңа хикәясен укырга ябышты. Хикәянең бер генә сүзе дә төзәтелмәгән булса да, әсәр инде хәзер аныкы да, аныкы түгел дә кебек иде. Габдрахман үзен бер үк вакытта язучы итеп тә, укучы итеп тә тоеп, реаль җирлектән аерылып, иҗади очыш югарылыгына күтәрелгәндәй хис итте. Бу аның өчен әлегә кадәр кичерергә туры килмәгән, бөтен тәнгә, җанга ләззәт иңдергән, ниндидер канатлы очыш биргән кадерле, шул ук вакытта сират күперен кичкәндәй, үз-үзеңне вөжданың алдында кырыс сынау җаваплылыгы тойгандай илаһи бер мизгел иде.

Хикәя Италиядә үзенә очраган бер татар карчыгының фаҗигале язмышына нигезләнеп язылды. Габдрахман монда аның сагыну-җирсү белән тулышкан хис-кичерешләрен, җан сызлануын, эчке рухи моңын башка бер генә тел ярдәмендә дә тиешле нечкәлектә, табигый буяу төсмерләрендә тасвирлап биреп булмаслыгын тоеп алган иде... Һәм, ничек кенә кыенга туры килмәсен, үзенең гадәти хат язудан узмаган, инде анысы да шактый гына тутыга төшкән язма телен, язу тәҗрибәсезлеген, алда торган бөтен иҗади авырлыкларны җиңеп чыгып, әлеге кабатланмас милли фаҗига тирәнлеген бары тик балачакта, яшүсмер чакта күңеленә тирән кереп сеңгән туган теле аша җанландырырга ныклы карар кылды. Бүген инде ул үзенең ялгышмавын, моның бердәнбер дөрес юл икәнлеген күрде, шуңа эчке иманы белән тагын бер кат инанды. Димәк, Габдрахманның язучы буларак тормыш дөреслеген эзләүдәге юлы киләчәктә бары тик туган телендә түшәлгән булырга тиеш. Бу – аның теләгеннән туган ният түгел, ә бәлки чынбарлыкны тоемлавының табигыйлеге, тирәнлеге һәм нечкәлеге куйган олы таләпләрнең иң беренчесе. Аның өчен бу аксиомага тиң олы ачыш иде.

Габдрахман, азрак уйланып торганнан соң, «Совет әдәбияты» редакциясеннән килгән хатны ачты. Анда бүлек мөдире Әхәт Сафин берничә юллык язмасында шулай ук аны иҗат уңышы белән котлаган һәм хикәянең укучылар арасында киң резонанс уятуын әйтеп, шуларның икесен – аксакал әдибебез Фатих Хөснинең һәм Финляндиядән килгән бер укучы ханымның авторга юллаган хатларын, тәнкыйтьче Рушан Гаделевнең исә басарга рөхсәт ителмичә редакция портфелендә торып калган анализ-бәясен дә, автор үзе ишетсен дип, җибәрергә кирәк табуын әйткән иде.

Фатих Хөснинең хаты берничә җөмләдән генә тора иде:

«Габдрахман энекәш! Хикәягезне бик яратып укып чыктым. Тормыш-яшәешебез каршылыкларына тирән үтеп керүегезгә, тел байлыгыбызны гаҗәп нечкә тоемлавыгызга хәйран калдым. Героиня сөйләмендәге ул сүзләрне кайдан табып бетердең, шайтан малай!

Сезгә, һичшиксез, язарга кирәк! Иҗат уңышлары теләп, Фатих Хөсни».

Татар прозасының танылган сүз остасы Фатих Хөснидән Габдрахманның иң курыккан, иң йомшак дип йөргән урыны – әдәби теле турында шундый сүзләр ишетү – бу инде аның өчен иң зур бәяләрдән дә кыйммәтлерәк иде. Иң әһәмиятлесе шунда: әлеге сүзләр аңа алга таба милли әдәбиятта курыкмыйча кулына каләм алу дәртен ныгыта иде.

Журнал редакциясе Финляндия татарларыннан килгән хат турында да телгә

алып, анда: «Олы рәхмәтебезне Рахманкуловның үзенә җиткерегез әле, без аның бу хикәясен, «кулга эләгү белән, елый-елый укыдык», – дип язылуын хәбәр иткәннәр иде.

Габдрахман, ниһаять, Рушан Гаделевнең «Әдәбиятыбызга яңа талантлар» дип исемләнгән, әмма журналда басылырга рөхсәт ителмәгән тәнкыйть мәкаләсен укырга кереште.

«Рахманкуловның тәүге хикәясе киң катлам укучылык җәмгыятендә вә әдәбият белгечләре арасында ихлас кызыксыну уятуы очраклы хәл түгел, – дип язылган иде анда. – «Безнең өй»гә кадәр татар әдәбияты Ә.Еникинең «Әйтелмәгән васыять»ен, Н.Фәттахның «Ител суы ака торур», М.Мәһдиевнең «Без – кырык беренче ел балалары»н искә алмаганда, күбрәк социалистик ярышка, совет хөкүмәтенең татарларга бәхетле, мул, рәхәт тормыш бирүенә мәдхия җырлау белән мәшгуль иде. «Безнең өй»нең беренче җөмләсеннән үк укучы татарларның төрле якка сибелеп-чәчелеп бетүләре, диаспораның чит илләргә, Италиянең Генуя каласына, хәтта Америка континентына кадәр барып җитүе турында мәгълүматка юлыга. Барыгызга да билгеле: «йомшак геноцид» турында да, чукындырулар вакытында да татарларның туган туфракларын ташлап, качып китү бәрабәренә генә исән кала алулары турында сөйләргә ярамый иде. Хикәя авторы, татар әдәбиятында беренче буларак, әлеге проблеманы күтәреп чыга, һәм бу турыда ачыктан-ачык сөйләү мөмкинлеге булмаганлыктан, ул әдәби киная (подтекст) ысулын куллана. Татар карчыгы Италиянең Генуя каласына кызы янына килгән. Икенче кызы Америкада яши. Әгәр соңгы вакытта чит илләрдә яшәүче татарлар турында горурланып, хәтта ниндидер көнчелек белән язу ысулы кулланылса, укучыга бу хикәя андый тәэсир ясый алмаган булыр иде. Карчык исә, үзенең туган туфрагы – татар иле турында кан йотып җирси, сагына, өянке ышыгында утырган йортын күрү хыялы белән яши. Карчыкның газаплары татар кешесе өчен очраклы тойгы түгел. Халык җырлары, татар фольклоры тулысынча диярлек «үсеп җиткәч, чит илләрдә үтә безнең язмышлар...» сыктавына багышланган. Зәвыклы укучыга карчык гаиләсенең туган туфрагыннан куылуы, йорт-җиренең тартып алынуы турында аңлатып торасы юк. Хикәядәге сюжетның төп максаты – татарлар Рәсәй империясенең иң каһәрле төбәкләре саналган мәгъдән, ташкүмер рудникларында, армия хезмәтендәге дедовщина мәсхәрәсендә чиләнү белән генә чикләнмиләр, аларның «бәхет эзләү» дип аталган борын төртер җир эзләп йөрүләре хәтта чит илләргә тикле җәелгән. Хикәя авторы конкрет илдә, конкрет шәһәрдә газапланып яшәүче карчыкны, аның кызын, оныгын әдәбият алымнары белән сурәтләп күрсәтә. Мескен карчыкның: «Өебез исән булмаса да, өянкеләребез калгандыр әле...» – дип хафалануы да аның большевиклар алып килгән зур, глобаль фаҗигане абайлавы турында сөйли. Кешеләрне торакларыннан куып, мал-мөлкәтләрен тартып алу белән генә чикләнмичә, «коммунизм җәннәте» дип күз буяп илне тоташтан ГУЛАГ лагерьлары белән каплап ташлаучылар табигатьне дә таптап, пычратып, болыннарны, кыр-яланнарны, елга буена урнашкан авылларны су астында калдырып бетерүләрен карчык эчкерсез шәхесләргә хас сизгерлек белән сиземли. Хикәянең финалы, карчыкның яшерен рәвештә трюмга кереп посуы, юлда үлүе, өстән генә караганда, чама белмәү, арттыру булып күренергә мөмкин. Рахманкулов хикәяне көчле доминант җөмлә белән тәмамлый: «Карчыкны Феодосия портында үз туган җиребезгә җирләдек». Кырымның җирле халкы – кырым татарын туган туфракларыннан сөргә

каршы, татарларның империя тарафыннан туракланып бүленгән психологик стереотипларына каршы юнәлтелгән аңлатма бу. Урыслар бит беркайчан да үзләрен «новгород урыслары», «орёл-белгород урыслары», «урал урыслары», дип йөрмиләр. Нигә соң татарлар кырымлыларга, нижгарларга, себер татарларына, хаҗитархан татарларына, литва татарлары шикелле төрләргә бүленергә тиеш? Рахманкуловның төрлечә бирелгән иҗатында бу протест еш яңгырый».

Шактый кырыс һәм җитди бәя иде бу.

Мәкаләнең журналда басыла алмавы кызганыч, әлбәттә. Әмма бу аңлашыла да... Әлеге факт иң кыю фикернең дә сәнгатьле әсәр рәвешендә әдәбиятка тизрәк үтеп керә алуын тагын бер кат раслап тора. Димәк, Габдрахман бу яктан да хаклы булган. Әлегә ачыктан-ачык язар вакыт – алар заманы килмәгән. Димәк, Рахманкулов нәкъ менә кичекмәстән хәзер кулына әдәби каләм алырга тиеш булып чыга!

Габдрахман әдәбият галименең шактый тирәннән алып фикер йөртүенә бик канәгать калды. Язганнары бушка түгел, киң катлам укучыларга да алар барып җитә, димәк, мондый әсәрләр кирәк дигән сүз! Башкаларның әсәрдә син әйтергә теләгән фикерне, күтәреп алып, тагын да икенчерәк аспектларда яңгыратуын ишетүе әдип өчен бәхет түгелмени?! Димәк, тормыш каршылыкларын, барысына да син үзең генә гаепле кешедәй, үз эчеңдә кайнатып, кайгырып, борчылып йөрүгә караганда, язып, чишеләсе проблема – әсәр итеп замандашларыңа, укучыларыңа милләттәшләреңә җиткерә алуың күпкә отышлырак. Географик киңлек ягыннан да, төрле заман укучыларын бу мәсьәләгә җәлеп итү мөмкинлеге ачылу ягыннан да... Язарга кирәк!

Күр, Одесса егеткә әдәби иҗат өлкәсендә икенче тапкыр инде нинди кыйммәтле бүләк әзерләп куйган! Юк инде, монысын да күрмәмешкә салышып, колак яныннан шыпырт кына уздырып җибәрергә мөмкин түгел...

***

Соңгы елларда Рахманкулов бик озак бер үк төшне күреп интекте. Имеш, ярты сәгатьтән аның корабы диңгезгә чыгып китәргә тиеш. Таможенниклар, чик саклаучылар инде тикшерергә, тентергә керешкәннәрдер? Аврал уйнап, швартов бауларын ычкындырып җибәрсәләр, машина телеграфын өлкән штурман «полный вперёд»ка күчереп куйса, кораб яныннан артка таба ак яллы дулкыннар йөгерә башлаячак. Ә Габдрахман һаман такси тота алмый. Маңгайларында яшел ут янган җиңел машиналар аның яныннан узып тора. Ул кулын күтәрә, каршы чыгып карый – туктамыйлар. Өзгәләнеп кычкыра – ишетмиләр. Портка йөгереп барган булса, бәлки, өлгерә дә алыр иде?!. Йа Хода...

Диңгезгә чыккан корабыңа өлгерә алмый калу... Чын диңгезче өчен моннан да зуррак мәсхәрә буламы икән? Ничә ел эшләп, Габдрахманның бер генә тапкыр да корабына соңарып кайтканы булмады. Менә бүген... Ул хәзер ничек кеше күзенә күренер?

Кат-кат күргән әлеге төшен, монда берәр мәгънә ятмыймы икән, дип, Габдрахман үзенчә берничә төрле юрап та караган булды. Әмма бүгенге халәте диңгезгә ике мәгънә өстәп аңлаудан уза алмады: бәлки, бу минем шулай «тормыш диңгезе»ндә яшәвемнән соңга калу куркынычы булуга кисәтүдер?.. Бәлки, бу, талпынып та, халкыма хезмәт итәрлек язу стихиясенә ирешә алмаган «иҗат диңгезе»дер?! Ә бәлки икесе бергә?! Ни генә булмасын, өйләнергә кирәк!

Ни генә булмасын, язу дәртенә ныклап керешергә кирәк! Олы язмышыңа соңга калмаска иде!

Чынбарлыкны күзәтеп һәм аның турында уйланып йөрү белән генә чикләнмичә, шәхси тормышың, яшәү мәгънәсе биргән каләмең турында да ныклап уйларга вакыт килеп җитте булса кирәк. Тукай әйткәнчә:

Игътиля итсәң (югары ашсаң), канатың ач, – вакыт җитте бугай, –
И тумыштан гарше әгъляларга (югары күкләргә) җилкенгән күңел!..

**2**

Чынлап та, кайчан, ничек килеп чыкты, ничек бирелде соң әле Габдрахман бу әдәби иҗат хирыслыгына?

Бәлки, әлеге омтылыш аның хыялый балачагына барып тоташадыр?! Бәлки, авылда, җир куенында аунап үсү, кечкенәдән эш арасында табигатьнең мең төрле үзгәрешләрен күзәтергә өйрәнүдән тугандыр бу нечкәлекләр?.. Матди һәм рухи җитешсезлекләр, авыр хезмәт, тормыш кыйнаулары да үз эзен салмый калмагандыр әлеге тирән кичерешләргә?.. Яшәештә гаделлек эзләү тойгысы кайчан барлыкка килде икән?.. Мөгаен, монда авыр сугыш елларының фаҗигале язмышлары белән очрашу үз өлешен кертми калмагандыр?.. Бәлки, бу тынгысыз дәрт, хыялый ашкыну хисе тормыштан бертуктаусыз яктылык, нур, иман эзләү белән бәйледер?!

Армия хезмәтендә хискә бирелүчән, көндәлек тормыштан яшәүнең зур, бөек максатын эзләп көн күргән егеткә хәрбилекнең аяусыз кырыс, боерыкка, буйсыну-буйсындыруга көйләнгән тәртибеннән әлеге дә баягы бары тик шушы әдәби әсәрләр дөньясына яшеренеп кенә котылу мөмкин булгандыр? Бигрәк тә Сахалинда чакта, культуралы тормыштан читтә, ябык гарнизонда яшәгәндә, госпитальдә ятканда һәм зарыгып армия хезмәтеннән котылуны көткән чакларда китап уку, әдәби сурәт тормышына чумып, кешелек сыйфатларын югалтудан саклап калгандыр?

«Бөек Ватан сугышы» дип аталган үтерештә җиңеп чыгу шатлыгыннан исерүнең нәтиҗәсе – шапырыну, масаю, тормыш хезмәтенә нәфрәт белән карау, сорыкортлык армияне әкренләп черетә, глобаль дедовщина шартларына котылгысыз рәвештә алып килә иде. Болар барысы да шушы нечкә, саф күңелле егет кичерешләре аша үткән бит.

Мәскәү университетының филология факультетын сайлауда да эчке бер мантыйк булмыйча калмагандыр, билгеле.

Әмма армиядә чакта шундый ымсындыргыч тоелган студент тормышы, Советлар Союзындагы иң данлыклы уку йортында белем алу Габдрахманга үзенең икенче – караңгырак якларын күрсәтергә дә бик тиз өлгерде. Фәннәр баштанаяк марксизм-ленинизм тәгълиматына яраклаштырылып, идеология белән агуланган. Ихлас күңелдән чын белемгә, фикер тирәнлегенә, мөстәкыйль рәвештә фәнне үзләштерүгә омтылучылар – юләр санында. Күп студентларның төп максаты – диплом алу, шул мөһерле кәгазь ярдәмендә көнкүрештә көч түкмичә генә өскә үрмәләрлек урын табып тормыш кору. Данлыклы уку йортында да чын белемне ил күләмендә мәшһүр профессорларның лекцияләреннән түгел, каядыр читтән, патша чорыннан сакланып калган шәхси китапханә киштәләреннән, Андрей Синявский, Владимир Лакшин шикелле аспирантларның махсус семинарларыннан эзләргә туры килә. МДУда укыганда, Габдрахман педагогия институтына, Алексей Лосев лекцияләренә бара, «итәк

астыннан йөргән» китапларны уку белән мавыга иде. Ниһаять, ул шундый фикергә килде: илнең беренче югары уку йорты саналган университетка да ышанырга ярамый, әгәр чын белем, хакыйкый, идеология имгәтмәгән фәнне үзләштерәсең килсә, аны үзлегеңнән эзләргә, яшерен сакланган китапларны табарга, шулар ярдәмендә белемгә ирешергә кирәк. Чын белем ул китапларда гына түгел, тормышның үзендә, адәм баласының яшәешендә, аның бәхет эзләвендә, ялгышуларында, өметләрендә, шул өметләрне җимерүче көчнең каян туып торуын ачыклауда.

Бактың исә аның калган бөтен биографиясе дә ихлас күңел белән шушы «тормыш университеты» сабакларын үзләштерүдә; яшәешенең аерым тармаклары – әдәбиятка килүенең аерым этаплары.

1955 елның көзендә Габдрахман Одессага килде һәм зур авырлыклар белән Кара диңгез пароходчылыгына эшкә урнашты. Диңгезчелекнең үсеп китү процессы тулысынча аның күз алдында үтте.

Габдрахман диңгезчелек һөнәрен сайлауда ялгышмаган иде. Диңгезче җир шарының теләсә кайсы төбәген, теләсә кайсы илне күрә, андагы тормышны күзәтә ала. Үз илендәге тормышны күзәтә ала. Үз илендәге тормышны тирәнтен аңлау өчен, бу мөмкинлек чиктән тыш кирәкле, күзәтү, чагыштыру, анализлау – язучының төп коралы, вазифасы.

### 3

Әлбәттә, әдипләрне, барыннан да элек, үзе яшәгән чор-заман тудыра. Шәхеснең формалашуы һәм, өлгереп җитеп, актив яши башлавы, үз чорының төрле вакыйгаларына катнашуы исә аның субъектив үзенчәлекләре белән бергә үрелә. Ә алар яшәгән чор, бу очракта илдәге диңгезчелек тормышына караган вакыйгалар, чыннан да, мондый кискен үзгәрешләргә гаҗәеп бай булды.

«Морфлот» – Сәүдә диңгез флоты министрлыгы унсигез пароходчылыкны берләштерсә дә, вак елгадагы – диңгезчеләр телендә «тавык диңгезе»ндәге Урта Азия пароходчылыгын бу санга кертмиләр иде. Әле яңа гына Кара диңгез пароходчылыгы биргән вак-төяк кораблардан оешкан Грузин пароходчылыгыннан да диңгезчеләр йөз чөерә иде. Күбрәк буксирлардан, баржалардан, бәләкәй кораблардан торган Совет – Дунай пароходчылыгына да мариманнар кимсетеп карый. Владивостоктагы Ерак Көнчыгыш, Ленинградтагы Балтика һәм патша заманындагы Добрфлот белән Ропит компанияләрен берләштергән Одессадагы Кара диңгез пароходчылыгы – менә шушы өч иң зур, иң тәҗрибәле оешмалар мариманнарның тәкәббер горурлыгы иде. Соңгы елларда гына Кара диңгез пароходчылыгыннан Новороссийск берәмлеге һәм ваграк кораблардан оешып, Грузиянеке эшли башлады. Балтика пароходчылыгыннан Латвия, Литва, Эстония берләшмәләре аерылып чыкты. Архангельски, Мурмански, Камчатка һәм Сахалинда сугышка кадәр оешкан пароходчылыклар эшләп ята. Тик алар берсе дә, өч гигант пароходчылык кебек океан киңлекләрен гизеп, ерак диңгезләр аша чит илләргә йөк ташу эшен башкара алмый иде.

Шунысы кызык: хәрби флотка катнашы булмаган тынычлык кораблары, Ленин һәм Троцкий васыятен тормышка ашырып, җир йөзенә социализм «ташыйлар», социализм тараталар иде. Кешеләре ярым ач, ярым ялангач яшәсә дә, совет җитәкчеләре аларның соңгы сыныкларын авызларыннан тартып алган шул акчага ясалган коралларны социализм төзергә вәгъдә биргән илләрнең авантюристларына илтеп тапшыралар иде. Бөтендөнья революциясен эшкә

ашыру мөмкин түгеллеге югыйсә күптән ачыкланды. Политбюро шуны белә торып, халкы эшләп тапкан хәләл малны бушка туздыруын дәвам итә иде.

Сталин тәхеттә утырганда, сәүдә флоты белән Лазарь Моисеевич Каганович җитәкчелек иткән. Бөек юлбашчының башка куштаннары шикелле үк ул да шыр надан булган, күрәсең. Аның сәүдә флоты зыян гына китерә, бер сумлык керем алу өчен, дүрт-биш сум чыгым китә дип, Сталинны ышандыра алуы шул хакта сөйли. Сталин чорында Советлар Союзының чит илләргә йөри торган сәүдә кораблары булмаган диярлек. Дөрес, ул чакта да сәүдә флоты корабларыннан тулысынча котыла алмаганнар. Колыма лагерьларында ничәмә миллион репрессия корбаны алтын казыган. Ул тирәдә тимер юл юк, автомобильләр аз. Шуларны һәм тоткыннар казып чыгарган алтынны ташыр өчен, тоткыннарны Магаданга, Сахалинга, Чукоткага илтер өчен, «дальфлот» дип аталган махсус пароходчылык тотканнар. Андагы кораблар белән Берия идарә иткән. Трюмнарына «тере товар» тутырып, Магаданга илтәләр дә Одессага, Ленинградка алтын төяп кайтаралар.

Сугыштан соң бу эшкә Германиядән репарация буенча талап алынган танкерларны да җигәләр. Габдрахман эшкә урнашкан чакта пароходчылыкта «Москва», «Кремль», «Сталин» менә-менә таралып төшәр хәлгә җитеп эшләп йөри иде.

Сәүдә флотының кирәклеге, Иран шаһын тәхетеннән бәреп төшереп, Премьер-министр булып Моссадыйк утыргач барлыкка килде. Иран нефть акчасына яшәүче ил иде. Нефть ташучы танкерлар – капиталистик илләрнеке. Алар шаһка теләктәшлек йөзеннән Иранга танкерлар җибәрми башлагач, Моссадыйк, Мәскәүгә мөрәҗәгать итеп, Советлар Союзыннан танкерлар сорады. Бу эшкә «Москва», «Кремль», «Сталин» гына аз, Иран нефтен чит илләргә илтеп тору өчен йөзләгән танкер кирәк иде. Нәкъ шул чакта хөкүмәт җитәкчеләре, сәясәтне тормышка ашырыр өчен, сәүдә кораблары кирәклеген аңлап алдылар. Ул заманда хәрби кораб төзи торган заводлар инде байтак кына иде. Сәүдә корабларын тизрәк шунда төзергә керештеләр. Тик алар өлгерә алмады, сәүдә корабларын кичекмәстән чит илләрдән сатып алу ихтыяҗы туды.

Фидель Кастро Кубада баш күтәреп, тауларда корал килгәнен көтеп утырган арада Советлар Союзы Франциядән сатулашып тормыйча гына биш теплоход сатып алырга өлгерде. Совет иле зур, халкы талымсыз, күндәм, һәркемнең эш хакыннан утыз-кырык, җитмеш процентны басып калган очракта да йөзләгән-меңләгән кораб сатып алырга мөмкин иде. Эш хакыннан тыш совет кешесенең башка кереме юк, ачка үләсе килмәсә, ул барыбер эшкә чыгачак иде. Шулай итеп, ил тиз арада үзенең сәүдә флотын аякка бастырып куя алды. Рахманкуловка да диңгезче булып китәргә, һичшиксез, әнә шул сәяси вазгыять ярдәм итте.

## 4

Әлеге объектив вакыйгаларның уртасында кайнап, аның барышына күпмедер юнәлеш биреп тору вазифасы, әлбәттә инде, заманның иң көчле, иң актив шәхесләренә йөкләнә. Белүебезчә, шәхес ул – әдәбият һәм сәнгать әсәрләренең дә үсеш коллизиясен барлыкка китергән төп үзәк көч. Әсәрнең психологик умыртка баганасы. Бу уңайдан Габдрахманның диңгезчелектә узган гомер юлында кулга-кул тотынышып эшләгән нинди генә язмышлы шәхесләр очрамады. Әсәрнең бер каһарманы булган Владлен Семёнович Лебедев та шул күпләрнең берсе иде. Ул чор турында Лебедев яшәп үткән юл үзе генә дә күп нәрсәләр сөйли алыр иде.

Кораб төзү институтын тәмамлаганнан соң, Владлен Кара диңгез пароходчылыгында комсомол секретаре булып урнашты. Аннары партком секретареның урынбасары итеп сайладылар.

Илдә, Черненко үлгәч, генеральный секретарь итеп Горбачёвны куйган чор иде бу. Әлеге еллар барыннан да элек СССР белән капиталистик илләр арасында торган «тимер рәшәткә»нең бер кат алынуы белән истә калган.

Владлен эшләгән чорда «Победа» исемле теплоход пароходчылык тарихында беренче тапкыр совет заманының элитасын Одессадан, Урта диңгез, Атлантика портларын күрсәтеп, Ленинградка алып барырга Үзәк Комитеттан рөхсәт кәгазе юнәтте. Рөхсәткә ияреп, Үзәк Комитетның катгый боерыгы да килде: чит илләргә баручы, дөньядагы иң алдынгы карашлы совет бәндәләре держаның абруен төшермәс өчен, чиктән тыш дөрес киенергә, чит ил портларында йөргәндә дә социалистик илнең абруена тап төшермәскә тиешләр. Шушы үтә зур җаваплылыкны пароходчылыкның парткомына йөкләделәр. Партком исә туристларның киемнәрен тикшерү максатыннан, махсус комиссия төзеде. Ул чакта Рахманкулов, ялдан соң корабының рейстан кайтканын көтеп, резервта тора иде. Аны да комиссия исемлегенә теркәделәр. Аларның тикшергәннәре шул булды: ирләрнең өстендә – кыйммәтле яңа кара костюм, ак күлмәк, затлы галстук һәм яңа ботинка; һәр хатын-кызның ак һәм кара костюмнары, ак һәм кара перчаткалары, ак һәм кара эшләпәләре, ак һәм кара туфлиләре булырга тиеш. Үзәк Комитетның боерыгы катгый рәвештә үтәлгәнме? Комиссия чит илләргә барырга әзерләнгән һәр пассажирны тикшереп чыгарга тиеш иде. Тикшергәннән соң, җентекләп протокол төзеделәр. Шул протоколга кул куйган чакта Рахманкулов комиссиянең җитәкчесе Владлен Лебедев белән якыннан танышты.

Туристларның җитмеш-сиксән проценты Үзәк Комитетта эшләүчеләр, җитәкчеләр тирәсендә чабата туздырып йөрүчеләрнең хатыннары, балалары, кардәш-ыругулары иде. Күз буяу өчен, биш-алты процент чамасы алдынгы эшче-колхозчылар – Социалистик Хезмәт Геройлары. Шулар арасына, ни хикмәт, Константин Паустовский, Даниил Гранин, Михаил Ульянов, Святослав Рихтер, Георгий Отс шикелле күренекле шәхесләр дә эләгә алган. Коммунистлар партиясе, чыннан да, ышандырырлык итеп күз буйый белә иде.

Туристларның киемнәрен тикшергән атнада Габдрахманның пароходы «Чолман» Одессага кайтты. Херсон портында тиз генә бодай төяп ташладылар да, пароход Италиягә юл тотты. Неапольдә аны причалга куйдылар. Йөк бушаткан арада туристларга Истанбул, Афина портларын күрсәтеп өлгергән «Победа» Неапольгә килеп җитте. Неаполь – Италиянең иң көләч, җыр-моңга күмелеп яшәгән каласы. Монда кызу канлы, кайнар табигатьле, татарга тартым неаполитаннар яши. Берзаман ак костюм, ак перчатка кигән министр хатыннары базардан һәм шәһәр кибетләреннән үзләренә гаять кирәкле һәм кыйммәт булып тоелган пластик таслар, чиләкләр, төрле савытлар сатып алып, каюталарына ташый башлый. Советлар Союзында пластик савыт-саба юклыгы башларына да килмәгән итальяннар моңа шаклар катып карап тора: «Нинди бәндәләр бу! Өсләренә үткән гасырларда яшәгән аристократларча кием кигән матур симез ханымнар, идән юучы хатыннар шикелле, базардан, күтәренеп, урам буйлап тас-чиләк алып кайта?!»

Озак еллар Советлар Союзы капиталистик чынбарлыкны яшереп торган «тимер пәрдә» артында яшәде. Шул пәрдәне ачып җибәргәч, «социалистик җәннәтнең» ямаулык каплаган хәерчелеге күз алдына килеп басты.

«Победа» теплоходы совет туристларын утыртып Европага илткәндә, Греция флагы астында йөзүче «Олимпия» лайнеры, Америка туристларын төяп, Одессага килеп төште. Капитализм шартларында яшәүчеләрнең беренче тапкыр совет чынбарлыгы белән очрашулары иде бу. Шуңа да аларны тиешле югарылыкта каршы алыр өчен, бик озак һәм бик җитди әзерләнделәр. «Красный» һәм «Одесса» (патша заманында – «Лондонский») рестораннары иң зиннәтле, иң тәмле ашлар пешереп торды. Одессаның опера театры иң югары сыйфатлы спектаклен – «Кармен»ны куярга тиеш иде.

Әмма, хәерчегә җил каршы дигәндәй, «Олимпия» Одессага килгән көнне диңгез өстен куе томан каплаган. Лайнерны каршы алырга баручы лоцман катеры, локаторы булмаганлыктан, «Олимпия»не табалмыйча, сәгатькә якын адашып йөргән. Ниһаять, катер корабны эзләп тапкан. Лоцман корабны портка керткән. «Граница на замке» заманы. Чик саклаучылар, таможенниклар, КГБ кешеләре туристларның каюталарын, багажларын актарып тикшерә башлаганнар. Инструкция кушканча, һәр туристның каютасын, әйберләрен капшый-капшый сәгатьләп тентергә тотынгач, америкалылар, протест йөзеннән, рестораннан да, операдан да, ярга чыгудан да баш тарткан. Рестораннарда туристларны сыйларга дип пешерелгән тәмле ашлар суынып беткән. Гафу үтенеп, юмалап, ниһаять, туристларны ярга чыгарга күндергәннәр. Порт аша үткәндә, тагын бер матавык-гауга килеп чыккан: тимер юлда торучы вагоннар астыннан өстенә мазутка баткан сырма кигән, көпчәк майлап йөрүче бер хатын килеп чыккан. Туристлар бу экзотик күренешне фотога төшерә башлаганнар. Фотоплёнка Америкада чыга торган газеталар битенә эләгеп, мәсхәрәле сенсация куптару куркынычы булганлыктан, КГБ кешеләренә тагын бер борчу тудыра. Әмма алар совет чынбарлыгына тап төшерәчәк ул фотоплёнканы юкка чыгара алмаган. Вагон көпчәкләре майлап йөрүче хатынның сурәте «Нью-Йорк Таймс» газетасында басылып чыккан. Илчелектән шул хәбәр килүгә, социализм чынбарлыкларын тиешле дәрәҗәдә күрсәтә алмаганы өчен пассажир лайнерлары флотына җитәкчелек итүче тәҗрибәле карт начальникны урыныннан төшереп, яшь, культуралы, помполит булып эшләгәндә чит илләрдәге тәртип белән танышкан Лебедевны утырттылар. Владлен бу җитәкчелекне шактый уңышлы башкарды. Чит илләргә чыгып йөри торган пассажир лайнерларының санын икеләтә арттырды. Билетны профсоюз аша алганда, круизда йөреп кайту шактый арзанга төшә иде. Билет бәясен тулысынча үз кесәсеннән түләп алучылар саны да аз иде. Шуңа күрә Владислав Семёнович иң яхшы, иң комфортлы корабларны Америкадагы бер компаниягә тайм-чартерга[2] тапшыра башлады. Бу Совет системасы өчен яңалык иде.

Шулай уңышлы гына җитәкчелек итеп ятканда, Мисыр белән Израил арасында сугыш башланды. Мисырга корал ташуны, инструкторлар илтүне Кара диңгез пароходчылыгы карамагына тапшырдылар. Шунысы мәгълүм булды: Израил Мисырга күпме һәм нинди корал киләсен, кайсы кораб китерәсен, кайда бушатачакларын энәсеннән җебенә кадәр алдан белеп торган. Чара күрмичә калу мөмкин түгел иде. Пароходта эшләүчеләрнең «бишенче пункты»н тикшерергә керештеләр. Баш бухгалтер, оператив план кору начальнигы, капитал төзелеш начальнигы, валюта бүлеге начальнигы, шул исәптән пассажир флоты белән җитәкчелек итүче Лебедевның гарәпләргә каршы сугышучы милләт токымыннан икәнлеге ачыкланды.

[2] Тайм-чартер (*ингл.*) – корабны чит ил компаниясенә үзара килешенгән хакка вакытлыча биреп тору.

Лебедев «бишенче пункт»ын яшерү белән генә чикләнмәгән икән. Тикшерә башлагач, пассажир лайнерларын тайм-чартерга аның Америкада круиз компаниясе тоткан әнисе белән бертуган апасының малаена биреп торуы ачыкланды. Җинаять чиктән тыш зур, гөнаһ чиксез-чамасыз иде. Соңыннан бу кешенең төрмәдән ничек котыла алуына гаҗәпләнеп бетә алмадылар.

Ул чакта инде Рахманкулов диңгез флотының үзәк институты саналган «Союзморниипроект»та баш белгеч булып эшли иде. Беркөнне аның кечкенә эш бүлмәсендә Владлен Семёнович Лебедев пәйда булды. Бәлки, аның турыдан-туры директор янына керергә дә мөмкинлеге булгандыр. Владлен акыллы һәм тәҗрибәле җитәкче иде. Ул институтның нинди эшләр башкаруын, киләчәктәге мөмкинлекләрен, директорның нindирәк кеше икәнлеген – барысын да җентекләп сораштырды. Пароходчылыкта начальник булып утырганда, бу кеше вакытын бушка уздырмаган икән. Киләчәген кайгыртып һәм аттестация комиссиясе җитәкчеләренең круизга йөрергә яратуларыннан файдаланып, докторлык диссертациясе дә яклап өлгергән иде. Лебедевне бер атна эчендә «Союзморниипроект»ка өлкән фәнни хезмәткәр итеп эшкә алдылар. Ул анда яхшы гына эшли башлады һәм, бер ел үтүгә, Сергей Михалков яши торган Никулина Гора дип аталган җирдә аның зур, иркен дачасы, Горький урамында дүрт бүлмәле фатиры да бар иде инде. Менә бүгенге көндә социализмнан баш тартып, капитализм төзи башлагач, Рахманкуловның танышы өч дистәләп пассажир лайнерларының хуҗасы икәнлеге дә мәгълүм булды.

Күрәбез, халыкара күләмдәге тормыш күренешләре, аның каршылыклы чагылышы да, булачак әдәби әсәрләреңнең геройлары да шул ук олы тормышның үз эчендә яши ләбаса! Әдип кешегә аларны күрә һәм чагылдыра белү генә сорала!

Бактың исә Габдрахман өчен аның һәрбер сәяхәте язылмаган яңа әсәр иде!

**5**

Яңа әсәрләрне дөньяга китерер өчен, язучыдан талант көче һәм язу осталыгы, гражданлык намусы һәм иҗат тәҗрибәсе таләп ителә. Шуңа да, үзеңә кадәр иҗат иткән сәнгать корифейларын, шул исәптән атаклы каләм осталарының әсәрләрен белү иң мөһим таләпләрнең берсе булып тора. Язучы булыр өчен син, барыннан да элек, дөнья классикасын укырга, гомумән, актив һәм бик яхшы укучы булырга тиешсеңдер, мөгаен?!.

Синең милли әдип булуың – ул язучы һөнәре генә түгел. Ул синең эчке вөҗданың, яшәү намусың. Ул синең халык тамырлары белән бергә тоташуың, фаҗигале милләт аһәңен, бер генә мизгелгә дә йөрәгеңнән җуймый, җаныңда йөртү, милләт язмышы синең изге вазифаңа, яшәү мәгънәсенә, үз язмышыңа әверелү!

**6**

Өч айга сузылган йөзүдән кайтышлый Рахманкулов биш кенә көн Одессада торды да авылына кайтып китте. Оксана да туган авылында өч атна торып килде. Соңгы вакытта Дерибас урамына ул бик сирәк чыга иде. Күбрәк үтеп барышлый гына. Шул арада да егетләрнең әрсезләре, теләгән кызны мин үземә карата алам, дип ышанып йөрүчеләре, аңа шактый еш очрый иде. Андыйлар белән уртак тел табу мөмкин дә түгел. Алар бит үзләрен генә тыңлый беләә. Синең сүзең аларның бер колагыннан керә, икенчесеннән чыга.

Ниһаять, Оксана Габдрахманның тавышын ишетүгә ирешә. Институттан

кайтып, ашарга гына утырган иде. Комендант булып эшләүче хатын ишектән башын тыгып кычкырды:

– Ярёменко, сине телефонга.

Габдрахманның тавышын башка беркемнеке белән дә бутап булмас иде.

– Кайттыңмыни? – диде Оксана, шатланып. – Бу юлы көтү шулкадәр озакка сузылгандай булды.

– Кил, мин сине көтәм.

– Кайда көтәсең?

– Шул урында инде. Воронцов сараеның пропелеяләре төбендә. Син яраткан урын бит.

– Көт, – диде Оксана. – Хәзер киенәм дә чыгам.

***

Одессаның иң матур биналарыннан берсе саналган Шәһәр думасының колонналары янында Ак Санәнең сыны пәйда булды. Әле бит сыны гына күренә, ә Габдрахманның колагында инде аның тавышы тудырган музыка яңгырый, хәрәкәтләрендә – Мәскәүдә алар бергәләп караган әндәлүз биюенең тылсымлы тәэсире. Оксананың баш өстендә чиксез зәңгәр күк. Ул диңгез ярына тезелгән Беренче завод, Карбыз гаване, Икмәк гаване, Нефтегавань һәм офык артына яшеренгән Балта шәһәр тарафына таба атлап бара. Сулдарак – Сабанеев күпере янындагы граф Толстой сараена урнашкан Галимнәр йорты, йөз яшәгән платаннар астындагы эскәмияләрдә утыручылар кызны күзләре белән озатып калалар. Ирләрнең карашында канәгатьлеккә ирешә алмаудан туган мәңгелек комсызлык. Хатын-кызлардагы тойгы катлаулырак: гәүдә-сын, атлап баруның җиңеллеге, сизелер-сизелмәс кенә артка таба тайпылып торган куе саргылт чәчкә күмелгән башның тотылышындагы горурлык. Яшьләр исә ләззәтләнеп карый иде. Малайлар «мин үсеп җиткәч, менә шушындый кызны табарга тиешмен» дигән сыманрак итеп, үсмерләр «чәчне менә ничек ясатырга кирәк икән, гәүдәне менә шулай тотарга кирәктер... әнә бит, елмаймый да, үзе тирә-якны балкытып бара...» дип, күңел түрендә нидер кузгалып җанланганын сизәләр иде. Белмим, юлына аркылы төшкән егетләрдән ничек котыла алды икән Оксана?..Тупаслык та юк бит үзендә, тәкәбберлек тә...

Матур кызга өйләнсәң, гомер буе дер калтырап яшәргә тиешлегеңне аңлата бу. «Бигрәк тә диңгезче өчен, гомер буе тынгы белмичә, хатынымны аздырмасалар ярар иде, дип куркып яшәү бит бу...» «Тиле дә инде син, Габдрахман. Синнән башка беркем мине чибәр кызга санамый. Аннан соң, әйттем бит, мин сиңа кияүгә чыккач, ким дигәндә, җиде бала үстерәм, дип. Балалы хатыннарның иренә хыянәт итәргә вакытлары булмый. Син шуны да аңламыйсыңмыни? Минем артымнан бит зур начальниклар ялынып йөрделәр. Буйдаклары кияүгә чыгарга өндәп теңкәмне корытып бетерде. Өйләнгәннәре, хатынымны аерам, мин сине бәхетле итәм, дип, ниләр генә вәгъдә итмәде».

Кыз якынлашкан саен, матурлыгыннан яңгырап чыккан моңсу музыка көчәя төшкәндәй тоела иде. Сарай коймасы янына җиткәч, кыз берничә минутка югалып торды. Менә ул капкадан кереп килә...

Габдрахман каршы барып, аны иплəп кенә кочаклап алды да, бер адым артка чигенеп, сөйгәненә карап тора башлады.

– Нигә берни дә әйтмисең? Әллә минем соңарып килүемә үпкәләдеңме?

– Юк, үпкәләмәдем. Әйтергә сүз таба алмыйм.

– Йа Хода, син дә сүз таба алмагач инде. Очрашканда мин синең авызың йомылып торганын хәтерләмим.

– Бүген менә югалып калдым. Кирәкле сүз искә төшми... – Ниһаять, Габдрахман, ихтыяр көчен туплап: – Соңгы очрашуыбыз бу... – диде һәм дәвам итә алмыйча тукталып калды. – Мин өйләнергә вәгъдә биреп кайттым.

Оксана егеткә текәлеп карады да бер адым артка чигенде.

– Кемгә?

– Якташыма.

– Миңа хыянәт итепме?..

– Хыянәт, дип... Алай ук түгелдер инде. Мин бит аңа өйләнәм.

– Кацапкагамы?

– Үз милләтемнән. Татар кызына.

– Син шулай милләтчемени? Мин синең хыянәтче хәйләкәр икәнлегеңне белми идем. Күпме вакыт: без – кыпчаклар, безнең тамырларыбызда бертөрле кан ага, дип, күземә төтен җибәреп, миемә пудра сөртеп йөрдең. Ә мин, дура, шуңа ышандым.

«Милләтче» сүзенең мәгънәсе пропаганда аңлатканның киресе икәнлеген аңлатырга кирәк иде. Нишләптер теле Габдрахманга буйсынмый иде. Һәм һәр әйткән сүзенең мәгънәсе үзенә каршы, Оксана файдасына яңгырый шикелле тоела иде. Кызның гап-гади, риясыз сүзләре егетнең йөрәгенә ук булып килеп кадалып тора иде.

– Милләтченең дә милләтчесе икәнсең. Минем каршыда шундый оста итеп яшереп йөрдең.

– Синеңчә «мин татар милләтчесе», дип кычкырып йөрергә тиеш идеммени? Син милләтче түгелме? Әнә бит украиннарның һәр матур сыйфаты сиңа газиз!

– Зиһенем таркалганга, «милләтче», дип әйткәнмендер инде. Син – ялганчы. Украиннарда һәм татарларда кыпчак каны ага, дип күпме ялганладың. Ялына дип уйлый күрмә тагын. Бик дөрес эшләгәнсең. Өйләнешсәк, без барыбер бәхетле була алмас идек.

Аңа ышанып, әллә никадәр егетләрдән баш тартканын әйтеп, Оксана гаепли башларга тиеш иде кебек... Кыз бу турыда сүз кузгатмады.

– Ә бит мин, дура, сине көттем. Син диңгездә чакта танцыга да йөрмәдем, хәтта иптәш кызларым җыелган җиргә дә бармый идем, егетләр мине эзәрлекли башлар дип куркып. Шул кирәк миңа... Менә кирәген алдым.

Оксананың ихласлыгы каршысында аклану сүзләренең барысы да көчсез иде. Мәхәббәт җимерелгәндә, бөтен нәрсә кирәксезгә, абсурдка әверелә. Нәрсә икән соң ул мәхәббәт? Аны шулай бер сүз белән җимереп, юкка чыгарып ташлап була микәнни? «Өйләнәм» сүзен әйткәнчегә кадәр Габдрахманга ул җир йөзендәге иң зур, адәм баласын бәхетле дә, бәхетсез дә, бөек тә, мескен дә итә ала торган илаһи бер көч булып тоела иде. Аның күз алдында шул бөек көч җимерелә, юкка чыгып килә.

Адәм балаларының язмышлары белән идарә итүче, кешене бәхетле дә, бәхетсез дә итә ала торган бөек көч, диләр мәхәббәтне. Ул нигә соң үзе шулай көчсез? Инде өченче ел аның уй-хисләре, теләкләре белән идарә итеп, киләчәккә матур өметләр өеп торган көч бер сүз – «өйләнәм», дип әйткән бердәнбер сүздән җимерелә, аны ташлап китеп азаплана иде.

Оксана елап җибәрүдән курка иде. Бераз туктап торганнан соң, ул ниндидер ят тавыш белән дәвам итте:

– Күреп торам бит, ялгышуыңны үзең дә аңлыйсың. Минем әле синең болай

мескен сөйләшүеңне күргәнем юк иде. Курыкма. Ялыныр дип уйлый күрмә тагын. Ул татар кызының миннән нинди өстенлеге бар соң? Матурракмы? Әллә акыллыракмы? Онытканмын икән... Бер милләттән бит. Шулмы аның өстенлеге?

– Эш өстенлектә түгел. Безнең бит күп мең еллар тупланып килгән гореф-гадәтләребез бар. Урыс басып алганнан соң да, ата-баба шуны саклап кала алган. Без шуны киләчәк буыннарга тапшырырга тиешбез. Бүгенге көндә тоташтан диярлек маңкортлашу бара. Без бит бу турыда күп сөйләштек, онытмагансыңдыр, шәт...

– Кабатлама, беләм. Көчләп чукындырулар. Явыз Иван Казан ханлыгын яулап алгач, тоташтан кырып барулар. Сөйләдең син миңа. Мин хәтта ышандым да. Хәзер инде ышанмыйм. Син гап-гади бер трепач. Аңладыңмы?

Оксана авыр итеп урыныннан кузгалды. Оныттымы, теләмәдеме – саубуллашмады... Менә ул Воронцов сараеның капкасына таба атлап бара. Һәр очрашуда Габдрахман кызның матурая төшкәнен тоеп куана, горурлана иде. Менә бүген... ул кинәт кенә... сине акылдан яздырырлык дәрәҗәгә җитеп матураеп китте. Шул тәннәрне чымырдата торган матурлык һаман ерагая, һаман читләшә, китеп югалуга таба бара...

Шак-шок, шак-шок, шак-шок... Туфли үкчәсе асфальтка өзлексез бәрелә. Үкчәдән чыккан тавыш түгел бу. Тойгылар шулай бәргәләнә... «ярамый мәхәббәт белән шаярырга»... «шаярырга ярамый»... дип ыңгыраша асфальт астындагы җир.

Капкадан чыгуга, Оксана күздән югалды. Нәрсә булды аңа?.. Габдрахман йөгереп капка төбенә килде. Оксана ашыгып Пушкин һәйкәленә таба атлый иде. Кызның атлап йөрүендәге сихри матурлыкка кискен тәвәккәллек кушылган. Агач төбендәге эскәмияләрдә утыручылар кызны карашы белән озата да бик озак карап торалар. Бәлки, аны җибәрмәскә кирәк булгандыр? Яисә өйләнергә җыенуын әйтү дә ялгыш булгандыр? Юк, шушы кызга гына өйләнергә кирәк булгандыр Габдрахманга. Өйләнү белән, диңгезне ташларга да гел аның янында гына торырга кирәк булгандыр. Эш табып булыр иде әле. Диңгездә йөзмәгәннәр дә яши бит. Ул да яшәр иде. Оксанасын көн саен, айлар, еллар буе, картайганчы күреп торыр иде...

Габдрахманның гаилә корырга җыенуына тәкъдир ничек карый икән? «Өзелеп сөйгән ярлар барыбер ятка кала, яр сөйсәгез, өзелеп сөймәгез», – ди халык җыры. Бу үгетне ничек аңларга?

Рахманкулов, чәрелдәп кычкырган тавышны ишетеп, туктап калды. Нәкъ аның баш очында зур акчарлак, Габдрахманны чукырга җыенган шикелле, бер урында төшә-менә, мәхәббәтенә хыянәт иткән егетне каһәрли иде. Габдрахман җиргә иелеп, таш эзли башлады. Куып җибәрергә кирәк иде бу мөртәтне... Тукта әле, ул миңа нигә каныга? Әллә Оксананы рәнҗеткәнемне аңлады микән? Каян аңлый алсын ул аңгыра – бар кайгысы балык тотуда булган диңгез акчарлагы?

Акчарлак белән мавыккан арада Оксана күздән югалып өлгергән иде инде. Кая китте икән ул? Ул бит әле аңа әйтәсе сүзләрен әйтеп бетермәде. Бетермәде? Нәрсә әйтер иде икән, әгәр менә хәзер аның каршысына Оксана килеп басса?.. Зиһен чуалып бетте. Болай булыр дип уйламаган иде. Нишләп соң кыз өч ел йөргән егетен болай ансат кына ташлап китте?.. Габдрахман бит аңа барысын да әйтергә өлгермәде... Аңлата алмый калды. Яратышу бер хәл... Гаилә корып яшәү, бала үстерү, шул балалар ярдәмендә милләтнең киләчәген

тәэмин итү... Бу бит бөтенләй башка нәрсә. Шуны аңлатырга әзерләнеп килгән иде Габдрахман очрашуга. Ә ул китте дә барды. Туфли үкчәләре асфальтка бәрелгәндә чыккан каргышлы тавышлар гына ишетелеп калды...

Тукта әле, ул бит йөзүдән кайткач, ял алып, Мәскәүгә китәргә тиеш... Шул баруда әле яңа гына өйләнгән энесенең балдызы белән язылышып, башлы-күзле булып кайтырга... Бу бит уйдырма түгел. Уйлап чыгарган сүз дә түгел... Туйда Габдрахман сүз биреп китте ләбаса... Егет кешенең сүзе бер булырга тиеш. Әйе, бер булырга тиеш. Ә Оксананы кая куярга?.. Ташларгамыни?! Тынычланыргамы?.. Йә Ходаем, бар нәрсә үзара буталышып бетте. Аңлап кара син хәзер нәрсә эшләргә кирәклеген?!.

***

«...Татар кызының миннән нинди өстенлеге бар?» Шушы сорау Габдрахманның колагында һаман яңгырап тора иде әле. Нинди өстенлеге бар?.. Бармы икән, калдымы икән татар кызының өстенлеге?..

Таш брекватерны дулкын дөмбәсли. Габдрахманның Оксана белән аерылуына диңгезнең дә йөрәге әрни микәнни? Әнә ул җирдә хакыйкать юклыкка авыр гөрселдәүләр белән күкләргә зарлана. Әллә бульварда һава сулап йөрүчеләргә дә аларның аерылу фаҗигасе тәэсир иттеме? Аларның атлап йөрүләре сүлпәнәеп китте шикелле... Сөйләшүләре басынкырак тоела. Хәзер урыннан кузгалып, шулар яныннан үтәсе бар. Габдрахман кузгалырга куркып утыра иде.

## Унынчы бүлек

### 1

Эш сәгате чыкты. Владлен әкренләп өйгә кайтырга җыена башлады. Башкалар да урыннарыннан кузгалып, хуҗа яныннан, бөгелә төшеп, берәм-берәм ишеккә узарга кереште. Лебедевның офисы Көнбатыш илләрендәгечә үзара пыяла белән генә бүленгән бер зур бүлмәгә урнашкан иде. Эш көне тәмамлануга карамастан, күпчелек китәргә ашыкмыйча, компьютерына берегеп, әле эшен дәвам итә. Лебедевның уң кулы булган баш бухгалтер Дебора Феликсовна компьютер экраныннан нәрсәләрдер чүпләп, тиз-тиз генә принтерына күчереп куйды. Владлен үзенең баш бухгалтерын Нью-Йоркта махсус укытып кайтарды. Аның офисында әнисе ягыннан кардәшләре, хәтта әнисе белән бертуган апасы компаниясендә тәҗрибә туплаганнар да байтак кына иде. Акча туплау тәҗрибәсе елдан елга, гасырдан гасырга камилләшә килгән. Лебедев шул традицияне яңа Мәскәү шартларында кулланышка кертү эшен җәелдереп җибәргән иде.

– Дебора Феликсовна, бизнес эшенең аның очы-кырые юк. Сез болай да биш кешелек хезмәтне үз җилкәгезгә алдыгыз. Азрак ял да итегез. Иртәгә башкарасы эшләр калып торсын. Яңа көнгә яңа көч җыегыз.

– Ерак Көнчыгыш төбәгендә яшәүчеләр арасыннан клиентура эзли идем. Акча бирә торган эш бервакытта да алҗытмый бит ул, Владлен Семёнович. Совет системасында тәрбияләнгән хезмәткәрләрең кичке алты тулганны гына көтеп утыралар. Эш тәме белән ләззәтләнү һәр кешегә дә бирелми, күрәсең.

– Дебора Феликсовна, сез бит Пласидо Домингоны яратасыз?!. Онытa да язганмын, кичә миңа аның концертына ике билет китергәннәр иде. Ул бүген Кремль сараенда җырлый. Башланырга кырык минут вакыт калды. Өлгерерсезме?

– Унбиш минутлык юл, – диде Дебора Феликсовна. – Концертка махсус киенеп-ясанып йөрү бетте бит хәзер. Концерт башланганчы, әле мин кичке ашны ашарга да өлгерәм.

***

Офисында берүзе калгач, Владлен Монте-Карлога шалтыратты:

– Кәефләр ничек, чибәркәем?

– Менә синең янына кайтырга җыенам. Иртәгә самолётка билет китерәчәкләр.

– Машина белән генә кайт. Анда минем иң яраткан машинам «Бентли» тутыгып ята. Рульгә Жораны утыртсаң, ике тәүлектән кайтып та җитәсез. Сорарга онытканмын. Минем бәләкәчем анда ниләр майтара?

– Яраткан кызың иртәнгә кадәр төнге клубларда күңел ачып йөри дә көндез йоклый. Караңгы төшкәч, тагын чыгып китәчәк. Мин аны күрмим дә диярлек.

– Ярар, син аңа ачуланма инде. Кияүгә чыкканчы йөреп калсын. Бала тапкач, күңел ачарга вакыты бик калмас.

– Кияүгә чыгу турында уйлап та карамый. Инде мин аның гаилә кора алуына да ышанмыйм.

– Корыр, кайгырма. Мин аңа менә дигән япь-яшь олигарх табып бирермен. Мин яккан майлы ипине ашап ятучы ничә дистә егет бар монда. Әйдә, йөреп калсын, син аңа тел тидермә.

– Игорь да мин шалтыратсам гына сөйләшеп ала. Ул да синең шикелле үк кораблары өчен генә яши. Монда мин бер ялгыз. Сөйләшер кешем дә юк.

Лебедевның беренче хатыныннан туган өлкән улы Игорь Лондонда «Океан юллары» компаниясенең филиалын җитәкли иде. Әтисенең эшен тулысынча үз кулына алуны Игорь зур түземсезлек белән көтә, җае чыккан саен, шуны якынайтырга төрле чараларын да күреп тора иде.

– Оксюша, синең яшьлек мәхәббәтеңнең диңгезгә чыгаруны сорап миңа ялынуын әйткән идем. Аның исемен ишеткәч, синең пульсың туктамагандыр бит? Мин аңа, синең исемеңне йөрткән корабыма утыртып, круизга чыгарга вәгъдә бирдем. Киоскта газета-журналлар сатачак. Стукач булып, экипаждагы вакыйгаларны миңа җиткерүне дә өстенә алды. Бүгенге көндә кем пенсиянең кысыр акчасына яши алсын инде? Ул, мескен, корабның гальюннарын[3] юарга кушсам да риза иде. Андый эшне кушмадым инде. Сине кызгандым. Мин аны син кайткан көнне Юсупов сарае янындагы коттеджга кунакка чакырдым. Килергә вәгъдә бирде. Туйганчы сөйләшерсез. Аның исеме ничек әле? Бергә эшләгәндә дә хәтерли алмый идем. Каян таба алар телеңне сындырырлык ямьсез исемне?!

Берничә минут Оксана дәшми торды.

– Нигә шатлыгыңны уртаклашмыйсың? Әллә шатланудан телеңне йотып җибәрдеңме? Әйт, канәгатьме син Рахманкуловны кунакка чакыруыма?

– Инде бит никадәр вакыт үтте. Без тәмам картайдык. Ул да картаеп беткәндер? Аны ни өчен кунакка чакыруыңны мин яхшы аңлыйм. Менә синең яшь чакта сөйгән егетең! Нинди карт, нинди ябык, бөкрәеп беткән. Круизга билет алырга да акчасы юк. Ялынып миңа килгән. Шуларны күрсәтеп, дәрәҗәсен төшерер өчен генә чакыргансың бит син аны. Мин бит аны кунакка чакыр, дип синнән сорамадым. Беләм, син, Влад, инде менә ничә ел аннан көнләшүдән тыела алмыйсың.

[3] Гальюн – кораб бәдрәфе.

– Ярый, җитәр. Бу сүзләреңне син хахалең каршында әйтерсең. Бывай! «Бентли»га утырып кайт. Туган авылыңа да кереп чыгарсың. Чистые Криницы юл өстендә бит.

Алар, саубуллашмыйча гына, сөйләшүдән туктадылар.

**2**

Оксана Монте-Карлода инде тугыз ел яши иде. Ул торган вилланың икенче каты тулысынча Оксана карамагында. Беренче катта бакча караучы, аш пешерүче, шофёр яши. Лебедевның коттеджы иң кыйммәтлеләрдән түгел. Әнә өстәрәк, тау битендә, Рәсәйнең беренче президентының кызы белән кияве яши. Ул вилланы унтугызынчы гасырның урталарында мәшһүр Британия лорды салдырткан булган.

Оксана тәрәзәдән карады. Аның йокы бүлмәсе каршында гына бакчачылык фәненең иң югары казанышларын кулланып, назлап үстерелгән роза куаклары. Зәңгәр чынаяк плитка җәйгән сукмакborгаланып аска, капкага таба төшеп китә. Капка Һолливудның иң якты йолдызларын кино фестиваленә җыя торган сарайга таба каратып утыртылган. Капкадан чыгып, уңга борылсаң, пассажир лайнерлары туктый торган портка юлыгасың. Сулга борылсаң, миллионерларның тынгысыз акчаларын кесәләреннән бушатырга көйләнгән мәшһүр казино. Казинога янәшә, төн кунган өчен гади эшченең еллык эш хакын бер тәүлектә йотып җибәрә алган мәшһүр отельләр, төнге клублар, җенес кыбырсуын басар өчен, төрек солтаннарының серальләрен артта калдырган кәнизәк йортлары бар.

Эшенең ярты өлешен Лондонга күчергәнгә кадәр, Лебедев елның ярты өлешен диярлек монда яшәп ала иде. Кызлары Марианна Париждан күчеп килгәнче, ике елдан артык, сигез бүлмәле, бассейнлы, зур бакчалы виллада ул ялгызы яшәде. Әнисе исән чагында туган авылына кайткалап йөрде. Хәзер инде Мәскәүдән һәм Лондоннан тыш кайтыр җир дә юк.

Җәйнең эссе айларында һәм кышларын Оксана Монте-Карлода яши иде. Мәскәү янындагы мәшһүр Йосыпов сарае – Архангельск янындагы коттеджларына ул Яңа ел бәйрәмен каршыларга һәм, диңгез һавасы туйдырганнан соң, ылыс исен сагынган чакларында кайта. Шушы коттеджлардан тыш Лебедевнең Арбат тыкрыгында йортның өченче каты, ниһаять, Одессаның Аркадиясендә тыйнак кына ике катлы дачасы бар. СССР таркалганнан соң, башта биш, аннан соң җиде, ниһаять, утыз океан лайнеры, Алланың бер кодрәте белән, Владленның хосусый милкенә әверелде. Кораблар гизүеннән акча ясарга Владлен Кара диңгез пароходчылыгында өйрәнгән иде. Кораблар үзеңнеке булгач, акча ясау тагын да уңышлырак булып чыкты. Лондондагы һәм Сингапурдагы банкларына доллар елгасы агып керә башлады. Оксанага аның туган авылы Чистые Криницыда йорт салмакчы иде, хатыны каршы килде. Аңа бабасының бабасыннан калган, саман кирпеченнән салынган камыш түбәле хатадагы балачак оясы чиксез истәлекле һәм газиз иде. Балалары ул йортны өнәмәделәр. Владлен да бер тапкыр күреп кайтты да онытты.

Иренең байлыгы Оксанадан читтә кала килде. Яшәү шартларының уңайлы һәм рәхәт булуы аңа бернинди шатлык-куаныч китерми иде. Әйе, ул күп миллион долларга төшкән коттеджларда яши, әмма никадәр тырышып караса да, аларны үзенеке итеп күз алдына китерә алмый иде. Кайчакларда студент елларындагы туңдырма тәме, студент ашханәсенең кәбестә шулпасы искә төшеп сагындырып ала. Әмма Оксананың мул сулы тирән елга шикелле тыныч яшәеше үзгәрешсез һәм куанычсыз ага бирә иде.

Ә менә бүген... Оксана бу исемне оныттым, инде күптән тынычландым, аның белән очрашсам да, бернинди дулкынлану, югалып калу булмас, дип инанып беткән иде. Иренең авызыннан ишетелгән шул таныш исем көтмәгәндә бәгырен әрнетте, шул әрнү аша тынгысыз рәхәтлек йөрәгенә килеп кадалды. Тамакка ачы төер килеп утырды һәм, бер сәбәпсез, бәгырьләрне көйдереп, Владленга ачу килү, рәнҗү китереп бәрде. Иренең хәйләкәрлеген, акыллы, культуралы, үзен-үзе тота белүе аны һәрчак коткарып килүен Оксана бергә яши башлагач кына аңлый алды. Бу юлы да Рахманкуловның исемен искә алуы, син кайткач, мин аны кунакка чакырам, дип әйтүе Оксанадан: «Юк, чакырма. Минем аны күрәсем килми», – дип әйттерер өчен генә кузгатылган сүз иде. Хатынының: «Әйдә, чакыр!» – дип җавап бирүен һич көтмәгән иде ул. Бәлки, Оксанага «чакырма», дип әйтергә кирәк булгандыр? Бу очракта гаиләнең җайга салынган, тыныч, ышанычлы агымына Рахманкуловның исеме килеп кереп, хисләр киеренкелеге тудырмас, нервыларны бозып ташламас та иде.

Уйлый торгач, Оксана, юк, мин дөрес эшләдем, үкенергә кирәкми, дигән фикергә килде. Владленның баеп китүен, җәмгыятьтә яулаган урыны белән мактанасы килүен Рахманкуловка белгертәсе килә иде аның. Рәсәйдә пенсионерлар ачлы-туклы, кимсетелеп яши. Бәлки, Габдрахман да хәзер шул хәлдәдер. Владленның: «Кыз чагында син менә нинди кешеләр белән йөргәнсең», – дип, астыртын гына мыскыллап аласы килгәндер. Оксана бүлмәдә йөрүеннән туктап, көзге каршына барып басты. Кырау төшеп, соргылт төс кергән, дулкынланып торган куе чәч. Кызы Марианна әнисенең чәчен буятырга ничә тапкыр кыстап карады. Ул бит беркем белән аралашмыйча, бикләнеп яши. Юк, Оксана чәчен буятмаячак. Хәтта макияж ясатып, төсен дә үзгәртмәячәк. Күз кырыйларын, авыз читен, ияк астын каплый башлаган җыерчыкларын да тигезләтмәячәк. Аның карасу зәңгәр күзләре һич тә үзгәрмәгән. Керфекләре дә кыскармаган, сыекланмаган. Буй-сыны да кыз чагындагыча диярлек. Оксана атнасына ике тапкыр фитнеска йөри, ел әйләнәсенә диңгездә су коена, йөзә, дайвинг[4] белән шөгыльләнә. Гәүдәсенең җыйнаклыгын саклар өчен генә түгел. Алар нәселендә бер генә юан хатын-кыз да юк. Гәүдәсенең зифалыгы токымнан. Элек гимнастик күнегүләр ясаганда, шулай иде. Хәзер йөзгәндә, тауларга менеп йөргәндә, Оксана һәрвакыт тән рәхәтлеге, мускул шатлыгы тоеп ләззәтләнә.

Әгәр очрашсалар, Габдрахман Оксанада Одессада яшәгән елларындагы мәхәббәте исән саклануын тоеп алачак. Нишләр икән ул, ниләр кичерер икән мине күргәч?..

Шушы уйларга чумып утырганда, асрау Оксананы кичке ашка чакырды. Оксана инде күптән балык ашы, яшелчә-җимеш белән генә туклана иде. Ул аскы катка төште. Өстәлгә Оксананың яраткан ризыкларын куйганнар. Ипи, бал, кыздырылган бәрәңге. Сөт өстендә томалап пешерелгән йөзем әкәмтөкәме. Өстәл уртасындагы зур фарфор тәлинкәдә парда пешкән форель балыгы, аның тирә-ягына диңгез үсемлекләре тезелгән. Шунда ук диңгез керпесе уылдыгы, кальмар, устрица, европалыларның иң яраткан ризыгы – диңгез кысласы – омар да бар. Аны Урта диңгездә генә тота алалар. Диңгез ризыкларының тәме ачыграк сизелсен өчен, араларына вак, хуш исле лимон туралган.

Оксана, минераль су кушып, ярты стакан «Шато-икем» шәрабе эчте. Бер телем ипигә бал ягып ашады да ярты стакан минераль су белән иртәнге ашын тәмамлап куйды.

[4] Дайвинг (*ингл.*) – су астында йөзү.

Ул әле һаман үзенең беренче мәхәббәте турында уйлана иде. Инде күпме еллар үткән, югыйсә. Ничә еллар аны оныттым дип ышанып йөрде. Мәхәббәткә хыянәт итеп, сөйгәнен ташлаган, башкага өйләнгән егеткә тугрылык сакла, имеш... Бу бит горурлыкны югалту, үзеңне санга сукмау, түбәнчелек дигән сүз. Оксана һаман әле егетнең исемен җиңел генә әйтә алмый иде. Аңа кияүгә чыккан булса, иренең һәм үзенең бер тапкыр ресторанга кереп ашап чыгарга да җитмәгән пенсиясенең мескен акчасына, теләкләреннән баш тартып, ачлы-туклы, иске-москы киеп яшәмәс идеме?.. Андый тормышта, билгеле, Ауропаның гына түгел, дөньяның иң күренекле, иң бай кешеләре генә урнаша алган Монте-Карло Оксананың төшенә дә кермәс иде. Әйе, ул элек йөргән егетен күрәсе килүен иренә сиздерде. Мондый чакларда, әлбәттә, Владлен тавыш куптармый, хәтта канәгатьсезлеген дә белгертми. Шул ук вакытта Оксана иренең һәрнәрсәгә, хәтта хатынының тойгыларына да хуҗа булырга тырышып яшәгәнлеген яхшы белә.

Өйләнешкән елларны Владленның хатынын иң кыйммәтле мал итеп башка ирләрдән теш-тырнагы белән сакларга тырышуы ачыктан-ачык сизелеп тора иде. Башта Оксана моны аңлый алмаган булып кыланды. Иренең табигате шундый: Җир йөзендәге һәр кыйммәт торган нәрсә аныкы булырга тиеш. Әгәр иң кыйммәт, иң затлы нәрсәне аңа бирергә теләмәсәләр, ул җаен табып, барыбер тартып алачак. Оксана иренең бизнесына бәйле кешеләргә күрсәтеп мактаныр өчен тотылган затлы бер брэнд булып яшәде. Затлы нәрсәне саклыйлар, кадерен беләләр. Владлен да хатынының кадерен белде. Оксана теләкләренең һәммәсе үтәлеп килде. Бары бер теләк тормышка ашырылмады, бу – яратышу. Аларның затлы, күркәм мөнәсәбәтләрендә мәхәббәткә урын юк иде. Бәлки, кайчандыр мәхәббәтнең нәрсә икәнлеген ул аңлагандыр да... әмма Владленның хәзерге вакыты, көче, хәтта тойгылары бизнеска тотылып бетә, шунлыктан мәхәббәткә теләк тә, дәрт тә, вакыт та калмый. Оксана картая башлады. Владленны яшьрәкләрне, кайнарракларны эзләргә мәҗбүр итте. Инде Оксанага бәя түләнгән. Затлы ашау-эчү, затлы торак, иң данлыклы кутюрье теккән затлы элитар кием. Лебедевның хатыны хәзер инде коллегаларына горурланып күрсәтерлек түгел иде. Яшьрәк чакта Оксана өстендә нәкъ шул вазифа иде бит.

**3**

Ял җитте. Лебедев, кая барырга белмичә, ялгызы кабинетында утыра. Ярата иде ул офистагы кабинетын! Диварларда эре масштаблы кыйммәтле карталар. Владлен аларны, заказ биреп, Лондоннан эшләтеп кайтартты. Диңгезчелек тарихында җуелмаслык эз калдырган «Олимпик», «Титаник», «Нормандия», «Куин Мери», «Андреа Дорио», «Канберра», «Котти Сарк», «Фермонилы», «Лейтнинг» кебек җилкәнле корабларның, тарихка кереп калган лайнерларның затлы сурәтләре. Түр диварда буйдан-буйга шул ук Лондоннан кайтарткан, палисандр агачыннан ясалган шкафлар. Урта шкафның бары тик Владлен гына белгән бер сере бар иде. Тотка астындагы бер сәдәф-кнопкага бассаң, шкаф ишеккә әверелә дә электромотор ярдәмендә акрын гына ачыла башлый. Яшерен бүлмәгә керергә юл әзер. Ул бүлмәдә ике зур суыткычта төрле илләрдән, төрле диңгезләрдән кайтарткан диңгез деликатеслары. Европа илләреннән, Япониядән китертелгән экзотик ашамлыклар һәм иң затлы, иң кыйммәтле эчемлекләр. Бүлмәнең ишеге Владленга кирәкле эшмәкәрләргә, дәүләт түрәләренә һәм иң чибәр хатын-кызга гына ачыла иде. Туксанынчы

елларда Лебедев оештырган компания эшли генә башлаган чорда шкаф-ишек шактый еш ачыла иде. Затлы эчемлекләр дә, деликатеслар да атна саен яңарып тора иде. Соңгы елларда кыйммәтле кәеф-сафа кору аны әллә маемлаттымы, әллә картая башлаган тән бу татлы гөнаһны, тәмле тукلануны күтәрә алмый башладымы, инде ул кирәкле кунакларны аена, күп дигәндә, ике-өч кенә тапкыр сыйлау белән чикләнеп яши башлады. Бәлки, бүген дә төнге клубта, элита гына җыела торган банкет-мазарда танышкан берәр озын ботлы чибәрне чакырып, күңел юшкынын кырып, юып ташларга кирәктер? Тик менә теләк бик сүлпән. Ни булды Владленга?! Әллә инде ул көнләшә дә белми башладымы? Шул яшерен бүлмә ләззәтләреннән тыш, Владлен Семёнович үзеннән утыз яшькә яшьрәк горлефрэнд белән даими төн куна иде. Ул аңа Патриаршие Пруды дигән ымсындыргыч урында ике бүлмәле фатир булдырды. Мәскәүгә ГИТИСка укырга килгән җиреннән башкалада калган Светлана – Кубань кызы иде. Владленның Светланадан туган кызына инде алтынчы яшь. Диңгез суы сусауны басмый. Аны эчкән саен эчәсе килү көчәя генә бара. Чибәр хатын-кыз да шулай. Аларның саны күбәйгән саен, күбәйтәсе килү арта, көчәя генә тора.

Аның тагын бер мавыгуы – чакыру белән килеп җитә торган иң затлы кәеф-сафа күбәләкләренең телефоннары ноутбукка язылган. Кнопкага басып, Владлен барлык исемнәрне укып чыкты. Ни гаҗәп, шуларның берсен генә дә чакырасы килмәде. Йөрәк әрнүен баса алырлык яңа мавыгу, яңа объект кирәк иде. Төнге клубка барып, нечкә билле, зур, авыр күкрәкле, мендәр арт санлы берәр кызны үзенең әле яңа салдырткан буш квартирына алып кайтып, бәлки, Оксанадан үч алырга кирәктер? Ике балалы хатынын ташлап, Оксанага өйләнүенә ике елдан утыз ел тула. Утыз ел эчендә үзенең яшьлек мәхәббәте – хәерче татаринын һаман онытмаган, стерва! Шушы еллар эчендә, димәк, аның тәне генә минеке булган. Хурлык! Аерылганыннан тыш, Оксана аның никахсыз хатыннары барлыгын да, атнасына ике-өч тапкыр төнге клубтан төн кунарга бия алып кайтып йөрүен дә яхшы белә иде. Бер генә тапкыр көнләшеп гауга куптарсын икән! Паспортындагы мөһере аның Владлен хатыны булуын расласа, йөрәгендә исә һаман шул татарның җан сөйгәне булуын дәвам иткән. Ни өчен Оксанадан туган кызы әтисен яратмый икән, дип баш вата иде Владлен, аның сәбәбе менә кайда икән! Көмәнле чакта ул, һичшиксез, шул татарин турында уйлап, шуны сагынып яшәгән. Шул эчке, рухи омтылыш Владленның Оксанадан туган кызына да күчкән булса кирәк. Кыз әнисен үлеп ярата. Америкада яшәүче өч балалы Лиза, Англиядә эшләүче Игорь да Оксана өчен утка-суга керергә әзерләр...

Офисында ялгыз утырганда, ул Одессадагы «порт киленнәре»н, Мәскәүнең «төнге күбәләкләр»ен исенә төшерде. Алар Владленны аңлый ичмасам. Юкка гына аларны кимсетәләр. Чагыштырып карасаң, төнге клубларга йөрүче мең доллардлык стерваларга караганда, «төнге күбәләкләр» аңа якынрак та тоела иде. Аларны ачка үлү куркынычы урам чатына чыгара, шуңа күрә аларда шоу-бизнес стерваларындагы борын чөю, үзләрен әллә кемгә куеп шапырыну юк. Тәкәбберлек тә юк аларда, чөнки аларны сутенёрлар җәберли, милиция җаннарын ала. Кемгә генә өлеш чыгармыйлар, мескеннәр.

«Төнге күбәләкләр» белән елдан артык эш иткәне юк иде Лебедевның. Таушалып бетмәгән яшьрәкләре кайсы урынга җыела икән? Чынбарлык үзгәреп тора, туктаусыз, сиздермичә генә. Түләүле җәриәләрнең генә клиент эләктерә торган урыннары үзгәрми диярлек, озак еллар буена алар гел үз урынында. Владлен Мәскәүгә күчеп килгән елны скульптор Кербель Зур театр

мәйданы каршына «Метрополь» белән «Мәскәү» кунакханәләре арасына мәрмәр таштан Маркcның бюстын ясап куйды. Озак та үтмәде шул һәйкәл каршына «төнге күбәләкләр» җыела башлады. Студент халкы аларны шундук «марксисткалар» дип йөртә башлады. «Марксисткалар»дан тыш аларның иң кайнарлары «Националь» кунакханәсенең баскычы каршындагы тротуарга җыела иде. «Төнге товар»ның иң арзанлылары исә Мәскәүнең өч вокзалы арасындагы Комсомол мәйданына туплана.

**4**

Владлен офисыннан чыкты. Аның «Мерседес»ы тротуарда. Машинаны милиционер саклый. «Мерседес» Герцен урамыннан Манеж мәйданына юнәлде. Каршыда – «Мәскәү» кунакханәсе. Шуңа җитәрәк, ул, сулга борылып, Тверская урамына китте дә, машина тәрәзәсеннән күзәтеп, «күбәләкләр» җыела торган урынны эзли башлады. Пушкин мәйданына җитәрәк, тротуарда тыгыз иңбашларын уйнатып дүрт-биш яшь кыз йөри иде. Алар ашыкмыйча гына Кызыл мәйданга таба баралар. Лебедев, тыкрыкка кереп, машинасын кире якка борды һәм әкрен генә алар артыннан бара башлады. Үзәк телеграф янына җиткәч, кызлар бераз туктап тордылар да киредә борылдылар. Монда аның игътибарын тартырлык «күбәләк» күренми. Чиктән тыш тупас, шактый таушалган кыяфәтле иде болар. «Националь» бинасы каршында Владлен ярты сәгатькә якын машина тәрәзәсеннән күзәтеп утырды. Тротуарда гел күңелгә ятмаган шыксызлары гына йөри иде. Инде китәргә җыенып торганда гына, аның машинасы турыннан урамның теге ягына бер брюнетка уза башлады. Бусы кулдан кулга йөрмәгәнгә охшаган. «Свежак, – диде Владлен эченнән. – Тотып карарга кирәк...»

Машинасын бикләп, Владлен тротуарга төште дә җир асты тоннеленнан урамның каршы ягына йөгерә-атлый бара башлады. Ул өскә чыкканда, кыз аның каршысында иде инде.

– Һава сулап йөрүме? – диде Владлен.

Җавап бирер алдыннан кыз Лебедевка күз йөгертеп чыкты.

– Ә сезгә нәрсә кирәк? – диде кыз һәм, сизелер-сизелмәс кенә, тәнен уйнатып алды.

– Миңа сез бирә алган байлык кирәк, – диде Лебедев.

– Квартир мәсьәләсе ничек?

– Бар ул бездә тукталыр җир. Күпме сорыйсыз?

Кыз Владленның киеменә, битенә, гәүдәсенә күз йөгертеп алды да ике бармагын тырпайтып күрсәтте:

– Яшелдән.

Ике йөз доллар дип уйлады Лебедев. Димәк, минем «Мерседес»тан чыкканны күреп торган. Ә болай товарның хакы илле доллардан артык түгел иде. Билгеле, бу очракта сатулашырга ярамый. Сатулашу Лебедевның дәрәҗәсен төшерәчәк иде.

– Килештек, – диде ул, һәм кызның шул мизгелдә урамның теге ягындагы иргә ымлавын тотып алды. Владленның машинасы янында битен тәк баскан, горилланы хәтерләткән егет аларның сөйләшкәнен күзәтеп тора иде. «Крыша», – дип уйлады Владлен. Бу өлкәдә дә бит менеджмент идарә итә. Сутенёр «төнге күбәләкләр»не хулиганнардан, параноиклардан саклый, керемнең яртысын кесәсенә салып тора. Сутенёрдан тыш һәр урынның «күбәләкләр»дән ришвәт сава торган милиционеры да була. Кайбер «күбәләкләр» милиционерларга

акчалата бирмичә, үз хәзинәләреннән өлеш чыгара. Бу өлкә Владленга яхшы мәгълүм иде.

Лебедев, машинасының ишеген ачып, кызны алгы утыргычка урнаштырды да урыныннан кузгалды. Владлен мондый очрашулар өчен махсус әзерләп куелган ике бүлмәле фатирына юл тотты. Анда беркем дә яшәми. Атнасына бер тапкыр җыештырып китәләр дә, калган вакытта квартира буш тора. Мондый бәясе туктаусыз төшеп торган «агач» акчалы торак бәясен капларга Лебедевның елдан-ел бәясе күтәрелгән йортлары, аерым фатирлары бар иде.

### 5

«Күбәләк» йорт җиһазларын дикъкать белән карап чыкты:

– Круто! – диде ул, тәнен уйнатып. – Монда һәр җиһазның хакы бер күтәрәм. Диван-караваты нинди! Мондый караватны мин Тверская урамындагы комиссион кибеттә генә күргәнем бар иде. Ә хатының кайда? Диңгез буена ялга озаттыңмыни?

– Әйдә, сөйләшергә күңеллерәк тема табыйк әле. Мин хәзер табын әзерлим. Ә син ваннага кереп юынып чык. Анда спринцовка һәм махсус дару бар. Тәнең ял итсен. Андагы халатны киеп чык.

«Төнге күбәләк», кыстатып тормыйча, ваннага кереп бикләнде. Сумкасын үзе белән алды. Аның бу кыланышы Лебедевка көлке тоелды. Күз сирпеп карау белән, кыз аның нинди дәрәҗәдәге кеше икәнлеген чамалый алган иде бит инде югыйсә. Ә үзе, ахмак, сумкасын калдырырга шикләнә. Бизнесы аны шуңа өйрәткәндер, күрәсең?..

Кыз юынып чыкканда, табын әзер иде. Суыткычта «Һеннеси» коньягы, «Баллонтин» виские, кыйммәтле башка шәрабләр дә бар иде. Әгәр кәнизәк ризасызлык белдерә башласа, вакланып тормыйча, аңа иң затлы – мең долларга төшкән шешәне ачарга да әзер иде ул. Владлен өстәлгә тәм-томның затлысын, кызыл һәм кара балык уылдыгын куйды, кальма консервасын ачты, сервилат казылыгы турады. Банкир Рөстәм Тарика чыгара торган иң затлы аракы – «Русский стандарт» өстәл уртасына килеп утыргач, шешәне тышкы яктан тир бөртекләре каплады. Эчеп җибәргәч кабар өчен «боржоми», «тоник», «кока-кола» куйды.

– Мондый зур хөрмәт безгә сирәк эләгә, – дип, «күбәләк» аны мактап алды, янына ук сырышып, диванга утырды.

– Танышу хөрмәтенә, – диде Лебедев. – Мин – Аркадий Мартынович. Синең исемең ничек?

– Жанна, – диде кыз, хрусталь рюмкадагы аракыга комсызлык белән күз ташлап. – Отчеством юк әле, чөнки мин кияүгә чыкмаган.

«Ничек инде этиеңнең исеме юк? Җилдән тумагансыңдыр бит?» – дип сораудан Лебедев көчкә тыелып калды.

Чәкештереп эчеп җибәрделәр. Кыз чәркәсен корытып куйды да, кыргый бер омтылыш белән, балык уылдыгын, сёмганы авызына тутырырга кереште.

– Икенчене, гадәттә, эти-әни хөрмәтенә эчәләр, – дип аңлатты Владлен. – Синең эти-әниең исәннәрме?

– Кем белгән инде. Әти әнине мин туганчы ук ташлап киткән. Әнине наркотик белән сәүдә итә, дип, төрмәгә утырткач, мин приютта үстем. Эти-әнисез яшәү, аңлый торгансыздыр, чиктән тыш авыр – һәр подонок сине кулланырга тырыша.

– Шулай да бу рюмканы әти-әни хөрмәтенә күтәрик, – диде Лебедев. «Күбәләк» кабат чәркәсенең төбен корытып куйды.

– Миңа җитте, сиңа да туктарга кирәктер, – диде Лебедев, аракы шешәсен суыткычка яшереп. – Ә закусканы ашап бетерергә кирәк. Суыткычтан бер чыгаргач, кире куйсаң, аның тәме бетә.

Кызның комсызлыгын яшерергә көче җитми иде. Озак ач торганмы, әллә мондый ризыклар аңа чиктән тыш тансык булгангамы, өстәлдәгеләрне ул бик тиз сыпыртып ташлады.

Савыт-сабаны кухняга илтеп, кран астына куйгач, Владлен урын әзерләргә кереште. Мендәрләр, җәймәләр, юрган җәелеп бетү белән, кыз халатын салып ыргытты да юрган астына чумды.

**6**

Лебедев шактый гына хәлсезләнгән иде. «Күбәләк» исә капылт кына китәргә җыена башлады. Эш кешесе бит, ашыга. Акчаны күбрәк төшерәсе килә торгандыр...

– Минем иптәш кызым белән очрашасым бар, – диде ул. – Вәгъдә бирмәгән булсам, моннан һич тә китмәс идем. Монда рәхәт, монда бит оҗмах шартлары.

Әйтмәсә дә, кыз Лебедевтан тиешле акчаны тизрәк алырга тырыша иде. «Эш» хакын аласы килүгә астыртын курку, мәкергә юлыгудан шөлләү дә кушылган иде. Лебедев җарияне кызгангандай итеп куйды. Өметләнгән акчаны ала алмыйча, җәбер-мәсхәрә татыган чаклары күп булган, күрәсең.

– Синнән сорыйсым килә, – диде Владлен. – Әгәр мин синең чамадагы яшь егет булсам, сиңа өйләнәсем килсә, миңа чыгар идеңме? Чыксаң, син минем тәнемне генә яратыр идеңме?

Сорауның мәгънәсен «төнге күбәләк» аңлап җиткерә алмады. Бу сорау аңа артык катлаулы тоелды.

– Син әле дә ябь-яшь, матур, чын-чыннан Аполлон кебек. Мин сине шушы яшеңдә дә үлеп яратам. Күрсәттем бит яратуымны. Аңламадыңмыни?

– Киресенчә, син минем соравымны аңламадың, – диде Владлен Семёнович. – Мин менә утыз ел чамасы бер хатын белән торам. Яратып өйләндем. Чынярату белән. Мин аны өрмәгән җиргә утыртмадым, аның күңелен күрер өчен, миллионнарны кызганып тормадым. Менә шушы көннәрдә генә аңлашылды: ул мине тыштан гына, минем тәнемне, җәмгыятьтәге урынымны, байлыгымны гына яраткан булган. Җаны исә миңа кадәр йөргән егете белән яшәгән. Мин сиңа өйләнгән булсам, син дә тәнең белән генә яратыр идеңме? Җаның, күңелең, хыялларың башка егеттә калыр идеме?

– Мин менә әле дә сине җаным-бәгырем белән яратам. Әгәр без ир белән хатын булып яшәсәк, мин синең аягыңны юган суны да яратып эчәр идем.

Ялганны дөреслектән аеруы чиктән тыш авыр шул. Владлен аның сүзләренә ышанмады. Тәнен сатып тамак туйдыручы, тойгыларын акча түләүчегә өләшеп йөргән кызга ничек ышанып бетмәк кирәк. Шул ук вакытта чибәр кызның әлеге сүзләре аңа ошый да иде. Аның үзеннән утыз яшькә яшьрәк никахсыз хатыны да «төнге күбәләк»нең фикерләрен гел кабатлап тора. Ул да Владленга җанын гына түгел, кирәк икән, газиз гомерен бирергә әзер. Оксана исә... Хәләл җефете исенә төшү белән, Лебедевнең кәефе кырылды. Нишләп соң ул Оксананы хатынын аерып, аңа өйләнгәнче үк аңлый алмаган?.. Бер кыз бала тәрбияләп үстереп биргән, бүген-иртәгә Газраил килгәнен көтеп яшәүче карчыгыңны

ташлап китеп булмый бит инде. Калган гомер дә аның ире статусында үтәргә язгандыр, күрәсең...

«Төнге күбәләк», ванна бүлмәсенә кереп, чәчен рәткә китерде. Иренен буяды, чыккач, күз карашын диван-кроватенда чалкан яткан Владленга текәде.

– Кием шкафын ач әле, – диде Лебедев.

Кыз шкафны ачты.

– Ачтым, – диде ул. – Тагын нишләргә?

Ул Лебедевның пиджәген тотып тора иде.

– О,кей, – диде Владлен. – Пиджәкнең түш кесәсендә минем партмоне. Ал шуны. Алдыңмы?

– Алдым.

– Ач хәзер. Ачтыңмы? Аның бер бүлегендә яшел йөзлекләр. Санап ал эш хакыңны.

Кыз ике йөз долларлык купюраны алганнан соң, Владленга боек кына күз ташлады.

– Ал тагын берне. Берсе синең матурлыгың өчен. Икенчесе акыллы булганың өчен. Өченчесе исә миңа җаныңны бирергә торганың өчен. Пиджәкне урынына эл.

«Төнге күбәләк»не кулын кабат кесәгә тыгасы килү теләге дер селкетә иде. Ул көч-хәл белән булса да тыела алды.

– Хәзер саубуллашыйк.

«Күбәләк», иелеп, Лебедевне кочагына алды да ирененнән суырып үпте, аның изүен ычкындырырга кереште.

– Юк, җитте. Рәхмәт, – диде Владлен.

– Өстәлеңдә телефон номерын калдырам. Исеңә төшереп, миңа шалтыратсаң, биш минуттан янында булырмын. Мин бит сине җаным-тәнем белән яратам. Их, минем шундый ирем булса!..

«Төнге күбәләк» елап җибәрде. Үзе елый, үзе күзләре белән бүлмәдәге әйберләрне капшый иде. Төп эшеннән тыш ул фатир басучыларга информация да җыя иде, күрәсең. Тик Лебедев бу квартирасында суыткычтагы затлы ашамлык-эчемлектән, ванна бүлмәсендәге юыну-чистарыну әсбаплары һәм диван-караваттагы сөлге-җәймәләрдән, стенадагы шәрә хатыннар сурәтеннән тыш урларга ярарлык әйбер тотмый иде.

## 7

### Эпилог урынына

– Күрше, чык әле, сүзем бар.

Габдрахман Рахманкулов көзге сарымсак утыртырга тотәл әзерли, күршесе Евгений Моисеевич Резник койма аша аны урамга чакыра иде.

– Үзең кер. Нигә куркасың?

– Куркудан түгел, көрәгең кулыңда бит. Көрәк кулыңда чакта син сөйләшү сәләтен югалтасың.

– Тагын диңгезгә чыгарга җыенасыңмы әллә? Син бит мине круиз алдыннан гына исеңә төшерәсең.

– Киңәшең кирәк. Бу юлы мине «Комсомольская правда» Татарстанга җибәрә. Шәймиев турында очерк язарга.

– Круиздагы язмаңны миңа күрсәтмәдең бит. Мин көткән идем. Күргәннәреңне дә кереп сөйләмәдең.

– Барып чыкмады ла ул круиз. Әйткән идем бит, круизга Лебедев җибәрә,

дип. Диңгезгә чыгар алдыннан гына Владлен Семёнович үзе югалды. Бераздан ишеттем, салым түләмәгән өчен җавапка тарттыра башлагач, Лондонга качып киткән. Хәзер шунда яши, диләр. Дәүләткә бирми калдырган миллиардка якын бурычы җыелган, ди. Качып китмәгән булса, төрмәгә тыгасылар икән. Аны әле дә эзәрлеклиләр, ди. Хәзер инде Лубянканың кулы җитмәячәк – Британия гражданлыгы алган.

– Офисы монда калганмы соң? Мин аңа атна буе шалтыраттым. Трубкасын алмый.

– Аның офисы да Лондонда.

– Миллионнары да шундадыр инде?!

– Билгеле. Инглизләр әйтәләр бит: йомыркаларның барысын да бер кәрзиндә тотмыйлар, дип. Аның акцияләре йөзләгән банкларда акча эшләп ята торгандыр әле.

Ниһаять, Рахманкулов төшенде: Лебедевка ул юкка рәнҗегән икән.

– Ул бит мине Архангельскидагы князь Йосыпов утары янындагы коттеджына кунакка чакырган иде. «Хатыным Монте-Карлодан кайта. Оксананың синең белән очрашасы килә, көтеп тор, машина җибәрәм», – дип вәгъдә биргән иде. Мин, ахмак, шуңа ышандым. Көне буе көтеп утырдым. Машина килмәгәч, офисына шалтыратып карадым. Телефонны алучы булмады.

– Син Лебедевның хатыны белән таныш идеңмени?

– Яхшы белә идем. Оксана заманында нәфис гимнастика буенча Одессаның чемпионы иде. Шуңа өстәп, ул шәһәрнең иң беренче чибәре дә иде.

– Лебедевның хатыны Мәскәүгә кайткан чакта автокатастрофага юлыккан. Әллә ничә газета язып чыкты бит, укымадыңмыни?

– Ничек алай?.. Мин бит сары прессаны укымыйм, аларның телләре ят миңа. Күңелне болгатырлык итеп яза ул газеталар.

Резник, җил капкасын ачып, эчкә керде дә Рахманкуловның колагына пышылдады:

– Автокатастрофаны Владлен Семёнович үзе оештырган, дигән версия дә бар. Югыйсә, мин үзем ышанып җитмим җитүен... Хатыны комачаулаган, имеш... Халык ярым ач, ярым ялангач яшәгәндә, миллионнарны кыйммәтле сөяркәләр белән туздырып йөрү зур гөнаһ, дип... Лебедевның исә Мәскәүдәге эстрада йолдызлары белән боткасы пешә иде... дип сөйлиләр.

***

Оксананың вафат булу хәбәре Габдрахман аңына тетрәнүле кичерешләр дулкыны кузгаткан олы югалту булып килеп керде. Бер уйлаганда, бу хәлнең чынлыгына әле ул ахыргача ышанып та бетми иде кебек, шул ук вакытта эчтә – бәгырь тирәнлегендә, җанны өшетеп, Габдрахман кинәт үзе өчен гаять мөһим булган бер яшәү тамырының төптән шартлап өзелгәнен ачык тойды. Бәлки, күңеле сизгән булгандыр мәрхүмәнең. Бу хакта уйлау Рахманкуловка бүген икеләтә авыр иде. Аны күрергә дип әнә бит ул ничек ашкынган иде! Соңгы көннәрендә дә аның Ак Санәсе шулай матур идеме икән? Әйе, Лебедев аны байлыкта, Монте-Карлодагы күп миллион долларга төшкән затлы сарайларда яшәтте. Киемнең дә иң затлысын кигәндер, ашамлыкның да иң тәмлесен ашагандыр «кыпчак кызы Ак Санә». Ә менә шул тышкы рәхәтлекләр аны бәхетле итә алдымы икән? Мөгаен, юктыр. Байлыкка да, данга да ымсынмый иде ул кыз. Оксана зур мәхәббәткә, саф сөю һәм сөелү бәхетенә омтыла иде. Кулга

тотып карап булмый бит ул бәхет дигән нәрсәне. Күреп тә булмый. Аны сатып алып та булмый.

Бирә алган булыр идеме икән Габдрахман ул чибәр кызга шул һәркемне ымсындырган тирән, олы кичерешләрне?

Ә соң үзе? Үзе бәхеткә ирешер идеме икән, әгәр ул кызга өйләнгән булса?..

– Син нәрсә? Әллә берәр җирең авыртамы? – диде Резник, Рахманкуловның җилкәсен кысып тотып. – Нигә җавап бирмисең?

– Нинди җавап?

– Саңгырауланмагансыңдыр бит? – Евгений Моисеевич иренен күршесенең колагына тери язып сорады. – Мин бит иртәгә Казанга китәм. Татарстандагы милләтара мөнәсәбәтләр турында язарга куштылар. Язгач, мин сиңа күрсәтермен. Татарстанда да җыйган материалны кемгәдер күрсәтеп, киңәш сорап алсаң, әйбәт булыр иде. Милли мәсьәлә чиктән тыш җитди нәрсә бит.

– Танышларым да, дусларым да күп. Әмма алар милли мәсьәләне үзләренчә күрәләр. Мәскәү исә аны бөтенләй башкача күрә... Анда Дамир Исхаков дигән бер галим бар. Аннан соң... Президентның киңәшчесе Рафаэль Хәкимов атлы галим. Миндә аларның телефоннары да, адреслары да юк. Тик Казанда, сорасаң, алар турында һәркем белә. Иң мөһиме – очеркны әзерләп бетергәч, аны миңа күрсәтергә онытма.

– Килештек алай булгач. Бәлки, аннан язылып беткән мәкалә дә алып кайтып булыр әле. Ярый, мин киттем.

Резник машинасына кереп утырды. Моторын кабызды. Ак «Ниссан» йомшак кына кузгалып китте дә, сулга, үзәк урамга борылып, күздән югалды.

Евгений Моисеевич китергән хәбәр моннан ике ай элек килеп чыккан фаҗига турында булса да, чынлыкта ул Габдрахманның үткән яшьлегенә дә, аның бүгенге тормышына, хәтта киләчәк көннәренә дә барып тоташкан мәңге төзәлмәслек яңа бер җан җәрәхәте иде.

Дөрес, гомеренең Одесса чоры аның өчен инде күптән бер матур һәм үкенечле төш-истәлеккә әйләнгән иде. Әмма ул Габдрахманның яшәешен гомер буе яктыртып торган олы бәйрәм балкышы булудан туктамаган иде.

Рахманкулов кулына көрәген алды, ашыгып түтәл казый башлады. Эшкә керешкәндә, татлы тоелган кул эшенең инде тәме дә, мәгънәсе дә калмаган иде кебек. Бакча хуҗасының хәзер тәне генә Истра сусаклагычы янындагы җирдә иде. Аның уй-хисләре, бөтен барлыгы әкияти җиңеллек белән Кара диңгез ярында, кырым татарларыннан тартып алган җиргә салынган көләч табигатьле хыялый шәһәрдә, күзгә күренми генә, өрәк булып очып йөри иде.

*2004-2014, 2017*



Данис
Хәйруллин

# БЕР ТӨЗЕГӘН ГОМЕР БУЕ ТӨЗЕР...

## «Гөлҗамал»

Күкрәкләрдән ташкын булып ташый,
Идел өсләреннән җыр ага.
Язмышыбыз һаман йөри әле
Ут тергезмәк булып чырага.

Урманнарга керсәм, урман шаулый,
Болыннарга чыксам, чык тама.
Тарихларга илтеп тоташтыра,
Моңнарына урый Гөлҗамал.

Җиде буын җыры җанны айкый,
Сагышларын сөйли халкына.
Канатланып китә алмый әле,
Язмыш әле һаман талпына.

Сызланма, җан, сулкылдама әле,
Мәңге тынмас, диеп, бу моңнар.
Арта гына барыр җырның көче,
Алмашынган саен буыннар.

## Дөньяның теге ягы...

Төннәр озын, шундый озын төннәр,
Тоташкандыр кебек теге якка.
Бу дөньяның теге ягын күрсәң...
Туганың күк булыр җиде ят та.

Данис ХӘЙРУЛЛИН (1945) – *шагыйрь; «Хәтер», «Йөрәк тибеше», «Казлар ник көлә?» исемле китаплар авторы. Чаллыда яши.*

Төннәр анда көнгә алышынмый,
Юллар анда җитмеш җиде чатлы.
Ул якларга барып эләксәңме –
Сагынып үләр идең җиде ятны.

Теге якның өйләреме ничек?
Юктыр анда тәрәз белән ишек.
Ай, кояшның анда исе дә юк,
Түрләрендә таз пәригә бишек.

Төннәр озын, шундый озын төннәр...
Алар өйдә һәрчак, без өйдә юк...
Теге якка берүк күз салмагыз –
«Тегеләр»дән башка берни дә юк!

## Мәңгелек

Ул – синдә,  ул – миндә
Сулкылдый җан булып, тән булып.
Гөлләрдәй шыта да ямь булып,
Сарыла сабыйга гамь булып.

Нигәдер керми ул төшләргә.
Сөт булып тама да түшләргә,
Исертә бу сабый дөньяны,
Бизәнеп мең төрле төсләргә.

Мәңгелек мәңгегә түгелдер
Калганда күзгә-күз, бергә-бер:
Нибары бер туу, бер яшәү;
Нибары өзелгән бер бәгырь.

## Моңсулану

И туганым, дәрт-дәрманың аман чакта
Нәүмиз җилне очратсаң да чык бер дога, –
Төпсез Вакыт коесына убылачак
Гомереңнең чыгыры да, чылбыры да.

Килер ул көн...
Кемдер калыр еламсырап,
Кемдер калыр агу чәчеп, елан сымак;
Үтәр еллар, тигезләнер калкулыгың,
Җилләр генә йөрер исеп, ямансулап.

## Нәрсәдән бу?

Сату – алу...
Бу кәсепкә шып тулганбыз.
Шуңамы соң, уптым гына сатылганбыз...
Акыл җыеп кайтмакка, дип, аңыбызга
Чоңгылларның чокырына атылганбыз.

Акның кара түгеллеген күрәбез без.
Бер алманы бишкә җиңел бүләбез без.
Бүленмәс сан бүленгәндә калдык калса,
Безне шуңа кушканнарын беләбез без...

Анда – артык, монда – кыска...
Кияү кызга
Ярашмаган кебегрәк, ахры, без дә.
Кырау төшә барамы соң аңыбызга –
Салмак кына әверелү бара бозга...

## Канун

Җимерелде!
Ишек тоткаларын,
Тәрәзләрен барлый кемсәләр.
Күрше-күлән, диләр, ымсынмасын,
Ишек аша керсен керсәләр.

Җимерелде!
Нигез исән әле,
Торгызырбыз, диләр, торбасын.
Ник аңламый алар торбаларның
Тырма сөяп кенә тормасын?

Җимерелде!
Торбаларда төтен –
Ут алумы, пыскып янумы?
Ник аңламый алар, маңгайларда
Ярылып ята тырма кануны!

## Зоопаркта

Зоопаркта яшәү  –  читлек, читлек, читлек!
Читлек артларында –  битлек, битлек, битлек...

Карышып кына кара –  җаны, тәне яра.
Өйрәсе дә өре кебек тора-бара...

Арысланга кара – нигә аңа тырнак?
Иң зур кыюлыгы алудыр бер ырлап.

Бүрегә ник азау, дөягә ник өркәч?
Шым калачак бар да, читлек эте өргәч.

Кырагайлык нигә, калҗа булгач итләч?
Юл юк монда. Сукмак – ул да киртләч-киртләч...

## Бер сүз

Коммунизм.
Кемнән чыккан сүздер,
Кайдан килеп кая киткәндер?
Тагын бер кат безнең искә төш тә
Тагын бер кат безне сискәндер!

Коммунизм.
Оҗмах исе килә...
Гомер буе тәмен сакладым.
Тырнакларны җиргә батырсам да,
Тамырларын өзеп атмадым.

Без шул чордан.
Безне аңлар өчен,
Безне алдар өчен сүз җитә.
Сүз күкләргә энҗе тезә бит ул,
Сүз кешенең җанын сүс итә!

## Ишек

Бүген бишектә син. Ә иртәгә
Ике кулың ике ишектә...
Икесен дә ачмак булырсың син,
Бик керәсең килеп ничек тә.

Берәрсендә булыр хәттин байлык,
Берәрсендә булыр ханбикә.
Андый чакта теләк кенә кала,
Андый чакта синнән аң китә...

Үтәр вакыт. Үтә барган саен
Арта гына барыр «ничек?»ләр.
Йорт, җир, дан, дип, йөзгә ярылсаң да,
Юк, ачылмас бөтен ишекләр.

Бүген аякта син, ә иртәгә,
Ә иртәгә, калгач таякка,
Шакыр өчен ике ишек булыр –
Оҗмах кайда, тәмуг кай якта?

## Битараф

Бер төзегән гомер буе төзер,
Матур итеп төзер, төз итеп.
Битараф – ул каккан казык кебек,
Карап торыр, күзен тоз итеп.

Бер уйлаган мәңге уйда булыр –
Уйга салыр иле, дөньясы.
Битараф ул башын гына кашыр,
Ашаса да кемнәр кем башын.

Корт шикелле кереп оялар да
«Дөнья мае» дигән туң майга, –
Миннән кемгә нинди зыян, дияр, –
Тискәре дә түгел, уңай да.

Битарафлык белән хөсетлекме?
Аралары бары бер адым!
Беләм ләса, син бу хакта бары
Битарафлык белән сорадың...



Алмаз
Хәмзин

# ШӘРӘФИ – «ХИ-ХИ» ТҮГЕЛ...

КИНАЯЛЕ ТАМАША

Соңгы араларда бөтенләй тынычлыгын югалтты Шәрәфи. Мәңгелек двигатель уйлап табуы тәмам борчуга салды аны. Өйдәгеләр дә шул халәттә. Шатланырга гына кирәк, югыйсә. Нинди бөек ачыш! Моңа кадәр берәү дә булдыра алмаган, күпләр хыялында йөрткән идеяне гади бер артист тормышка ашырсын әле! Шәрәфи! Ләкин менә шунысы бар: ул аны хәзер эшләвеннән туктата алмый. Мәңге эшләп тора торган двигатель булгач, ничек туктатасың инде аны. Эшли дә эшли шунда. Тегеләй итеп карады, болай итеп... бәрде, сукты, суга батырды, утка тыкты – юк файдасы кыйнавының. Аптырагач, бәдрәфенең лампочкасына тоташтырды – яктыртып торсын, нигә юкка дөрләргә. Фатирындагы бөтен техниканы эшләтергә куйса – сизәрләр дә килеп актара башларлар, нигә бу кеше бер дә электрга акча түләми, дип.

Монысы вак мәсьәлә. Дөньяви четереклелеге бар бит әле бу мәңгелек двигательнең... Әнә, кешелеккә гаять файдасы булачак, дип, атомның көчен буйсындырдылар да оран салдылар. Хәзер зыяныннан куркып яшибез – бөтен Җир шарын юкка чыгарырлык бомба тупланган. Изге ниятне яман куллар вәхшилеккә юнәлткән. Мәңгелек двигатель белән шулай булса, атомнан да әшәкерәк вазгыять тудырачак. Кешеләр эшләмәячәк, ялкауланачак, симереп бетәчәкләр... Пушкинның «Алтын балык» әкиятендәге хәл кабатланачак, яки мич башындагы Емеля кебек чуртаннан ташытачакбыз бәхетне. Һәлакәткә туры юл бу!

Шәрәфине менә шушы уйлары кайгыга батырды. Ярый, мәңгелек двигательне туктатып булмаса булмас, әмма аның барлыгын берәүгә дә сиздермәскә кирәк, дигән фикергә килде ул. Беркөнне гаиләсен җыеп әйтте:

– Сөеклеләрем минем, барыгызны да кисәтеп куям, бүгенге көннән башлап, безнең өйдә мәңгелек двигатель барлыгын онытыгыз, авызыгызны да ачмагыз, күңелегездән чыгарып атыгыз!

Алай-болай ул турыда үзара нәрсәдер сөйлисегез килсә, «Теге» дип әйтегез! Килештекме?!

---

Алмаз ХӘМЗИН (1947) – *прозаик, шагыйрь; «Озак яшисегез килсә», «Бармагыңнан үбәр идем», «Сагынып сөйләрлек еллар» китаплары һәм күпсанлы җырлар, юморескалар авторы. Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе. Казанда яши.*

– Килештек! – дип, бердәм ант биргәндә, караңгы бүлмәдә эшләп утырган мәңгелек двигательгә хәтле пышылдап ишетелде.

Ләкин...

Ләкин бу сөйләшү дә Шәрәфигә тынычлык өстәмәде. Хәтта сәхнәдән тамашачы каршында Гаяз Исхакыйның «Тормышмы бу?» әсәрендәге монологны сөйләгәндә дә, ул үзе үк кабынып китте.

– Күпме уйнарга була инде мондый спектакльләрне? Һаман шул искелек, һаман шул байлар, ярлылар, өметсез мәхәббәт, елаш, күз яшьләре... Классика, янәмәсе... Әйтерсең лә тормыш туктаган!

Бу хәлгә аптырап калган, тамашачы арасында утыручы режиссёр Зирәк Мудриевич сикереп торды. Шәрәфинең, әсәр темасыннан чыгып, мондый кискен фикер ычкындыруы көтелмәгән иде. Бәлки, аның аңына зәгыйфьлек килгәндер дип уйлады ул.

– Гафу итегез, хөрмәтле тамашачылар! Тынычланыгыз, борчылырлык сәбәп юк. Шәрәфи, туктаган җирегездән дәвам итегез!

Шәрәфи, ирексездән, монологка күчте:

– «Менә мин – шул иске тормышка әсир алынган, аның кергән саен чыга алмаслык иттереп ябыла торган унике ишекле зинданына куелган өметсез бер имам! Менә мин – сөймәгән, сөелмәгән бер хатын берлә гомеремне үткәрергә, сөю-сөешү нәрсә икәнне белмәенчә, яшьлегемне уздырырга, картлыгыма кадәр былчырак хезмәтче хатыннар, әдәпсез күрше киленнәре берлә күңелне мыскыл итә, вөҗданны газаплый торган мөнәсәбәтләрдә яшәүче, йомыркалар, кибәкләр, утыннар, саламнар, чүпрәкләр өчен судлашучы кеше калдыгы!»

Уф, юк, мин моны уйный алмыйм! Гафу итегез! Исхакый бөек, шигем юк, әмма гасырлар буе һаман шул бер нәрсәне туглау... Хәзергене язсыннар, Исхакый кебекне, уйнармын... бик теләп...

– Шәрәфи, өзмә инде спектакльне, халык алдында уңайсыз...

– Уңайсыз түгел, шулай бит, җәмәгать? Әнә, тамашачы кул чаба...

– Провал ясама инде, Шәрәфи, үтенәм?!

– Укыйм. «Менә мин – хәзер шул суык көндә, шул ыжгырып торган җилдә, шул хатыным берлә бер түшәктә яткан өйдә, үткән гомеремдә бернәрсә эшләмәгән, киләчәгендә эшләргә идеалын, иманын югалткан, күрше хатыннары берлә маташудан башка эшкә ярамый торган бер адәм калдыгы! Менә мин – шул үземнең тормышымның начарлыгын уйлап та, аңлап та, үземне үзем шул начарлыктан, баткаклыктан чыгара алмаган көчсез, хәлсез бер әрәмтамак».

Җәмәгать, бармы хәзерге заманда Исхакый кебек ачынып, дөреслекне язучы берәр мулла? Үзе турында яза бит даһи. Мең рәхмәт. Исхакый заманыннан да хәтәррәк чорда яшибез бит. Бирегез миңа үзебез турында уйнарлык пьеса, куегыз шуны сәхнәгә! Ә?.. Каяле син, Зирәк Мудриевич? Режиссёр! Тап миңа шундый пьеса? Бир миңа төп рольне!

– Юк бит андый әсәр.

– Юк шул. Булса да куя алмыйсың син аны. Куркасың...

– Дәвам ит инде, Шәрәфи абзыкай, зинһар өчен!

– Ярар, тыңлагыз!.. «Әнә минем киләчәгем! Зур корсаклы, көненә ун бәлеш төбе ашый торган, күрше хатыннары, асраулар берлә маташа, былчырана торган мин! Әнә мужиклар берлә юк нәрсәләр өчен ялган шаһитлар яллап-яллап, хөкүмнәргә йөрүче мин! Әнә мужик хатыннары берлә каз бәбкәләре өчен орышучы мин! Әнә тагын мин! Әнә тагын мин!»

Мине дә шундый хәлгә төшерәсез бит, иптәш режиссёр. Мине дә! Этлегем,

үҗәтлегем белән генә чиста тормыш алып барам бит. Миңа да сатылырга кушалар, ялганларга, куштанланырга. Җәмгыяте шундый, имеш...

Балконнан тавыш ишетелеп куйды:

– Тимә, җәмгыятькә! Сылтама! Тирәнгә төшәсең, актарма!

– Ә-ә! Анда кунакладыңмыни, синең тавыш икән, Җәмгыять Иваныч. Сез һәрвакыт бөтен нәрсәгә өстән карарга яратасыз... Төш аска, халык белән бул!

– Шәрәфи Шиһапович, монологыңны тәмамла инде. Аз гына калды бит.

– Ярар. Синеңчә булсын! Исхакыйның бөеклеге хакына гына укыйм.

«Җилнең ыжгылдавына минем күңелемнең ыжгылдавы, аның суыклыгына минем күңелемнең суыклыгы кушыла. Мин эчтән-тыштан туңам, калтырыйм, дерелдим. Үткән гомеремнең, үтәчәк гомеремнең начарлыгы өчен кайгырырга, егларга, шул беткән идеалымны озатырга, бәхилләшергә бер тамчы кайнар яшь таба алмадым. Мин туңдым, мин каттым, мин беттем!

Шулмы гомер? Тормышмы бу? Бу сөаль, үлгән кешенең өрәге кеби, алдыма килеп басты! Мин җавап бирә алмадым. Сездән сорыйм: «Тормышмы бу?»

Залда шау-шу аралаш, хуплау авазлары, алкышлар лепердәп куйды. Өстән тагын теге тавыш яңгырады.

– Авызыңны чамалап ач, телеңне кисәрләр, Шәрәфи!

– Билләһи, мине бүгеннән соң эштән куалар, – дип хафаланып йөренә башлады Зирәк Мудриевич.

Шәрәфи һаман үзенекен әйтә торды.

– Син бу әсәрне, Мудриевич, үзеңнең абруеңны саклап калу өчен генә алдың, беләм. Гаяз Исхакыйны сәхнәгә чыгарасың, янәмәсе. Аның исеме белән министрлыктан акча каерып була. Ләкин әсәрнең актуальлеген бик аңлап бетермәгәнсең. Өстәгеләр дә аның бу хезмәтен бүгенге көнгәчә аңламыйлар. Миңа яраклаштырып, минемчә, маңгайларына чәпәп, аңлатырга кирәк булганын төшенмиләр. Хәзер менә шундый әсәр кирәк. Бүгенге көнгә «чәлт» иткән.

– Менә шул «чәлт!» иткән әсәрләр язганы өчен чит илгә качып китәргә мәҗбүр булган да инде ул.

– Шулай итмичә, даһи булып булмый. Патша яки совет җитәкчеләренең сәяси ялгышларына һәм аларның кочагындагы җәмгыятьнең торышына каршы көрәшмичә бөеклек килми.

– Төрмә көтә сине, Шәрәфи! – дигән тавыш кабат ишетелеп куйды. – Шул инде, Җәмгыять Иваныч.

– Бөегебез, тынычлан! Билләһи, син генә рәтли алмыйсың бу дөньяны! Әйдә, ипләп кенә эшлик әле.

– Ничек шулай дип әйтә аласың син? Кара инде тегене, балконга менгән. Мине аста – халык арасында тыңларга курка, чөнки минем сүзләрне куәтләп, кешеләр аны дөмбәсләргә мөмкиннәр.

– Аксакалыбыз, синең бүгенге чыгышыңнан соң, һичшиксез, мине эштән тибәләр.

– Типмиләр!

– Тибәләр!

– Типмиләр!

– Ничек кенә тибәләр әле!.. Ну әйтеп тә карыйсың!

– Нәрсә әйттем соң әле мин?

– Җәмгыять начар, дисең бит.

– Мин әнә теге Җәмгыять исемле маңкорт турында гына шыттырдым,

ачуым килеп... Алар...

– Кемнәр?

– Өстәгеләр... Нәкъ шуның кебек инде. Балконда утыра торган шикелле... Кая әле ул?

– Әнә теге яктагысында... балконда.

– Инде анда күчкәнмени?.. Ай-яй тиз алыштырасың син юнәлешләрне... Ләкин аска төшмисең... Колбиләүчелек, феодализм, капитализм, социализм, коммунизм, тагын ничек?.. Ә, Мудриевич? Уйла, уйла! Синең отчестваң шундыерак бит. Мудрить итә торган... Профессияң дә...

– «Мудрый»дан алынган ул.

– «Кыландыру» дигән мәгънәгә якынрак бу исем. Кыландыр әйдә, кыландыр! Бик беләсең килсә, Коммунизмда яшәп алганбыз икән без, хәзер «кыландыризм» җәмгыятендә җан асрыйбыз.

**I**

Булмады...
Безнең халык үз иленнән
Уңмады.
Бигрәк тә
«Вак халыклар» интегә
Ирекә
Дәүләтле
Идек бит без, куәтле,
Кодрәтле!..
Таркаулык
Җитте башына, бетте
Бу ханлык
Чукынды
Морзалар, иман качты,
Сатылды.

**II**

Ах, син, уй!
Иреккә сусавыңны
Алга куй!
Җитәрдер!..
Алда өмет бирердәй
Көннәрдер!
И, Ходай!
Безгә ярдәм кылырдай
Син, бугай!

...Һәм алга таба да шулай дәвам итеп, шигъри юллар сөйләргә була.

– Абзыкай, Исхакыйга кайтыйк инде?! Тезләнеп сорыйм.

– Ник, шуны дәвам итәбез түгелме соң? Ничек әле әсәренең исеме?

– «Тормышмы бу?»

– Шул турыда бара бит бәхәсебез – тормыш турында. Гаяз Исхакый үзе яшәгән чорны тасвирлый. Аны шуңа, ул җәмгыятьнең начар якларын үтәли күрә белгәнгә, хәзерге заманда даһилыкка күтәрделәр ич. Теге чорны, әле генә үткән совет чорын да кушып, аларны фаш иткәнгә, боларына хакимияттә утырырга җай чыкканга, яраткан булып кыланалар бүгенге түрәләр. Әнә теге балконда утыручысы да – шундыйларның берсе.

– Беркем дә белмәгән Исхакый турында лыгырдавыңны туктат инде, Шәрәфи!

– Син белмисең аны – попугай, халык белә – надан түгел!.. – Шәрәфи балкондагы «Тутый кошның» һаман шул бер үк сүзне кабатлап утыруыннан туйган иде инде. – Тюрьма плачет, тюрьма плачет!.. Төш монда! Күкрәк терәп сөйләшәбез... Әйт, хәзерге яшәешебез элеккесеннән нәрсәсе белән аерыла? Әйт, әйбәтрәкме безгә бүген? Нәрсә арлы-бирле йөренәсең? Кулыңны ал кесәңнән, акчаңны барлыйсың мәллә? Күп ул синдә! Эшләп куандырмасаң да бирәләр аны синең ишеләргә... Сатып алмакчы буласыңмы мине? Без андыйлардан түгел!

– Ә зерә...

– Безнең кавем бар булганына шөкер кылып яши. Акча колына әйләнмәдек сезнең кебек, беркайчан да!..

– Үзеңә кара. Минем исәп – тәкъдим итү.

– Акчаңның күплеге әле ул син бәхетле дигән сүз түгел. Син кешеләрне яратмыйсың, шуңа күрә өстә аерым утырасың. Хәтта хатының да юк янәшәңдә. Беләсеңме нәрсә, беркемне дә сөймәгән кеше, үзен яратмаганнардан күпкә бәхетсезрәк. Менә син шундый! Ник эндәшмисең? Сүзең бетте мәллә?.. Наным, чык әле монда, үлчә әле!

Сылу гәүдәсенә килешеп торган матур халат киеп, сәхнәдә Шәрәфинең хәләл җефете күренде. Кулында кан басымын үлчи торган табиб әсбаплары.

– Кулыңны тыныч тот! Сөйләшмә!

– Ничә?

– Бераз тагын күтәрелгән, җаным. Бәлки бүгенге спектакльне башка вакытка күчерергәдер?

– Юк, юк, – дип, моңа хәтле тавышсыз утырган режиссёр Зирәк Мудриевич чәчрәп чыкты. – Берничек тә ярамый: план, акча, бизнес... Элеккеге вакытлар түгел хәзер, спектакльне өзәргә ярамый, хөрмәтле тамашачылар, шулай бит!

Залдан: «Уйнагыз, уйна, бик шәп бара. Афәрин, Шәрәфи!» – дигән тавышлар режиссёрның тәкъдимен хуплады.

– Мин башкача булдыра алмыйм, дусларым. Әйтәсе сүзләрем, фикерләрем байтак җыелды. Әйтеп калыйм, дим. Инде өлкән яшьтә икәнлегемне беләсез, исәнлек тә әллә ни шәптән түгел.

– Саулыгың да чамалы гына булгач, нигә үз киреңне киереп йөрисең соң син? Җәмгыятькә яла ягып... – дип такмаклый торды өстәге попугай.

– Менә сезнең кебекләрне дөмектереп бетерү ихтыяры гына яшәтә дә инде мине. Үз сәламәтлегеңнең әллә ни мөһимлеге калмый икән яши-яши, ә менә синең кебекләр ничегрәк җан-тәслим кылырлар – менә монысы кызыктыра.

– Нигә шулхәтле каныгасың соң син аларга?! – дип, Наные Шәрәфине битәрли башлады. – Күреп торасың бит, монысы китсә, аның урынына тегесе киләчәк.

Тамашачылар, балконга карап:

– Әй, син анда безгә спектакль карарга комачаулап утырма әле, – дип кычкыра ук башлады. – Полиция чакыртырга кирәк!

– Тимиләр аңа барыбер! – диде кемдер халык арасыннан.

– Булса соң, бу җыелыш түгел, театр бу, теләсә-нәрсә кычкырып утырырга.

– Бәреп төшерим әле шуны балконнан, – дип, алагаем гәүдәле ир урыныннан купты.

Аны күрептерме, Җәмгыять Иваныч балконыннан каядыр ычкынды. Моңа хәтле нишләргә белмәгән режиссёр Зирәк Мудриевич залдан туры сәхнәгә атылды.

– Менә нәрсә куптардың, Шәрәфи Шиһапович? Хәзер бу җәнҗал турында Америкада сөйләячәкләр!

– Курыкма, безнекеләрнең тыны да чыкмаячак. Ә Американыкын безнең халык ялган дип кабул итә. Дөнья – киш-миш...

Хатын, каяле син?! Борчылма! Вундеркинд оныгыбыз килмәгәнме анда безгә? Аның «Теге нигә» күз салгалап йөргәнен сиздем мин соңгы вакытларда. Шалтыраткалап тор әле эти-әнисенә! Мине шунысы ныграк борчый. Аллам сакласын!

– Ярар, Җаный, тынычлан гына, – диде дә Наные, әллә шалтыратырга, әллә өйләренә кайтып килергә ниятләнеп, сәхнәдән чыгып китте.

Шәрәфи дә сәхнәдәге буталышка һәм залдагы шау-шуга игътибар итмичә уйга чумды. Зирәк Мудриевич пәрдәне яптырырга исәпләп сәхнә эшчеләрен эзли башлады, таба алмагач, пәрдә итәген үзе тарта башлады. Күрәсең, автомат

ябу җайланмасы эшләми, әллә эшләтә белми, ә залдагы халык Җәмгыять Иванычны эзли. Һәм, беркадәре, режиссёр белән тартыша: Зирәк Мудриевич пәрдәне – бер якка, ә берничә ханым аны кирегә өстери торды.

***

Сугыш еллары. Ил хәсрәте аның кебек малай-шалайга, әби-бабайларга, апаларга төшкәнен үзләре дә сизми йөрделәр алар. Гомергә рәхәт күрмәгән бала-чагага «рәхәт тормыш» дигән нәрсә – әкият булып тоела инде. Хәер, төшенә кергәләде андый дөньялар. Беркөнне Сталинны күрде. Ап-ак кителдән, мин сиңа әйтим. Шул кителен киеп Тегермән тавына менеп бара. Пропеллерларына утырып, әллә нинди белмәгән җирләрне күреп әйләнәсе килгән җил тегермәне канатлары яныннан үтеп, Таган асты дигән җиргә китеп баруы. Ул шул көнне иртән искиткеч рәхәт уянды. Әйе, аннан да бәхетле кеше юк иде кебек әлеге иртәдә. Сталин хәтле Сталинны күр әле син! Дусларына төшеп сөйләп котларын алды. Берсе: «Мылтыгы бар идеме?» – дип сорый. Икенчесе: «Сине күрдеме?» – ди. – Күрде, – дип җавап бирә ул. – Баштан сыйпап китте. Әле сиңа да сәлам әйтте», – дигән була. Малайлар: «Миңа нәрсә диде?» – дип интектереп бетерәләр үзен.

Шуннан соң, Кыш җиткәч, аларның алагаем зур ап-ак кәҗәсен бер бүре шул Сталинны күргән җирдән – Тегермән тавыннан алып китте. Ул елларны бүреләр бик азган чак. Күрәсең, кешеләр ач, бүреләр тагын да ачрак булган. Авылдан ерак түгел җирдә таптылар алар кәҗәләрен. Ашап бетерә алмаган, ләгънәт төшкән нәрсә. Ап-ак кительле Сталин белән ап-ак кәҗәнең төшенә керүен нәрсә дип тә аңлатырга белмәде ул. Шул, Ил бәлагә баткан, балалар сөтсез калган.

Тагын бер вакыйганы искә төшерде Шәрәфи, һаман шул сугыш вакыты. Әтисе фронтта, бер абыйсы да шунда. Әнисе аны ялгызын өйдә бикләп эшкә киткән. Өстенә кияргә киеме дә, аягына гәлүш тә юк. Пес итәргә чиләк калдырганнар. Өйалдына чыгышлы. Тәрәзәсез. Берзаман ап-ак сарык бәрәне, арт аякларына басып, ишек пыяласына шакый. Ул күзләрен уып карый, өнеме бу, төшеме? Каян килгән бәрән? Ишекне ачып кертмәкче була, бикле. Этте, төртте, типте – булмады, шул ара бәрән югалган да. Әнисе кайткач өйалды тактасына кыстырылган тышы-ние юк бер китап алып керде. Искереп, таушалып, ертылып беткән, урысча язылган китап иде ул. Укыштыргалап карады аны бәләкәй чагында Шәрәфи, ләкин бернәрсә дә аңламады. Хәзер, гомерләр узгач, шуны уйлап утыра: бәлки ул изге бәрән булгандыр, ягъни Хозыр Ильяс. Алар бит төрле затка әверелеп йөриләр, ди. Димәк, аны Шәрәфигә Ходай җибәргән. Кертергә кирәк булган, бәлки, тормышы икенчерәк юнәлештән китәр иде.

Хәер, биргәненә шөкер.

Бу хатирәләрдән соң Шәрәфи канатланып китте. Гомер юлы буйлап аны Хозыр Ильяс алып бара икән бит. Ул һәрчак аның янәшәсендә, аның сагында!

Шулчак:

«Әйе, мин һәрвакыт синең янында», – дигән сүз колагына ишетелгән кебек булды.

Балачак хатирәләренә чумып утырган Шәрәфине залдан күтәрелгән тамашачының:

– Шәрәфи туган, бераз онытылып киттең, ахрысы, әллә күңелең кителдә шунда, игътибар бирмә! Аның исе хәлләр синнән генә калмаган, – дигән сүзләре сискәндереп куйды.

– Сез кем? – диде Шәрәфи, әлеге тамашачының Хозыр Ильяс булу ихтималын чамалап.

Чыннан да әлеге тамашачының килеш-килбәте театрга даими йөри торган кешенеке төсле түгел иде. Милли бизәкләр белән чигелгән утыртма якалы күлмәге өстенә ап-ак озын чапан кигән. Башында, кырыйлары эшләпә шикелле җәелеп киткән, әмма киелгән өлеше затлы татар түбәтәенә охшаган үтә шәп картуз. Муенына яшел шарф элгән. Аягында читек. Кашы, мыегы, сакалына көмеш төсе кунган.

– Син мине белмисең, ләкин безнең очрашкалаган булды, – дип әйтеп куйды теге тамашачы бераз вакыт узгач.

– Кайчан?

– Беренче мәртәбәсендә син кечкенә идең әле...

– Сугыш елларындамы?.. Кышкы салкында, син миңа...

– Әйе, әйе...

– Ак бәрән булып...

– Әйе.

– Мин Сезгә ишек ача алмадым...

– Шулай, әмма теләгең изге иде. Бүгенге гамәлләрең үткәннәреңә караганда тагын да саваплырак.

– Сез Хозяр Ильяс түгелме?

– Мин сиңа үземнең кем икәнлегемне әйтеп тормыйм, анысы мөһим түгел, әмма ләкин синең язмышыңны гадел юнәлештә алып баруны мин инде үземнең вазифам дип саныйм. Хәер, синең минем ярдәмгә бик үк мохтаҗлыгың да юк. Алай дип тә әйтеп бетерергә ярамый. Сине театрдан куган чакларда, филармониядә эшләгәндәге кышкы суыкларда катып үлә язган вакытларда, аннан соң, бер мәртәбә инфаркт булгач минем кирәгем чыкты. Мин гел янәшә туры килеп тордым.

Хәзер бу катлаулы һәм мөһим мәсьәләне – җәмгыять белән театрның торышын куптаруың үзең өчен генә түгел, кешелек дөньясы өчен бик актуаль. «Теге ниең»не дә җәмәгатьчелек кулына тапшырырга бик ашыкма. Бер дә туктамый эшли торган «дыр-дырың»ны әйтәм.

– Киңәшләрегез өчен рәхмәт йөзеннән, сезнең кулыгызны кысарга мөмкинме?

– Ярамый. Кыстыгыз дип исәплә.

– Кочарга ярыймы?

– Анысы да кирәкми, чөнки без кешеләр белән хисси мөнәсәбәттә булырга тиеш түгелбез.

– Мин киләчәктә нишләргә тиеш?

– Моннан җитмеш биш ел элек калдырган китапча яшә! Хәзергә хушыгыз!

Шәрәфи Хозыр Ильяс дип уйлаган сәер зат кинәт юк булды. Әйе, теге ак бәрән калдырган китапның авторы бөек рус язучысы Герцен икәнен ул инде күптән белде. Шәрәфи аны кибетләрдән эзләп тапты. Исеме – «Үткәннәр һәм уйланулар» икән. Кешелек дөньясы өчен иң кирәкле әсбап итеп күрә ул китапны хәзер Шәрәфи. Шуңа күрә Герцен фикерләре аның иң якын киңәшчесе.

***

– Наныем, Хәмзәнең шалтыратканы булмадымы?

– Әй, онытып торам икән, шалтыратты, шалтыратты. Бүген килергә исәбе бар. Мин аңа театрда булабыз дидем. «Спектаклегезнең башына ук килә алмам, сәхнә артына гына кереп чыгармын», – диде.

– Килсә, сәхнәгә үк чыксын инде, яме! Монда тамашачылар да бар. Яшереп сөйләшәсе сүзләребез юк.

Наныйның телефоны аваз салды.

– Әйе, Хәмзә, тыңлыйм сине. Шәрәфи кайда, дисеңме? Ул бит сәхнәдә, телефоны үзе белән түгел. Ә-ә, килдең дәмени. Чык монда сәхнәгә. Шәрәфи абыең, чыксын, ди. Анда тамашачы бардыр бит, дисеңме? Булса соң, мин дә шунда йөрим ич. Әнә, ишетәсеңме, сине кул чабып чакыралар.

Шәрәфи телефоннан сөйләшүгә колак салып торды да:

– Наный, бар, кунакны каршыла! – диде.

Хуҗабикә кирә-керешкә гадәттәгечә ипле тавыш белән:

– Әй, Хәмзә, күптәннән Шәрәфи абыең турында язып әле дип йөри идең инде, кирәк микән соң?.. Бәлки кирәкмәстер? Ә?..

Хәмзә халык белән исәнләшкәннән соң, күчтәнәчләрен бирә-бирә:

– Кирәк, Наный ханым, бик кирәк, аңа кирәкмәсә, халыкка кирәк, – дип, тамашачыны кул чаптырды. Аннан соң сүзен дәвам итте:

– Монысы әпитит өчен – дару, монысы – шуны йотканнан соң кабып куярга – кәнфит, монысы – ананас – кызык өчен. Минем чәч юк, башым пеләш, кызыктым ананасның причёскасына.

– Уңайсыз хәлгә калдырасың, Хәмзә, без алай яратмыйбыз бит. Наный, карале моны, тагын күчтәнәчләр белән. Өйгә килгәндә дә шулай итә. Монда сәхнәгә чыгарып куйыйкмы инде?..

– Кая куйсагыз да ярый, хәзер сезнеке инде алар. Мин үзем дә яратмыйм күчтәнәч алып килгәннәрен. Ләкин кайвакытта әйбәт булып китә: искә төшә дә, каяле теге Шәрәфи бүләк иткән нәрсә, дип эзләштерәм.

***

Шәрәфи яңадан мәңгелек двигателен искә төшерде. Төшерде, дип, аның онытылганы да юк инде... Шулай фатирының караңгы бүлмәсендә гомер буе бер файдасызга эшләп утырыр микәнни ул? Акыллы башлар табып булмасмыни соң, шуны кешелеккә хезмәт иттерер өчен.

Бу серне кемгә ачарга?.. Әнә бит күпме фаҗигаләр булып тора Җирдә... Ачлыктан, сугышлардан, гарасатлардан, шартлаулардан, янгыннардан миллионлаган җаннар кырыла. Ярдәме тимәс иде микәнни ул двигательнең?.. Аның, Африкадагы коры сөяккә калган, күз яшьләре кипкән, эчләре эчкә баткан, кабыргалары коелырга торган балалар, апалар күз алдына килде. Әйе, алар елый да алмыйлар.

Сүриядәге шәһәрләрнең хәрабәләре астыннан кояш күрергә теләп баш калкыткан, тузанга баткан битле сабыйлар, бер телем икмәк, бер йотым су бирмәсләр микән дип күтәрелгән нәни куллар... Донбасс мәктәбенә төшеп шартлаган бомбаның вәхшилеге – идәндәге бала гәүдәсе...

Нишләргә? Атом энергиясен куллану максаты да изге булган лабаса... Нәтиҗәсе – Хиросима, Нагасаки... йөзәр мең корбаннар... гарипләр... ятимнәр... Ә гафу үтенүче юк...

Инде менә яңа куркыныч яный... һәр ике бер-берсенә баш бирмәс як – сәяси көч сынаша... һәм корал туплыйлар... гайрәт күрсәтәләр... Алга таба ни килеп чыкмас?.. Аллам сакласын!. Халык куркуда...

«Юк, мин әле «теге»не чыгармый торачакмын», – дип, үз-үзенә ант итеп куйды ул эченнән генә. Шулай тынычрак булыр...

Ләкин... Ләкин һаман шул сорау кала бирә:

Нишләргә?

Бу сорауларга җавапның әле табылганы юк. Шәрәфи билгесезлектән җиңелчәрәк сорау белән чыкты:

– Хөрмәтле тамашачылар! Кайда йөри икән анда безнең режиссёр Зирәк Мудриевич белән Җәмгыять Иваныч?

Шулчакны залның арткы ишегеннән, югалганнар килеп керделәр. Режиссёр зур эш кылгандай сүзен башлады:

– Менә Җәмгыять Иванычны буфеттан эзләп таптым. Спектакль карамыйча кәеф-сафа корып утыра.

– Чәй эчәме? – дип сорап куйды Шәрәфи, аларга карамыйча.

– Исертә торган чәй икән шул.

– Җәмгыять үз ролендә, – дип әйтеп куйды Хәмзә дә.

– Безнең җәмгыять белән бу Җәмгыять Иванычның бернинди аермасы юк, монысы беренчесенең продукты гына!

Сәхнә артыннан подноска коньяк шешәсе кырыйлап чәркәләр тезгән Наный ханым килеп чыкты. Аны күрүгә Шәрәфи:

– Кире керт! – дияргә мәҗбүр булды.

– Хәмзәнең күчтәнәче. Тәкъдим итмәсәк, уңайсыз, диюем.

– Кирәкмәс, әнә Җәмгыять Иваныч нинди булган?

Җәмгыять Иваныч, бераз кәпрәебрәк, соңгы елларда сүздә ирешелгән уңышлар турында фикерләр ыргыта башлады.

– Икътисад үсә!

Хәмзә аның һәр әйткән сүзенә җавап биреп бара:

– Аның үсү күрсәткече – безнең буш кесә!

– Тормыш яхшыра! – Синеке!..

– Байлар арта.

– Бомжлар да...

– Миллиардерлар күбәю – горурлык!

– Минемчә – хурлык. Миллиардерларның үрчүе – җәмгыятьнең череп таркалуы ул!

– Нәрсә, миңа ябыштыгыз?! Аңламый дип беләсез мәллә минем белән нәрсә эшләргә маташуыгызны? Теге дөньяга олактырмакчы буласызмы?

Сез – журналистлар, минем беренче дошманым, – дип, ул Хәмзәнең якасына барып ябышты.

Режиссёр Зирәк Мудриевич белән Шәрәфи аларны аерып ыргыттылар. Хәмзә һаман тынмый:

– Әйе, иптәш Җәмгыять Иваныч, журналист һәм язучы буларак, мин әле сезгә дошман гына түгел, пенсионер буларак нагрузка да. Без сезнең турыда язабыз, ләкин сез аны бастыртмыйсыз, чөнки анда дөреслек бөрки. Ә пенсияне безгә эткә сөяк ыргыткан кебек кенә ташлыйсыз, анысын да бирәсе килмичә генә. Әмма, бер шагыйрь язганча, шуны белегез:

> Сез очарсыз биек болытларга,
> Һаваланып күктә йөрерсез;
> Ни кыланып йөрсәгез дә өстә,
> Барыбер кайтып, гүргә керерсез!

Менә шулай, Җәмгыять Иваныч, сез халкыбызның каргышында. Кешеләр сезгә бәддога укый. Барыгыз, бар, тагын берәр затлы нәрсә чөмерегез дә,

диңгезләр, дәрьялар буйлап сәяхәткә ычкыныгыз. Йөрмәгез монда, ачу китереп, халык арасында нәфрәт тудырып. Имеш сез – гади, үз кеше. Гади түгел сез – халык бавырына төшкән яман шеш! Вәт шул!..

– Бу сүзләреңне чамалап әйттеңме?

– Әйе, салкын баш, аек акыл белән. Миңа һәрвакыт уяу булырга кирәк. Югыйсә, сезнең ялчыларыгыз һәр почмакта бәреп китәргә чамалап торалар.

– Үкенерсең бит?!

– Күп тукмадылар инде. Бар кит, юлыңда бул!

Җәмгыять Иваныч, йодрыгын төйнәп боларга усал караш ташлады да, аумаклап, сәхнәдән чыгып китте.

Шәрәфи, аны тыңлап алҗыганлыктан, янәшәсендәге кәнәфигә утырды.

– Уф, Хәмзә, син дә ярсырсың икән...

– Соң үзең күреп торасың ич, җанбиздергеч бәндә.

– Туфан Миңнуллин әйтмешли, халкы нинди – депутаты шундый инде.

– Халыкның шундыйлыгы җәмгыять торышына бәйле, Шәрәфи дус. Җәмгыяте нинди – халкы шундый, дип өстәсәк дөресрәк булыр.

– Фикереңне бүлмим, сөйлә, кәнәфидә ятып тыңлыйм. Синең фәлсәфә – минем уйларым кайтавазы.

– Тыңла, алай булгач. Театр ул – тормыш, дибез. Әйе! Гаяз Исхакый да барлык әсәрләрен тормыштан алып язган. Әйдәгез, без дә бүгенге тормыштан театр ясап карыйк әле. Әлбәттә, дөреслекне чагылдырып. Әгәр театр чын сәнгать жанры икән, ул нәкъ шул принципка таянып эшләргә, иҗат итәргә тиеш. Театрга хезмәт итүчеләрнең вазифалары да шушы нигездә гамәл кылырга хаклылар. Шулаймы?

– Шулай.

– Әмма бүгенге театр – чордан, аның максатлы юнәлешеннән читтә кайнаша.

– Мин бүген нәкъ шул фикерләр белән тулган башымның чатнавын тыя алмыйча чәчрәп чыктым бит инде сәхнәдә.

Шәрәфи яткан җиреннән сикереп үк торды.

– Без һаман, классикага таянган булып, халыкка киләчәктә нишләргә тиешлегебезне аңлатырга тырышабыз янәмәсе, югыйсә әле бүгенгесен дә аңламыйбыз. Йә, кайсыбыз әйтә ала, без бүген нинди җәмгыятьтә яшибез? Капитализмдамы?.. Әйтүче юк бит!.. Капитализм шикелле... Чөнки безне талыйлар... Байлар бар, ярлылар күп, дөресрәге, ил тулы хәерче. Минемчә без әле төзелеп тә, укмашып та бетмәгән җәмгыятьле илдә яшәгән булып маташабыз. Күмәк һәм төп максатыбыз юк. Һәр кешенең күңелендә ничек кенә булса да бераз юньлерәк яшәү өчен акча табу. Акча – король! Акча – патша! Акча – император!

Кая әле безнең режиссёр! Керсен әле монда! Эчтәлекле, мәгънәле сөйләшү барганда иң беренче ул булырга тиеш бәхәс эчендә. Алга таба ничек яшәргә, эшләргә, иҗат итәргә кирәклеген ачыклыйбыз бит.

Шул арада Зирәк Мудриевич пәйда булды. Якында гына йөргәндер. Аның эленке-салынкы кыяфәтен күреп, Шәрәфи:

– Нәрсә, үпкәләдең мәллә, борыныңны салындыргансың? – дип сорап, шелтәле сүзләренә күчмәкче иде, тегесе бүлдерде:

– Бүгенге җәнҗалдан соң мине һичшиксез эштән куачаклар! – диде, еламсырап.

– Кем кусын сине? Синең бит дөньяда бар икәнеңне дә белмиләр. Кайчан түрәләрнең спектакльләргә йөргәнен күргәнең бар, бер шагыйрь-депутат

белән спикердан башка һәм менә бүгенге әтрәк-әләм Җәмгыять Иванычтан кала.

– Монысының әле беренче генә килүе, – дип, җөмләгә дөреслек кертте режиссёр. – Театр карый белмәгән башы белән.

Шәрәфи кире өзелеп калган фикеренә кайтты:

– Кумыйлар. Алар сине түгел, мине дә белмиләр инде. Элеккеләре эштән китте, ә балалары татарча белми, гәрчә этиләре үз кәнәфиләренә аларны утыртып калсалар да.

Бөек артист, нәрсә уйлаптыр, Зирәк Мудриевичның башыннан сыйпап утыра башлады. Алда әйткән сүзләренең дөреслеген сюжетка сала, күрәсең. Шуны сизепме, режиссёр уңайсызланып әйтеп куйды:

– Шәрәфи Шиһапович, ичмасам, халык алдында мине юатып башымны сыйпап утырма инде, бала-чага диярләр, тагын... әлләниләр уйларлар.

– Хөрмәт итеп, яратып шулай эшлим мин сине, театрга бөтен көчеңне, күңелеңне бирәсең бит. Татарның бөтен классикасын куеп чыктың, яңа авторларны куандырып торасың. Җәмгыятебездәге җитешсезлекләрне ара-тирә тамашачыларыбызга күрсәткәлисең. Эчүчелек, аерылышулар, наркомания... һәм төрле шырдый-бырдыйлар... Андыйлары да кирәк әлбәттә, менә аларның хәзер килеп чыгуында кем гаепле һәм нишләргә кирәк икәнлеген кыегайтып кына булса да күрсәткән спектакльләребез аз. Менә син, хөрмәтле режиссёрыбыз Зирәк Мудриевич, мең спектакль куярсың, исемеңне дә отып калмаслар. Ә менә, мин әйткәнчә, берәгәйле берне чыгарырсың – мәңге онытылмаслык булыр. Бәлки бер генә көн куярга өлгереп тә! Белдеңме?!

– Белдем, ди. Шәрәфи Шиһапович, андый әсәрне башта кем яза әле – билгесез, бу бер мәсьәлә; икенчедән аны бер куеп данлыклы да булдым ди, шуннан соң ничек яшәрмен? Беркая да эшкә алмаячаклар, гаиләне ничек туендырыйм. Дурак, син, диярләр! Менә шул.

– Димәсләр!

– Синең үзеңне бер куганнар иде түгелме соң?

– Булды андый хәл. Театрдан китәргә туры килсә дә, югалып калмадым. Илһам Шакиров белән гастрольләрдә йөрдем. Театрдагыга караганда акчам күбрәк иде.

– Ярый да синең шундый талантың бар: юмор сөйлисең, монологлар, скетчлар уйныйсың... Пушкиннарның, Лермонтовларның «тегенди-мондый» шигырьләрен тәрҗемә итеп көлдерәсең.

– Шундый булырга сиңа да беркем комачауламый. Талант болай гына килми ул, аны гомереӊ буе тупларга, баетырга кирәк.

– Ә менә минем кебек кеше ни кыра ала?

– Әй, дустым, беткәнмени балтага сап?.. Барасың да бер театрга, куясың шундый спектакльләр! Билгеле, тормыш таләпләрен күтәрә торган пьесалар тапсаң. Агылачак халык, агылачак! Монда, министрлык кендегенә бәйләнеп театр тоту, бик җиңел нәрсә түгел ул?.. Аңлыйм. Ярый, икебезне дә театрдан куу өчен җитәрлек контрсүзләр сөйләдем.

Шәрәфи Шиһапович, әйдә, теге тәрҗемәләреңнең берәрсен сөйлә халыкка, сине дә эштән куачакларына шигем калмасын.

– Ярамый, сәхнә нәфислекне ярата. Мин түрәләрнең банкетларында күп сөйләдем инде аларны. Анда сөйләгәннәрем дә миннән үч алырга җитәрлек инде.

Шәрәфи җырга күчте:

Элек ачык сөйли идек,
Кыенлашты тик быел.
Себер китәсең килмәсә,
Күп сөйләвеңнән тыел.
Эх, алма кортлады.
Бу дөньяга бер туып та
Рәхәт яшәп булмады.

Бу җыр күңелләрен канәгатьләндереп бетермәде, ахрысы, Зирәк Мудриевич:

– Әлеге җырың шәп синең, әйдә, тагын бер көйгә, – дип, җырлый-җырлый биюгә күчтеләр.

Мин, Шәрәфи, шаян кеше,
Шаяннар аз минише.
Шаяру, көлү, төрттерү –
Абзагызның төп эше.
Шәр-шәр, шәр-шәр,
Шәрәфи, хи-хи... шәрә.
Шәрәфидән көлә-көлә,
Каласыз бит шәп-шәрә!..

Шәрәфинең сулышы капса да күңеле күтәренке, ул режиссёрга баш бармагын күрсәтеп:

– Мудриевич, без әле синең белән байтак әһәмиятле эшләр майтарачакбыз, – дип, кәнәфиенә ауды.

Җаныеның хәле беткәнне тоеп, су һәм тастымал тотып, Наные килеп чыкты.

– Җаный, нигә шул хәтле сикерәсең инде. Бала-чага түгел бит шул хәтле котырырга. Сине дә әйтер идем инде, Зирәк Мудриевич, сиксән яшьлек әртисеңне үрле-кырлы сикертмәсәң.

– Без уртаклык таптык, Наный ханым!

– Минем өчен Шәрәфи Шиһапович уртак түгел шул, ул – бердәнбер!

– Бүген спектакль бик авыр бара, бераз күңелне күтәреп, җырлап-биеп алдык.

Шәрәфи урыныннан күтәрелеп:

– Нишләп авыр барсын, бик әйбәт бара!

– Әйбәт бара, Җаный, әйбәт бара...

***

Шәрәфинең хатыны алтын аның. «Җаный», дип кенә тора, «борчылма!» – ди бит. Булса иде бар хатыннар да шундый. Карл Маркснең хәләл җефетенә охшаган ул. Марксны гел көйләп, җайлап, кадерләп кенә торган хатыны. Җиде ел аерым торганнар ди өйләнешкәч. Җиде ел Алманиядә укыганын көткән ялгызы, һич хыянәт итмичә, сагынып, сагышланып, өтәләнеп, хатлар язып көткән. Үзе капиталист кызы, югыйсә. Кайткач менә дигән итеп тормыш корганнар, ике кыз үстергәннәр. Шәрәфинеке – «Җаный», – дип эндәшсә, Марксныкы – «Женни» икән. Бар инде ул бәхетле парлар. Шәрәфи бит аны ике кыз арасыннан сайлап алган. Үзе сөйләве буенча, беренчесе – бик талантлы, киләчәктә атаклы театр артисткасы булачак чибәр кыз. Икенчесе – гади авыл кызы, үзенә караганда күпкә яшь, әмма сылу, чибәрлеккә дә беренчесеннән калышмый торган нәфис зат – шушы «Җаный» дип эндәшүчесе. Тегесе «өйләнешүне берәр елга кичектереп торыйк» дигән. Шәрәфи әйтүенчә, күрәсең, берәр баерак кияүне күздә тотып

йөргәндер – шундый шарт куйган. Әле «Наный» булырга өлгермәгәненнән: «Ашарга пешерә беләсеңме?» – дип сорагач, анысы: «Өйрәнермен!» – дип җавап бирүен Шәрәфи бик яраткан. Менә шуннан соң матур гына итеп яшәп киткәннәр һәм хәзергә хәтле сокланып туймаслык гомер кичерәләр. Күзләр генә тимәсен инде, ярабби Ходаем! Кулларына гел дару белән йотып җибәрергә су шешәсе тотып йөри бит ул Шәрәфи өчен. Койган да куйган Женни менә – үзенең бөтен тормышын ире белән бергә, кулга-кул тотышып революцион эшкә багышлаган шул Аурупа кызы. Наный да ире өчен җанын кызганмый торган чын Шәрык алиһәсе! Фани дөнья Фәрештәсе!

Әнә, сәхнәгә башын тыгып, тагын бер мәртәбә Җаныен барлап алды.

Ире тагын режиссёр белән гәпләшә. Кызып-кызып нәрсә турындадыр сөйләшкәндә, Шәрәфи кинәт хатынына:

– Наный, мин бераз һавага чыгып керәм, югалтма! Озак тормыйм, – дип әйтеп куйды.

Ялт итеп атылып чыккан Наные кунакка гына киеп йөри торган казакиен Җаныеның иңенә салды.

– Матур итеп йөр! Кайтуыңа нәрсә пешерим соң?

– Өчпочмакларың тәмле була синең? Хәер, нәрсә кылансаң да яратып ашыйм бит инде, Наныем!

– Ярар, берәр нәрсә әмәлләрмен. Озак йөрмә! Бу тирәләрне генә әйлән! Телефоныңны алдыңмы?

– Әйдә, киттек! – дип, Шәрәфи Зирәк Мудриевичкә кул изәде.

***

Шуларның эзенә үк басып диярдәй, залдан сөйләшә-сөйләшә Хәмзә белән Җәмгыять Иваныч сәхнәгә күтәрелделәр.

– Сиңа нәрсә җитми, Хәмзә, жить надоела что-ли в конце концов? Ә? Әйт?.. Эшлибез! Безнең өстән язасың да язасың... Җитте!.. Түземлекнең чиге була. Мондый чакта синдәйләргә ике төрле генә чара кулланалар: җә телеңне кисәләр, җә – психбольница!

– Беләм. Бик каты кыланасыз. Бер тапкыр инде шулай булды. Синдәй берәүгә: үзе язучы, үзе композитор, үзе биюче дигәндәй, алай гынамы соң – депутат, җирле олигархка элэктем мин. Бөтен артистларны сатып алган кеше ул. Кая артистларны гына, композиторларны, язучыларны, сәнгать өлкәсендә эшләүче байтак куштаннарны кармакка элэктерде. Кармакның очында дефицит колбасалар, сыр һәм башка фәлән-төгән, күбрәк акча инде, әлбәттә, кая алай гына булсын – машиналар өләшә хәтта!.. Минем белән дә байтак сөйләшүләр алып барды ул, ләкин тәкъдим иткән шартларына күнмәдем. Тик шулай да бер каптым.

– Ә-ә, майлы калҗа кызыктырдымы? Барыбызның да тәмле ашыйсы килә!

– Тукта әле! Сөйләп бетермәдем бит. Ул сабантуйлар үткәрергә ярата иде, үзең беләсең.

– Кемне сөйлисең син?

– Үзең дип белдең мәллә?

– Төрттереп, ачуны китереп әйтәсең бит. Астыртын итеп.

– Сез бөтенегез бертөсле, бу син түгел, ләкин нәкъ синең төсле. Тыңла!

– Әйдә, әйдә, түзәм, сайра! Тик авызыңны чамалап ач!

– Куркытам, дип уйлыйсың инде син мине, уйлап чыгарган хәл түгел – булган вакыйга. Янама!

Сабантуй үткәрә бу. Сценарий язарга кирәк. Шәһәр читендәге бер офисына мине чакыра. Машина җибәргән. Иномарка. Җаным кыелып, ачуым килеп барды. Кем инде ул? Ит комбинаты директоры Мөнирович әйтмешли: «Бер «Кояш» сүзендә биш хата ясый. Миндә шофёр булып эшләгән надан бит ул».

– Ничек инде «Кояш» сүзендә биш ялгыш ясап була?

– Үзең санап кара. Менә син ул сүзне ничек язар идең? Хәрефләп әйт.

– «К», «Ы», «Я», «Ш».

– Молодец, синеке берәү генә икән әле ялгышың. «К» хәрефеннән соң «О» языла.

– Аңа карап, Кояш үзенең яктыртуыннан туктамый бит.

– Туктамый туктавын, ләкин ул сездәй наданнар...

– Чамалап ач дидемме авызыңны?..

– ...Безграмотныйлар җир йөзендә күбрәк булган саен Кояш тизрәк сүнәргә мөмкин. Чөнки сез дөньядан күбрәк алырга күнеккән, ә үзегездән бирергә кирәкен белмисез. Чөнки сезнең каныгызда – Акча дигән вирус.

– Карале, бу керпеләр ничек «нитешәләр» дигәннән...

– Сезнең уегызда акча белән шул «нитешү» генә бугай...

– «Кояш» сүзендә ничек итеп биш ялгыш ясап була соң, гел шуны уйлап утырам.

– Ул «К» хәрефеннән соң «катылык билгесе» куйган, аннан соң «ы» хәрефе, «кыска И», «А» язган да «ш» дан соң «нечкәлек билгесе» өстәгән.

– Анасын сатыйм!..

– Менә шундый сезнең братлар!

Ярый, сценарий язарга чакырган дидем бит. Килдем. Колагыннан телефоны төшми. Әле берсе шалтырата, әле икенчесе, аннан соң үзе тотына. Миңа вакыты юк. Кайттым дә киттем җәяүләп, шәһәргә хәтле ике чакрым бар. Атлыйм, артка карамыйм да. Инде автобус тукталышына җиттем дигәндә шофёры куып җитте.

– Нишләп киттең? Шеф чакыра – ди.

– Соң, – мәйтәм, – инде ике сәгать көттем бит.

– Зинһар өчен, әйдә, утыр, сине алып кайтмасам эшеңнән куам, диде.

Шофёрны кызганып кире киттем. «Эш, вакыт тыгыз, тегеләй-болай, гафу ит?!» – дигән була.

Кыскасы, яздым мин моңа егерме биш битлек сценарий. Шалтырата бу:

– Булдымы?

– Булды.

– Кил, машина җибәрәм.

Бардым. Миннән гафу үтенә-үтенә һаман телефоннан сөйләшә. Ай, шул хәтле кирәкле кишер яфрагы булып кылана инде. Әйтерсең лә ансыз дөнья тәгәрмәче әйләнми. Аякларын атландырып киң кәнәфиенә чумып утыра, эш өстәлендә ятып сөйләшә, ревматизм дигән була, тәмәке төтеннәрен боҗралатып очыра, Ленин кебек подтяшкасын чиерттергәләп йөри, ә өстәлендә кемдер язып биргән калын җырлар китабы ята. Бары бер китап... Аныкы! Композиторларга сызгырып язган җырлар алар!

Карале, син яздырдыңмы әле үзең турында берәр эпопеялы бестселлер? – дим.

– Нәрсә соң ул?– ди.

– Иң күп басыла һәм укыла торган китап. Рәсем тулы альбом булса да ярый. Хәзер байлар үзләрен мактатып шундый китаплар чыгаралар. Менә ул президент белән төшкән, менә аның океан дулкыннары өстендә тибрәлгән

лайнер палубасында төшкән рәсеме, менә ул Маркиз утрауларында, Таиландта, космоста... Анда булганмы ул, юкмы, анысы мөһим түгел, шунысы факт – фотосы бар. Кайберләрегезнең бит Айда, Марста төшкән кеше ышанмаслык сурәтләре кергән ул фотоальбомнарга. Янәшәгездә хатыныгызмы ул – җен белсен... Әмма ләкин, күз явын алырдай чибәркәйләр. Ну типтереп тә карыйсыз инде, малай!

– Ә, кәк же! Бер генә яшибез дөньяда! Кояш кайда, без шунда!

– Сүзен дөрес язмасагыз да...

– Дөрес язылмаган законнар да бар бит әле, «Кояш» сүзе генә түгел.

– Ә менә монысын син хак әйтәсең. Беләсең, шуларны үзеңә яратып кулланасың, файдаланасың, кабахәт!

– Үпкәләмим, әйт! Шулай итмәсәк без байый да алмаган булыр идек.

– Менә синең кебек кабахәт турында сөйләп бетермәдем бит әле.

– Дәвам ит, ихтыярың...

– Бушады, ниһаять. Телефонын тәхетенә ыргытты. Сценарий укыганымны тыңлый.

«...Сабантуй – халкыбызның бик ерак гасырлардан бүгенге көнгә хәтле сакланып килгән иң зур бәйрәме. Аны борынгы болгар бабаларыбыз ислам динен кабул иткәнгә чаклы дәверләрдә үк үткәргәннәр. Гадәттә, Сабантуй язгы кыр эшләре ...»

Ул мине бүлдерде.

– Иртәгә кил, мин сиңа үзем сценарий язып бирәм, – диде.

Менә сиңа мә! Үзе яза икән бит! Нигә мине аптыратып йөртә. Үзем дә җүләр! Никләр риза булдым соң? Ярар. Кызык бит, нәрсә язар икән, белермен.

Икенче көнне төш вакытында тагын мине килеп алдылар. Бардым. Утырам карап. Кайда икән соң моның сценариесы? Әллә берәрсе язып бирде микән?

Бик җитди кыяфәт чыгарып, эндәшми генә өстәле янында йөренгәннән соң, шакмаклы дәфтәр битенә язылган бер кәгазьне алды кулына.

– Мә, – ди.

Укыйм. Биш-алты җөмлә генә. «Сапан туйы сәгыәт ун икедә башлана. Перизидинт киләсе пулгач Хамзә калхусчылар утырган арбада гармун уйнатып бара. Фылак күтәрелә».

– Әйбәт бит инде. Кыска һәм җайлы.

– Шәп, синең сценарий буенча үткәрербез, – дидем. Миңа ул Сабантуй мәйданына каратып ясалган сәхнәдә концерт алып баруны да йөкләгәннәр иде.

– Ну, ничек үтте бәйрәм?

– Әйбәт. Хәбәр иреште, президент килә, дип. Мин, гармун күтәреп, арбага менеп бастым. Колхозчылар җырлап җибәрде. Ат шәп! Куркуыннан атылып китте, мин чак кына арбадан очып төшмәдем. Дилбегә тотучы атның муенын шатырдатып тәртәгә кыскач, тизлек җайланды. Түрәләр утыра торган тирмәнең балконына күз төште. Президент елмая. Шеф канәгать! Мәйдан эчен яңгыратып өч әйләндек тә, читкә чыгып, арбадан коелдык. Мин сәхнәгә менеп киттем. Дөңгердәтәбез генә җырларны. Шеф борчулы йөз чыгарып килеп җиткән.

– Сабантуй флагын күтәрергә кирәк, флаг юк, – ди.

– Кирәктер шул, – мәйтәм. – Табыгыз, күтәрегез!

– Кемнәр күтәрергә тиеш?

– Үткән елгы батырлар.

– Кемнәр соң алар?

– Анысын син беләсең инде. Синең сценарий буенча бара бит бәйрәм.

Мине тыңлап утырган Җәмгыять Иваныч сүгенеп үк куйды:

– Анасын сатыйм. Президент алдында хур булган бит бу.

– Минем анда ни эшем бар! Аның сценариесы буенча бара ич бәйрәм. Үзең дә хупладың, шәп язылган, кыска һәм җайлы, диден.

– Мин каян белим аны...

– Кеше кесәсенә керә беләсез, ә шуны белмисез, мелочына хәтле кырыпсеберен аласыз. Сәнгатьтә мелочь юк. Шуңа күрә сез язучы, җырчы, рәссам, биюче, композитор эшен вакка саныйсыз. Сәнгать шалапайлар эше дип уйлыйсыз.

Ярый, флагын да, күтәрүчеләрен дә тапканнар...

– Шуннан?

– Шуннан нәрсә кирәк?.. Әйт әле үзең?..

– Мин каян белим.

– Белмисез шул. Гимн кирәк күтәргәндә уйнатырга!..

– Анасын сатыйм! Ул да юкмы?..

– Юк. Аның сценарие буенча бара бит.

– Бетергәнсең син моны.

– Мин бетермәдем. Син һәм синең кебекләр, сез тудырган вазгыять, мохит, җәмгыять галәмәте бу. Сез ахмаклар, сез кабахәтләр ясаган тормыш бу, Җәмгыять Иванычлар! Белдеңме? Сезнең сценарий буенча яшибез... Рәсәйне нинди ил диләр әле – Ахмаклар иле, диләрме?! Сез шуның вируслары!

– Җитте! Авызыңны тегеп куярга да күп сорамабыз, һәм үзеңне дә кайда илтеп тыгарга...

– Юлыңда бул!

***

Борчылган кыяфәттә сәхнәгә Наный чыга.

– Нишләп алмый соң ул телефонын? Шалтыратам-шалтыратам, һаман җавап бирми. Тукта, кызым нихәлләрдә яшәп ята икән?

– Кызым, әниең бу. Исән-саулармы! Ә-ә, ярар. Әтиеңме – менә әле һава суларга чыгып киткән иде. Шалтыратам, телефонын алмый. Юк-юк, борчылып әйтүем түгел. Тәрәзәдән урамга карап сөйләшәм синең белән. Әнә, кайтып та килә икән инде. Әтиеңне әйтәм. Озак йөрде шул. Тагын бер кеше туктатты әле үзен. Танымаган кеше юк әтиеңне. Этен ияртеп прогулкага чыккан бер яшьрәк кеше белән сөйләшеп тора әнә... Кем дип?.. Күргәнем дә бар кебек шуны. Юк, юк, начар кеше түгел. Карале, хәтеремнән чыккан исеме, артист инде ул... Син дә беләсең аны. Тавышы калын, үзе нечкә. «Җаныем-бәгърем»не җырлый. Сәхәбиевмы? Юк ла инде. Сәхәбиевны мин таныйм бит. Ә менә хәзер син аның кем икәнен әйтәсең: ул үзен элитный йортта тора икән дип уйласыннар өчен, этен гел безнең ишегалдына алып килеп йөртә. Исеңә төштеме инде? Әйе, әйе, аның кушаматы бар – «Думдук». Шул Думдук инде. Тәки моңа хәтле тулай торакта яши бит. Җәмгыятебез шундый булгач нишләсен инде?! Әйе шул. Ярый хәзергә, сау бул!

Улымнан бу араларда бер хәбәр-хәтер юк. Нихәлләрдә икәннәр?

– Улым, нишләп ятасыз? Ә-ә, безгә килгән идегезмени? Вундеркинд беләнме? Оныкны әйтәм. Карале, «теге» барында күренеп йөрмәсен, гел шунда чуала... Әйе шул, эшең тыгыз, беләм. Үзем шалтыратам шуңа күрә. Хатының авырыймыни? Дарулар эчертәсеңме соң? Борчылма, дисеңме? Төчкерер, төчкерер дә бетәр, дисеңме? Ничек борчылмыйсың инде. Балага йога күрмәсен, инфекция йөри бит шундый әшәке. Аптекага үзең чык. Чыктыңмыни инде?

Кем иярде, дисең? Бер егет? Нишләп сиңа иярде соң ул? Аптекага кергәнче генәме? Тышта калдымы? Ә-ә, алай икән. Чыккач, һаман көтеп торамы? Нәрсә кирәк соң аңа? Син Шәрәфи улымы, дигән буламы? Бер йөз тәңкә акча биреп тор әле, диме? Эчәргәдер инде. Борыны кызылмыни? Күргән кешеңме соң ул? Юк? Вәт, кешеләр, бер таныш түгел адәмнән оялмыйча көпә-көндез акча сорыйлармы инде? Бирдеңме соң? Юк, дидеңме? Кыйнап ташламасын тагын. Хәер, син үзең махы бирә торган егет түгел. Тимәдеме? Юкмы? Ни ди? Менә шулай итеп татар егетләре әрәм булып бетәләр инде. Әстәгъфирулла! Ир башы белән шундый сүз әйттеме? Син гаепле булып калдыңмыни инде хәзер моның махмырдан интегүенә. Кая карама шулар хәзер һәм бомжлар, этләрдән дә күбрәк. Этләргә дә рәт юк инде, улым. «Аларга инфаркт буламы?» – дип сораганнар берәүдән. «Була, этләргә дә кешенеке төсле яшәү шартлары тудырсаң», – дип җавап биргән ул.

Ярый, улым, сау булып тор. Бу ял көннәрендә тагын килеп чыгыгыз безгә, яме!

***

Шәрәфи, кайтып керешкә сөйләнә башлады:

– Урамга чыксаң да шул, монда да шул. Кругом беда. Картаюдыр инде: элек шатландырган нәрсәләр, хәзер ачуны чыгара.

– Нәрсә булды? – дигән сыман карап алды аңа Наные.

– Кайтып киләм, каршыма авылдашым Салих очрады. Яшьтәш.

– Теге аргы яктагы урамда яши торган чулак Салихны әйтәсеңме?

– Әйе.

– Карале, исән-сау икән. Ходай Тәгалә алга таба да аңа бәрәкәтле еллар иңдерсен!

– Шулай. Сорый бу миннән. Каян кайтып киләсең, кордаш? Бүлнистән, – мәйтәм.

– Ник алай дип әйттең инде?

– Үзе дә авырый торгандыр, хәлләребез бертөсле булсын дип уйлаган идем. Кеше бит хәзер үзе чирле булса, кешенең таза-сау йөрүен бик яратып бетерми. Шуңа күрә, шулай дип әйттем.

– Шуннан?..

– Бу да сүзен бик үлчәп бетермәде ахрысы: йә, кайчан үләсеңне әйттеләрме, дип шаяртып алды булса кирәк. Юк. Әле сиңа кадәр авылдашың Салих бар, диделәр, – дидем.

– Ишкәнсең икән ишәк чумарын.

– Шулай шул... Безнең авыллар шундыерак бит.

– Бөтенесе синең кебек инде.

Кыен хәлдән чыгару өчендерме, сүзгә Хәмзә кушылды:

– Безнең авылда мал врачы авырып китә. Моңа табиб чакыралар. Кешенекен. «Кая, кай җирең авырта?» – дип сораштыра башлый бу авырудан. «Мин маллар янына баргач, сөйләштереп тормыйм бит, карыйм да дәвасын билгелим», – ди, моңа җавап итеп мал врачы.

Табиб авыруның хатынына:

«Алай булгач, апа, менә шушы даруларны эчертеп карагыз да, ярдәме тимәсә, егып чалырсыз», – ди дә, чыгып китә.

– Нигә көлмисез? – дигән сүзләренә җавап бирүче булмагач, Хәмзә гаилә темасына күчте.

– Ну, Шәрәфи Шиһапович, сайрашып та яшисез инде!

– Ул әйбәт, мин түгел. Гаилә җылысы хатыннан тора.

– Хатын-кыз кияүгә чыккач, күп ирләрнең игътибарын берәүнең игътибарсызлыгына алмаштыра икән бит.

– Мин алай булмадым – чын-чынлап яраттым һәм тик аны гына!

– Ир кешенең иң зур бәхете шулдыр инде?

– Бәхет ул – чагыштырма нәрсә, бар чагында аны сизмисең, ул югалгач кына сизелә, Хәмзә дус.

– Бәхетне, мәсәлән, юктан да табарга була. Менә мин хезмәт хакы алудан да шатлана идем элек. Чөнки ул минем эшемнең әһәмиятенә бәрабәр иде. Шуңа гаиләңне тәэмин итеп яшәргә була. Өйгә кирәк-яраклар алырга, җиһаз-фәләнгә җыярга җиткерә идек. Үзеңне ул замандагы җәмгыятьнең кирәкле, файдалы кешесе итеп тоясың, һөнәр кешеләренә хөрмәт белән карыйлар, яхшы эшләсәң – үстерәләр. Мактаулы исемнәр биреп, күңелне үсендерәләр. Син илеңне, Ватаныңны яратучы патриот булып яшисең. Ә хәзер нәрсә? Патриотлар бармы бездә? Ватан бармы? Сатмадылармы аны алай-болай, безнең белән бергә?! Ник эндәшмисең, Шәрәфи Шиһапович!

– Дөресен генә әйткәндә, инде бу яшьтә ялкынланып сөйләшәсе дә килми. Ни өчен дигәндә, без канаты сынган кошлар. Очып китәр идек – гарип без, гарип... гарипләндерелгәннәр... Ай, ничек үкенечле!..

Кәккүкләрдәй моңланыр ил түгел дә,
Былбыллардай сайрар җир түгел.
Елама, җаный, ник елыйсың,
Без бу җирләрдә бит ир түгел...

Яшьләр китә. Менә шул кошлар кебек алар. Ләкин, ләкин, ләкин... Китәләр дә яңадан кайталар. Менә, дустым, уйла әле, ни өчен алар җылы якта бала чыгармыйлар. Нигә кирәк аларга монда кайтып, балалар үстереп, салкыннар башлангач, яңадан китәргә? Мин моны бары тик бер нәрсә белән генә аңлатам: кошлар да туган якларына сагынып кайталардыр, ямьледер монда, гүзәлдер бу җирләр, җимледер...

Татар баласы кая киткән булса да «Кәккүкләрдәй моңланыр ил түгел» дип чит җирләрдә әлеге җырны җырлар!

– Башкача яшәп булырмы соң? – Була, билгеле!..

– Ничек?

– Наный, чыгар әле Хәмзәнең үзе алып килгән җимеш суын! Әйдә, шаулатып дөньясын бер җырлап утырыйк әле!

– «Ай-ли авылда, рәхәт тормыш калхузда!» – дип җиппәрә иде минем бабай кәефе килгән чакта «Алмагачлары» көенә.

Бабай да, әти дә сугышта булганнар. Бабайны гына сөйлим. Ул Волхов фронтында пленга эләккән, чолганышта калып. Власов бөтен гаскәрен немескә калдыра бит.

Концлагерь. Берзаман боларны советка каршы легионнарга җыя башлаганнар. Ничек инде мин үзебезнекеләргә каршы барыйм дип уйладым, ди. Язылмаган легионга. Аннан соң, байтак вакытлар, әле бер концлагерьдан икенчесенә күчереп, бик озак интектергәннәр аларны һәм ахырдан Алманиядә эшләргә таратканнар. Ул, мин бер фраумадамга эләктем, ди. Болай миңа начар мөнәсәбәттә булмады, иртәдән кичкә кадәр хуҗалыгында, кыр-басуда эшләтте,

ди. Радиодан гел герман гаскәрләренең Мәскәүне, Ленинградны, Сталинградны алулары турында сөйләгәннәр.

Бабай безнең ил беткән икән дип уйлап йөргән.

– Шулай радиодан гел тукып торгач, ышанмас җиреңнән ышанырсың, – дип ухылдап куйды Наный.

– Ләкин, соңрак, радиолары тавышында да моңсулык сизелә башлаган. Фраумадам да боеккан. Ире дә һәлак булган. Кешеләр дә бабайга сәеррәк караш ташлый башлаганнар.

– Әһә, асларына юеш йөгергәнме?!.

– Алар өчен күңелле хәл түгел инде, Наный ханым.

– Ә безнекеләр монда күпме кан-яшь койган?..

– Сугышның бөтен ахмаклыгы, мәгънәсезлеге шул чакта ныграк беленә башлый шул...

– Шулай, Шәрәфи Шиһапович.

– Менә бит хәзер дә сугышып яталар әле, һаман акыл керми.

– Байлык җитми, җир җитми. Нәфес!

– Ах, шул нәфесне нишләтергә? – дип Наный да уфтанып алды, ачынып.

– Ничек соң, бабаң исән-сау кайтканмы?

– Кайткан. Хәтердә, илле өченче елны, өйдә без бабай белән икәү генә, ниндидер кешеләр килеп, бабайга медаль тактылар. Алар киткәч, бабайның күзләрендә яшь күрдем. Шул чакта нигә ул елады икән дип уйлаганыем. Сталин үлгәч ул медальне пленда булганнарның күбесенә биргәннәр икән. Ә бит сугыштан соң, шушы медальне биргәнчегә кадәр, алар «сатлык җаннар» булып исәпләнеп, эшкә урнашырга да рөхсәт ала алмаганнар. Шуңадыр, бабам медальне чүпрәгеннән өзеп: «Мә, улым, акчалы уйнаганда аткыегыз юк бугай», – диде дә шуны кулыма тоттырды.

– Ай-яй, бигрәкләр бәгырьләренә төшкәннәр икән...

– Әйе, рәхимсез вакытлар, Наный ханым.

– Ә хәзер ул чаклардан артык чамабыз бар мәллә? Юнь күрсәтәләрме авыл халкына? Әллә эш бармы? Бирегез, табыгыз аны авылдагы алыптай егетләргә, җимештәй өлгергән кызларга, апаларга, абыйларга! Сугыш юк бит илдә! Аларның куллары эш сорап тилмерә!

– Кызма әле, Җаный. Тагын нервысы чыкты инде. Мә, монысы йөрәктән – тынычландырыр, әйбәт таблетка.

– Анда безгә малай белән онык килгән, дисең, нигә без өйдә юк чакта килгәннәр соң инде?

– Килен авырып тора икән. Дару алырга әптиккә чыкканнар да улы әйдәләгән.

– Вундеркинд – шайтан малай, «теге» нәрсәне кымтырыкларга чамалый инде ул, аннан соң белә безнең театрда икәнне.

– Шундый оныгыгыз бармыни?..

– О-о! Ут! Белмәгән, кызыксынмаган нәрсәсе юк шуның, Хәмзә.

– Димәк, бабасына охшаган!

– Хуже. Нәрсәдә тукталып калдык әле? Әйе. Син бабаң турында сөйләдең, мин эти турында әйтеп китим әле.

Минем эти сугыштан бөтенләй кайтмады. Сугыш кырында ятып калган, диделәр. Ул бик батыр кеше булган. Илле немесне берүзе әсир иткән бит. Киявем аның өч батырлыгын Интернеттан тапкан, һәр батырлыгы геройга тиң. Ул Краков шәһәре тирәсендә сугыш бармаганда үлә. Әти турыдан яра торган кеше.

– Син дә шулай.

– Әйе. Андый кешене, үзең беләсең, бик яратмыйлар, сугышта бигрәк тә. Шуңа күрә «герой» исеме дә бирмәгәннәр аңа. Әтине атып үтергәннәрдер дигән фикердә мин, чөнки безнең авылның бер кешесе аның белән бергә сугышкан, ә ул, авылга кайтып, безне җыеп сөйләшмәде дә – тып-тын. Әтине безнекеләр аткандыр, дидем. Батырлар сугыштан соң кирәкми. Менә хәзер кайберәүләр яратмыйлар бит сугыш турында сөйләшкәнне. Ул, әтием минем, дөресен сөйләячәк иде.

Үкенечкә калды... Мин аның үлгән җиренә барып кайта ала идем... Аның портреты минем бүлмәдә тора. Йөзендә миңа үпкәсе бар кебек. Сугышкан чакта үлми ул, ә батырларча һәлак булды дип язалар...

– Синең әтиеңнең тормышы белән минекенеке чагыша икән...

– Әтием турында минем берәүгә дә сөйләгәнем булмады. Бер генә мәртәбә күз алдымда калды ул зәңгәр томан артында.

Безнең олы гына мич бар иде, аннан соң, подтопка – җылыту өчен генә яга торган, ул менә шуңа сөялгән. Бер кырыйда сәке, сәке кырыенда ирләр ашап-эчеп утыралар. Әти басып карап тора, мин почмак ишегеннән күзәтәм. Тышта яңгыр, пычрак. Болар Корноухово ягыннан килгәннәр дә, авылны чыгып барышлый, безгә юнәлгәннәр, чөнки авылдагылар аларның берсен дә кунарга кертмәгән, әти керткән. Шулар булмады микән дим мин бу ашап утыручыларны. Атлары, арбалары бар. Болар чыгып киткәч, әти карый, бүкәнгә кадап куелган плотник балтасы юк. Хәзер бу атка атлана да чыгып чаба, авылларына барып җитәрәк куып җитә дә җайлап кына: кайсыгыз алды балтаны, ди. Юк, алмадык, диләр, тегеләр.

Шуннан әти кабатлап: карагыз! Кайсыгыздан чыга, җәзасын үзегез бирегез, ди. Табалар. Кыйныйлар тегене. Әти балтасын алып кайтып китә.

Менә шундый кеше булган минем әти!

– Чын коммунистлар алар! – дип, кысылып куйды Хәмзә.

– Райком кабинетларында кода-кодагыйлык керә башлап, төптән тәҗрибәсез килеш өскә үрмәләгән бай балалары утыра. Борын аслары кипмәгән, ат җигә белмәгән нәмәрсәләр фашистны бугазлап кайткан абыйларын өйрәтәләр бит, – дип кулын гына селтәде Шәрәфи, дөньядагы хәлгә уфтанып.

– Ә хәзергене әйтсәк...

– Хәзергене әйтәсе дә юк. Бүлнискә барырга куркыныч...

Кем малае ул хирург?.. Кем кызы ул – терапевт? Бөтенесенең фамилиясе министрларныкы яки депутатларныкы!.. Яра беләләр, тегә белмиләр. Ала беләләр, бирә белмиләр.

– Белемнәре җитми?

– Сорап торасың тагы. Мәктәпкә ЕГЭ, институтка акча биреп, ничек булсын ди белем?! Әле беркөнне мәгариф министры сөйләгәнне тыңладым. Ольга Юрьевнаны. Ул әйтә: «Мин телсез калдым, – ди. – ЕГЭ АКШта уйлап чыгарылган икән бит. Беләсезме ни өчен? Үсеш чамасы түбән булган балаларның белем дәрәҗәсен күз алдында тоту өчен. Андыйларның телдән җавап бирү мөмкинчелеген ачыкларга шулай җайлырак икән. Болай укытучыларның да эш сыйфатын бәяләп була, укучыларныкын да, шуңа менә әлеге сораулар уйлап табылган. Ә безнең хөкүмәт моны үрнәк итеп алган һәм кайчандыр дөньяда иң яхшы булган бездәге белем системасын «табышмак»ка әверелдергән».

Нигә тел шартлатып утырасыз? Хәер, безгә телнең шартлатып утырырга гына кирәге калыр, мөгаен.

– Алай ук төшенкелеккә бирелмә әле, Җаный, – дип куйды Наный, шактый озак эндәшми тыңлап торганнан соң. – Безне дин коткарыр.

– Әйе шул, динне телсез дә тотарга була. Утырасың шунда дисбе тартып, эчтән мыгырдап.

– Алай димә, Җаный, Ходай ишетер...

– Ишетсен, ул мине шулай тудырган – дөреслекне әйтер өчен. Мин беркайчан да ялган сөйләмим, сөйли дә белмим мин аны, шуңа күрә тотылмыйм да. Кайберәүләр көненә биш намаз укый, унбиш кешене алдый, шул хәтленекенең кесәсенә керә, шулай бит, Хәмзә?

– Дөрес әйтәсең. Андыйлар күп. Дин, дигәннән, сез миңа бөек рус язучысы Купринның дин турында әйткән сүзләрен искә төшердегез. Без татарларга карата да җылы фикерләр бар аның җөмләләрендә. Ул яза:

«Гаҗәеп яхшы татар халкы, алар барысы да намуслы, сүзләрендә торалар, пөхтәләр, кыюлар, гүзәлләр, тумыштан оста җайдаклар һәм шәп сугышчылар. Ә диннәре шул хәтле гади, шул хәтле җайлы, уңайлы, бернәрсәгә комачауламый һәм кешене күкләргә күтәрә. Их, шуны аңламаган бөек кенәзебез Владимир, Кызыл Кояш, тукталырга иде аңа ислам диненә, сайларга иде Мөхәммәтнекен! Шулай эшләгән булса – без инде хәзер...»

– Нишләгән булырлар иде? – җавабын ишетеп бетерәсе килде Наныйның.

– Менә анысын әйтеп бетермәгән...

– Дөньядагы иң бай, иң куәтле, иң гадел ил – без булыр идек. Әнә нефтьле гарәп илләренә карагыз! – дигән горур уйчанлык туды Шәрәфидә.

– Тынгы бирмәсләр иде... – дип каршылыклы фикер өстәде Наный.

– Юк, безнекедәй көчле, зур илгә борыннарын да тыга алмаслар иде, – дип эреләнеп куйды Хәмзә дә.

– Хакимлек кемдә булыр иде илдә?

– Илдә, димә, Наный, империядә, диген!

– Дине Мөхәммәтнеке булгач, халкы татар була түгелме соң?

– Менә шулай булырга тиеш булган шул! Их, Кызыл Кояш, Кызыл Кояш! Куприн әйтеп бетермешли, булмаган синдә баш, булмаган синдә баш! Эчәргә рөхсәт биргән динне сайлагансың бит! Менә хәзер бөтен ил белән эчеп ятабыз – нәтиҗә!

Наный, бар әле бу нәмәстәкәйне чыгарып ат!

– Син нәрсә, Хәмзә күчтәнәченме? Даруны!

– Гафу, гафу! Әйдә, бисмилланы әйтеп, дару кабып куйыйк алайса! Җимеш суын, әйеме, Хәмзә!

– Әлбәттә!

– Мин һич шикләнмим... Дустым, әйдә, «Тымытык»ны сыздыр әле.

Яңа бер җыр туды, диеп,
Сөенче алыйк әле.
Ык буенда буй үстереп
Мәңгегә калыйк әле, һәй!
Тыммы, тыммы-тыммы Тымытык ла,
Тымытыкның төнбоеклы сулары.
Су буенда кер чайкыйлар
Кызлары ла, кызлары ла, кызлары.

Җыр уртасында Шәрәфи сөйләп китте:

– Бер төнне төш күрәм – шушы җырны Әҗәл белән җырлыйбыз. Җыр көенә кызып китеп, бераз биеп тә алгач:

– Син каян беләсең бу җырны, – дип сорыйм моннан.

– Аны бит Хәмзә җырлый, – ди.

– Мин биргән гәҗитне укыгач белдеңме бу мәгълүматны? – дим.

– Әйе. «Сираҗи сүзе»ннән, – ди. – Маладис!

– Мин кешеме инде хәзер? – ди бу.

– Юк әле.

– Үзең бит бу гәҗитне укысаң, кеше булырсың, дигән идең.

– Юк әле, син ноль бөтен йөздән бер Сираҗи гына булып киләсең. Кеше булыр өчен сиңа «Идентификационный номер» кирәк. – Иден... Иденти... Иденти... фикционный.

– «Фикция» түгел, Идентифи-ка-ци-онный. «А»га басым.

Аннан соң, страховой таныклык, медполис – номерлары белән. Пенсиядәме син? Ничә яшь? – Яшәү кәрҗине... Карале, боларың булмагач, син юк бит. Болар бар икән – без бар, без кеше. Ә синең юк, димәк, син – юк. Хатының бармы?

– Юк.

– Димәк син әле ир дә түгел. Нигә Ленинны алып китмисең соң син? Мавзолейда интегеп ята. Шуны алып китеп, әйбәтләп Газраил белән күмсәң, менә дигән кеше булыр идең. Илдә егетләр дә, ирләр дә юк, шуны күммиләр. Күмү генә түгел – нишләргә белмиләр. Менә син алып чык та күм! Бар, бар, йөрмә монда, номерлар ал, гәҗит укы, Ленин сине үлгәннән бирле көтә. Аның иң нык көткәне – син! Нигә кергәндер ул төшкә. Шуңа аптырап куйгалыйм?

***

Сәхнәгә режиссёр Зирәк Мудриевич күтәрелә.

– Шәрәфи Шиһапович, тамаша әйбәт кенә бара, бераз төзәтмәләр кертербез әле соңрак, кәнишне. Хәзергесе моментта сюжет таптаныбрак тора. Бәлки, өстәмә персонаж кертербез, ә? Әйтик, Тарихи Сабак?

– Ваклandырма сюжетны. Булганы белән тормышыбызга анализ ясасак, әйбәтрәк булыр.

– Ничек итеп?

– Бер карасаң вак мәсьәләләр юк безнең тормышта. Мин, мәсәлән, нәрсә сөйләсәм дә, әлбәттә, үземне күзәтәселәрен беләм, телефонымны тыңлыйлар, шуңа карамастан, беркемнән дә куркып тормыйм. Шунысы яман, кайвакытта үзем сөйләмәгәнне минем исемнән әйткән кешеләр бар. Бу нәрсә бик әшәке. Мисал китерәм: берәү минем алда 42 минут репетиция ясады – сүкте безнең бер җитәкчене һәм мин бу турыда Наныйга кайтып әйттем. Мәйтәм, менә шушы сүзләрен ул мин әйтте дип тегеңә җиткерәчәк. Шуннан соң әлеге җитәкче минем белән бозылыбрак йөрде, ә бу кабахәт койрыгын бот арасына кыстырды – мин әйтер дип курыкты. Мин икесенең берсенә дә ым какмадым. Бу хәл вакыт үтә-үтә онытылды, ә моның күңелендә мәңгелеккә калды.

– Нәрсә турында иде соң ул?

– Бик начар итеп сөйләде җитәкчебез турында. Шул гына. Ә үзе аның көчеге булудан узмады.

Менә шундый пычрак кешеләр бар, иптәш Мудриевич.

– Дөнья тутырук алар хәзер.

– Җәмгыяте шундый. Кешеләр бер-берсен ашый торган заман. Шуңа күрә дә кызып киттем мин бүген. Болай яшәп булмый алга таба. Үзгәртергә кирәк җәмгыятьне, кешеләрне тәрбияләргә кирәк, җаннарын нурландырырга,

карашларын үзгәртергә, максатларын өметләндерергә, яшәүләренә сөенеч өстәргә кирәк.

– Хәзерге вакытта син, Шәрәфи Шиһапович, ник туганыңа үкенәсең кебек.

– Туу миннән тормаганга, үкенмим. Әгәр ул миннән сорап торса, бәлки үкенгән булыр идем. Кайвакытта, тумаган булсам әйбәтрәк булмас иде микән дип уйлап куям.

– Менә бит Илһам абый Шакиров та үзен: «мин иң бәхетсез кеше», ди. Мин дә үземне бәхетсез дим. Бу илдә йә бик ахмак, йә бик кабахәт кеше генә бәхетле була ала, мин берсе дә түгел.

Кызып-кызып сөйләшеп утырасыз икән, дигәндәй, каядыр югалып торган Хәмзә керә-керешкә сүзен башлады:

– Һаман шул бер балык башыдыр – җәмгыятьне сүгәбездер инде.

Сүкми дә булмый шул. Һәр вак мәсьәлә дигән нәрсә артында җәмгыять тутырган җитешсезлекләр ята. Без шул турыда сөйләшәбез, бәхәсләшәбез. Менә алыйк телевизорда бара торган «Терәлү киртәсе»н. Анда төрле катлаулы темаларга, кешелек алдында торган кыенлыкларга җавап бирергә маташалар. Катнашучы кунаклар бер-берсен уздырып, башкалардан акыллырак булырга тырышып, очына-очына бәхәсләшә башлыйлар. Бәхәс, кайвакытта, сугыштырыр хәлгә җитәргә мөмкин. Ләкин куелган сорауга төгәл җавап бирә алучы юк, чөнки тапшыруны алып баручы каравылда тора. Алай-болай берәрсе гаепләләрне, җаваплыларны бармак бөгеп саный башласа, килә дә кысыла. Ул, «прези...» дигән ике иҗек чыгу белән, сүзне икенчегә бора. Яки «Пу...» дигәндә ахырдан «н» хәрефе чыгачагын сизеп, «без мәсьәләгә якынрак килик әле», дигән булып, фикерне ераккарак озата. Югыйсә бит, тапшыруга килгән һәр белгечкә, үзәккә социаль мәсьәләләр куелган булса, җәмгыятьнең торышыннан эзләргә кирәк җавапны, инде дә фикер куәсең төплерәк булсын дисәң, милләт югарылыгыннан сөйләргә мәҗбүр ит үзеңне. Юк. Янәмәсе, вакыт җитмәү сәбәпле таралышалар, «Киләсе очрашуларга кадәр сау булыгыз!» дигән булып. «Пока, пока!» дип тә куялар әле кайчакта.

– Иптәш Мудриевич, дөрес әйтәмме?

– Әкәмәт мач!

– Ә сез менә спектакльләрне нинди максаттан чыгып сайлыйсыз?

– Ни инде... классик драматургларга мөрәҗәгать итәбез.

– Ничек аларга? Алар исән түгел лә инде?

– Әсәрләре китапта бит. Аннан соң, безнең театр белән тыгыз элемтәдә булган драматурглар бар.

– Димәк, танышлар белән...

– Пьесаларга конкурслар игълан ителә.

– Ярар... Хуш... Шуларны куясызмы?

– Күңелгә ошаганнарын куябыз. Ләкин алар бик аз.

– Җәмгыятькә, бүгенге тормышыбызга туры караш төбәгәннәре бармы?

– Бар.

– Ник куймыйсыз шуларны?

– Нигә икәнен үзегез дә беләсез бит инде.

– Менә шуңа күрә безнең театр эше дә халкыбыз мәнфәгатьләрен канәгатьләндерерлек репертуарлы түгел. Телевидениедәге «Терәлү киртәсе» кебек кенә булып чыга.

– Ә сезнең үзегезнең дә бит әле андый пьеса яза алганыгыз юк.

– Ник булмасын?! Мин ике мәртәбә «Татар империясе» дигән сатирик

әсәрләремне Камал һәм Тинчурин сәхнәсендә куйган кеше. Әнә, Шәрәфи ялганнарга ирек бирмәс. Шулаймы?

– Шулай.

– Аннан соң «Әлфия Авзалова кияүгә чыга» дип аталган җырлы-юморлы тамаша эшләдем. Монысында да үзем режиссёр идем. Шәрәфи кияүне уйнады. Тамада ролен дә башкардым.

– Матур тамаша иде ул, аны синнән башка берәү дә уйлап чыгара алмый шул, Хәмзә дус.

– Ул тамашаны без өнәп бетермәгән депутат халкы да мактады әле ул чагында. Нигә менә мондый тамашаларны телевизордан күрсәтмисез дип, телевидение җитәкчеләренә шелтә белдерделәр.

– Өстәлдә аракы бар иде, шуңа күрә эфирга чыгара алмадык дип акланганнардыр...

– Дөрес әйтәсең, Мудриевич, эш бит аракыда түгел, тамашаның матур булуында, тирән эчтәлегендә, тәрбияви әһәмиятендә, программасының югары зәвыклыгында һәм үрнәгендә иде.

Менә карагыз, бүген дә өстәлдә ул утыра. Хөрмәтле тамашачылар, ул сезгә комачауламыймы? Бозамы ул бүгенге тамашаны? Әллә эчтәлекне баета гынамы? Ну, без аны өстәлдән алып куйдык, ди. Аның түрдә утырмаганын күреп, сәрхуш эчүдән туктыймы? Киресенчә, сәхнәдә аңа карата нәфрәт уяту кирәк. Аракыны беребез дә әйбәт нәрсә дими, ләкин ул безнең җәмгыятебезнең аерылгысыз дусты. Шуңа ул җәмгыятьнең хәле дә әллә ни мактанырлык түгел.

– Чыннан да шәп иде ул тамаша! – дип сөйләү дәртен куәтләп җибәрде Шәрәфи Хәмзәнең.

– Мин ул тамашаны ни өчен эшләдемме – юньле, әйбәт концертлар эшләп була икәнен күрсәтергә. Артистлар анда катнашырга атлыгып тордылар, хәтта үзләренә түләү турында авызларын да ачмадылар. Ул концерт эстрада артистларының активлыгын көчәйтеп җибәргән иде. Кара син, Бөек Әлфия апабыз Үзе баш геройны уйнады бит! Рәхмәт әйтеп, башымны сыйпаган җылы кулларының назын әле дә тоям.

Эстрадабыз таркау. Берләштерү өчен менә шундый күмәк тамашалар кую кирәк.

Элек җырлар моңлы иде –
Илһам күк былбыл кирәк!
Аның янында башкалар,
Чыпчыклар кебегерәк.

Әлфия кебек җырлаучы
Юк хәзер – шундый кирәк!
Шырды-бырды җырлаучылар,
Такмакчылар күберәк!

– дип язып куйдым мин күптән түгел, эстрадабызга күз йөртеп, аптырап калгач.

– Кибет төбендә вак-төяк сатып утыручы әбиләр дә шагыйрь хәзер, – дип куйды Шәрәфи.

– Тозлаган кәбестәсен тәкъдим итүчесе:

Уң якта да «Магнит» бар,
Сул якта да «Магнит».
Рәхәтләнеп яшәр идем,
Акчам гына менә нет...

Икенчесе күтәреп тә тормады, сөйли башлады:

Анда да «Эдельвейс»лар,
Монда да «Эдельвейс».
Гади халык коры чыбык,
Ә хуҗалар – сип-симез!

Әле сөйләгән сарымсак сатучысының шигыре бетәр-бетмәс өченчесе башлады:

Адым саен гипермаркет,
Адым саен әптикә.
Секунд саен ашыгыч ярдәм,
Тәмугка алып китә.

Җылы оекбаш сатып утыручы әбинеке менә мондый:

Һәр йорт астында банклар,
Һәр кеше кредитта.
Хатын-кызлар декретта.
Президентлар банкетта,
Әбиләр кризиста.

– Мин гомер буе тәҗрибәләр ясарга яраттым! – дигән кыяфәттә беразга катып торды бөек актёрыбыз, әбиләрнең шигырен сөйләп бетергәч.

– Ярый гына кызыклы төсмер ала түгелме соң әле бу үзгәреш! – диде дә Хәмзә, блокнотын чыгарып, нәрсәдер теркәп куйды. – Әйдәгез әле, егетләр, шул хөрмәткә ирен калынлыгы гына итеп җимеш суын бәяләп алыйк.

– Шәп! – диде режиссёр, рюмкасын бушатып.

– Шәп кенәме соң! – дип куәтләде аны Хәмзә.

– Чиста! Әйбәт күчтәнәч! Бу нәрсәдә син профессор, ахрысы. Чын әрмән коньягы! – диде Шәрәфи дустының Хәмзә булуына ишарә ясап.

Коньяк шешәсендәге язуларны өйрәнеп утырган режиссёр:

– Киләсе күчтәнәч миннән булыр! – дип масаеп куйды, имеш, ул да хәзер Шәрәфинең иң якын дусты.

Юморның да рәте юк бит –
Сәхнәдә әтрәк-әләм
Бетте юмор, пеләшләнде,
Мин үзем кебегерәк,

– дип үзе язган шигырен чәпелдәтеп куйды Хәмзә бу төштә.

– Безнең сәхнәдә дә шул дәрәҗә...

– Рәхмәт, Мудриевич, объектив карашыңа!

– Беркөнне телевизордан балалар тапшыруын карадым, – дип сөйли башлады Мудриевич, – шул хәтле ошады, шул хәтле ошады! Алар матур итеп татарча сөйләшәләр. Шигырь сөйлиләр дә: «Вау!» – диләр, җырлыйлар да: «Вау!» – диләр, бииләр дә: «Вау!» – диләр. Аннан соң бер кечкенә кыз мондый шигырь сөйләде:

Минем исем дә горур яңгырар
Телевидениедә.

Шуның өчен көн-төн татар теле
Бетмәвен телимен дә.

Барысы да режиссёр яраткан сүзне кабатларга тотындылар:

– Шулхәтле шәп! Шулхәтле шәп! Вау, Вау!

– Менә сиңа бүләк – китап! Минем иң яраткан язучым Герцен язган аны. Укы. Югалтма! Алып килерсең. «Үткәннәр һәм уйланулар» дигән автобиографик китабы ул аның, – дип, Шәрәфи Мудриевичка бүләк бирде. – Билләһи чын кеше ясыйм мин синнән! – дип өстәп тә куйды.

Һәм, күптән хәтерендә тотып та, үзе күренмәгәч артык борчымаска теләгән хатынын чакырды.

– Наныем, син монда гынамы?

– Әйе, Җаный, балалар, оныклар белән сөйләшеп, мавыгыбрак киткәнмен.

– Өйдә, гаиләләрендә тынычтыр бит?

– Бар да әйбәт, Аллага шөкер! Кызның да баласы белән безгә килергә исәбе бар.

– Килсеннәр. Өйнең астын-өскә китерәләр икән инде тагын.

– Боздә иркен бит – уйнасыннар!

– Анысы шулай, «теге»нең белән шаяра күрмәсеннәр инде. Үзең кайтып килмәссеңме соң?

– Кайтыйм әле, алай дигәч. Җаның тынычрак булыр яннарында мин булсам.

– Шулай ит!

***

Шәрәфи хатынын озатырга чыгып керде. Шул чакта залда ут кабынып, тәнәфескә чакыручы музыка яңгырады. Ләкин тамашачының ник берсе чыгып китсен. Чөнки сәхнәдәгеләр һаман уйныйлар иде. Бөек артист кабат сәхнәдә күренүгә, тамашачыларның урыннарыннан күтәрелгәннәре дә кабат утырдылар. Җылы гына кул чабулар булып алды.

– Иптәш Мудриевич, Җәмгыять Иваныч күренми, кая югалды икән?

– Буфетта ул. Калын иренле ике кыз белән утырып калган иде.

– Бар, төшеп алып мен әле шуны.

– Аның кыяфәте халыкка күрсәтерлек түгел.

– Кайчан син җәмгыятьнең халыкка яраклы чагын күргәнең бар? Без монда Хәмзә белән көтеп торабыз. Бар, бар! Әйтми калганнарын әйтәм мин аңа, алайса ник туганыңа үкенә башлавың мөмкин.

Картаям, ахрысы – элек шатландырган нәрсә, хәзер эчне поштыра. Ниндидер яхшы эш эшләргә тотынасың, ә ул начарга китереп чыгарыр. Изге гамәлеңне хилафлы юнәлешкә борырга маташулар барлыкка килә. Кешегә файдасы булыр дип уйланылган фикерләр синнән урланып җәмгыятькә каршы эшли башлый.

– Шәрәфи дус, кемне иң якын дустың, фикердәшең дип саныйсың?

– Әйтә алмыйм. Ныгытыбрак уйласаң, синең белән фикердәштер. Башкалары йә куркалар, йә яшьләр, йә мин инде аларның кем икәнлеген күптән беләм, аннары күпләре бөтенләй гамьсез кешеләр. Шулай да, бик үк бетереп тә әйтеп булмый. Дус түгел, әмма егетлекләре булганнары да бар араларында.

– Тәрҗемә кылуыңнан ни кызык табасың?

– Марсель котыртуы белән генә башладым мин аны. Берне эшләдем дә, карале, әйбәт чыга бит, диде.

– Тәрҗемәләрең шәп, Шәрәфи дус, чыннан да.

– Ә менә җитди әйберләр тәрҗемә итеп карыйм – чыкмый.

– Эшләгәннәрең җитди түгел дип әйтеп булмый. Мин хәзер шул хаклыгымны исбатлыйм, килешерсеңме? Нигә соң бөек даһиларыбыз Пушкин, Лермонтов, Тукай, әйтеп бетерә алмаган нюансларны, фикерләрне, сүз уйнатуны шундый жанрда язганнар? Бик уңышлы кулланганнар бит! Әйеме?!

– Пушкинның бер шаяртуын синең дә ишеткәнең бардыр бит? Кызлар балконда торганда әйтәләр икән моңа: «Пушкин, напиши нам стихи?!.»:

> На небе три звезды,
> На балконе три...

Ә мин бу юлларны татарчага болай әмәлләдем.

Шәрәфи Хәмзәнең колагына үрелеп, нәрсәдер сөйләде. Рәхәтләнеп көлделәр...

Мин бөек түгелмени?

– Шәрәфи дус, син минем белән булган хәлне искә төшерттең. Губкин урамындагы бер йортның балконыннан кызлар кычкыра. Балконның идәне җәелмәгән, арматура гына: «Хәмзә, Хәмзә, пеләшең ялтырап күзне чагылдыра», – диләр. «Ә мин җирдән ни нәрсәгез күренгәнен әйтмим бит әле», – дим. Чыркылдашып өйләренә кереп качтылар болар.

– Пушкинчарак шигъри юллар белән әйтсәк:

> Балконда – өч кыз
> Өчесе дә ыштансыз.

– Синеке көчлерәк чыга, Шәрәфи. Менә шундый шигырьләрне дә татар теле көчәйтебрәк җибәрә ала икән бит. Син чиста кеше, Шәрәфи Дус! Көлүең чиста. Эчең, җаның, уйларың, максатларың матур синең. Көнләшү хисең дә юк.

– Анысы бар: ләкин ул – ак көнләшү. Кара көнләшү дәрәҗәсенә үк төшәрлек надан түгел мин. Бар – сокланган кешеләрем. Санап китимме? Шаляпин – бөтен яктан талантлы, Магомаевка исләр китә, Пласидо Доминго дигән җырчы бар – алардан көнләшәм.

– Паваротти... Син үзеңнең кем икәнлегеңне беләсең... Менә мин сиңа сокланып утырам, Шәрәфи дус.

– Кара көнләшү түгелдер бит?!

– Юк, юк. Бу соклану! Иҗатыңа, кешелегеңә!

– Әйе. Соклана белү зур бәхет! Мин бөек җырчылар җырлаганда елап җибәрәм. Күр әле – Илһамыбыз «Кара урман»ны ничек башкара – мин исәрләнәм шул чагында.

– Ләкин алар кайбер гамәлләрдә Шәрәфидән өстен була алмыйлар. Икенче мәсьәлә бар: мин үземнең Илһам абый белән филармониядә эшләгән чагымны искә төшердем. Илһам абыйның кәефсез чаклары да була.

– Әйе, аның булгалый андый вакытлары.

– Баш авыртуын әйтәм мин.

– Мин дә шуны уйлаган идем.

– Аның белән булган бер кызык хәлне сөйлим. Сәнгать җитәкчесе кәнәфиендә утырган дәрәҗәле чагы бу бөегебезнең. Күз алдыгызга китерегез, килештереп өстәл артында уйга баткан кешене. Ул, әлбәттә, андый эшкә

күнекмәгән. Гомерен гастрольләрдә үткәргән артист бит. Ә монда фасонын китереп, эшләгән кыяфәттә, үз өстәле артында кәгазьләргә күмелеп, язгалаган булып, кешеләр кабул итеп, киңәшләр биргәләп ала. Җитмәсә, теге «нәмәстә»не кыстыргалап керәләр – Илһам белән утыру зур дәрәҗә аларга. Ә икенче көнне теге «нәмәстә», кемнән булуына карамастан, башны авырттыра.

Мин моңа әйтәм: «Илһам абый, әгәр авырып китсәң, шалтырат кына, син булып директор кабинеты каршыннан җырлап үтәрмен. Бу киңәшкә ул әллә ни игътибар бирмичә, елмаеп кына куйды да китеп барды. Әмма, берничә көннән шалтырата: «Хәмзә, тегене эшлә әле!» – ди. Мин коридорга чыгып директор ишеге төбеннән: «Урман ничек шаулар, / Ишелмәсме таулар», – дип, аныңча гөлдерәтеп узам.

Ярты сәгатьтән соң директор мине чакыра: «Илһам абый кайда икән ул, әлегенәрәк җырлап йөри иде», – ди. «Әйе шул, – мәйтәм, – мондадыр ул».

Кайда булсын инде – өендә, терелеп ята. Шулай берничә мәртәбә минем кирәгем чыккан иде аңа. Күнеккән иде. Ләкин аңа үпкәм калды: мине филармониядән җибәргәндә ул мин булып җырлап мине коткара алмады.

– Шул-шул! Кабатлый алмыйлар безне!..

– Шәрәфи дус, сине буй буенча да уздыра алмыйлар. Гәүдәң озын булганга оялмый идеңме?

– Хәзер инде ис китми. Элек бөкрәеп йөри идем. Дусларым тәбәнәк гәүдәле булдылар.

– Син, Шамкай әйтмешли, вешалка, плечик.

– Яшь чагымда уенга чыккач җырлыйлар иде:

> Кулымдагы йөзегемнең,
> Исемнәре Насырый.
> Озын тәре, колга тәре
> Әнкәң ничек асырый?..

Шул вакыт:

– Минем турында җырлыйсызмы әллә дип торам, – дип сәхнәгә Мудриевич килеп чыкты. – Мин Герценны укып бетердем.

– Бик тиз укыгансың? Башыңа берәр юньле нәрсә кереп калдымы соң?

– Ришвәт турындагы бер җире ошады. Шунысы күңелгә сеңеп калды. Түрәгә берәү кешеләр күз алдында ришвәт бирә. Алганы зур төргәк акчаны кулларында тоткан килеш һавалардан уратып: «Яхшы кешеләр менә шулай эшли», – дип күкрәк кесәсенә тыгып куя. Нинди оятсызлык. Герцен да шулай дип әйткән бу турыда.

– Хәзерге ришвәтчеләрнең мондый гамәлен күрсә иде ул! Ничек итеп тәсвирлап язар иде икән?! Мин Герцен китапларын, үлгәч, үземнең баш астыма кыстырып куярга кушар идем.

– Гомумән, Рәсәй үзгәрмәгән, – дип җөпләп куйды Хәмзә Шәрәфинең сүзләрен.

– Үзгәрмәгән. Шушы ришвәтчелекне бөтен дөньяга тараттылар бит. Англиядәге урыс бае, Чичваркинмы әле исеме: «Безнекеләр таратты Ауропага шушы чирне», – диде.

Бүген, бу спектакльдән соң, миңа тамашачы бәлки якты йөз күрсәтмәс. Достоевскийның «Карамазовлар» спектаклендә бер әшәке фамилияле персонаж бар – Смердяков. Шуны МХАТта бер артист уйный.

Спектакльне туктатып, тамашачы аны алты мәртәбә сәхнәгә чакырып чыгарды. Грибков аның фамилиясе.

– Нәрсәсе белән алдыра иде ул?

– Тискәре роль бит. Шул хәтле смердящий – әшәке кеше! Шул әшәкене шул хәтле оста уйный – сәнгати! Театрда беренче мәртәбә күрдем, спектакльне туктатып, баш идергәннәрен.

– Бездә шундый очрак булганы бармы?

– Юк.

Шулвакыт сәхнәгә атылып режиссёр Зирәк Мудриевич менә.

– Шәрәфи Шиһапович, Җәмгыять Иванычны теге ике кыз исертеп, каядыр алып киткәннәр. Чишендерәләр инде болай булгач моны!

– Үтереп тә ыргытулары мөмкин! – диде Шәрәфи.

– Пычранып тормаслар аның белән, – дигән фикер әйтеп куйды Хәмзә.

– Заслужил! – дип өстәде Шәрәфи юри урысча. – Рәсәйдәге җәмгыятьне шундый язмыш көтә! Заманында Салтыков-Щедрин әйтеп калдырган: «Йөз елдан соң мине уятып сорасагыз, Рәсәйдә хәзер нишлиләр дип, мин эчәләр һәм урлыйлар, дип җавап бирермен».

Уйламаганда, сәхнә уртасына, кулына зур ачкыч тотып, майга баткан малай чыгып баса. Һәм көчле яңгыравык тавышы белән:

– Бабай, туктаттым мин теге мәңгелек двигательне! – ди.

Нишләргә белмәгән Шәрәфи, оныгын күреп:

– Афәрин, улым! Кирәксә яңадан кабызып та җибәрә аласыңмы?

– Җибәрәм, бабай!

– Яшибез икән әле! – дигән сүзләр Фәрит Яруллинның «Шүрәле» балетыннан алынган музыка яңгырашында ишетелеп кала.

Шулвакыт, сәхнәгә атылып, режиссёр Зирәк Мудриевич чыга.

– Хөрмәтле тамашачылар! Бер мизгелгә игътибарыгызны экранга юнәлтегез әле. Андагы Ак бәрән сурәте тылсымлы әверелеш ысулы белән бүгенге сәхнәдә инде Хозыр Ильяс образында пәйда булган иде. Ул, шул ук вакытта, әнә, чын килеш, сезнең каршыда!

Хозыр Ильяс Шәрәфи оныгына зур форматтагы Габдулла Тукай китабын тапшыра да, тамашачы арасына төшеп китә. Бу сюжет экранга да бирелә. – Аның сезнең арада икәнлеген халкыбызга якты, матур киләчәк теләве буларак кабул итегез! Игътибар! Яшь чагындагы видеосурәттә Җәмгыять Иваныч һәм ул каршыгызга... Үзем – яшьлектә һәм бүген... Хәмзә – элек һәм хәзер... Бөегебез – Шәрәфи – яшьлеге, Наные, оныгы – киләчәге!..

Исемнәре әйтелгән әлеге персонажлар сәхнәгә чыгып, тамашачылар алдында баш ия торалар...

Саубуллашу...

Алкышлар...

# ҮКЕНЕРЛЕК ЯШӘМӘДЕК БУГАЙ...



*Шәфикъ Иматдинов 1950 елның 8 сентябрендә Татарстанның Чүпрәле районы Иске Кәкерле авылында дөньяга килә. Балачак еллары бик җиңелдән булмый, шуңа күрәме күңелендәге уй-кичерешләрен, хис-тойгыларын ак кәгазьгә күчерү белән бала вакытыннан ук шөгыльләнә. Мәктәптә укыган чакта ук аның язмаларын Чүпрәле районында чыга торган «Яңа юл» газетасында бастыралар. Аннары ул табигый сәләтен мәркәзебез Казанның балалар матбугаты – «Яшь ленинчы» газетасы һәм «Ялкын» журналы битләрендә сынап карый. Ә соңгы вакытта Ульяновск өлкәсендә нәшер ителә торган «Өмет» газетасының даими авторы.*

*Язмыш кушуы буенчадыр, мөгаен, инде 1967 елда ук ул бәхет эзләп Ульяновск өлкәсенең Сенгилей районы Красный Гуляй бистәсенә килеп урнаша. Эшче һөнәрләрен үзләштергәч, Ульяновск шәһәренең төзелеш техникумын тәмамлап, Красный Гуляй авыл хуҗалыгы төзелеш комбинатында инженер-техник вазифаларын башкара. Читтән торып югары белем ала. Озак еллар җитәкче урыннарда эшли.*

*Шәфикъ агай дистә еллар дәвамында милли хәрәкәттә актив катнаша, татар милли-мәдәни мохтариятенең Зөя аръягы районы бүлекчәсен җитәкли. Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы, тынгысыз йөрәкле шәхес буларак, ул шигырьдә дә, тормышта да ана телебез һәм мәдәниятебезне үстерү, саклап калу өчен хәлдән килгәнчә тырышлык куя.*

*Берничә китап (шул исәптән 2017 елда Татарстан китап нәшриятында дөнья күргән «Йөрәк сәгате» җыентыгы) авторы Шәфикъ Иматдиновның яңа шигырьләрен тәкъдим итәбез.*

**Ркаил ЗӘЙДУЛЛА**

# Шәфикъ Иматдинов

## Авылда, печәнлектә

Төнге авыл. Төнге тынлык.
Айның яктысы төшкән.
Җем-җем килеп күзен кыса
Йолдызлар төмсә күктән.

Мин ялгызым түгел икән –
Сарыла төнге сагыш.
Йөрәгем уттай янганга,
Уяндым, ахры, ялгыш.

Җил дә йокламый, күрәсең,
Башымнан сыйпап үтте.
Әллә нигә бер сәбәпсез
Йөрәгемне җилкетте.

Төнге авыл. Сәер тынлык.
Якын иптәшем – сагыш...
Авыл ялгыз, авыл ятим,
Этләр дә өрми ялгыш...

## Өч көнлек дөнья

Без киткәч тә, тормыш дәвам итәр –
Килер язлар, явар яңгырлар,
Иртәләрен салмак җилләр исәр,
Манарадан азан яңгырар.

Әле генә миңа алтмыш иде,
Җитеп киләм менә җитмешкә.
Кая гына ашыга соң сулар
Мин иелгән көмеш инештә?

Өч көнлек бу дөнья, диеп, халык
Әйткән аны шуның өчен дә...
Мәшәкате ләкин, мин үлгәч тә
Калыр аның тагын өч көнгә.

Калыр барсы... Җансыз җәсәдемне
Каплар бары кәфен – кесәсез.
Тик бөтенләй югалмабыз, димен,
Саба җиле булып исәрбез.

Үкенерлек яшәмәдек бугай,
Тормышыбыз булды, дип, сансыз.
Җаннардан да газиз туган җирдә
Туфрак булыр өчен туганбыз.

Җиңел булыр ул мөкатдәс туфрак! –
Кабул булыр, бәлки, бу догам.
Кая таба кузгалсам да хәзер,
Изге сүзгә килеп юлыгам.

Бер юаныч минем – миннән соң да
Нәсел җебе әле өзелмәс.
Исем калыр миннән бер мизгелгә,
Һәм эз калыр сизелер-сизелмәс.

Тик шулай да кичер мине, Ходам,
Аралый күр кайнар тәмугтан –
Гадел булмас уттан котылып бер,
Килеп керү тагын бер утка...

## Мин әлегә исән

Хуш, авылым, газиз туган ягым!
Кайтып әйләнермен бер тагын...
Ялгыз үскән миләш куагының
Истәлеккә алдым ботагын.

Тәлгәш-тәлгәш миләш, янып тора!
Ачылыгы сеңгән каннарга.
Татлы җимешләргә алгысынып,
Китеп бардык әллә кайларга.

Ачы миләш тәме иренемдә…
Бүтән тәмне белмим, нишләтим?
Ризык эзләп, тоймый дөнья ямен,
Тормыш иттек читтә ким, ятим.

Җан яралы шул китүдән безнең…
Сыкрау, нәфрәт җиргә таралган.
Туган илдән, телдән мәхрүм булган
Яңа буын җирдә яралган.

...Шатланмагыз, мин әлегә исән,
Мин булмамын, чүгеп баш исәм.
Чыдамлыкның төбе җиңү булыр,
Киссәгез дә, тамырдан үсәм.

## Сәер уйлар

Бәхетеңне эзләп менәр идең – бик текә яр.
Табалсаң, табалмасаң да, кире төшәсе бар.

Чишмә суын ятып эчәр идең – басмасы тар.
Ашар идең күккә – җиргә кабат кайтасы бар.

Сөйләр идең хакыйкатьне, җавап тотасы бар.
Балтага сап куяр идең – балта остасы бар.

Җилгә каршы төкерүең шикле – фетнәсе бар.
Аннан үз битеңнән төкерекне сөртәсе бар.

...Тик шулай да, яшисең ич җирдә!
Яшисе бар.
Яшәр өчен ләкин, башта, ашыйсы бар...

## Кеше

Җиһаннарны яулый кеше көче –
Ташлар яра, таулар күчерә,
Елгаларны бора давыл төсле –
Искитәрлек кеше көченә.

Ләкин бер көн килә – күзләреннән
Тамган яше йөзен пешерә:
Ул күчерә алмый үз гәүдәсен,
Китә алмый кирәк төшенә...

## Миләш тәлгәше

Көзге урман сукмагыннан атлыйм,
Төпсез уйда моңсу күңелем.
Картлык шатлык түгел, дисәләр дә,
Күңелдә көз түгел түгелен.

Җәй артыннан тагын җәйләр килмәс,
Булыр яңгырлары, салкыны...
Көйдергәләп алыр шул салкында
Көзге миләшләрнең ялкыны.

Берән-сәрән яфракларын көзнең
Миләш төпләренә тараттым.
Тәм йөгергән миләш тәлгәшедәй,
Ахры, бүген минем халәтем.

## Төш

Сине төштә күрдем, әнкәй-бәгърем,
Хәлең ничек, улым, диден син.
Башларымнан сыйпап, элеккечә,
Зур үскәнсең, диеп, сөйдең син.

Ә син һаман шундый борчылучан,
Кызу канлы һаман, күрәсең.
Миңа – дәү этигә, рәхәтләнеп,
Төшләремдә киңәш бирәсең.

Шатланасың, гүя, безнең өчен,
Көлеп-көлеп нидер сөйлисең.
Безнең хакта, безне искә алып,
Вәгазь-догаларың көйлисең.

Сагынабыз, әнкәй-бәгърем, сине
Язын, көзен, җәен, кышын да.
Нинди бәхет – яши алсаң әгәр
Балаларның күргән төшендә.

## Алыштырмас идем

Яшел келәм – уҗым кырлары,
Саубуллаша авыл тын гына.
Гомер читтә узды,
Картлык кулын сузды,
Яшьлектән калды тик моң гына.

Башын игән моңсу каеннар,
Яфракларын юлга җәйгәннәр.
Сизми дулкынланам,
Тукталып тын алам,
Шунда иде безнең җәйләүләр.

Китеп баруым булса да уйлыйм,
Кабат сиңа кайту җаен мин.
Авыл егетләрен –
Татар бөркетләрен
Искә алам кайткан саен мин.

Язмыш, юлны борып кирегә,
Кайтып булса әгәр ул көнгә.
Китмәс идем синнән,
Аерылып җирдән,
Алыштырмас идем беркемгә.



Фәрит
Яхин

# ЯЗ ЯМЕ БЕЛӘН БЕРГӘ

ПОВЕСТЬ

Яз ул – кызлар кебек юләр була. Нәгыймә дә күңеле утырып җиткәнче ничәмә тапкырлар койма аша сикерде. Шуның аркасында азмы хаталанды? Әмма яратса да яраткан икән шул: арадан Хәлил кебекне сайлады. Исмәгыйль кебекләр аркылы төшеп карадылар, аларга исе дә китмәде аның. Тик менә тормышлары гына Нәгыймә теләгәнчә барып чыкмады.

Ә яз, әнә кичә генә, әле кары, әле салкын җиле белән җәфалады. Быел килмәс, җәйне дә күрмичә, караңгы көзгә тоташып китәр кебек иде көннәре. Бүген бөтенләй башкача барысы да. Иртәннән бирле кыйбла ягыннан җылы рәхәт җил исә. Аңа һаман да битне куеп торасы килә. Төшке вакытта кояш шундый җылытып өлгерде, хәтта кар, суга әверелә барып, үзәнлекләргә җыелырга да өлгерде. Болай булса – килә яз, килә! Мең шөкер! Бәрәкәте белән, бәхете белән! Без, адәм балалары, аны бик тә сагынган идек. Ялындырып кына килә дә сиздерми, белдерми китеп тә бара. Бакчаларына утыртылган нәзберек үсентеләрен тәрбия итүче хуҗабикәләр июнь урталарына кадәр төрлечә каплый-каплый, кырау сугу хәвефеннән тәмам гарык хәлдә җәйгә узалар. Җылы яңгырлар явып, яфраклар калынаеп, бәрәңге тишелә башлаганда, язның төнге суыклары да үзе белән бергә китеп бара. Гаҗәеп төгәл тәртип белән яши табигать, шуңа да дөньялык матур да, сөйкемле дә, хәвеф-хәтәрле дә...

Нәгыймә бу вакытта Дүсем почмагындагы нефть-газ чистарту цехында иде. Ул тирәләрнең көнчыгыш тарафында калын урман булып, көнбатыш ягына басу-кырлар сузыла, Ләшәүтамак авылына межа төшеп китә. Ә янәшәдән генә, төньяктан көньякка таба асфальт юл сузыла, бу – Мөслим-Әлмәт трассасы. Нәкъ Дүсем почмагыннан көнчыгышка таба чат алып, Азнакайга да туры бара. Әүвәле текә тауны күтәрелергә кирәк, ә аннары – тигезлек китә, тагын да алга таба әле сыртларга күчеп, әле үзәнлекләргә төшкәләп узыла. Ян-якта калкулыклар, авыллар, урманнар, кырлар, болыннар кала.

Дүсем почмагындагы цех-буынтык – үзенә бер завод. Ул елдан-ел үсеп килде дә соңгы вакытта гына бар көченә эшли башлады, әмма хәзер ары киңәергә уйламый. Ул шушы төбәктән чыгарыла торган барча чи нефтьне-газны товар хәленә җиткереп баету, күкерттән аеру өчен корылган. Сыйфаты ягыннан

монда шактый яхшыртылган кара алтынны дистәгә якын торбалар буйлап, ничәмә чакрымнарны уздырып, Сөләй ягындагы үзәккә таба куалыйлар. Аннан аны тагын да арырак җибәрәләр. Нәгыймәнең белүенчә, Әлмәттән башланып киткән «Дуслык» үткәргечләреннән нәкъ шушы нефть ага да инде. Дөрес, аңа башка урыннардан да өстәлә. Мондый цех бер Дүсем почмагында гына түгел, арырак та бар, Ямашта да, башка урыннарда да. Әмма монда – иң заманчасы, барча технологик чараларны алдынгы җиһазлар ярдәмендә уздыралар. Башкача булуы мөмкин дә түгел. Шуңа да анда эшкә теләсә кем урнаша алмый, исерекләргә, аяк өсте йоклап йөрүчеләргә монда урын юк!

Ике ел була инде, цехка бердәнбер яңа кеше урнашты. Аның исемен «Вахит», диләр. Буйдак. Кырыгына якынлашып килә. Хак булса, әлегә кызлар кулын тотып караганнардан түгел, ди... Шул сүзләргәме Нәгыймә ышанырга тиеш? Әмма күңелен кытыклый шушы Вахит! Нәгыймә аны ничә тапкыр күрде, һаман да хәлсез калды. Әллә нинди сәер бер халәт, аны аңлата да алмый, чөнки егет каршында бичарага әверелә. Ә ул, эһ шул Вахитны, Нәгыймәнең барлыгын да күрми, хәйранлыгын да сизми. Чыннан да, кызлар кулын тотып караганы юк микәнни? Бәлки, аның күңел тойгылары башкачадыр? Инде Вахитны өйрәнергә, мең күз белән күзәтергә итә. Әмма һаман да эше барып чыкмый, чөнки аның каршында аңы югалгандай була. Менә бүген дә нигә дип цехның шушы ягына килде? Язны эзләп, дияргәме? Әгәр дә шулай икән, моның өчен Нәгыймәне битәрләргә кирәкме? Намусына көч килсенме? Язда бар табигать уяна, хәтта кешеләр дә үзгәрәләр, яз – бәхет чоры ул!

***

Нәгыймә нефть-газ сепараторлары янына җитте. Алар монда ике рәт тезелгән иде. Газлары артык җыелганда, аларны чыгаручы бөкеләрнең дөрес эшләвен, винтельләрнең биеп утырмавын Вахит, килеп, һичшиксез, карап китәчәк әле. Һәркайсыннан мәгълүматлар компьютерга тапшырылып барыла анысы, әмма операторның үз күзләре белән тикшереп китүе, һәр агрегатның дөрес эшләвенә игътибар итәргә тиешлеген Нәгыймә яхшы белә. Бүген Вахитның сменасы! Җитмәсә яз һавасы, көннең яме, дөньялыкның дәррәү уяныргa җыенуы Нәгыймәнең болай да таркау хисләрен кузгата. Бер яктан, бу яхшы да, ханым үзендә сизем көчен тоя, әмма, икенче яктан, уйлары җаваплылыкны киметә, дәртенә көч биреп, өмет-теләкләрен буташтыра. Адәм баласы шундый инде ул. Аңарда акыл салкынлыгы кышкы кар катламы сыман, язгы кояш кебек хисләр кайнарлыгы тидеме, хәзер юкара башлый. Ярый әле Нәгыймәгә балалары үз акылында калырга этәргеч бирде. Ә ире Фатих? Ә ул – саташты, хатыннар кочагына кереп юләрләнде. Ир-ат халкы бер тапкыр азгынлыкка бирелдеме, холыкта да тиз генә утыра алмый инде ул. Хатын-кыз да шундый инде анысы. Кешегә генә хас сыйфатмы, әллә инде бөтен тереклек ияләренәме? Тиздән бал кортлары чәчәктән-чәчәккә күчеп йөреп оча башларлар. Әмма моны азгынлык буларак күзалларга ярамый. Бал корты – эштә, җенси теләкләрен канәгатьләндерүдә түгел! Кем иде соң әле хезмәтне җенси омтылыш буларак аңлаткан, кайсы галим? Нәгыймәнең ул хакта укыганы бар иде. Эш сөюне җенси азгынлык белән тәңгәл куй инде, юләр! Ул вакытта байлыкка, мул тормышка омтылышны да шулай ук дип бәяләргә кала.

Торбаларда йөргән нефть агымы шавы белән җиләс җил сөйләшкәләп алгандай исте. «Мин килдем, сезгә яз алып килдем», – дия кебек иде ул. «Безнең

анда ни эшебез бар?» – дип, гүяки үзсүзлеләнә иделәр торбалардагы агымнар. Дөрес, бары тик Нәгыймә генә аларны шулай аңлады, чынлыкта нефть агымы торбаларга сыешырга теләми, урамга агып чыгарга ашкына, үзенә ирек даулый түгелме? Физик закончалык бу! Җил дә юлында каршылыклар булуга ачуланып йөри. Бусы да гади физика, табигать.

Нәгыймә Җәлил нефть-газ идарәсендә сылаучы-буяучы, ягъни штукатур-маляр хезмәтендә иде. Аларга эшнең мәңге бетәсе юк. Балта остасы Сәмигулла агай әйтә: «Әгәр дә кирәге булмаса, балтаны уйлап тапмаслар иде», – ди. Шушы уртача буйлы, ябык һәм сабыр абыйның кулга гаҗәеп тә оста икәнлеген мактап сөйлиләр. Бер дә тик тора белми икән. Аз гына вакыты булдымы, машина гаражы өстенә корган икенче каттагы мастерскоенда кисә, кага, шомарта, каезлый башлый. Имеш, әле шкаф ясый, әле өстәл, урындык. Шушы кадәр уңган, шушы кадәр булдыклы, диләр. Тик хатыны ягыннан гына китек. Анысының сәбәбен холыклары килешмәүдән күрәләр. Тормышта ир һәм хатын «ә»гә «җә» белән яшәргә тиешләр алар.

Кызганыч, Нәгыймәнеке дә барып чыкмады шул. Фатихы һаман да әрсез булды, һаман шул хәл: хатын-кыз халкына хирыслыгын баса алмады. Нәгыймә үзе дә әллә аңлап бетермәде? Фатихы юктан гына түгел, көнчелектән шулай бозылдымы икән әллә?

Юк инде, нигә алай булсын, ди? Әрсезлек һәм комсызлык харап итә адәм баласын. Шулар аркасында башы да бутала, күңеле дә утыра алмыйча интегә. Югыйсә, әти-әниләре укытучылар булган, әмма уллары Фатихка игътибарлары җитмәгән. Әллә аны артыграк иркәләгәннәрме? Башлы, акыллы кеше түгелмени ул?

Нәгыймә шунда ирен сагынуын тойды. Үз күңеле дә чуарланып алудан, Вахитны күрергә итеп, аны ничек тә кызыксындырмакчы булып, ул монда, шушы урынга килгән иде түгелме? Менә егет, һичшиксез, күренер, җайланма-җиһазларның дөрес эшләвен тикшереп йөрер, ә Нәгыймә шунда җырлый-җырлый, матур, түгәрәк буй-сын калкулыкларына җиңелчә ирек биреп, боргаланып-сыргаланып торбаларны, винтельләрне буяр. Юккамы ул бүген шушылай күзгә күренерлек итеп киенде. Сәмигулла агай шушы цехка вахта машинасында килгәндә үк ничә тапкыр: «Бүген балтам кулдан төшәр инде, күз алдымда һаман нечкә бил йөренер», – дип, юкка гына сүзләрен боргалап сөйләнмәгәндер?.. Электрик Гатаулла белән монтажчы Галимҗан аның кем һәм нәрсә хакында телгә салынуын аңламадылар. Ә Нәгыймә барысын да төшенде, күңел дөньясы шуңа да шау чәчәкле чуар бакча иде.

– Әллә буяп өлгердегез дә инде?

Нәгыймә сискәнеп алды. Янында гына Вахит басып тора икән. Бераз боргаланасы, сыргаланасы, ямь күрсәтәсе иде аңа. Ничек болай вакытсыз йөри?

– Нәрсә дип әйттегез?

Зиһене таралудан булыр, Нәгыймә, чыннан да, Вахитның сүзләренә төшенмәгән сыман иде. Буйдакка көлке тоелды, ирен читен кымшатып кына елмайды. Аның бераз он куна башлаган кара елтыравык чәче озынаяй төшкән, борын һәм бит очлары сипкел йоктырган. «Абау, бигрәк шөкәтсез күренә түгелме соң?» – Нәгыймәнең күзләре, күңелен юри үртәгәндәй, артык-портыкка игътибар итте.

– Өлгермәгәнсез икән әле, – диде Вахит, приборларны карап, кран-винтельләрне кирәгенчә боргалап, торбалар эчендәге шаулы агымнарны тигезләп.

«Өлгермәс Нәгыймә! Июль җиләге кебек мәмрәп пешкән ул!» – Бу юлы ханымның күңеле, җавап йөзеннән булыр, күзләренә ияргән акылын бутады. Аңа шушы кадәр үртәлмәсә дә мөмкин иде.

***

Вахитның ялгызлыгын ил халкы арасында озын телләр төрлечә фаразлый иде. Арада киң таралган сүзләрнең берсе – бәхетсез мәхәббәт хакында иде. Шулай инде ул, күпләр гыйшык-сәгадәт тарихлары белән күңелләрен сугарырга ярата. Хәер, андый сүзләр өчен егетнең тормыш сәхифәләре дә этәргеч бирерлек икән шул. Вахит берара Казанда яшәп, анда авиатөзелеш заводында эшләгән дә, актив буларак, төрле комсомол чараларында үзен күрсәтеп өлгергән. Андый егетләрне марҗа кызлары сөя, билгеле. Вахитны да шундый бер чибәркәй исәрткән. Әмма, ни гөнаһ, бөтенләй дә кирәкмәгән хәл килеп чыккан, марҗа – кыз түгел, ханым икән. Ире – инженер, Вахитлар өстенә кайтып кергән. Гомерендә беренче тапкыр егет кочак күргән, анда да адәм хурлыгына каласы булган. Ярый әле ханым аны балконга куып чыгарырга өлгергән. Вахит тугызынчы каттан, ничек мөмкин, шулай, күршеләр ашамы, башкачамы, бәхете – котылып чыга алган. Әлбәттә, җиргә сикермәгән инде. Югыйсә, аяк-кулсыз калыр иде. Җәй көне бит, ә аста – асфальт юл үтә.

Һәм менә шуннан Вахит, эштән җибәрүләрен сорап, заводның кадрлар бүлегенә тиз арада гаризасын илткән. Әмма аңа Хабаровски ягына китәргә, андагы авиатөзелеш заводына яхшы эшчеләр кирәк булуы хакында белдергәннәр. Аннан килгән агент та Вахитны кодаларга керешкән, сүзләргә катнашып китеп, шактый олы бәхет вәгъдә иткән. Иртәгә юлга да чыгасылар икән, бер урын хәзергә буш, ди.

Мондый форсатны ычкындыра торган егетме Фатих? Чыннан да, Ерак Көнчыгышка китеп барган. Әмма марҗаның инженер ире анда да барып чыккан. «Бүреге янган» Фатих үз хәсрәтендә көйгән, билгеле. Геологлар экспедициясенә язылып, алар белән сәфәргә киткән. Һәм кырык яшенәчә шулай Тайга романтикасы белән йөреп, ахырда үз иленә кайткан.

Матур әкият. Әмма Вахитка бәйле һәммә төрле сорауларга да аннан җаваплар табыла. Димәк, хакыйкать була алмый, бәлки күңел теләге һәм минбеләмлек хикмәтләре эчендә барлыкка килгән буш сүзләр генә болар.

Сөйләнгәннәрнең икенче төрлесе дә бар. Алары Вахитның холкына, хатын-кыз халкына битараф булуына бәйле аңлатма рәвешендә кузгатыла иде. Ишеткәне бар, әмма Нәгыймәгә андый хәбәрләр ошамый, асылсыз кебек тоелалар.

Ә менә өченчеләре? Болары – җитди, бераз сәеррәк тә, ләкин ышанычлы, дөрестер сыман. Адәм балаларында шундый хикмәт бар: алар үз күңелләренә, дөньяларына туры килгән, хисләренә муафыйк хәбәрләрне сайлыйлар һәм хәтерләрендә саклыйлар.

Ул тасвирча вакыйгалар тезмәсе, имештер, болайрак икән...

Вахитның бала чагыннан бергә уйнап үскән дусты булган. Үзара һаман да арка терәге болар. Нинди уйлары бар – уртаклашалар, авыр эшләрдә бер-берсенә булышалар. Аларны матур тормыш хыяллары колакларыннан тартып үстергән, әмма көннәрнең барышы юлларын аерган. Дусты, яхшы укуы сәбәпле, билгеле, институтка кергән, ә Вахитка андый бәхет тәтемәгән, чөнки белемендә ул уртачарак икән. Дөрес, алар үзара үпкәләшмәгәннәр, әмма араларына усал кешеләрнең сүзе кергән. Менә шундыйлар тормышларны

туктаусыз болгатучан. Вахит та, дусты да, яшьлекләре сәбәпле, андый бәндәләрнең сүзләрен колакларына элгән булсалар кирәк? Ә бер ишеткән сүз, күңелгә сеңә-сеңә, көннәрдән бер көнне хәтердә тамыр җәеп, олы агач кебек үсеп чыга да акылыңны каплап, күңел офыкларыңача ябалдашларын җәя. Болар белән дә шулай булган. Андый кешеләр тормышларында алга таба һичкемгә ышанмыйча, үз дөньялары белән генә чикләнеп яши башлыйлар. Егетләрнең икесен дә язмыш дулкыннары әле ары, әле бире ташлаган, әмма кабат очраштырмаган. Хәер, бәлки күрешкәннәрдер анысы, әмма иске дуслар буларак, яңарып китә алмас агач сыман бер-берсен тойганнардыр? Фатих белән Нәгыймә дә шулай булдылар түгелме?

Ә нинди гашыйклардан иделәр! Егет чагында Фатих аны бер күреп сөйләшү өчен генә дә көненә ике-өч килеп, подъездлары төбендә көтә-көтә зарыга иде. Белмичә калмый иде Нәгыймә, тәрәзәдән күзен алмый, әмма янына төшми, үзләрен әлегә андый уеннар өчен бик яшькә саный. Ояла, имеш. Ә менә кичке караңгыда агач арасында яшеренеп үбешә белде. Җәлил бистәсендә ул елларда күп булса – унбиш-уналты йортта кеше яшәгәндер. Һәркем бер-берсен таный. Нәгыймәнең әти-әнисе – төзүчеләр, Минзәләбаш авылыннан күченеп килгәннәр. Ә Фатих – укытучылар баласы, һәркемнең күз уңында, зыялылар гаиләсеннән санала, укуы да бары тик бик яхшы билгеләрдән генә тора. Нәгыймә дә төшеп калганнардан түгел, алдынгы укучы, активистка, пионер дружинасында тәрбия-пропаганда өчен җавап бирә, һәртөрле чараларны әзерләп, үткәреп кенә тора, ә аннары – комсомол комитеты җитәкчесе иттеләр. Әмма ул институт бетерүгә, югары белем дипломы алуга ирешмәде. Тормыш аны үз дулкыннарына бик иртә бөтереп алып кереп китте, балалары, аларны үстерү, Фатихның үзсүзлеләнүе – бердәм рәвештә өстенә ишелеп, барлык омтылышларын юкка чыгарды. Аерылышып та, балаларын әти-әниләренә йөкләп тә яшәп карадылар. Әмма иске тормышлары агышына әйләнеп кайта алмадылар. Нәгыймәгә, әнисенә ияреп йөреп, буяу эшенә өйрәнергә туры килде. Аңа электән андый хезмәт таныш иде. Бер-ике ел гына, балаларым аякларына бассыннар да диярәк башлаган иде, инде унбиш елдан артыкка китте, һаман да шушында. Аларның бригадасы яңа цехларны буяу-төзекләндерүдә дә катнаша, әмма тәртиптә тоту, төсләрне яңарту, язуларны үзгәртү кебек эшләрдән алып, һәр багана төбен агартуга кадәр – һәммәсе өчен дә җаваплы. Балта остасына да, башкаларына да көндәлек эш җитәрлек, тик утырганнары булмады, хәтта яңгыр, буран астында да тукталып калырга туры килми иде. Ә Фатих? Ул үзенчә яшәп китте. Бераз вакыт, баштарак, сукбайлыкта йөреп алды да, үзен тәртипкә кертеп, олы кешегә әверелде дә куйды. Институт та бетергән, начальник та булган, өйләнгән, хәтта балалар да үстерә, диләр. Нәгыймә аның читтә яшәвен генә белә. Элекләрне бер күрешү өмете, гаиләсен кабат яңарту күңелендә бар иде, ә хәзер... Юк, кирәкми! Тормышын җайлаган, тәртипкә керткән, гаиләсе бар! Матур яшәсеннәр, хәтерен яңартып, хисләрен бозып куюы мөмкин. Нәгыймә дә үзенә, менә бит, яр тапты! Шикәр кебек ирне әле, җитмәсә. Кызларның кулын да тотып карамаганны!.. Ул бары тик Нәгыймәнеке генә була ала. Аңа боргаланып-сыргаланып күренергә дә, сөйләштереп алырга да өлгермәде тик. Вахит килде дә, китеп тә барды. Эшләре күп. Һәр агрегатны әнә ничек аңлап, белеп, торбаларда нефть-газ йөрешен тыңлап эш итә. Куллары нинди зур иде! Гәүдәгә дә ыспай гына күренә, бер дә дуңгыз кебек симермәгән. Холкы да тыныч тоела. Хатынша да түгел. Анысын Нәгыймә шунда ук сизде. Ирләрне ул төгәл белә! Алар ике төрле: яки хатын-кызга

кул сузарга гына торалар, Фатих шундый иде; яисә ужым бозавы булалар, хатын-кыз холыклы. Ә Вахит – берсе дә түгел, Нәгыймәнең әтисе кебек, зат кеше: чын ир-ат! Ачык, төгәл, туры һәм тугры. Төзелештә аның әтисе балта остасы булды. Сурәте һаман да мактау такталарында иде. Аны коммунист булырга өндәделәр, кермәде. Югыйсә, орден-медальле буласы иде. Ә ул аның ишегә кызыкмады. Фатихны да үз итә алмады... «Безнең нәселгә төс түгел!» – дия иде аның хакында. Хәтта, күңелен үзгәртер өчендер инде, үзенә ияртеп йөреп, эшкә өйрәтеп карады, булмады. Үгет-нәсихәт итте, сеңмәде. Ә ачуланышырга теләмәде. Бары тик аның белән сөйләшмәс булды. Аралары шулай өзелде. Хәер, аңынчы Нәгыймә аерылышырга өлгерде. И юләр баш, ул бары тик егерме өч яшьлек ана гына иде ул вакытта, ике баласы да бар, җитмәсә. Чыннан да, и юләр баш, юләр баш! Шул Фатихны кулымда тотам, дип, бер-бер артлы балага узмадымы? Гадел Кутуйның «Тапшырылмаган хатлар»ындагы Галия белән Искәндәр сыман түгел иделәрме? Чынлап торып уйлап карасаң, язмышларында, аз булсын, охшаш урыннар бар сыман. Әмма... Ул Галия нинди көчле рухлы икән шул! Институтны бетереп, табиб дипломы алган, аннары – тормышын кабат көйләгән, ир тапкан... Ә Нәгыймә? Ярый әле әтисе, әнисе аңа гаилә булдылар, ә югыйсә – нәрсәләр эшләп бетәр иде? Энесе исә – нәкъ аталары, ничек горур басып атлап китте тормыш сукмагы буйлап! Хәзер үзен, әнә, идарә башлыгы булырга өндиләр. Кайтмады шунда Җәлилгә, бәхетен Уралда тапты. Хатыны да илдә бер, үзе чибәр, үзе акыллы, үзе уңган! Каян Уралда андый татар кызы үскән икән? Татарчасына кадәр гөлләр кебек. Тукайның шигырьләрен дә, Җәлилнекеләрне дә шартлатып татарча яттан сөйли, ә үзе табибә генә, югыйсә. Укытучы да түгел. Нәгыймә дә шундый ук саф акыллы, чиста күңелле түгел идеме соң?.. Юк икән шул, юк икән!

Ә Вахитны сөйләштерә ала иде ул. Әллә ничек хәтере таралды да китте. Хәзер җае булырмы кабат? Бер-бер хәйләсен дә белми, юләр баш!

***

Нәгыймә, үзен ачуланудан туктап, шактый озак онытылып эшләде. Буяуларны яхшылап болгатып, торбаларны тиешенчә чистартып, туктый белми газапланды. Кулы тимәгән урыннарны калдырмады. Яхшы тимергә буяу тигез төшә. Бу яктан Нәгыймәгә җиңелгә туры килде. Аннары, тырышып чистартылган булгач, алга таба эшең дә җиңелләшә. Чатнаган, купкан, кояш нурларыннан төсләрен югалтырга өлгергән буяулары яңартылгач, сепараторлар тирәсе тәмам ямьләнеп китте. Монда әле берничә көнлек эш иде.

Бераздан Нәгыймә хәйлә итәргә дә уйлап алды. Әгәр дә буяган вакытында берәр винтельне махсус рәвештә, сизми калганмын дигән булып, юри бикләп яки кысып куйсынмы? Менә Вахит йөгереп киләчәк. Нәгыймә винтельне шунда сиздерми генә бушатыр. Вахит һаман үрсәләнер, анда ябышыр, монда!.. Шулай кызык булыр, очрашып сөйләшер өчен җай табылыр!

Юк! Булмый да, ярамый да! Мондый гамәл – зыян салу, цех эшенә аяк чалу буларак бәяләнәчәк, туктаусыз барырга тиешле сепаратлау, товар ясау процессында өзеклек туачак. Аның ахыры нәрсә белән бетәсе билгесез. Әнә Вахит, һәр торбадагы агышны йөрәге белән тыңлап эш итә, сепараторлар, торбалар, винтельләр арасында әледән-әле йөренеп ала. Ничек барысын да аңлап, тоеп өлгерә – билгесез. Кешенең намуслы хезмәтен юкка чыгару булмасын!.. Аның өчен зинданга салалар. Көнчелек беләнме, үч итепме, әллә юри, шаяртып кыласыңмы – барыбер, моның өчен хөкем бер генә төрле.

– Син баядан бирле карап торасың! Гөнаһы бар дип тә белмисең!

Нәгыймә шушы сүзләрдән куркынып күтәрелде. Сәмигулла агай әйтә икән. Кыңгыр эштә эләккән малай хәленә төшеп, Вахит кызарынырга өлгергән. Ничек акланырга белми тәмам каушады, уңына тартылды, сулына, керер урын таба алмады.

Нәгыймә шунда пырхылдап көлеп җибәрде. Менә бит, Вахит алдында боргаланырга да, сыргаланырга да өлгергән. Димәк, бөтен дәртен күрсәтеп, егетнең йөрәген яулау аңа да насыйп булган!

– Сез икәнсез! Мин әйтәм, кемнәр йөри соң ул цех эчендә, дим?

Нәгыймә нәрсәләр әйткәнен үзе дә аңламады булса кирәк? Аның чибәр алсу бит алмалары дөнья ямենә тәм биреп балкый. Буяу пумаласын тоткан кулын бик йөретмәскә тырышып, сул кулын маңгаена төшә барган яулыгын һәм саклык каскасын арткарак кузгату өчен күтәргән иде дә, эрергә иткән аяк асты бозыннан аягы таеп китеп, чак егылмады. Аны тотып калырга теләп, Вахит сузылды, шунда сулышлары үзара кушылды. Нәгыймә аның тынын тойды. Таныш та иде сыман, ничектер рәхәт, җылы ис.

– Кара инде моны, безнең кызыбызга үрелмәкче!

Сәмигулла абзый юри түгел, белеп һәм ачуланып сөйләгән төсле иде. Нәгыймә ялгышмый: балта остасы – иманлы, мәчеткә дә йөри. Аның алдында кыланып тору мөмкин түгел.

– Сез инде бигрәк, Сәмигулла агай! Аягым таеп китте. Ярый әле Вахит тотып калды. Югыйсә, хезмәт урынында харап буласы идем. Аннары – сезгә җавап тотарга калачак!

Нәгыймәнең бу рәвешле сөйләвен Сәмигулла абзый аңларга теләмәде, йөзенә ачуы чыкты. Вахит исә үзенчә акланып карады:

– Өлгермәдем, тотып кала алмадым! – дип, бу сүзләрен ике-өч кат кабатлады.

«Тотарга өлгермәдең шул, пешмәгән!» – диярәк ачуланырга кирәк иде аны. Әмма Нәгыймәдән дә, Сәмигулла агайдан да андый сүзләр чыкмады. Алар башкача уйлыйлар иде булса кирәк? Хәер, агайның күңелендә нәрсәләр бары шунда ук беленде:

– Бу кадәр күзең төшкәч, яучы җибәрергә кала инде, энем, кем, Вахит! – диде ул, сүзләрне тәмам үзенә кирәк җайга борып. Форсатны ычкындырмавы, файдаланып өлгерүе уңышлы чыкты. Алга таба ул ишарәләү куәтен теленә тагын да өстәде һәм шунда егетне, егып салгандай, матурлап әйтеп тә куйды:
– Әллә юкмы? Тәндәге көчне әйтәм! Хәзер бит кызыл ыштанлы зәңгәрләр белән илне тутырдылар!

Вахит аңлы да икән. Сүз төбен шунда ук төшенде һәм ачу белән:

– Бутамагыз, Сәмигулла абзый! Буш сүз – үзе дә гөнаһ, намаз иясенә килешми! – диде, аның күзләренә туры карап.

Әгәр дә икесенең берсе тагын да сүз әйтә калса, үзара ирлек мәсьәләләрен тикшерүгә, хәтта мыскыллауга күчәргә тиеш иделәр. Рәхмәт, Ходай Тәгалә икесенә дә акылның камилен биргән. Әмма барыбер дә күзләреннән ут, кылыч орышы галәмәтләре сизелми калмады. Татар ирләре шул, җитмәсә, нindиләре әле!

***

Вахитның Нәгыймә янында калуы Сәмигулла агай өчен дә көтелмәгәнрәк хәл иде булса кирәк. Китеп барганында да, борылып-борылып карап, күзләрем дөрес күрәләрме диярәктер, аптырашта торгалады. Ул бөтенләй дә аптыраошта

идеме? Аннары, өченче борылышында, кулын селтәп, гүяки чукынышып китсеннәр, үз эшләре дигәндәй, адымнарын ашыктыруга күчте. Агайның бу кыланышлары әллә ничек, сәеррәк сыман күренде. Әллә театр уены корамы шунда? «Эшләрем күп килеш! – Сөйләнеп тә ала инде кеше. – Монда мәңге бакый сезне саклап тора алмыйм!» – имеш. Нинди сүзләрне китереп чыгарды бит, сөйләнүен җитмешкә борырга өлгерде. Татар түгел диген инде син аны! Әмма дә Вахитны кәкре каенга китереп терәде. Ничек кенә итеп әле! Бичаракаем:

– Сәмигулла абый, сез нәрсә? Нәгыймәне күңелем ошатмый дип беләсезме әллә? Аның уенда ниләр ятканын сораганым юк, ә үземнекен – яшермим! Буйдак булгач, хакым бар! – диде дә, шушы сүзләре белән хәтта Нәгыймәне дә тәмам шаккатырды. Кадаклаган кебек иттеләр алар. Ханым бөтенләй дә телсез калды.

Карагыз сез аны, күрегез! Китапта да сүзләрне болай ук җебен – җепкә, ямен – ямьгә китереп җиткерә белмиләр! Мирзалар чоры да узган. Ә Вахит, әллә Александр Дюма әсәрләрен укып шушылай сәерләнгән? Юк-юк, хата! Сәерләнмәгән! Гаҗәеп соклангыч кешегә әверелгән. Адәм баласының кемлеге теленә чыга. Әгәр дә ул сүгенеп сөйләшүчән икән, димәк, сатанага ияргән! Туган теленнән ваз кичкән икән – сантыйланган! Туган телле кешенең теле дә матур, тәмле аның. Ә тәмле телле кешенең күңеле ямьсезлектә була алмый! Моны Нәгыймә үзеннән дә белә. Фатих белән әйткәләшкәннәрендә нинди генә сүзләрне кузгатмый иделәр. Юләрләнгән булган шул, шашынган. Хәер, Нәгыймә ул вакытларда кая бара ала иде соң? Аларның буынын, җитмәсә, руслаштырып газапладылар. Шуннан башланмаганмы тормышында барча бәлаләре? Ярый әле Нәгыймәгә ата-ана тәрбиясе кереп калган. Һәм менә, гаиләм дип, бөтен күңелен балаларына биреп, институтын ташлап... Фатих Казанда укуда калды. Һәм ул – юньсез, иреккә чыккан, лекцияләренә йөрмәгән, көне-төне күңел ачуда гомерен уздырган. Зачёт-имтихан сессиясен яба алмыйча, тагын да ярты ел чиләнеп йөреп, эт типкесенә калган хәлендә Нәгыймә янына кайтып төшмәсенме? Әйткән булды әле: «Минем барысы да яхшы, сине кайгыртып башым каткан», – дип акланды. Һо, аның ул күңел йомшаклыгы, хәзер әллә нинди шома, ясалма иде кичәге саф Фатих өчен. Нәгыймә аны баштарак тоймады шул, шома сөйләнүенә күңелен ихлас итте.

Бу Вахит та шундыйлардан түгелме соң?

Юк, әлбәттә! Мең кат юк!..

Ә бәлки, Нәгыймә кабат ялгышадыр? Җаны теләгән – елан ите ашаган, диләр. Хуш күргәне өчен генә Вахитка соклана түгелме? Әлбәттә, шулай! Йөри монда Нәгыймәнең күңелен бутап, яз ямен бозып...

– Мин бит сине күзләүдә түгел идем... Ялгышып винтельләргә кагылырсың да системаның режимын бозып куярсың дип курыктым. Шуны карап тора идем...

«Ни сөйлисең син, Вахит? Нәгыймәне шушылай мыскылларга ярыймы инде?» – Ханымның йөзендә балкыган нурлары шунда ук бердәм сүнделәр. Аның башкача уйламавы күңеле сизгер кеше өчен көн кебек ачык булып күренергә тиеш иде.

– Сер булсын, инде яшермим. Мин, Нәгыймә, сезгә күптән күз салып йөри идем... Юк, юк! Күз салып түгел. Әллә нинди, ямьсез килеп чыкты... Гафу итегез! Кыланчык, кыланып сөйләгән сыман... Китапча...

Күңел серен ачканда кеше ничек каушаса, сүзләр таба алмыйча аптыраса,

Вахит та шул халәттә иде. Нәгыймә аны аңлады. Әмма ярдәм итеп, сүзләр эзләшергә үзендә көч таба алмады. Куллары һаман эшендә булды. Пумаласы тәмам корып беткән, ә ул буялмаган урынга аны ышкый да ышкый... Әллә тимерне ялтыратып куймакчы?

Вахитның күңелендәниләр бары аңлашылган иде инде. Нәгыймә тагын да шуны белеп өлгерде: ул, чыннан да, китапча кеше икән! Аның белән тормышта җиңелме булыр, авырмы? Фатих та китапларны күп укыган, укый торган иде. Әмма ул аларны күңелен ял иттерер өчен файдалана. Ә менә Вахит, укып кына калмый, китапча яши, ахрысы. Әллә китапта яшиме? Бу сүзләрнең икесе дә бер үк мәгънәдә түгелләрме соң? Китапта яшәү һәм китапча булу? Юк икән шул! Китапча булу ул – китап кушканча яшәү, әйтик, чын мөселманнар кебек. Алар Коръәннең бер хәрефен югалтудан да котлары очып гомер кичерәләр. Шуңа күрә дә фанатиклык дәрәҗәсенә җитәләр. Ә китапта яшәү ул – эсәрләнү, китап вакыйгалары аша тормышны кабул итү, аңлау, бәяләү. Үзләрен әдәби герой сыйфатында күзаллап гомер сөрүчеләр азмыни? Ә тәэсирләнүчән, йогынтыга бирелүчән кешеләрне сәясәтчеләр үз максатларында оста файдала беләләр. Менә тугры коллар кемнәр алар – китап кешеләре! Димәк, Вахитны Нәгыймә үзенә кирәкчә бөгә, сындыра, әвәли, юк итә яки үзгәртә алачак! Ә Фатих? Аны «китап кешесе» дип атарга мөмкин түгел икән шул!

***

Фатихның 9 Май бәйрәменә атап кайтуы хакында Нәгыймәгә әнисе әйтте. Өстәлгә куелган вазада шау чәчәкле кызыл гөлләр бәйләме утыра иде.

– Балаларын сагынган, – диде Нәкыя ханым.

Гомер яше күптән әбиләрнеке булуына карамастан, килеш-килбәтенә, кием салымына һаман да зур игътибары аркасында аңа артык күпне биреп булмый иде. Әле дә сабыр була белде. Укытучы кода-кодагыйлары янында да үзен зыялы тотты. Хәер, әгәр дә аның буяу эшендә гомерен уздыруын белмәсәң, берәр түрә яки, кимендә, клуб мөдире, яисә китапханәче булуын күзалларга мөмкин анысы. Гомергә китап яратты һәм укыды. Яшьлегендә рәссам булырга хыялланып, хәтта Лениногорски шәһәрчегендә училищега конкурслар, имтиханнар узып кергән, аны кызыл дипломга тәмамлаган. Берара вакыт Минзәләбаш мәктәбендә укытып та йөргән. Тик егете Әхмәт аны шәһәргә алып киткән. Монда укытучылык эшендә урын булмагач, эшче һөнәрен үзләштергән. Бәхете аны зур рәссам итеп үстерергә теләмәгән, ахрысы? Яшьлек хыялыннан алга таба ваз кичеп, хәтта мәктәптә укыту теләгеннән дә баш тарткан кеше ул Нәкыя. Нефть эшендә икәнсең – малярмы син, балта остасымы, башкамы – акчасы да яхшы, дәрәҗәсе дә әйбәт, хөрмәте дә зур. Аннары, ул чорларда эшче халкына ил хөкүмәте даими игътибарлы булды, бәйрәмнәрдә түшләренә орден-медальләр кадады, хезмәт хакларына өстәп зур премияләр бирде. Ире Әхмәт тә, төзелештә эшләсен, әмма нефтьчеләр идарәсенең бер звеносына беркетелгән оешмада иде. Нәкыяне дә шунда алып килде. Гомергә акчалары мул булып, елына бер тапкыр илнең яхшы ял йортларына бармый калмый иделәр. Матур яшәделәр, матур...

Минзәләбашны да тиздән оныттылар. Әхмәтнең энесе анда төп йортта калды, ә киленнәре үзен кунакчыл итеп күрсәтә белмәде. Хәер, Нәкыя дә туган авылы белән араны тиз өзде түгелме? Кияүгә чыкканының икенче елында әти-әнисе бердәй җир куенында урын алгач, анда кайтып күренү күңеленә

авырлык сала башлады. Йортлары нигезләрендә торып череде, ихата-кураны, бакчаны-лапасны кычыткан басты. Нәгыймә үсеп җитеп килгәндә, аннан бер урап килгән иделәр. Нигез ташлары өстендә яшь кәҗә бәтиләренең уйнавына кызының карап торуы гына исендә калган. Ул чакта ихаталары инде юк, бакча һәм ишегалды урыннары яшел хәтфә үлән иде.

– Кычытканнар да чигенгәннәр икән, койма яннарына сыенганнар... Нинди матур болынлы урынга әверелгән, – диде Нәкыя.

Кызы аңа карап куйды. Әллә әнисе шушы күренешкә шатлана иде, әллә кайгыра?

Күршедәге йорттагыларга хәер-сәдака итеп күчтәнәчләр кертеп чыктылар. Аларның үсмер малайлары ат җигеп маташа иде. Нәгыймә аның гади киемле, әмма төскә-кыяфәткә матур булуына игътибар итте. Андыйларны ул чорларда пионер газета-журналларындагы сурәтләрдә күрә торган иде ул. Менә бит, тормышта, чыннан да, бар икәннәр. Тик кызыл галстугы гына юк, әмма шундый да эшлекле, аңлап-белеп башкара барысын да. Аты да аның әмерләрен адәм телен аңлагандай төгәл үти. «Чик», «тыр-р», «әйдүк» сүзләренең мәгънәләрен төгәл белә микәнни, әллә бу атлар белән сөйләшү телеме?

Нәгыймә авылда үсмәде, андагы тормышны да күз алдына китерә алмый. Җәйләре пионер лагерьларында узды. Уку чорында мәктәптән кайтып кермәде, һәртөрле түгәрәкләргә йөрде. Хәтта утырып торырга да вакыты булмый иде. Ә аннары – Фатих...

Менә ул да кайткан. Егет чагында да Нәгыймә янына чәчәксез килми иде. Ул елларда мондый розалар юк иде әле.

– Балаларын сагынган,– диде Нәкыя ханым, кабатланып. – Әтиең әйтте, синең рөхсәттән башка мөмкин түгел, диде.

Нәгыймә шунда үз хакларын уйларга, кайда булуы белән кызыксынганмы-юкмы – шуны сорарга тиеш иде, югыйсә. Әмма ул актан да, карадан да эндәшмәде. Дүрт бүлмәле фатирның озынча коридоры буйлап узып, түрдәге үз бүлмәсе ягына китте. Олы көзге яныннан үткәнендә тукталып, чәчен бераз төзәтте һәм:

– Әткәй кайда? Гараждамы? – дип сорады.

– Мәктәптән бүген Марат иртәрәк кайткан иде. Аның белән киттеләр. Машина йөртү өчен имтиханга әзерләнергә булыша!

– Замир кайтмадымы?

– Аның бүген тренировкалар көне.

– Бөек хоккеист! Кәшәкәче! – диде шунда Нәгыймә, әллә көлеп, әллә сокланып.

– Ашарга әзер. Сине көтә идем, – диде Нәкыя ханым. – Ашны бүлә торам...

Һәм ул кухня ягына кереп китте. Шул арада кызы да, киемнәрен алыштырып, битен-кулын югач, өстәл янына килеп җитәргә тиеш иде. Әмма ашыкмады. Көткән анага күңелсез иде булса кирәк:

– Син кайда, кызым? – дип дәште.

– Хәзер, әнкәй! – диде Нәгыймә, бу вакытта киемен дә алыштырырга онытткан хәлендә, караватына сузылып яткан килеш, җавап биреп. – Мин хәзер!

Ул бүген алай ук арымаган да кебек иде, югыйсә. Эштән соң Вахит белән күрештеләр. Алар хәзер еш очраша башлаган иделәр. Гүяки, егет белән кыз кебек булдылар да куйдылар. Нәгыймә үсеп җиткән уллары барлыгын да аның янында онытты. Мараты быел мәктәпне бетерә. Җитмәсә, юләр баш түгел, диген, машина йөртергә укый. Борын төбендә – сынаулары. «Бердәм дәүләт

имтиханнары», диләрме әле аларны хәзер? Ничекләр генә куркытмадылар шулар белән, белемне гадел билгеләү чарасы, имеш. Шулайдыр инде, шулайдыр! Нәгыймәләр укыганда, әллә ул билгеләрне укытучылары күктән алып куя идеме? Белемле кешеләрне машина да саташтыра алмый, наданны әллә нинди чаралар да гыйлем иясе ясамый. Һәрнәрсәгә һәвәслек кирәк, фәннәрне үзләштергәндә – бигрәк тә!

– Ашың суына! Кызым! Син кайда?

Бу юлы Нәгыймә, җавап бирмичә, караватыннан торып, киемнәрен тиз-тиз алыштыра башлады. Шифоньер көзгесеннән үзенең сылу буй-сынына игътибар итте. Әгәр дә аны Вахит яшь чагында күргән булса иде!.. Ул елларда Нәгыймәне башкалар кызыксындырмый иде шул.

– Кызым?.. Ә-ә, киенәсең икән!

Нәкыя ханым инде Нәгыймә бүлмәсенең ачык ишеге төбендә иде.

– Мин сине, кая югалды бу, дип уйлаган идем. Йоклап киткәнсеңме дип торам. Ә син көзге алдында болганасың икән!

– Тагын башлана инде! – диде шунда Нәгыймә һәм үзе дә шушы сүзләреннән аптырап калды. Аның алай әйтмәвенә инде бишбылтыр, Фатихка кияүгә чыкканыннан бирле иде. Ул бу хакта төгәл белә, моны исенә хатасыз төшерде.

– Яратасың, әйеме? – диде Нәкыя ханым. Шунда аның йөзенә шатлык билгеләре чыкты. Ул, әлбәттә, Фатихны уйлый, Вахит хакында берни дә белми иде. Күңелендәге серен Нәгыймә дә ачарга теләмәде. Әмма җавабында:

– Әйе! – дип әйтеп өлгерде.

Аның бу сүзеннән әнисе Нәкыя ханымның йөзенә курку йөгерде. Ул уң кулы белән авызын каплады, еларга җиткән халәт кичереп алдымы шунда, тавышы калтыранып:

– И кызым! – дип, баласын кызганып сүз башлады, әмма уйлаганын телендә дәвам итә алмады, ашыгып кухня ягына китте. Әнисенең күңеле йомшару кызын аптырашка салды. Ул шунда кискен сулыш алды да, тиз генә халат киеп, Нәкыя ханым артыннан кухня ягына ашыкты.

– Әнкәй, син мине дөрес аңламадың!

***

Ишектә кыңгырау тавышы булгач, барып ачкан иде, Фатих икән. Бу вакытта Нәгыймә Вахит белән очрашуга чыгып китәргә әзерләнеп кенә өлгерде, югыйсә. Ә монда ире басып тора. Ярар, элеккесе, искесе булсын! Әмма аңардан башкасы әлегә юк бит. Димәк, ире инде.

– О-о, мине көткәннәр икән! Бик тә күңелле, бик тә күңелле! – диде Фатих, кулындагы чәчәк бәйләмен алга сузып. – Бусы – сезгә!

Нәгыймә дә югалып калмады. Фатихны ул гүяки танымый иде. Шунлыктан өн салды:

– Әнкәй, монда сиңа тагын бер егет килгән! Бусы да чәчәк тотып! Кертимме?

Нәкыя ханым диванда китап укып утырган җиреннән күтәрелеп, бераздан ана каз кебек йөгереп диярлек килеп җитте. Күзлеген төзәтте. Вак хәрефләрдән соң олы дөнья шәүлә хәленә калган идеме – ачык кына, аңлаешлы сурәттә күренмәде. Шулай да бераздан Нәкыя ханым елмайды:

– Абау, – диде. – Кызым! Бу безнең Фатих кияү бит! Нинди егетләр булсын?

Шул вакытта көзге каршыннан китеп, сул колагына алка элеп маташучы Нәгыймә, дорфалык булганын уйламады, әмма әйтте:

– Теге, Себергә сөрелгән Фатихмы? – диде. Эшен ул арада тәмам итеп: –

Таныдым мин аны! Уларын күрергә килгәндер? Үстереп бирдегез, рәхмәт, дип әйтергә. Бәлки әле егерме еллык алимент акчасын да китергәндер? Сора, әнкәй, кызыксын!

Әмма ана кеше үз кызының бу рәвешле усал кылануын теләмәде. Күкрәгенә китап кыскан хәлендә, күңел түреннән ягымлы сүзләр эзләп аптыраган кыяфәттә, хәйранлык белән кыенсынуда әсирләнеп торды да, бераздан аңына килеп:

– Керегез, кияү, керегез! – диде.

Фатих исә, каушаса да, ишектән узды. Бу юлы чәчәк бәйләмен Нәкыя ханымга сузды.

– Нәгыймә дөрес әйтә, әлеге чәчәкләр – сезгә, әби!

Йа Ходай, бу нинди сүз инде – «әби»? Хатының әнисенә шулай дип ничек әйтергә була? Хәтта әтисенә «бабай» дигәннәре дә сәер. Ул Минзәлә сөйләше татарлары әллә бөтенләй дә башка кавем инде? Казаннар «әти», «әни» дип, матур итеп әйтәләр, һәртөрле киртәгә дә сыешлы.

– Ярый, әнкәй, мин киттем әле! Кичкә каласым килми!

– Син кая болай, кызым? Фатих кияүне калдырып? Ул бит сиңа килгән, сине күрергә!

Нәкыя ханым аптырашта иде. Кызын ул беренче тапкыр шушылай мәгънәсез һәм дорфа итеп күргәч, нәрсә уйлый ала иде, ни әйтә?

– Борчылмагыз, мин дә аның белән! – диде шунда Фатих, авызын ерып һәм күзләрен челт-челт йомгалап алып. – Шулай түгелме, Нәгыймә ханым?

Аның хаклы булуы аңлашыла иде. Дөрес инде, Фатихның күңелендә ниятле уе бар. Нәкыя ханым янында ул көндез булган, сөйлисе сүзләрен әйткән, белешәсен – белешкән. Хәзер чират – Нәгыймәдә. Ул аңа: «Син, Фатих, вакытсыз килгәнсең. Мин – егетләр янына барам», – дип әйтсенме? Ә бәлки аны, чыннан да, ияртергәдер? Аларны таныштырырга? «Менә, мин нинди шәп ирне сиңа алыштырам, Вахит!» – дип әйтергә? Рәхмәтен белдерер, бәлки сөенер? Вахит түгел, Фатих, әлбәттә! Җитмәсә, нәкъ кинолардагыча: «Син гомергә шулай минем бәхетемә аяк чалдың! Бүген, язмышым хәл ителергә тиешле көндә, син тагын монда», – дияргәдер аңа?

Подъезд төбенә төшкәндә:

– Нәгыймә, Нәгыймә! Сүзем бар, сүзем! – дип, ияреп атлады Фатих. Баскычлар тарайды, әмма Нәгыймә тукталмады. Подъездан чыккач кына:

– Әлбәттә, Фатих, мин сине тыңлыйм! – диде ханым, шунда аны хәтта култыклап алды.

Ире гомергә шушылай затлы киенә белде. Гәүдәсе дә ыспай, бер дә киңәймәгән, ямьсезләнмәгән. Үзен карап, саклап кына йөртә белә. Фатих белән урам буйлап атлавы да күңелле була торган иде.

Шунда Нәгыймә фатир тәрәзәләренә күтәрелеп карыйсы итте. Анда әнисе кояшның үзе кебек чын бәхет нурлары белән балкып елмаеп карап тора иде. Сәлам биреп кул изәде, «мин сине яратам» дигәнне белдерүче «кош очыру» күренешен ясады. Аның шулай уч төбен үбүе – күңеле тулы романтик хисләрдән иде. Шулайдыр шул, юккамы ул «Ак чәчәкләр»не укый. Бүген дә кулында шул китап бит. Бәхетле кешеләр өчен язылган роман. Нәгыймә генә «Ак чәчәкләр»не үз итә алмады. Анда сурәтләнгәнне күтәрергә күңеленең көче җитмәде. Ә әнисе – бәхетле! Кызы моның өчен аның язмышына мең рәхмәтле булырга тиеш. Бәхетле кешеләр шат балалар үстермиләрме? Алма үз агачыннан ерак тәгәри алмый. Тик менә Нәгыймә генә?.. Ә нигә? Аның

уллары бар! Марат та, Замир да әллә ятимлек ачысын татыдылармы? Аларга әниләре Нәгыймә бары тик өлкән апалары сыман гына булды. Асылда Әхмәт бабалары белән Нәкыя әбиләре чын ата һәм ана иделәр аларга. Хәтта балалар бакчасында, мәктәптә дә, аларны әти-әниләр исәбендә йөрттеләр. Бервакыт Маратның сыйныфташы Андрейның әнисе Надежда Антоновна:

– Сез нинди бәхетле, Нәгыймә туташ! Шундый акыллы энеләрегез бар! Гомергә аларга сокландым. Минем Андрей кебек тиле булмадылар, – дип сөйләнеп торды.

Аңлашыла, улы тәмәке тарта, аракы эчә. Моны бөтен кеше белә. Мәктәптә укый алмады. Техникумга йөрде дә, аны да ташлаган, ахрысы. Көн дә иртәннән салмыш хәлендә очрый. Нәгыймәне күрсә – кача, чөнки элек, туры килгәне саен, икмәк алырга дигән булып, ун сум, илле сумнар сорый-сорый, бурычка батып бетте. Ә бервакыт, шулай туры килде, Нәгыймәнең вак акчасы юк иде, аңа мең сумлык сузды. Оялыр, алмас, дип уйлады. Ә ул, киресенчә, акчага комсызланып ябышты:

– Бирәм, билләһи кайтарып бирәм! – дип, мең кат антлар эчеп калды.

Ярый әле шулай иткән. Бурычлы булуы Андрейның хәтеренә кереп калган. Бирәчәге бугазыннан тотамы – күренгәне саен качу ягын карый. Әмма Надежда Антоновна ялгыша, Нәгыймә бернинди дә өлкән апа түгел, Марат белән Замирның газиз әнкәсе ул. Ә менә бу ыспай, баштанаяк ясанып киенгән ир – аларның газиз әткәләре! Андрей кебек улмы качып йөрмәде, хәтта Себергә китеп олакты. Ә хәзер кайтып җиткән. Әллә көтеп утыралар дип уйлаганмы? Уллары сагынган, имеш. Бар икәнлекләре исенә төшкәнме?

Шулай да затлы ир белән янәшә култыклашып атлавы күңелле. Күрегез, кешеләр, хәтерегезгә салып куегыз: бу – Нәгыймә, шушы җиңү алды көнендә герой-шагыйрь Муса Җәлил исемендәге посёлок-шәһәрчектә тигез урамнан үзенең ире белән бара. Улмы бәхетле түгел? Улмы кимсетелгән? Менә аның ире нинди затлылык иясе!

– Фатих, син өйләнгән кеше түгелме соң? Ничек оялмыйсың чит хатыннар белән йөрергә?

Нәгыймәнең башына бу сорау каян килгәндер, әмма тәэсирле, хәтта катлы-катлы, төрттерүле һәм кисәтүле булып чыкты, Фатих хәтта куырылып куйды. Ә Нәгыймә карары ныклы иде. Ул аның беләгеннән эләктергән кулын да алмады, әмма кисәтте:

– Курыкма, җаным! Тотып ашамаслар! Ашасалар да, сөягеңне кимермәсләр! Калдырырлар!.. – диде. Бу аның Фатихны чын мәгънәдә мыскыллавы иде.

***

– Алсу Сәгыйдулловна белән Фирдәвес Гариповичның хәлләре ничек соң?

– Алардан сезгә сәлам!

– Үзләренә дә! Алар яхшы кешеләр!

Нәгыймә яшел плащтан иде. Ә кара чәч бөдрәләре җилкәсенә төшеп тора. Хәтта башына яулык та бөркәнмәкче иде, әмма кече яшеннән яланбаш йөрергә өйрәнгән кешегә суык та тими, кояш та сукмый. Ә бүгенге кичәне эссегә дә җиллегә санарлык түгел сыман.

Алар нәрсәләр хакындадыр сөйләшергә тиеш иде. Нәгыймә аңлый булса кирәк. Әгәр шушы очрашулары булмаса, һаман да аралары нокта куелмаган хәлдә калыр иде. Әмма гомер агачлары кабат кушылып, яшәреп үсеп китү

куркынычы да бар. Аларның язмыш юллары икенең беренә илтергә тиеш. Башкача мөмкин түгел. Тик әлегә нокта куелырлык итеп сөйләшкәннәре юк, куш булып яшәрерлек дәртләре барлыгы да сизелми.

– Әни әйтә, улларың үсеп бетте инде, ди! – Фатих сүзләрне һаман да балалары ягына борырга тырышты. Аңлашыла, уллары – аларның тормыштагы уртак җимешләре.

– Алсу Сәгыйдулловна аларга һәрвакыт миһербанлы булды, – диде Нәгыймә, – ярый әле әткәй-әнкәй үзләренә сыендырды, энекәш тә фатир таләп итеп башларын черетмәде.

– Минем каениш һәрвакыт шулай акыллы булды, – дип, бу юлы да Фатих уртак тормыш картинасының тукымасын тергезерлек асыл җепләрне барлады. Аның күңелендәге уйларын аңлар өчен, кемгәдер шушы сүзләрне ишетү дә җитәр иде. Әмма Нәгыймә һаман да күңелендә кайнаган үз хисләре белән мәш килгәндәй тоелды. Вахит белән әле бу көннәрдә генә алар шушы юлдан атладылар. Әнә анда турник булачак. Элек Вахит монда иртә-кичен йөгереп йөрүне гадәт иткән. Турникта уйнауларын да әйткәч, Нәгыймә аның хакында хәтта: «Бигрәк яшүсмерләрчә кылангансың», – дигән иде, шаяртып үртәгәндәй. Әмма күңелен тиз җыйды. Ә нигә, чит ил киноларында хәтта өлкән яшьтәге кешеләрнең дә, музыка тыңлау җайланмаларын колакларына киеп, йөгереп йөрүләрен күрсәткәлиләр. Алар өчен мондый тормыш – гадәти, мәдәни күренеш! Ә безнекеләргә нәрсә? Мәзәкмени? Борын астына мыегы чыкмастан алда Фатих, коры калудан куркыптыр инде, кызлар артыннан куа башлаган, Нәгыймәнең ишеге төбен таптады. Ә менә Вахит чын егетләрчә булган!

Бу яктан Вахит Фатихтан өстен чыга алырлык. Уйлары Нәгыймәгә гөман-нәтиҗәләр ясарга мөмкинлек бирергә тиешләр, югыйсә. Әмма ул барыбер дә Фатихка елышты. Моны ир кеше үзенчә аңлады. Ханымның кулыннан сыйпап өлгерде һәм:

– Син, Нәгыймә, һаман да чибәр икәнсең, бөртек тә үзгәрмәгәнсең! – диде, кайнар дулкынлану кичереп. Ә бераздан бөтенләй дә ачылып китте: – Мине бит синең яшел күзләрең саташтыра иде! Нигә син озын чәчләреңне кистердең? Аларга мин гашыйк идем!

Хәзер ул тукталачак, ханым каршында тезләренә төшәчәк һәм башын иеп гафу үтенер сыман иде. Әмма андый батырчылыкка бара алмады. Нәгыймә дә эреп йөзгән уйларыннан айнып, көтмәгәндә көлеп җибәрде һәм:

– Бары тик чәчләремне генә яраткансың! – диде. – Уйлаган идем аны!

– Юк-юк! Бар җиреңне дә! Һәммәсенә дә гашыйк идем, – дип, хатасын төзәтергә ашыкты Фатих. Аңа, хатын-кызлар күңелен саташып күп аулаган кешегә, бу юлы сынату килешми иде. Әмма адәм баласының акылы шундый инде: иң кирәкле җирдә сыната. Аннары, ярый әле хатасын вакытында аңлап өлгерсә, шушыларны төзәтергә мөмкинлеге туа, акланырга җитешә: – Мин сине бөтен барлыгың белән сөя, ярата идем, Нәгыймә! Син бу хакта белә идең!

– Идең... Идем... Барысы да үткән заманда! Бүгенге түгел!

Фатих бу юлы: «Киләчәк заманда да булыр!» – дияргә тиеш иде. Әмма андый сүзләрне әйтергә башына да килмәде. Ә Нәгыймә көтте. Ул инде үз хисләрендә адашып-буталып аптырауларчылар хәлендә иде.

– Синең хакта, яңа гаилә корып яши, диләр. Ялган сүз сөйләмиләрдер инде?

Бу сорау барыбер дә, иртәме-соңмы, бирелергә тиеш иде. Фатих аны көткән булып чыкты.

– Син кияүгә чыкмагансың икән...

Аның бу сүзләреннән: «Аңлыйм, күрәм, Нәгыймә, кабат кавышуыбызны телисең, әйтмисең генә!» – дигән уйларын ишетергә мөмкин иде. Әмма ханым һаман да башка төрле уйларда буталды булса кирәк? Аны ишетмәде.

Теге көнне буяу эшләре белән Нәгыймәне Дүсем чатындагы цехта ялгызын калдырып китәргә тиеш иделәр. Әмма алай булып чыкмады. Бригадага монда да өстәмә эшләр табылды. Барысы бергә булдылар. Шулай да Вахит белән Нәгыймә арасы ул көнне тәмам төйнәлде дә куйды. Монда әлеге дә баягы Сәмигулла агай «гаепле» иде. Нәгыймә буяу эшләре белән мәшгуль вакытта Вахитка сепараторлар өстенә клапаннарны карарга менәргә туры килде. Алар кабат үзара якынайдылар. Егетнең тын исен ханым яңадан тойды. Үз-үзен аңламыйча дулкынланып, кулындагы буяулы чиләген төшереп җибәрде. Ә ул, сепараторның өстенә түгелеп, көне буе башкарган эшен бозып өлгерде. Сәмигулла абзый шушында гына икән:

– Сез анда нишлисез, яшьләр? – дип, торбалар ягыннан атылып чыкты. – Башыма төшердегез бит!

Болай ук кирәкми иде. Беренчедән, Нәгыймә кабаланды, икенчедән, Вахит борчылды:

– Мин гаепле, Сәмигулла абый, клапан тыгылган, шуны кичектерми чистартырга иткән идем, – диде, нигә монда булуын аңлатырга теләп. – Чиләкне күрмәгәнмен, аягым тиеп китте!

– Беләм мин синең нинди клапан чистартырга теләгәнеңне! – диде Сәмигулла агай, йөзенә-холкына кискенлек билгеләре чыгарып. – Малай актыгы булмасаң, болай йөрмәс идең!

– Нәгыймә, гафу ит! Мин бит күрмәдем!

Вахит мескен хәлдә иде.

– Буяуны сыпырып алырга булышам!

Ул шунда корытыр чүпрәк рәвешенә китерергә өлгергән бияләен учына кысып, аның белән сепаратор сыртына таба үрелде. Буяуны болай гына җыеп алырга мөмкинме инде? Вахитның кулы тигән саен, ул киңрәк тарала торды. Аңа бияләйдәге мазут та кушылды.

– Юк-юк, Вахит! Син нишлисең? Алай итмә! Мин үзем! Алай итеп тыгылма! – дип, Нәгыймә аның беләгенә ябышты. Шунда гүяки бөтен дөнья шым калды. Алар инде үзләре дә буяуга батарга өлгергән иде. Шушы күренештән Вахит та, Нәгыймә дә көтмәгәндә көлә башладылар. Сәмигулла агай:

– Юләрләр! Агылый белән тагылыйга әверелеп беткәнсез шушы атна эчендә! – дип, ачуланып, аларны калдырып китеп барды. – Ярый әле мине чумдырмадыгыз!

***

Сүзләре дә ялганып китә алмады, күңелләре дә китек хәлдә калды. Әгәр дә бу очрашу булмаса, Нәгыймә үзенең Фатихтан шушы кадәр дә ераклашканын аңламас та иде. Кешеләр еллар буена бер-берсен күрми яшиләр, хәтта онытып та бетерәләр. Әмма көннәрдән бер көнне юллары туры килә дә, хәтерләре яңарып, хәтта сөйләшеп туя алмыйлар. Ә монда, ир белән хатын үзләре, икесе дә ни гаилә, ни тормыш хакында мәгънәле сүз таба алмыйча аптырыйлар. Кемнәр алар? Уртак балалары да бар, әмма хисләре? Ни өчен хәтта ничек яшәүләрен белешәселәре килми? Үз тормышлары хакында Фатихмы сөйләргә теләми, әллә Нәгыймәме?

Дөнья да мең кат үзгәрде, яңарды, бозылды, аннары кабат аякка басты, югыйсә. Шушы вакыт эчендә Фатих баеп алырга өлгерде. Аның кулында хәзер ничәмә нефть коесы бар, имеш, товар вагоннары Европага, Кытайга йөреп тора. Ә ул монда тән сакчыларыннан башка гына, үзе теләгәнчә тәпили, кемлеге белән мактансын иде, юк! Ничек итеп элеккеге пионер, аннары – комсомолец, иле өчен җан атарга, буржуйларга каршы көрәшергә чакырып кызыл чыгышлар ясаган өлге укучы бүгенге көндә үз байлыгы белән мактана алсын? Әллә кем булу гына аз, тагын нәрсәләрдер кирәк адәм баласына? Намусмы? Әлбәттә, намус хисе! Ул юк икән, кеше үзен бәхетле тоя алмый. Хәтта Нәгыймә дә! Менә ничек Фатихның янәшәсендә атлый, хәтта аңа тагылып бара. Ә күңелендә Вахиттан гайре һичкем юк түгелме? Шушымы намус сызыгын санга алуы, улмы үзен бәхетле итеп тоярга тиеш? Сәмигулла агай дөрес әйтә: «Матур яшәү өчен акча һәркемгә дә җитә, әгәр дә күңелең тыныч булса», – ди. Күңел тынычлыгын намус хисе, аны суытмый саклау бирә түгелме соң?

Фатих болай йөреп арыдымы, әллә күңеленә ят уй керттеме, шунда Нәгыймәне барган җиреннән кирегә борып алып китте. Бу юлы асфальт юл буйлап килделәр. Шунда ак күлмәктән, гади костюмнан бер ир кешенең ашкынып атлаганы күренде. Ул түбән карап бара иде. Аны Нәгыймә танып өлгерде һәм шунда тораташтай тукталып калды. Әмма Фатихның беләгеннән кулын алырга өлгермәде, ир кеше алар янына җитте. Фатих ары китмәкче иде. Ул да тукталырга мәҗбүр булды. Нәгыймә:

– Хәерле кич, Вахит! – дип сәлам бирде.

– Хәерле кич, Нәгыймә! – диде Вахит. Алар инде бер-берсенә шактый якынайган иделәр.

– Таныш булыгыз, бу – минем ирем, Фатих, – диде шунда Нәгыймә.

– Мин бик шатмын! – дип, Вахит шунда бу парның әле берсенә, әле икенчесенә аптырабрак карап торды.

– Әйе, мин – Фатих! Нәгыймәнең ире! Сез, минем белүемчә, шул кеше инде! Аңлашыла! – диде Фатих, йөзгә-биткә тәмам караңгыланып, Вахитка түбәнсетерлек караш ташлаган хәлендә.

– Һе? Сез барысыннан да хәбәрдарсыз! – дип, юри шаярткандай, ләкин чынлыкта аптырап әйтте Нәгыймә. Әмма шунда ук үзен кулга алды һәм: – Әйе, бу – Вахит! – диде батыраеп. Кулын Фатихның беләгеннән бушатты. – Мин аны яратам! Ул минем белән очрашуга килә! Без бүген аның белән күрешергә вәгъдәләшкән идек!

Ике ир бер-берсенә ачу белән карап торганда, Нәгыймә Вахит ягына чыгарга өлгергән һәм аның терсәгенә ябышып алган иде инде.

– Шушы сала юләре, Салам-Торханмы? – диде шунда Фатих, әллә чыннан да җирәнеп, әллә юри, мыскылларга тырышып.

Әмма аңлаган кешегә төшенерлек иде: Нәгыймәнең күңелен Вахиттан кайтарырга теләп, махсус шулай театр уены кора ул. «Син мине гомерем буена бәхетсез ясадың, хәзер дә шул теләгеңнән киткәнең юк күренә!» – дип уйларга тиеш иде аның хакында Нәгыймә. Әмма әйтелгән сүзләре күңелендә андый уйлары тууны сиздермәде:

– Вахит, менә шушы инде минем балаларымның атасы! Күреп кал! Сорауларың булса, үзенә бир... Аннары, соңыннан, мине аптыратмас өчен! – диде, гүяки аны Вахит кияүгә алырга җыена, ә Нәгыймә ул хакта бер дә икеләнми, имеш.

***

Тормышта кешенең иң ныклы терәге – сабырлык, әлбәттә. Шуңа таянып гомерен уздырып бара иде Нәгыймә, ә бүген дөньясы буталды да куйды. Ул моның өчен Фатихка рәхмәт укырга тиештер инде? Кирәк бит шулай: инде онытылып беткәч кенә, нәкъ яңа тормыш учагы кабынырга торганда гына суык җил, яңгыры-кары белән килеп, чылатып-өшетеп үтсен инде? Моны ничек аңларга? Әллә соң, Вахит белән Нәгыймә арасын бозар өчен, кемнәрдер махсус оештырамы моны? Юк инде! Аларның мөнәсәбәтләре хакында – бары тик хезмәттәшләре генә хәбәрдар... Ә алар Нәгыймә өчен үлеп тора, аның бәхетле булуын тели. Галимҗанны ал, ул һаман да сүзне бер генә төрле сөйләргә ярата:

– Нәгыймәкәй, туегыз кайчан? Мине чакырырга онытмагыз! Гөлнарам белән үкчәләрдән ут чыгарып, бии-бии килеп җитәрбез, – ди. Мондый кеше көнчелек итә алмый, киресенчә – бары тик вакыйгаларны ашыктыра гына белә.

Ә Гатаулламы? Юк инде, мөмкин түгел! Шулай да анысы бар икән әле: Фатих белән танышлыгы! Әмма Нәгыймә белән Вахит хакында гайбәт сөйләрлек дәрәҗәдә түгел кебек аралары. Улмы:

– Фатих өйләнгән инде. Әллә кайчан, Нәгыймә! Сиңа да үз тормышыңны көйләргә вакыт! – дип, әле ике көн элек кенә әйтеп тормадымы? Дөрес, ачу китерерлек сүзләр булды алары да. Әмма Нәгыймәнең бәхетен кайгыртудан иделәр бит! Аңа рәхмәтле калмаска мөмкин идеме соң?

Сәмигулла агай? Вахитка Нәгыймәнең җылы карашы барлыгын беренче булып ул тоеп алды, һаман да араларын якынайту өчен тырышты, егетнең күңеленә әле ут салды, әле су, дигәндәй, теңкәсен, үз җаена көйләп, кирәкчә корыта белде. Аннары:

– Мин синең әтиең Әхмәт агайга гомерем буе рәхмәтле! Ул миннән оста ясады, ул мине кеше итте! – дип, исенә төшкәне саен әйтеп куя. – Син миңа якын, сеңлем кебек, Нәгыймә! Сәмигулла абыеңны тыңла! Ул начарга өйрәтмәс! Теле усал булыр, әмма сүзенең ахыры гадел эш белән тәмамланыр!

Болар – аның сүзләре, тормыш-яшәеше гаделлеккә корылган. Аңардан начарлык өмет итү дөрес түгел, сүзе дә әйткән җирендә кала, артыңнан ияреп аптыратмый. Чын татар ире башкача була алмый.

Димәк, Вахит белән Нәгыймә арасын бозарга теләүчеләр хезмәттәшләре арасыннан түгел! Әмма кемгәдер нәрсәдер җитми һәм ул кеше махсус рәвештә шулай эшли. Аңа бары тик Нәгыймәнең бәхетсез яшәве генә кирәк! Менә нәрсә хакында уйларга, белешергә тырышырга тиеш иде ул Фатихтан, ә ул әтисен сорашты, әнисенең хәлен сөйләтте һәм бернинди тулы-тугры җавап та ишетмәде. «Әйбәт» белән «яхшы»ны без болай да беләбез, нечкәсен әйтсен иде, асылын, менә булыр иде сүз.

***

– Ник әле болай, авыз-борының уңга-сулга ишелгән?

– Бәйрәмнән соң кәеф булмый инде ул, Сәмигулла абый, – дип җавап бирде Гатаулла Нәгыймә өчен.

Аларны эш урыннарына илтүче вахта машинасы бу вакытта юлдан басу ягына таба борылып төшәргә һәм беренче сикертмәгә очрарга өлгерде. Җиңел туп кебек сикеренергә генә торган чиләкләр тәгәрәшеп китмәсен өчен, Галимҗан аларга таба кочагын ачып үрелде.

– Әкренрәк, түгеләләр! – дип аваз салды Гатаулла, шофёр утырган кабина

ягына таба кычкырып. Гүяки аның сүзләре анда барып җитәләр, шуңа да ул якка ачулы карап-карап алды.

– Ишетми ул сине! – дип, Сәмигулла агай фургон калаена суккалап өлгерде. – Ничә әйтелгән аңа, һаман юк. Күзен тондыра да чаба!

Бу вакытта «Вахта» йөрешен тынычландырырга өлгерде. Әле апрель ахырында гына кар суы ергалаган юллар инде тәмам кипшеп һәм ныгып өлгергән иде. Урыны-урыны белән хәтта тузан да күтәрелер сыман. Һәммә болын-кырлар яшелләнә бара, басуда тырмалар таккан тракторлар йөгерә, таулар ягында көтүчесез сыер-сарыкларның үз ирекләрендә, төркем-төркем таралышып йөргәне күренә. Шуларны карап барган Нәгыймә онытылган булган, ахрысы, күңеле иптәшләре арасына кайтып, Галимҗанга таба карады да:

– Рәхмәт! Ярый әле сез бар, – дип әйтеп куйды.

– Тугызынчы май көнне Фатихны күрдем, – диде шунда Гатаулла, Нәгыймәгә текәлеп.

– Нишләп йөри ул? – дип сорады нигәдер Сәмигулла агай. Шулай ук Нәгыймәгә карап алды һәм аннары гына Гатаулла ягына таба борылды.

– Дөрес булса сүзләре, әти-әнисен Себергә алып китәргә кайткан. Олыгайдылар инде, аларны ялгыз калдырып булмый, ди.

– Акыл керә башлаган үзенә, – диде Сәмигулла агай, тамак кырып алып. – Акча шулай итә ул! Чыга башласа – акылдан яздыра, керергә тотынса – дивананы да аңга кертә!

– Мондый сүзне бер дә ишеткәнем юк иде, – диде Галимҗан һәм, аптыраш күрсәтеп, баш селкеп куйды. – Әмма дә дөрес сүзгә охшаган!

– Пәйгамбәрнең хәдисеннән түгелме? – дип шаяртты Гатаулла. Аның йөзенең җитдилегенә игътибар итсәң, бер дә уен-көлкене сөйли белмидер сыман үзе. Ә вакыт-вакыт сүзләрне шундый итеп борып җибәрә, хәтта тәгәрәп көләрлек буласың. Бу юлы Нәгыймә дә елмайды. Шул җитте, эшчеләрнең йөзләре бердәм яктырып китте. Тик бераздан Нәгыймәнең сөмсере кабат коелды. Ул әлегә һичкем белән дә уйларын уртаклашырга теләми иде, аның үз-үзен тотышыннан моны хезмәттәшләре аңларга тиеш иде. Сәмигулла агай, тагын да нидер әйтергә теләгәндәй, тамак кыргалап алды. Ярый әле Вахитны берсе дә исенә төшермәде, Нәгыймәнең, югыйсә, болай да китек күңелен тәмам бозып ташлыйсылар иде. Бу хәлдә ул бүген ничек эшләр? Җитмәсә, хәзер барып җитәрләр, шушы килүләрендә нефть суырту куагындагы өч таганның төсен яңартасы бар аның. Барысы да бердәм булышырлар анысы. Әмма үзләренә йөкләнелгән эшләре дә җитәрлек.

Сәмигулла агай тагын тамак кырып алды, аннары гына:

– Килеп җиттек, – диде, җир куеныннан нефть суыртучы чыгыр-таганнар ягына таба күрсәтеп. Вахта машинасы да урынны җайлап туктады.

Кичә, 9 Май көнне, бөтен гаиләләре белән Хәрби парадны телевизордан карап утырганда, Нәгыймәләргә, алдан шалтыратып рөхсәт тә сорап тормыйча, Алсу Сәгыйдулловна килеп керде. Ишекне Марат ачты. Керә-керешкә ханым аңа асылынырга өлгерде һәм:

– И улым! И улым! Шушы юньсезләр аерды безне! – дип, чәче-башы, кулы-йөреше белән тугланып-болганып елый да башлады.

Әхмәт ага хәлне бик тиз аңлады, аңа эчәргә су китерде, утырырга урындык куярга Замирга әмер итте.

– Кирәкми миңа сезнең суыгыз, кирәкми урыныгыз! – диде Алсу

Сәгыйдулловна, ярсып. – Миңа улларым кирәк! Кая минем Маратым? Кая минем Замирым?

Шунда ул урындык янында басып торган кече оныгын тотып алды.

– Синмени әле бу, җан кисәгем! – дип, тагын да такмаклый-такмаклый елап алгандай итте. – Шушы аждаһалар сезне миннән аердылар, улларым! Сине әйтәм, Әхмәт кода, сине әйтәм, Нәкыя кодагый! Киленем, дияргә телем бармый! Безне бәхетсез иттең, Нәгыймә! Синең үзсүзлелек, кирелек аркасында боларның барысы да! Тынычлана алмадың! Улымның кадерен белмәдең! Менә кем булды хәзер Фатихым! Борыныңа чирттеме? – диде аннары.

Һичкемгә сүз әйтергә бирмичә, ул һаман үзе генә сөйләде. Эченә сыеша алмый иде.

– Сез явызлар аркасында күпме җәбер-золым күрдек, кода, күпме хәсрәт чиктек, кодагый! Безне: Фирдәвесне дә, мине дә, бигрәк тә улым Фатихны балалардан аердыгыз! Явызлар сез, явызлар!..

Аңа каршы беркем дә бер сүз әйтмәде. Нинди катгый һәм каты Әхмәт абзый да хәйранда иде, ни сүзле Нәкыя ханым да теленнән язды, Нәгыймә инде бөтенләй югалып калды. Алар гомерләрендә дә мондый сүзләрне ишеткән кешеләр түгел иде. Кемнеңдер шушылай уйлавын, гаепләп әйтә алырын да башларына китергәннәре булмады.

***

– Кая соң яшь киявегез? Нигә безгә күрсәтмисез? – диде диванда җәелеп утырган, инде чыга башларга җыенырга тиешле Алсу Сәгыйдулловна. – Ходай өчен, яшереп тотмагыз! Оныкларыбызны кем кулына ышанып тапшырабыз? Күрик! Эчми, тартмый, әүлиялардән, диләр аны?

Сүзләрнең Вахит хакында барганлыгын Нәгыймә аңларга өлгереп, шунда җиңелчә кызарынды. Нәкыя ханым үз кызына аптырап карап куйды. Бары тик Әхмәт агай гына, сер бирмичә:

– Өйдә юк вакыты иде! Эшче бит! Бүген – сменасы! – дип әйтте дә куйды. Бу – чын ялган, югыйсә. Әмма алдау кебек гамәл этисенең гадәтендә булмаганга, Нәгыймә куркынып калды. Вахит хакында Әхмәт ага белә дип кем уйлаган? Ә менә Фатихның әти-әнисе – башка нәрсә, улларыннан аның хакында ишеткән булырга тиешләр. Ул элек ничек очсыз иде, хәзер дә шундый икән. Моны, җитмәсә, әти-әнисе дә белдереп тора. Алар, кием элгече янына җиткәч тә, чит ир-атка бәйле нәрсә дә булса табарга теләп, уңны-сулны җентекләп тикшерделәр. Әмма анда Нәгыймәнең яшел плащыннан гайре һични юк иде.

Һәм шунда көтелмәгән хәл булды. Бүлмәсеннән Замир свитер күтәреп чыкты да:

– Әти моны бүген эзләгән иде, безнекеләр белән ияреп кергән, – дип әйтте дә, Алсу Сәгыйдулловна белән Фирдәвес Гариповичның әле китмәгән булуларын күреп, шунда ук телен йотты. Сүз, югыйсә, Әхмәт аганың свитеры хакында бара иде, «әти» дип әйтүе дә аңа бәйле булды. Ә кунаклар Замирның ул белдерүен үзләренә кирәкчә аңладылар. Нәгыймәнең исә аларны тынычландырасы килмәде. Дөрес эшләде, чөнки Әхмәт аганы да, улы Замирны да ялганчыга чыгарачак иде. Алсу Сәгыйдулловна:

– Әйдә, китик моннан! Безгә урын да калмаган, инде чит ирне «әти» дип атый башлаганнар! – дип ачуланып, ишектән үрдәк йөреше белән озаклап чыкты. Хәтта Фирдәвес Гарипович та хушлашып сүз әйтмәде. Югыйсә, сөйләүләренә караганда, аларны Фатих үзе белән Себергә алып китәчәк,

оныкларына изге теләкләр теләргә килгәннәр иде. Картлык галәмәтеме – нинди эш белән йөргәннәрен дә оныттылар, бәйрәмнең ямен, көннең кояшын, күңелләрнең яктысын бозып кына калдырдылар...

Башына төшкән шушы хәсрәтле уйлардан ничек арынырга белмичә, шуңа да аптыраган, аязучан болытлы һава кебегрәк халәттә иде Нәгыймә...

– Тот-тот-тот! – дип кычкырды Галимҗан. Һәммәсе шул якка борылганда, елгыр куян, сикергәләп, алар яныннан ук чабып узды да үзәнлеккә таба элдертте.

– Кара моны! – диде Сәмигулла агай. – Койрык очы ак калган!

– Адәм кебек, арткы аякларына басып килде. Нинди гыйфрит дип торам, котым алынды. Күрмәгән нәрсә дә түгел үзе! – дип, Галимҗан күңелле халәтне көлә-көлә сөйләп алды. – Бу чыгыр төбендә оясы бар микәнни?

– Яхшылап кара, бәлки табарсың? – дип шаяртты Гатаулла. – Үзең кереп качарлык түгелме?

– Теләсә кайдан тишек эзләп йөрергә, мине кемгә санийсың?

Аларның сүз уйнатып алулары Нәгыймә колагы өчен түгел иде. Ирләр шулайрак инде алар, нишләтәсең! Андый очракларда Нәгыймә ишетмәмешкә сабыша. Әмма бу юлы ул аларны оятлы итәргә булды, ахрысы. Чөнки:

– Аңламассың сине, Галимҗан. Әле болай әйтәсең, әле тегеләй! – диде.

Егетләр шаяртуларының урынсыз булуын тиз аңладылар һәм шунда ук шым калдылар. Гафу итүне теләнү кебек күркәм гадәткә алар өйрәнмәгән иде.

– Нәгыймә сеңлем! Сак булыгыз әле, егылып төшә күрмәгез! – дип, Сәмигулла агай шунда кисәтү ясарга кирәк тапты. Аның сүзләре, уңай якка сыпырган кул сыман, назлы тоелды. Нәгыймәнең үзенә аталмаган сөйләшүгә кушылып алуы һәм шунда, җитмәсә, саксыз әйтүе, хатын-кызга ярамаганны искәрүе – кәефенең үзгәрүе, күңеле яктыра бару хакында сөйли иде түгелме? Моны әгәр дә аңламаса, Сәмигулла агай кисәтү ясар идеме? Акыл кешедә: кемгә кайчан нәрсә әйтергә икәнен дә белеп тора. Менә шушындый ирләргә таянып яши Җир шары, алар – халыкның терәге. Нәгыймәнең әтисе шундыйлардан түгелме? Ә Вахит? Ә Фатих? Дөресе шул: Вахит хакында нәрсә дә әйтеп булмый әлегә, әмма Фатихка таянса, Җир шары әллә кайчан мәтәлеп китәр иде инде, хата сүз түгел!

***

Акыл дигән нәрсә – ул, бер кат кискәнче, җиде кат үлчәргә мәҗбүр итә, хаталанудан саклый. Әмма адәм баласында ашкыну дигән көч тә бар. Тормышның кулдан китәргә маташуын сизенеп, күңелне вәсвәсә итә ул, форсатны җибәрмәскә этәрә, ахыр чиктә – нәфесләндереп саташтыра. Син үзеңне бу вакытта башкалардан мең тапкырга акыллырак, хәйләкәррәк, остарак, булдыклырак тоясың. Аның саен ашкынуың арта, нәфесең котырына һәм бәла чокырына очып барып төшкәнеңне сизми дә каласың. Ә акылы бар кеше андый түгел. Ашкыну көчен ул хезмәт дәртенә күчерә, аны көннән-көнгә затлырак итә. Бүгенге Нәгыймә дә кичәге беркатлы Нәгыймә түгел. Моны кайберәүләр сизенми дә калырга мөмкин. Фатих әнә шул кичәге Нәгыймәне эзләп килеп тә, аны тапмыйча, Себеренә кабат китеп барды. Кызык, әти-әнисен үзе белән алдымы икән? Юк, әлбәттә! Ул үзен, авыр булсын, җиңелгә килсен, йөк белән чиклиме соң? Аңа Нәгыймә дә, уллары да, әти-әниләре дә кирәк түгел, үз бәхете белән генә яшәү уенда ул. Ә яшь хатыны? Бардыр ул, булмый

калмас! Фатих һаман да хезмәтчеләргә мохтаҗ, ә менә кәефне үзе өчен генә табарга ярата. Анымы Нәгыймә белми?

Әмма Фатих та бу вакыт эчендә үзгәргән иде: беренчедән, ят кешегә әверелүе – башка нәрсә, аңа ирлек сыйфатлары кергән, холкы да басылган; икенчедән, һәммә нәрсәгә шикләнеп карый башлаган. Ә элек дөньяга исе дә китми торган иде, гүяки аңа һәммә уңайлыклар алдан әзерләп куелган. Башкача булырга мөмкин дә түгел дип белә иде. Хәзер икеләнә, әйе-әйе, икеләнә. Димәк, башына уй төшкән, уңын-сулын үлчи башлаган. Бусы – яхшы, аның үзе өчен әйбәт, хаталарын аңлар әле, аңлар, белер әле Нәгыймәнең кем икәнлеген!

Ә бәлки, таный башлагандыр, шуңа күрә кайткандыр, шуның өчен аны, хатынын, эзләп килгәндер? Ә балаларын? Аларны күрергә килергә теләдеме соң? Ул хакта сүзе дә чыкмады!

Шулвакыт Нәгыймәнең йөрәге шомланып алды. Үзен һавасыз калган кебек тоеп, күккә карап, тынсыз басып торды. Аның хәлен Сәмигулла агай үзенчә аңлады:

– Башыгыз әйләнеп китте бугай, сеңлем? Буяу исе ярамый, ахрысы? – диде, кырык төрле уйларга бирелергә өлгереп, әмма гадәтенчә турыдан сорап куйды: – Вахит гаеплеме?

Нәгыймә шаккатты. Аның хәлен күргәч, башкача уйлау мөмкин түгел икәнлеген аңламады, ахрысы? Шуңа күрә Сәмигулла агайга ачуланып карап куйды. Шулай да соравына җавап бирергә үзендә һәм әдәбендә көч тапты:

– Юк! Башыма моңа кадәр төшмәгән уй килгән иде. Шуңардан хәйран иттем... Вахит сүздән артыгын белми ул, кулымнан да тотканы юк, – диде дә, әмма хәйранлыгын да яшермичә: – Кызганыч! – дип өстәп өлгерде.

Менә шушы соңгы сүзе Сәмигулла агайга:

– Ә син үзең башла, сеңлем! Үзең башла! – дип әйтергә мөмкинлек бирде. Аннары: «Аңладымы? Ачуландымы?» – диярәкме, уй йөртептер, Нәгыймәгә сынаулы караш белән карап-карап алды. Сүзләре дөрес иде, югыйсә. Чын киңәш!

Нәгыймә, ишетмәгәнгә сабышып, эшен дәвам итте.

Инде болары да үтте. Ә ул һаман пумаласын кая сыларга белми сыпыра, сыпыра, сыпыра. Барысы да кирәгенчә, ә аңа әллә эшендә хата калган сыман тоела идеме шунда?

***

Нәгыймә эштән бөтенләй икенче төрле кеше булып, гүяки чәчәк атарга җыенган алмагач сыман кайтып килә иде. Подъездлары төбенә җитәрәк, Вахитның басып торуын күреп алды. Адымнарын акрынайтты. Элек бу урынга Фатих килә торган иде. Әмма Нәгыймә Вахит белән Фатихны хәтта уйларында да янәшә куярга теләмәде булса кирәк, чөнки аның күңелендә, хыялында бары тик бер генә кеше калганлыгы күз карашыннан ук сизелә иде. Ул моны егеткә дә ачык сиздерде:

– Вахит!

– Исәнмесез! Мин сезне көтә идем...

– Бүген синең ялың иде шул! – диде аңа Нәгыймә. – Бәйрәмнәрдә эшлисең, кеше эшләгәндә син ялда!

Әмма шунда ул Вахитның кичә, бәйрәм көнне, сменада булуын төгәл генә

белмәвен, аны эштә дип әтисенең, Әхмәт аганың, Алсу Сәгыйдулловнага уйлап чыгарып кына әйтүен, улы Замирның сүзләрен каенаталарның хаталы кабул итүен шунда гына хәтере аша тере картиналарда уздырды, ахрысы? Мондый хәлдә аңа елмаймый мөмкин түгел инде.

– Юк, – диде шунда Вахит, үзен тыныч тотып, – мин кичә өйдә идем.

– Кызык, – диде Нәгыймә, йөрәге белән аны якын итүен тоеп, – ничек алай булган? Нишләп яттың анда берүзең, бер ялгызың?

Ә Вахит аңа җавап биреп тормады. Күңелендә уе бар кеше башкаларны ишетми шул ул. Моны Нәгыймә аңлап өлгергән иде инде, Вахитның беләгеннән тотты һәм:

– Җаным, берәр нәрсә булмагандыр бит? – дип сорады.

Аның бу сүзләре үзенә дә гаҗәп тоелырга тиеш иде.

– Әллә мин сине сагынам инде? – диде шунда Вахит, Нәгыймәгә курка-курка гына карап.

Бергә яши башласалар, бу ир усалланачак инде, шушылай ук уҗым бозавы булып тормаячак. Әмма хәзергә аның мондый булуы хәерле. Ир кеше хатын-кызга юләрләнеп капланырга тиеш түгел, чын мөнәсәбәтләрне саклык белән урнаштыралар, ямьле итеп алып баралар. Шул вакытта тормышлары да матур була. Бу яктан Вахитта бернинди хата һәм хилафлык күренми. Сәмигулла агай Нәгыймәгә мөнәсәбәтләрен үзенә башларга ялгыш киңәш бирде. Юкка ашыктыра вакыйгаларны. Вахит үзе дә төшеп калганнардан түгел ул!

Шунда, алар белән исәнләшеп, Марат узды. Әмма аны Нәгыймә туктатырга өлгерде:

– Улым, кая киттең әле?

– Әти сөткә җибәрде. Бетеп киткән икән, – диде ул, Вахит ягына аптыраган караш салып.

Аның сүзләреннән һәм аларның ничек әйтелүеннән өйдәгеләрнең подъезд төбендәге хәлләрдән хәбәрдарлыгы аңлашылды.

– Әтисе өйдәмени? – дип сорады Вахит. – Сез бергә яшисезмени?

– Юк! – диде бу юлы бөтен яме белән балкыган Нәгыймә. Вахитның кулларыннан тотты да, аны үзеннән читкә җибәрмәскә теләвен сиздереп, хәрәкәтләр ясап алды. – Үз әтиемә ике улым да «әти» дип, миңа ияреп әйтеп үстеләр. Аларны беребез дә төзәтмәде. Хәтта әниемә дә, миңа ияреп инде, «әни», диләр. Мин бит бала чагымнан «әткәй-әнкәй» дип әйтеп үстем. Ә улларымның телләре «әти» дип, «әни» дип ачылды. Чөнки мин Казаннан, үзем дә сизми, «әти-әни»гә күчеп кайттым. Сәер түгелме? Шундый борылыш ясарга мөмкинме?.. Казан киленнәре «әткәй-әнкәй»не каената-каенанага карата әйтә. Хуҗабикәбез шулай өйрәтте! Без бит минзәлә сөйләше кешеләре, бераз башкачарак! Белә идеңме? Йә, ярар! Алары калып торсын! Безнекеләрне дә күрдең! Мондый гаиләләр дә барын белә идеңме?

Вахит шунда елмайды һәм, Нәгыймәне ялганында тоткан кебек:

– Хаталанасыз! – дип әйтеп куйды.

– Ничек-ничек? – Ханым тәмам аптырап калды.

– Сез сөйләгәннәрдән шул ачылды, Нәгыймә ханым: улларыгызга ияреп, телегез үзгәргән, «әткәй-әнкәй» дә «әти-әни»гә әверелгән!

Алар бер-берсенә таба сыгылып көлештеләр. Вахитка барысы да дөрес һәм ачык аңлашылган булып чыкты. Нәгыймәнең сүзләреннән соң аның хәтта сулышы, кыяфәте, йөзе үзгәргән кебек тоелды. Барлык йөкләрне дә ул берьюлы

сыртыннан гүяки алып ташлады да тураеп басты. Һәм шунда, горур рәвештә, җитмәсә тәмам якын килеп:

– Без бергә булырга тиеш! – диде, үгетләп тә, үтенеп-сорап та түгел, бәлки ирләрчә әмер итеп.

Нәгыймә монысын ук көтмәгән иде! Бу юлы аның кулларын Вахит үзе тотты. Нәгыймә аның кочагына сыенырга йөрәге белән омтылды, әмма кеше күзенә кереп калачагын уйлап, бу адымны ясаудан тыела алды. Күңелендәге хисләрен раслап, тәрәзәләргә карады. Ни кызганыч, Нәгыймәне шушы бәхетле мизгелендә беркем дә күрми иде! Һәм ул – онытылды, хисләренә ирек бирде, кочагына кысып алырдай булып Вахитка үрелде, әмма бит очыннан үбү белән генә чикләнде. Күрсә, Сәмигулла абзый сөенергә тиеш иде, чөнки, чыннан да, беренче адымны Нәгыймә үзе ясады, Вахитның өлгереп җитүен көтмәде!

– Ә син һәммәсен дә уйлап бетердеңме? Мин бит ике бала анасы! – диде хисләрендә тынычлана алган Нәгыймә бераздан.

– Балалар безгә комачауламый! – диде Вахит, үз карарын үзгәртмичә. – Мин ул хакта да уйладым!

– Фатирың – бер бүлмәле, өчебез бергә килеп керсәк, безне кая урнаштырып бетерерсең?

– Сине – кочагыма, балаларны – уңыма һәм сулыма утыртырмын!

– Монысын да уйлагансың икән!

– Уйладым, Нәгыймә!


Ханым шунда тагын да сораулар эзләп маташкандай тоелды, маңгаен җыерчыклап алды. Ул чибәр, юк-юк, гаҗәеп тә матур кеше иде. Яшел плащы зифа буена килешеп тора, калын кара чәч толымнарына бары тик кызыл бантлары гына җитми, яшел күзләре тере зөбәрҗәтләр кебек, чиста, ак йөзе, килешле борыны, кызыл иреннәре сихрилек белән тулы. Анымы яратмаска мөмкин? Ул – гади эшче, ә үз эшен яратып башкара. Тормышның ачысын-төчесен тулысы белән татыган. Аныңмы бу дөньяда бәхетле булырга хакы юк?!.

Урамда яз тантана итте. Бакчаларның дертләп уянганы, бөреләрнең терт-терт ачылганы, чәчәкләрнең күзләр сирпергә ашкынулары, кошларның туктаусыз сайраулары Нәгыймәнең күңеленә ямь өстәми мөмкин түгел иде. Җаны аларга сәлам бирмәдеме?.. Хәер, Вахит та, табигатьтәге үзгәрешләрне, дөньясына бәхет тойгылары тулуны яшермичә:

– Сизәсеңме, ишетәсеңме, дөнья туй итә! – дип әйтеп куйды.

– Хәтта күреп торам! – диде аңа Нәгыймә.

Ул: «Миңа яз белән бергә бәхетем дә килде, мәхәббәт хисләрем дә кайтты!» – дияргә мөмкин иде. Алары да дөрес сүз иде...



*Нурлан Ганиев 1985 елның 5 июлендә Благовар районы Яңа Сынташ авылында туа. Биредә башлангыч, күрше авылда 9 сыйныфны тәмамлаганнан соң, Бәләбәй шәһәрендә педагогия колледжын һәм Башкортстан дәүләт университетының фәлсәфә факультетын кызыл дипломга тәмамлый.*

*Иң беренче мәкаләсе «Өмет» газетасының «Чаткылар» исемле балалар өчен кушымтасында IV сыйныфта укыганда басыла. 2004 елда Бәләбәй шәһәрендә ел саен үткәрелә торган «Илһам чишмәләре» төбәкара шигърият фестиваленең Ф.Кәрим исемендәге махсус премиясе лауреаты була. 2014 елда «Иделем акчарлагы» конкурсында Гран-при яулый.*

*Россия һәм Башкортстан Республикасы Журналистлар берлеге әгъзасы.*

Нурлан
Ганиев

# ИЛ БЕТМӘСӘ, БЕТМӘС ТЕЛЕМ ДӘ...

## Киткәннәрнең кадерләре арта

...Узып барасыңмы инде, елым,
Өмет баглап көтеп алганым.
Могҗизалар янә булмый калды,
Күңел – сабый. Тагын алдандым.

Уңышлар да булды, ялгышлар да,
Югалтулар күбрәк шул әле.
Ел да түгел, бу йөрәкне көн дә
Юатулар кирәк шул әле.

Узып барасыңмы? Йә, хуш инде,
Тарих битләрендә – урының.
Хушлашулар якынлашкан саен,
Һич табалмыйм очын уемның.

Күрешүләр булды, аерылу,
Тешне кысып түзгән көннәр дә.
Уңыш-шатлыклардан баш әйләнеп,
Биеп чыккан якты төннәр дә.

Барысы да булды. Өлешеңнән
Калдырмадың, рәхмәт, и елым.
Ни дип җавап бирим? Разыймын мин.
Ачуланып китмә. Бир кулың!

Синең белән күпме дустым китә,
Бергә чаклар китә мәңгегә...
Инде менә син дә хушлашасың –
Калам кебек җирдә мин генә.

...Узып барасыңмы инде, елым,
Күпме өмет баглап көткәнем?!
Киткәннәрнең кадерләре арта,
Синеке дә артыр, көт, яме...

## Тукайга әйтер сүзем

Ишетәмсең мине, Тукай абый,
Тыңла әле әйтер сүземне.
Рәсемеңә карап сөйләшсәм дә,
Күргән кебек булам үзеңне.

Бел әле син, безнең бу гасырда
Булып тора төрле вазгыять.
Һәр көн саен кырыслана бара,
Усаллана бара җәмгыять.

Сабый лепкәседәй ката бара
Инсаннарның нәүмиз күңеле.
Онытабыз кебек, Апуш дустым,
Бу гомернең икәү түгелен.

Күзне томалады матди байлык,
Иркен фатир, затлы машина.
Мул тормышта яшим, диеп, кеше
Күпме бәла ала башына.

Ярты Рәсәй бурыч коллыгында,
Котылырга бармы чарасы?
Җир белән күк арасыдай хәзер
Туган белән туган арасы.

Җырлаучылар белән тулды илем,
Каләм тота белгән – язучы.
Нишләр иде алар, синдәй сәләт
Биргән булса әгәр язмышы?

Ана теле хәзер «мама теле»,
Дәү әниләр хәзер «бабушка».
Күкрәгендә җаны булган кеше
Ничек түзеп торыр бу эшкә?!

Калды микән күбәләкләр белән
Сөйләшүче хисле балалар?
Бетә бара татарыма рухи
Бишек булган авыл-салалар.

Шундый гасыр бездә, Габдуллаҗан,
Көн дә сала халкың борчуга,
Телен-илен сөйгән кыз-егетләр
Бик санаулы калган бу чорда.

Бөртек кенә калган ул-кызларга
Өмет баглап яши милләтем.
«И туган тел», «Шүрәле»ңнән башка
Мин үзем дә җирдә бер ятим.

Тик җан гына керләнмәсен, димен –
Ил бетмәсә, бетмәс телем дә.
Йөрәгемнән ургый милли моңнар
Һәм яңгырый туган илемдә!

## Җыр

Мин Җыр булып туар идем җирдә,
Елый-елый тыңлый торган булып,
Елый-елый җырлый торган булып,
Яшәр идем күңелләргә тулып!

Табыннарда берәү башлаганда,
Икенчесе дәвам итәрлек җыр!
Кайгылардан арындырыр чара,
Туңган күңелләргә үтәрлек җыр!

Җырласыннар мине яңгыратып,
Биек тауның түбәсенә менеп!
Кеше туа җирдә. Җыр да туа.
Кеше китә, ә җыр ул – мәңгелек!

## Бар...

Атлап киттем, дигән чакта
Аяктан тотканнар бар.
Алда көлеп, арттан килеп
Җилкәгә сукканнар бар.

Сырпаланып, җаен табып,
Күңелгә кергәннәр бар.
Аннан чыгып, серләреңне
Таратып йөргәннәр бар.

Сагышыңны үз иткәннәр,
Зарыгып көткәннәр бар.
Җылы кочагына алып,
Маңгайдан үпкәннәр бар.

Барлар алар... Күпләр алар –
Чыннары сирәк кенә.
Чын дустым ул, ахрысы,
Үземнең йөрәк кенә.

## Хәлең ничек, балам?

Чит җирләрдә хәлең ничек, балам,
Рәнҗетмиме узган-тузганы?
Чык тамчысы кебек күңелеңне
Капламыймы шәһәр тузаны?

Чит җирләрдә ничек, бездәгечә,
Көндез кояш, төнлә аймы ул?
Оҗмах булсын, ләкин туган җирдән
Кадерлерәк җирләр бармы ул?

Сагынулар шулай сарымы да,
Кайгы бездәгедәй карамы?
Зәңгәр күктә кыр казларын күрсәң,
Йөрәккәең әрнеп каламы?

Иртәләрен минем кебек сөеп,
Назлап уятучы бар микән?
Йөргән юлың күңелеңдәй киңме,
Әллә эз сыймаслык тар микән?

Чит җирләрдә ничек, сары көзләр
Сагыш утларына саламы?
Туган җирең сагынудан, балам,
Йөрәккәең тоташ ярамы?

Язлар ничек анда, кышлар ничек –
Буладыр бит кары-бураны?
Адашмасын балам буранда, дип,
Дога әйтеп сузам кулларым.

Хәлең ничек, балам, көн итмешең?
Рәнҗетмиме дусы-дошманы?
Чит җирдә дә узып булмыйдыр шул,
Узып булмый язмыш кушканны...

***

Җанымның кыйналган чаклары,
Җанымның кыелган чаклары.
Беркем юк янымда-якында
Шул җанны якларлык-сакларлык.

Җанымның үртәлгән мәлләре,
Җанымның битәрле мәлләре.
Янымда йөз кеше, мең кеше –
Ник берсе аңласа хәлләрем.

Җанымның көенгән көннәре,
Җанымның төелгән көннәре.
Көенгән-төелгән җанымны
Җан итәр, яр итәр кемнәре?

Җанымның өзелгән мизгеле,
Җанымның өзенгән мизгеле.
Өзелгән-өзенгән җанымда
Гомерлек, мәңгелек көз инде.

Ялгызлык – язмышым җәзасы –
Яр эзләп упкынга тарыма.
Ялгызлык – бәхет, дип сөенәм,
Бәхетсез парларга карыйм да...

## Шушы куллар белән...

Мин барын да үз кулларым белән,
Шушы куллар белән башкардым.
Шушы куллар белән яшем сөрттем,
Кирәк икән, җирне актардым.

Шушы куллар белән печән чаптым,
Алдым балта, тоттым көрәген.
Шул кулларым белән җырлар яздым,
Учларыма кысып йөрәгем.

Шул кулларым күңелемне минем
Үсендерде, үргә үрләтте.
Усал булалмадым – йодрыкны да
Кесә аша гына күрсәттем.

Шул кулларым белән улларымны
Кочып алып, күккә чөйдем мин.
Шул кулларым белән йолдызларның
Тузаннарын сөртеп йөрдем мин.

Шул кулларны канат итеп җәйдем,
Тик аларны җыйдым еш кына.
Канатланма, диеп богаулыйлар,
Тик ни гаҗәп, куллар ычкына.

Күз тиярлек матур кул эшләрен
Эшли белмим – гафу, үпкәсез!
И кулларым, баксаң, үземнән дә
Яхшырак ла икән күпкә сез!

# НУРЛАН ГАНИЕВ. ШИГЪРИЯТ.

Нурлан Ганиев шигырьләре белән беренче танышуым. Җырлап торалар, вәзен, ритм ягыннан аксау юк. 10/9 («Киткәннәрнең кадерләре арта»), 10/10 («Җыр»), 9/9 («Җанымның кыйналган чаклары»), хәтта 7/7 («Бар...») вәзене кулланылганда да текстларның яңгырашы, аһәңе, эчке көе-музыкасы табыла. Эчтәлеккә тәңгәл форма гармониясе булу, тезмәләр генә түгел, сүзләр яңгырашының, кабатлауларның оста сайлануы, шиксез, аның шагыйрьлек таланты турында сөйли.

Циклның исеме («Ил бетмәсә, бетмәс телем дә...») беренче карашка шигырьләрне иҗтимагый-сәяси дулкында, гражданлык лирикасы үрнәкләре буларак кабул итүгә юл күрсәтә. Әмма танышып чыккач, күпчелек текстларның фәлсәфи эчтәлекле икәнлеге ачыклана. Лирик герой – тормышны күзәтүче, уй-гамь кешесе, ул үзенең тәҗрибәсе һәм карашлары белән уртаклаша, тормышның һәм кеше яшәешенең аерым мизгелләрен тергезә. Гадәттә, мондый шигърият тормыш һәм кеше хакындагы монологны көчле фикер, зур гомумиләштерү, сискәндерерлек нәтиҗә белән төгәлләүне таләп итә. Әмма Н.Ганиев шигырьләренең «көчле позициясендә» – соңгы тезмәләрдә һәрвакытта да моңа ирешелә дип әйтеп булмый. Шагыйрьнең үсү-камилләшү юлын да мин матур күзәтүләрдән – олы гомумиләштерүгә, көчле фикергә килүдә, аны яңача һәм көтелмәгән образлар ярдәмендә белдерүдә күрәм.

Инде шигырьләргә якынрак килик. Беренчесе – «Киткәннәрнең кадерләре арта», аны вакыт фәлсәфәсе дип атарга мөмкиндер. Лирик герой узып баручы елга эндәшә, үткәннәрне телгә ала, ел-көн-тарихны мәңгелеккә каршы куеп, китеп бара торган ел белән саубуллаша. Бу саубуллашуда кеше тормышында булган үкенечләр дә, сөенечләр дә чагылып китә. Әмма шигырьнең соңгы строфасы, исеме кебек үк, андагы эчтәлекне җыеп тора алмый. Бер яктан, кадерләре генә түгел, тарихына тәңгәл тискәре мөнәсәбәт тә үсәргә мөмкин бит, дип куясы килә. Икенчедән, кадер артуын көтеп торуын сорап, елны юату артык балаларча яңгырый.

Сурәтлелектә дә сораулар тудырган урыннар бар. Әйтик, текст башындагы риторик эндәш эчендә сынландыру (кешеләштерү) урынлы тоелса да, кабатланганда фикри төгәлсезлек килеп чыга. *«Барысы да булды. Өлешеңнән / Калдырмадың, рәхмәт, и елым. / Ни дип җавап бирим? Разыймын мин. / Ачуланып китмә. Бир кулың!»* строфасында елның кул бирүе дә, аның «риза булырлык» узуы өчен моңа көч салган кешене түгел, әлеге дә баягы елны сәбәпче итеп кую да ясалма тоела. Аннан соңгы строфадагы «Синең белән күпме дустым китә» дигән сүзләргә дә «дуслар кала бит» дип җавап бирәсе килә.

Икенче шигырь «Тукайга әйтер сүзем» дип атала. Анда лирик геройның җәмгыятьтәге тискәре күренешләргә борчылуы (матди байлыкларның өстен чыгуы, туганлыкның, туган телнең, рухның югалуы, кыйммәтләр үзгәрү) ахыр чиктә киләчәккә өмет белән алмашына: «Ил бетмәсә, бетмәс телем дә». Бу өметнең сәбәбе – милли моңнарның туган илдә яңгыравы кебек шәрехләнә. Әлеге очракта да соңгы, иң югары аккорд йомшаграк, бәхәслерәк булып чыга, шигырь буенча килгән тәнкыйди пафосның ахыргы нәтиҗә белән бәйләнеп җитмәве күзәтелә.

Циклдагы иң уңышлы шигырь – «Җыр», ул фәлсәфи лирика үрнәге булып чыккан. Җырның күңелләрне баету, сафландыру, кайгы-борчулардан арындыру сыйфатына игътибар итеп, Н.Ганиев аны иң югары, кешене гомере буе озата барып, мәңгелеккә тоташучы кыйммәт итеп күтәрә.

Шигырьне ачып җибәргән образ: «Мин Җыр булып туар идем җирдә» – беренче тезмәдән үк күңелгә керә, уйландыра. Аннан соңгы тезмәләрдәге эчке рифмалар шушы тәэсирне тагын да арттыра: *«Елый-елый тыңлый торган булып, / Елый-елый җырлый торган булып, / Яшәр идем күңелләргә тулып!»* Бу строфадагы 2, 3, 4 нче тезмәләрнең рәдифле рифмага корылуы да кичерешләрне көчәйтүгә хезмәт итә.

Шуңа *ав, бг* формасында рифмалашкан икенче строфаны да беренчесе формасына китерәсе килә. Дөрес, икенче, өченче строфалардагы эчке рифмалар моны өлешчә

тигезли. Әмма Н.Ганиевнең, тагын да көч салганда, текстны тулысы белән бер һәм әдәбиятыбызда бик сирәк шагыйрьләргә генә буйсына торган вәзенгә кора алуында шик юк. Әйтик, *«Табыннарда берәү башлаганда, / Икенчесе дәвам итәрлек җыр! / Кайгылардан арындырыр чара, / Туңган күңелләргә үтәрлек җыр!» – урынына рифмалашу: «Табыннарда берәү башлаганда, / Икенчесе дәвам итәрлек җыр! / Кайгыларны атлап үтәрлек җыр, / Туңган күңелләргә җитәрлек җыр!»* кебегрәк сайланганда, беренче строфада бер йодрыкка тупланган хисси төен таралмаган булыр иде. Автор вариантындагы «Кайгылардан арындырыр чара» тезмәсенең башкачарак рифмалашырга тиешлеге дә, «чара» сүзенең бу контекстка ябышып бетмәве дә аермачык.

«Бар...» шигыре, асылда, кеше фәлсәфәсен эчтәлеккә әйләндерә. Дусларның төрлесе бар – кешеләрнең төрлесе бар, дигән автор, ахыр чиктә, үз йөрәгеннән башка ышанычлы дус таба алмавын әйтә. Соңгы строфадагы *«Чыннары сирәк кенә»* дигәннән соң: *«Чын дустым ул, ахрысы, / Үземнең йөрәк кенә»* дигән дәвам сораулар уята: чөнки «сирәк» белән «бөтенләй юк» бәяләмәләре бу очракта тигез (синонимнар) булып чыга. Шигырьнең исеме һәм рифманың рәдифе кебек кабатланган «бар» сүзе белән бәйләнештә, текстның бетемен үзгәртү зарур: чөнки «Бар...» дип исемләнгән һәм «бар» дип кат-кат кабатлаган текстның «юк» дигән нәтиҗә белән йомгаклануы (бигрәк тә өченче строфадагы гаять матур сурәттән соң: *«Сагышыңны үз иткәннәр, / Зарыгып көткәннәр бар. / Җылы кочагына алып, / Маңгайдан үпкәннәр бар»)* эчтәлек белән дәлилләнми.

«Хәлең ничек, балам?» шигыре баласы читкә киткән, аның өчен борчылучы ана эндәшүе, монологы кебек иҗат ителгән. Текстта чичәнлек традицияләре дә сизелә. Матур, хисси-тәэсирле текст. Татар әдәбиятында мондый әсәрләр язу традициясе бар, Тукайның «Ана догасы»н искә төшерә алабыз. Н.Ганиев шигырьләренә хас рәдифле рифмалар, риторик эндәш-сораулар, сүзләрнең ятышлы сайлануы текстның тәэсирлелеген тәэмин итә. Әмма бу очракта да соңгы тезмәләрнең уңышсыз кулланылуын әйтергә кирәк: *«Хәлең ничек, балам, көн итмешең? / Рәнҗетмиме дусы-дошманы? / Чит җирдә дә узып булмыйдыр шул, / Узып булмый язмыш кушканны...»* Беренче ике һәм соңгы ике тезмәләр арасындагы бәйләнеш тә, язмыш кушканның ни икәне дә аңлашылып җитми.

«...Җанымның кыйналган чаклары» шигыре ялгызлык фәлсәфәсен тергезә. Монда да сүзләр сайланышы авторның зәвыгын, хисси нечкәлеген күрсәтә. Әмма беренче дүрт строфада ялгызлыктан газаплануын сөйләгән лирик геройның соңгы тезмәдә аны бәхет дип шатлануы – алогизм булып чыга. Бу өлеш текстта юануга әверелә, ә юанудан соң ясалырга тиешле гомумиләштерү җитми кала.

Шундый ук алогизм «Күңел күптән күнгән» шигырендәге «күңел кысанлыкта» – «хыял ирektә» сурәтендә дә хасил була.

«Шушы куллар белән...» шигыре кешенең булдыклылыгы, эшчәнлеге өчен горурланып язылган. Кешегә мәдхия, хәтта аны «йолдызларның тузаннарын сөртеп йөрү» биеклегенә күтәрү – көтелмәгән шәхсиләштерү белән төгәлләнә: *«Күз тиярлек матур кул эшләрен / Эшли белмим – гафу, үпкәсез! / И кулларым, баксаң, үземнән дә / Яхшырак ла икән күпкә сез!»* Тормышның кешегә авырлыклар китерүе хакындагы фәлсәфи «Тормыш шулай...» шигырендә дә нәтиҗә субъективлаша: *«Ни мәңгелек? Хәтер, акыл, сүзме – / Шуңа җавап эзләп җан атам. / Әллә уйлар йокыдан да көчле – / Сызылып кына алсу таң ата...»*

Н.Ганиев шигырьләрендә тәэсирле, яңалыгы күренеп торган, истә калучы образлар да юк түгел. Мәсәлән, «Мин дә бит шул кеше затыннан...» шигырендәге кабатланучы юллар: *«Күп күрсәттем көчсез чакларымны / Көчле булып калу хакына»*; яки «Тукайга әйтер сүзем» шигырендәге: *«Сабый лепкәседәй ката бара / Инсаннарның нәүмиз күңеле»* – шундыйлардан.

Нурлан Ганиев шигырьләрендә авторның табигать биргән таланты – алмаз таш яктырып ята. Әмма аны кыйммәтле бриллиантка әйләндерү өчен олы хезмәт куярга, текстлар белән кат-кат, төрле вариантларда эшләргә кирәклеге дә бәхәссез.

**Дания ЗАҺИДУЛЛИНА,**
*академик, филология фәннәре докторы*



Лира
Ибраһимова

# АЙЗИДӘ

хикәя

**1**

Көнозын янып арыган кояш баешка башын салган иде инде. Гөлҗамал тәрәзәдән күзен алмады. Әнә, март кояшының көләч нурында балкып яткан ап-ак тау битләренә зәңгәрсу төс иңә башлады. Урман авызында Айзидә әле һаман күренмәде.

– Быел әнә тагын укуы калды. Сез укысын, дип, баланы надан итәбез бугай инде, – диде Гөлҗамал, Айзидә турындагы сүзне әллә кайсы очтан башлап. Әйтерсең, кызына кагылышлы барлык чишелеш тапмаган мәсьәләләр тутырылган сандыкны ачып җибәрде дә, кулын тыгып, эләккән берсен тартып чыгарды.

Пошынып әрле-бирле йөргән анасының хәзер нидер кузгатып, туздырып атарга да күп сорамаганлыгын белгән Дәүләтҗан, беравык сүз катырга шүрләбрәк торды. Ләкин дәшми торуының да яхшыга илтмәгәнен белә ул.

– Әни, менә быел ни сәбәпле укырга бармады соң ул?

Күзгә бәреп сораганнан Гөлҗамалның кайнавы бераз басылып киткән сымак булды.

– Ник бармады? Соравы җиңел. Ник бармады, имеш... – Хатын, сорауга җавап эзләгәндәй, сөйләвеннән туктап, җәһәт хәрәкәтләр белән өстәлгә бер чуен «чикмәнле» бәрәңге, сөт, тозлаган кыяр, кәбестә, сөлгегә төрелгән кара икмәк чыгарды.

– Ничек барсын соң? Мин эштә, – дип, сүзен дәвам итте ул. – Заготзерного иртән китәм, кич кайтам. Ул да, мәктәпкә караңгыдан чыгып китеп, төнлә генә кайтып егыла. Якын ара түгел. Йортны кем карый? Икәүләшеп ташлап чыгып китеп буламыни? Сыерны бетерсәк, җиңелрәк булыр иде дә. Аны да бетереп булмый әле. Сезне укытасы бар. Сыерсыз бөтенләй терәксез калабыз. Әле тырыштырсаң – сөте, мае бар. Шул Айзидә аркасында гына кыш чыга инде ул, бахыр.

---

Лира ИБРАҺИМОВА (1967) – *прозаик; «Җимчәчәк», «Сукырлар йорты» һ.б. китаплар авторы. Алабугада яши.*

Гөлҗамал, сөйләнә-сөйләнә, тәрәзәдән урман ягына тагын борчулы караш ташлады. Әнә, олы юлдан төшеп килә түгелме, чукынчык кыз. Караңгы куерганчы кайтып керәчәк, димәк.

– Аллага тапшырган инде, – диде ул, тагын өстәл тирәсенә әйләнеп кайтып. – Укыса, кеше булыр иде дә соң. Бигрәк сыек инде үзе. Кеше арасында бераз йөрсә ныгып, усалланып та китәр иде. Артык гади булма, дип ачуланам да инде, югыйсә. Ни әйтсәң дә, авызын ерып тик тора. Үзен генә чыгарып җибәрү дә куркыныч. Кыз бала бит.

Дәүләтҗан әнисенең сүзне кай тарафка юнәлткәнен белә. Ул анасы теләгәнне бик теләп башкарырга да риза. Ләкин, аның шәһәрдәге бүгенге хәле әнисе уйлавынча, «кырган да борган» гына түгел иде шул.

– Әни, үземнең янга ала алмыйм әле мин аны. Белем кирәк. Башта техникумга илтмичә булмас.

Гөлҗамал, кызын исән-сау күрүдәнме, бераз яктырып киткән йөзен улына борды. Аның үткен карашын күтәрә алмый, Дәүләтҗан башын аска иде. Ни дип әйтсә дә, әнисе аңа ышанмас кебек тоелды.

– Үзе генә укый алырмы ул? Бигрәк җебегән бит. Авызына чәйнәп салганны да йотарга курка.

Әнисе хак сүзләр сөйләгәнен белә Дәүләтҗан. Чынлап, Айзидәне бу хәлендә берүзен генә шәһәргә чыгарып җибәрү куркыныч, әлбәттә. Сабый гына бит әле ул. Әнисе янында, аңа иңгә-иң куеп тормыш йөген сөйрәп барырга туры килсә дә, үзе һаман самими, хыялый бер зат иде. «Тормыш йөге», дип зурлап әйтелгән сүзне ул шул самимилеге белән йөк итеп түгел, ә гади чынбарлык дип кабул итте. Ни йөрәгең белән илтерсең дә, ни йөрәгең белән калдырып кайтып китәрсең? Дәүләтҗан бу хәлне, гомумән, күз алдына да китерә алмый иде хәтта.

– Соң, нишлисең? Башкача чара юк, – дип, үзенә-үзе җавап бирде кебек егет. – Быелдан да калдырырга ярамый, әни. Анда көн саен ун километр йөреп укыйсы түгел. Укыр. Торырга урыны да булыр.

Гөлҗамал, сәкегә килеп утырып, мөлдерәмә тулы карашын улына төбәде. Улы да, яңа гына укуын тәмамлап, укытучылар әзерләү курсларына эшкә урнашып йөри. Аннан да артыгын таләп итеп булмас. Дәүләтҗанның да бит үз көче белән, һәр мөмкинлеккә чытырдапябышып, тормышта үзенә юл ярырга тырышып ятышы. Ачулана аламы соң ул аны?

– Быел ук, дисеңмени? – диде Гөлҗамал.

– Соң, кайчан? Аннары син аны теләсәң дә укыта алмассың. Сыерның аяк сузганын көтеп утырып булмый. Кеше бит ул. Кешенең гомере кыска.

– Тәүбә, диген. Төкерен. Сыер сине дә туйдыра ул, шуны онытма.

Кирәкмәгән җайсыз сүз атып, тагын анасының ачуын китергән Дәүләтҗан, хәлне тиз генә уңай якка борып җибәрде.

– Ярый. Минем хәл бераз җиңеләйде. Хезмәт хакы ала башласам, авылга да ешрак кайтырга тырышырмын. Айзидәгә дә ярдәм итәрмен.

Улының бу сүзеннән Гөлҗамалның йөзе тагын да ачылып, карашлары язылып киткән кебек булды.

Ул арада, яңакларын боз каймалаган агач ишектән урам салкынына төренеп, Айзидә килеп керде. Кинәт, инде хәйран караңгыланып килүче өйдә дистәләгән лампаларны кабызып җибәргәндәй, яктылык бөркелде. Бу кыз, әйтерсең, үзе белән кояш яктысын, урманның сихри гүзәллеген, карның аклыгын алып керде дә, аны куаныч бөртекләре итеп өй эченә чәчте. Өйдә кунак абыйсын күргәнгә

Айзидәнең шатлыгы күкрәгенә сыймады. Ул туны белән шәлен йолкып алып яндагы сәке өстенә ыргытты да, йөгереп, абыйсының кочагына ташланды.

– Абый кайткан! Абый кайткан!

– Чү, ипләп! Кара инде, туның белән шәлең идәндә калды, Айзидә, – дип, юри генә шелтәләгән булды Гөлҗамал.

Айзидә аны ишетмәде. Ул кечкенә, арык куллары белән һаман абыйсын кочты, чәп-чеп битләреннән үпте.

– Эшләр ничек, Айзидә? Урман куяннары миңа күчтәнәч җибәрмәде мәллә?

Дәүләтҗан сеңлесенең йомшак чәчләреннән сыйпады.

– Җибәрде, әнә бит сиңа бер чана чыбык.

Айзидә тәрәзәгә борылып карамый гына йорт ягына ымлады, ә үзе абыйсы итәгендә утырган килеш ризык тулы өстәлгә карашын күчерде.

– Шул гомер йөрмәсәң? Тагын агач төбендә җырлап утыргансыңдыр инде? Җырларга дисәң, дөньясын оныта тәмам. Берәр бүре ашап китмәсен тагын үзеңне?

Бәгыре каткан ана, Айзидәне бүген генә түгел, башка вакытта да, бик ачуланасы килгәндә дә чынлап ачуланмады. Башка балаларына эләкте. Айзидә белән андый телдә сөйләшә алмады.

– Бүреләр миңа тимиләр ич алар, әни. Мин алар белән күптән дуслашып беттем инде. Агач арасына качып, җырлаганны тыңлап торалар да китәләр.

Гөлҗамал кулын гына селтәде.

– Менә күрдеңме? Моны ничек берүзен генә җибәрәсең шәһәргә?

Әнисенең авызыннан уку сүзен ишетүгә, Айзидәнең иңнәренә канат үсеп чыктымыни!

– Укырга?! Ур-ра! Ур-ра!

Айзидә өстәл тирәли такмаклап биеп әйләнергә кереште.

– Әйе. Укырга. Техникумга.

Айзидәнең әлеге хәбәргә шатланып чабып йөрүен Дәүләтҗан үзенчә фаразлады – авыр эштән, авылның караңгы тормышыннан, әнисенең усаллыгыннан туйган икән бу бала, дип уйлады.

– Ә кем булачакмын мин, укыганнан соң?

Айзидә, биюеннән туктап, абыйсының учларына кечкенә, әмма тупаслана башлаган кулларын салды.

– Укытучы.

– Укытучы?

Кыз аптырап калды.

– Мин укытучымы? Абый, әйдә, мин җырчы гына булыйм.

Аның җырчы булырга теләгәнен барысы да белә бит, нинди юк сүз сөйләп торалар соң болар?! Айзидә, шикле карашын башта абыйсына, аннары сәкедә кулларын итәгенә куеп, аптыраудан бераз таралып утырган анасына күчерде?

– Башта укып чык әле, һөнәр ал. Аннары карарсың үзең.

Анасы янында сүз көрәштерергә ярамаганлыгын яхшы белә иде кыз. Шуңа, әйтелгәнне төзәтүче кеше булмаганга, эшнең инде хәл ителгәнлеген аңлап, башын иде.

– Дәүләтҗан абыем, анда укысам, мин җырчы да була аламмы соң, соңыннан? – дип кенә пышылдады, абыйсын кочаклап.

Дәүләтҗан, җавап итеп, аның чәчләреннән сыйпады. Анасының теш кысып, этә-төртә барган тормышында андый хыялларның булуы гайре табигый иде.

**2**

Ничек кенә яратырга тырышса да, иренә күңелендә туган кара нәфрәт аркасында балаларын ана җылысына туендыра алмады Гөлҗамал. Тырышты тырышуын, ләкин... Улларының йөзендә ул һаман иренең сөймәгән шәүләсен, хәрәкәтләрендә аның ямьсез рәвешен күрде. Ире Шәрифҗан, унсигезе дә тулмаган Гөлҗамалны, яратмаган, риза булмаган килеш, урлап өйләнде. Яши алмаганга атасы йортына качып кайтып киткән кызны ул, ат койрыгына тагып сөйрәтеп, кире алып кайтты. Шуңа, аның белән ястык бүлешкән һәр төнен, ризык бүлешкән һәр көнен каргады хатын. Гомер итеп, иренә исеме белән дә эндәшкәне булмады. Рәнҗешле күз яшенә коенып, үзләрен көтмәгән, салкын, ана сөюеннән мәхрүм яшәешкә дучар ителде балалары. Ире, сугыштан соң озак та тормый, фанилыктан китеп барды. Гөлҗамал, балалары белән якты дөнья уртасында берүзе торып калды. Чамасыз усал, кырыс иткән иде аны ачы язмышы. Табигате белән бер-берсенә тарткан бала һәм ана арасында һәрвакыт, алар берничек тә гафу итә дә, кичерә дә, алып ата да алмаган салкын бушлык торды. Ни генә кылса да, бизмәннең икенче ягында һаман ире булды. Гөлҗамал, балаларына булган бурычын сөтләтә, майлата кайтарырга тырышты. Бар көчен салып, беркемнең дә ай-ваена карамыйча укытырга, белем бирергә, кеше итәргә омтылды. Олы улы укып чыгып эшкә урнашты, үз тормышын корды. Эшләгәне гаиләсенә җиткәнгә шатланып, Гөлҗамал алардан бернинди ярдәм көтмәде, тормышларына да катышмады. Олы кызы да Уфада эшкә урнашып, үз көнен үзе күрә. Инде менә Дәүләтҗаны укуын тәмамлады. Хатын шушыларга риза.

Барлык балалары арасыннан Гөлҗамал Айзидәне генә якын итте. Аның өчен йөрәге башка бер вакытта да, бер баласы өчен дә көймәгән кебек көйде. Кыз бала бер китсә, кире кайтмый, дип, булдыра алган кадәр янында озаграк тотарга, тормышының шушы бердәнбер яктылыгына ябышып көннәрен, сәгатьләрен һаман сузарга, торган саен аның җитлегә баруы фактына мөмкин кадәр игътибар итмәскә тырышты.

Ләкин вакыт үзенекен итте. Әнә, Дәүләтҗаны бер кулына чемодан, икенчесе белән Айзидәне җитәкләп капкадан чыгып та баскан. Айзидәсе яшь аралаш елмаеп аңа туктаусыз кул болгый. Бу хәлләрне төшендә күргәндәй хис итте Гөлҗамал. Өнендә булса, чыдамас иде кебек. Әйтерсең, аның йөрәгеннән тамыры белән бөтен яшәешенең мәгънәсен, ямен йолкып алдылар да, капканы ачып, җилгә аттылар.

**3**

Авылда, әнисе янында тәне белән дә, җаны белән дә тук, бар дөньяга берүзе хуҗа, алай гына да түгел, шул үзенең бәхетле мохитендә эреп яшәргә өйрәнгән Айзидәгә шәһәр тормышы чит, аңлаешсыз кебек тоелды. Һәркем каядыр ашыга, кабалана, кеше кешене күрми, ишетми дә. Авылда, тәненең шәрәлеген каплар өчен, кышын җылылык өчен кигән киемнәр дә монда бөтенләй башка сыйфатларга ия иде. Ул, үзен шул мохитеннән җыеп алып, шәһәр кануннары калыбына кертергә тиешлеген аңлый иде. Бөтен кеше шулай итә бит. Ул кемнән ким? Әнә бит, кызлар ничек? Чәчләре тарап үрелгән, итәк-күлмәкләре дә килешле генә. Сөйләшүләре бөтенләй башкача.

Менә ул да, абыйсы алып кидерткән матур чәчәкле күлмәген, аякларына ап-ак оекбашлар, уңайлы гына кечкенә туфли киеп алган. Җилкәсенә букчасын асып, кеше арасында кеше булып, дүрт ел укыячак техникум бинасы каршында

басып тора. Букчасында – белем дөньясы. Гиз дә гиз шул белем дәрьясын, энә белән кое казы, кем әйтмешли.

Бина эченнән ишетелгән кыңгырау тавышыннан Айзидә дертләп куйды. Ишегалдында да кеше күренми. Әллә соңга калды микән соң? Җәһәт адымнар белән бина эченә керде дә, буш һәм тын коридорга юлыгып, тагын аптыраштa калды. Беркем дә юк лабаса! Дулкынланудан тирләп чыккан учына кыскан сумкасын кулдан-кулга күчерде. Әле бер якка китмәкче булды, әле икенче якка.

– Тебе куда, девочка?

Якыннан гына килгән тавыштан Айзидә сискәнеп китте. Русча эндәшәләр тагын үзе. Кыз тавыш килгән якка борылды да өстәл артында утыручы олы гына апаны күреп елмаеп җибәрде.

– Туда, – диде Айзидә, кайсыдыр якка бармагы белән төртеп күрсәтеп.

– Ну понятно, что туда. Какая группа, я спрашиваю? – диде кыңгырау кагучы апа, һаман русча сөйләшүен дәвам итеп.

– Не знаю, – диде Айзидә, ханымда һәм үзендә туган сорауларга җавап итеп.

– Ну, если первый курс, то иди в 10-ый кабинет. Там у вас оргсобрание.

Һаман бирешергә теләми, нәрсәдер аңлатырга маташкан бу бәйләнчек хатынның бер сүзен дә аңламаса да, ул үзе төртеп күрсәткән якка кузгалырга булды. Коридор буйлап бара торгач, кинәт ун саны язылган бүлмәнең ишеге ачылып китте, аннан күзлеген борын очына эләктергән купшы гына, илле яшьләрдәге ханым килеп чыкты. Айзидәнең куркуыннан тагын сулышы кысылды. Беравык, ни дип сүз башларга да белми бер-берсенә карашып торганнан соң, купшы ханым бармак очы белән генә күзлеген күз төбенәрәк этеп, җентекләп Айзидәне өйрәнә башлады. Укытучы бу, дип уйлады Айзидә, аны карашыннан аңлап. Айзидә, эндәшми генә елмаеп, карашын түбән яшерде.

– Бусы нинди Аллаһ мескене тагын?! – диде укытучы, каршында басып торган кечкенә генә, самими карашлы кыз баланы күздән кичереп. Аннары, кире үрелеп ишекне ачты да: – Вера Сергеевна, вот, та девочка, которую мы недосчитали. Тут, у дверей стоит. Стесняется зайти, кажется, – дип сөйләнде.

– Бар, кер, нишләп торасың? Беренче көннән үк болай соңга калып йөрсәң, эшләр пешмәс, кызый. Бар, башкача соңлама, – диде ханым, тагын татарчага күчеп. Минем татар икәнне кайдан белә икән бу, дип уйларга да өлгермәде Айзидә, аны этеп диярлек сыйныф бүлмәсенә кертеп тә җибәрделәр.

Бүлмәгә кергәч, кыз тагын ишек төбендә туктап калды. Каушаудан күзләрен томан каплагандай, бүлмәнең зурлыгын да, аны тутырып утырган кыз балаларны да, тәрәзәләрнең яктылыгын да, өстәл алдында торган апаның үзенә ниндидер сорау бирергә дип авызын ачканлыгын да, маңгай күзе белән түгел, ниндидер башка күзләр белән күрде кебек.

– Айзида Шагабутдинова? – дигән сораудан ул кинәт айнып киткәндәй булды. – Идите, садитесь.

Айзидә, ашыга-кабалана, укытучы төртеп күрсәткән, тәрәзә буендагы бердәнбер буш урынга килеп утырды. Оялудан башын аска иде, авылыннан кадәр җилкәсенә асылынып килеп, инде аерылмас дустына әйләнгән букчасын кочаклап тынып калды.

Янәшәдә генә, тәрәзә каршында ук, буй җиткергән яшь каен, нәфис ботак-бармаклары белән сыйныф тәрәзәсен чиртеп уйнады. Аннары бу уеныннан

туеп, нечкә биленнән килеп кочкан шаян җылы җилдә кыланып боргалана-боргалана, алтын йөгерткән яфракларын тузгытырга, күккә чөяргә тотынды. Бөгелә-сыгыла, ботак очлары белән әллә кайсы тарафларга төртеп күрсәтә-күрсәтә, тәрәзә пыяласына ятып пышылдап, кызга нидер сөйләде. Әлеге хакыйкатьнең Айзидәгә һич кирәк түгеллеген, нindидер ялгышлык килеп чыгып, тормыш дәрьяларын җиңеп баручы яшәеш корабының башкасына, үзенә тиешлесенә утырмаганлыгын аңлатырга теләде кебек.

**4**

Тормышының шушы беренче сынавын уза алмады Айзидә. Көннәрнең берсендә, укуга барган җиреннән, олы юлга борылып маташучы йөк машинасын туктатты да авылына кайтып китте. Беркемгә әйтмәде, хәтта тулай торагына да кереп тормады. Чөнки, ни булган киеме өстендә, ә калган нәрсәләре шушы җилкәсенә аскан букчасында иде.

Район үзәгенә кадәр әлеге машинада, аннары урман аша чыга торган калган юлны җигүле ат арбасында кайтты. Ашыкты, кабаланды. Ашкынды. Үзенең сагынуы иксез-чиксез булганга, авылында да аны юксынган, сагынганнардыр, дип уйлады. Авылы янындагы калкулыкка килеп җиткәч, арбадан сикереп төшеп, таутүбән җәяүләп чапты. Йөгереп аргач, тау битендә озак итеп елгага, авылы өстенә карап ятты. Бер карашка бар нәрсә дә шул ук кебек булса да, нәрсәдер, һичшиксез, үзгәргән иде.

Әнә, Айзидәнең туган йорты. Йорт алды буш, капкасы ябык. Әйтерсең, ул киткәч, ансыз яшәү мөмкин булмаганга, өзелгән кинокадр кебек, мондагы яшәеш туктап калган да, менә ул кайткач тормыш тагын кабынып, ялганып китәр сыман тоелды аңа. Әле ярый кайткан! Шәһәрне яратканнар, әйдә, яшәсеннәр шәһәрләрендә. Укысыннар! Ул монда яшәячәк! Аның тормышы башкача булачак! Ул теләгәнчә! Ничек булачагын әлегә белми. Ләкин башкача. Шул уйлары белән кыз кыр юлыннан авылына таба йөгерде. Авыл урамын очып үтеп, туган йортының капкасына килеп асылынды. Бераз сулыш алгач, сак кына капка келәсен күтәрде. Капка җырлап ачылды. Менә ул! Аның бәхет иле – йортының хәтфә үләне, ком белән мунчалалап юылган сап-сары болдыр такталары, бакча башына өйгән чүмәләдән килгән печән исе...

Аның уйларын бүлеп, шыгырдап өй ишеге ачылды. Өйдә кеше барлыгын тоеп, Айзидә шунда омтылды. Менә әнисе! Ул аның кочагына ташланыр да мәңгелеккә шул җылылыкта калыр кебек тоелды.

Тик... Гөлҗамалның хәсрәт тулы кырыс карашыннан Айзидә кинәт туктап калды.

– Кайтып җиттеңме?

Әнисенең салкынлык бөркелгән тавышы кызны башыннан салкын су белән коендырып төшергән кебек айнытып җибәрде. Җавап итеп ул башын гына иде. Ни әйтсен соң? Кайтып дөрес эшләмәгән. Ялгышкан. Көтмәгәннәр. Аның монда бәхетле булуына караганда, бәхетсез укытучы булуы мөһимрәк, димәк.

– Әйттем бит, син җебегәннән булмас, дип.

Гөлҗамалның зәһәре көчле иде. Әйтерсең, аның тормышына булган бар нәфрәте өермәдәй берьюлы кузгалды! Ул, җәһәт кенә үрелеп, мич буендагы табагачны эләктереп алды да Айзидәгә килә башлады. Анасының холкын белсә дә, аның үзенә карата болай мәрхәмәтсез була алырын кыз башына да китермәде. Куркуыннан телсез калды. Гөлҗамал, каты итеп сукмакчы булып кизәнде дә, табагачны Айзидәгә таба селтәп җибәрде. Табагач сабы, кызга

бераз гына җитми, болдыр тактасының кырыена килеп бәрелеп, урталайга сынып төште. Айзидә, коты чыгып, капкага йөгерде.

– Кеше күзенә ничек карармын, акылсыз кыз. Җүләр кебек мөгрәп йөрүдән башканы белмисең бит син. Җырчы була, имеш. Җыр белән тамак туйдырып буламы? Акылсыз нәрсә. Бәреп үтерәм бит мин сине, Аллаһ мәхлугы. Ник кайттың? Мине кешеләр алдында рисвай итәргәме?

Гөлҗамал, табагачның сынык таягын үрелеп алмакчы булып иелде дә хәлсезләнеп баскычка чүгәләде. Ул җыерчык баскан кытыршы куллары белән җилдә кибеп яргаланган кытыршы битен каплап, үксеп еларга тотынды. Чарасызлыктан. Сагынган иде бит кызын, көннәрен санап көткән иде. Айзидәсенең укуын ташлап кайтып китү хәбәре килгәч, көн яктысын күрмәде. Кеше алдында болай мәсхәрәгә калдырыр дип башына да кертеп чыгармаган иде. Кирәкмәгәнгә акылы җиткән бит, җүнсезнең, дип өзгәләнде. Һәм үзенчә каты, усал итеп нәсыйхәт бирергә ниятләде.

– Бар, күземә күренмә. Теләсәң кая кит. Тик өйдә күренәсе булма! Укыйсыңмы, эшлисеңме – теләсәң нәрсә эшлә. Минем сиңа бирергә бер тиен акчам юк. Булганын кырып-себереп биреп җибәрдем, син акылсызга. Бар, кит! Дүрт ягың кыйбла!

Айзидәгә әнисенең ярсу халәтен күрү, үз өстенә яудырган ачы рәнҗешен тыңлап тору авыр иде. Шуңа, бераз күзенә күренмичә юкка чыгып тору нияте белән, ул йөгереп елга буена төшеп китте. Гомер буе шыгырдап ябылган капка да, бу юлы шыгырдамый, җай гына ябылып, келәсенә тавыш-тынсыз кереп утырды. Һавадагы кошлар да йортны урап очтылар. Бар тарафка ишетелердәй булып бары Айзидәнең йөрәге какты.

Озак утырды кыз елга буенда. Элеккеге кебек, әнисенең үзен эзләп төшүен, һич югы, тау башыннан кычкырып кына өйгә чакыруын көтте. Гөлҗамал күренмәде. Көзге салкыннан өшеп, тешләре тешкә бәрелә башлагач, кыз кайту ягына кузгалды. Тиз генә кайтып җылынасы, кара икмәк белән яңа сауган парлы сөт эчәсе килде. Сабыйлыгы белән ул әнисенә карата булган бар үпкәсен онытып, тагын өенә юнәлде. Тынычлангандыр, Айзидәнең елга буеннан йөгереп менгәнен күреп, ашыга-ашыга өстәл әзерлидер. Кайтуын тиз кайтты, тик капканы гына ача алмады Айзидә. Капка тереүле иде.

– Әнием, зинһар, керт мине! Мин синнән һәм авылдан башка яши алмыйм, – дип, капканы кага-кага үкседе ул. – Өшедем мин, әни, керт, зинһар, дим. Бәгырьләрең шундый катымыни соң синең? Мин бит синең кызың, әни!

Озак елады кыз. Әнисенең йөрәге чыдамас, менә-менә капканы ачып, кызын күкрәгенә кысар, дип өмет итте. Кыйнаса да, каргаса да риза, тик кертсен генә. Барыр җире юк иде аның.

– Әйттем бит мин сиңа, күземә күренмә, дип. Бар, теләсәң кая кит. Эшләп яшә. Кешеләрнең ничек яшәгәнен бел, – дип, ишеген ачып кына кычкырды Гөлҗамал.

Ул да булмады, йорт ягыннан шап итеп җиргә Айзидәнең сумкасы очып төште...

Олы юлга таба атлаганда, адым саен, Айзидә әнисенең эндәшкәнен, чакырганын көтте. Тавышын ишетми калмыйм, дип, тын гына атларга тырышты. Көтте, Аллаһтан ялварып, елый-елый көтте. Тик ул тавыш... ишетелмәде. Әнә, каяндыр арттан, авылның теге башыннан ук машина тавышы килде. Шәһәргә барадыр. Туктаса – нишләр? Утырып китәрме? Утырмаса – нишләр? Ә утырса, кемгә барып бәрелер? Кем ашатыр, яшәр почмак табышыр? Шул сораулар

белән кайнаган Айзидәнең башы чатнап авыртты. Үкереп елыйсы килде. Тик түзде. Әле, йөк машинасы янына туктагач та, шофёрга күтәрелеп карамый, артыннан йөгерүче, кул болгаучы булмасмы, дип өметләнеп, берникадәр авыл ягыннан күзләрен алмый карап торды. Гөлҗамал каны бар иде шул анда да. Шуңа, Айзидә күкрәген тутырып иркен сулыш алды да, тузанлы аягын машина тупсасына куеп, ишек тоткасына үрелде. Беткән баш – беткән! Хәзер ни булса да, аңа барыбер иде. Кемгә кирәк ул бу дөньяда? Кайтып, анасын рисвай итте, дип көләр авыл халкы. Аннары бераз исләрендә тотарлар да онытырлар. Ул да онытыр. Тырышыр, һич югы.

– Кайларга юл тота икән чибәркәй төнгә каршы?

– Шәһәргә кадәр алып барасызмы? Тик минем акчам юк.

Йөзе елаудан шешенгән, тузгыган чәчләре юеш битенә сыланган, аяклары тезенә кадәр юл тузанына баткан бу кызганыч кыяфәттәге кызны күреп, машина шофёры Тимерхан бераз аптырап калды. Нәрсә дип уйларга да белмәссең монда?

– Утыр, әйдә. Келтерәтеп кенә илтеп җиткерермен үзеңне, – дип шаяртмакчы булды Тимерхан.

Айзидә шофёрга күтәрелеп тә карамый, кабинага менеп утырды да, кечкенә мәче баласы кебек йомарланып, ишеккә сыенды.

– Курыкма, кеше ашамыйм мин. Ишеккә шулкадәр сыланма, төшеп каласың.

Айзидә эндәшмәде. Әле һаман борынын мышык-мышык тартып, нечкә бармаклары белән юеш күз төпләрен уды.

– Кайсы җансызы, шушы фәрештәне берүзен чыгарып җибәрде икән? Эшләрең шәптән түгел, ахры, кызый.

– Бар да әйбәт.

– Иреңнән качтың мәллә?

Айзидә, егетнең бу керделе-чыктылы сорауларын ишетмәгәндәй, тәрәзәгә карап барды.

– Атаң куып чыгарды мәллә өеңнән?

Тимерхан, туктаусыз сорау яудырып, кызны авыр уйларыннан арындырасы килде.

– Ярар, буласы булган инде. Үзең беләсеңдер. Дөньяда төрле хәлләр була, шулай бит. Тик борчылма, моның белән генә тормыш тәгәрәвеннән туктамый.

Бик озак тын гына бардылар. Егет, тәрәзәсен ачып, берничә тапкыр тәмәкесен көйрәтте. Кыз да бераз тынычланып йокымсырап бара башлады. Ләкин Тимерханның чираттагы тәмәкесен көйрәтеп җибәреп, җиңелчә генә йөткереп куюыннан сискәнеп, Айзидә күзләрен ачты.

– Исеме ничек соң бу чибәркәйнең? – дип сорады Тимерхан, кызның, ниһаять, уянуына шатлангандай.

– Мин чибәркәй түгел.

Тимерхан ир-ат дип аталмас та иде, әгәр шулчак кызның кулыннан эләктереп алмаса.

– Тотынма миңа, зинһар, яме. Зинһар!

Айзидәнең үртәлеп, әрнеп әйтелгән бу сүзләреннән егет әллә нишләп китте. Каушап калдымы, куркыпмы? Егет кызның кулын ычкындырды да, карашын алдындагы ватык-җимерек юлга күчереп, башкача ләм-мим дәшмичә кайтты.

Тимерхан начар күңелле кеше түгел иде үзе. Төз, озынча гәүдәле, чибәр үк дип әйтү килешмәсә дә, матур гына йөзле, хатын-кыз игътибарыннан мәхрүм булмаган, купшы гына шәһәр егете. Бераз гына масаючан. Инде яше утызга

җитсә дә, сугыштан соң тол калган ялгыз анасы белән яши бирде. Әнисе, югыйсә, улының башлы-күзле булуын күптән тели иде.

– Йә? Кайда калдырырга сине?

Тимерханның әлеге соравыннан Айзидә, теләми генә керфекләрен күтәреп, тәрәзә аша урамга карады. Алдында, кичке утларын балкытып, шәһәр урамнары таралып киткән иде. Кыз карашларын бер тыкрыктан икенчесенә күчерде. Кай урамнан китсен икән? Кайсысы аны көтә? Гүя, килгәнсең икән, әйдә, рәхим ит, дип, машина каршына тезелешеп басканнар.

– Белмим, – диде Айзидә, пышылдап кына. Аның бу машинага чарасызлыктан гына утырганын Тимерханга сиздерәсе килмәде.

– Миңа кайда булса да эшкә керергә кирәк, – дип куйды кыз, ничек тә монда кадәр килүен акларга тырышып.

– Бәй, барып керер кешең дә булмагач, ник килдең соң син монда? Шәһәр бит бу. Монда сине кем көтеп тора?

Айзидә, берни аңлатмый гына төшеп каласы килеп, ишек тоткасына үрелде.

– Белмим. Булды, мин монда төшәм.

– Нәрсә, урамда кунасыңмыни?

Тимерхан җәһәт кенә үрелеп кызның җиңеннән эләктерде дә кире утыргычка тартты.

Айзидә бу юлы ризасызлык белдермәде. Эчтән:

«Сабый гына бит бу», дип, Тимерхан кызны кызганып куйды.

– Йә, ярар. Әйдә, миндә кунып чыгарсың. Иртәгә төзелешкә алып барырмын. Бәлки, эш табылыр. Әнигә килен дә кирәк. Шатлансын әле, – дип шаяртмакчы булды егет.

Айзидә, коты чыгып, кузгалып киткән машинадан сикереп төшеп калмакчы булып ишеккә ябышты.

– Юк, юк, мин нишләп сездә куныйм, ди. Кирәк түгел. Калдырыгыз мине монда.

– Курыкма. Шаяртам гына. Утыр урыныңда, төшеп тапталасың килмәсә, – диде егет, кырыс итеп. – Бу, сеңлем, авыл түгел. Начар күңелле кешеләр дә күп. Бәреп үтерергә дә күп сорамаслар.

– Үтермиләр, – диде Айзидә, балаларча тискәреләнеп.

Тимерхан, машинасын үзе яшәгән урамга алып кереп, озак та бармый, түбәсе капка өстеннән күренер-күренмәс кечкенә өй янына китереп туктатты. Тимерхан кабинадан егетләрчә сикереп төште дә, сызгырына-сызгырына нидер көйләп, Айзидәнең ишеген ачты. Кызга кулын сузды. Кулын бирергә теләмәгән Айзидәнең сумкасын кулыннан алып капкага юнәлде.

Тимерханның әнисе Мөнәүвәрә карчыкның йортта тавыкларын кетәклеккә ябып йөреше иде. Тимерханының капкадан яшь кенә кыз бала ияртеп керүен күргәч, аптыравыннан катып калды.

– Йә Хода, бусы кем тагын?

– Әни, сиңа куян күчтәнәче алып кайттым, каршы ал, – дип шаулады Тимерхан, капкадан керешли. – Ярар инде әни, әллә ниләр уйлама. Килен алып кайтмадым, кайгырма. Хәсрәтең йөзеңә бәреп чыкты тәмам. Юлчы. Бүген бездә кунып чыгар. Барыр җире юк.

Улының холкын белә иде Мөнәүвәрә. Уены-чыны бергә аның. Шуңа ышаныргамы-ышанмаскамы дип, сынаулы карашлары белән кызны баштанаяк күздән кичерде.

– Кунар җире булмаган яшь кыз бала шәһәрдә шуфирларга утырып йөриме? Җүнле нәмәме соң бу?

Теле явыз иде Мөнәүвәрәнең. Шуның аркасында аны берәү дә кияүгә алырга теләмәде. Матурлыгына кызыгып килгән берсе, теленең әшәкелегенә түзми китә торды.

– Ярар инде, әни, агуыңны чәчмә. Нормальный бала ул. Шәһәргә киләсе килгән, эшкә урнашырга. Бөтен кешенең дә туганы юк бит инде. Әйдә кер, Айзидә. Курыкма.

– Һым.

Усал итеп нидер әйтмәкче булып, Мөнәүвәрә улына таба units укталды да, әйтәсе сүзен теш арасына кысып, борыны төбеннән үк кызны җитәкләп алып кереп киткән Тимерхан артыннан гаҗәпләнеп карап калды. «Кара син аны, ничек шәпләнеп киткән. Кулына оҗмах кошы эләккәнмени? Әллә киленле дә итәргә маташамы бу? Белмәссең», дип уйлады ана.

– Әллә нинди Аллаһ мәхлуклары бар инде дөньяда, Аллакаем, – дип, елан кебек агуын чәчеп калмаса, исеме Мөнәүвәрә булмас иде, мөгаен.

– Кети, кети, кети, кет, кет, – дип, саташып, кетәклеккә кереп, инде йокымсырап утыра башлаган тавыкларының котын алды Мөнәүвәрә.

«Алышынган мәллә, бу карт дивана», дигән кебек, тавыклары дертләп, аның ягына бер генә кискен караш ташладылар да, тынычланып, тагын башларын кырын салып, йокыга киткән рәвеш ясадылар.

**5**

Айзидә, башка барыр урыны булмаганлыктан, Мөнәүвәрәләрдә берне дә кунды, икене дә. Аны беркем кумады. Рәхмәт йөзеннән Айзидә Мөнәүвәрәнең йорттагы булган-булмаган бар эшен башкарырга тырышты. Эш сөю – әнисеннән алган бердәнбер бирнәсе иде аның.

Кызның йорт белән өйне бер итеп бөтерелеп чабып йөрүе Мөнәүвәрәнең күңеленә май булып ятты. «Шәһәрдән мондый килен табып буламы? Моны ычкындырсакмы, икебез дә җүләр булачакбыз», дип уйлады хатын. Һәм җае туры килгән саен, Тимерханга үз ниятен җиткерергә, улының игътибарын кызга юнәлтергә тырышты. Тора-бара, кеше арасына чыгып йөреп, дөньяга күзе ачылып китмәсен, дипме, кызның өйдән чыгып йөрүләрен дә өнәмәгән кебек кыланды.

Айзидәгә төзелештә эш табылды. Аны маляр өйрәнчеге итеп алдылар. Ул анда да матур гына эшләп китте. Берникадәр вакыттан соң норманы остазыннан да артыграк итеп тапшыра башлады. Озак та тормый малярлар бригадасында тулы хокуклы эшче булды.

Шулай бар нәрсә дә җай гына уңай якка киткән, бар нәрсә дә үз урынына утыра башлаган сыман иде.

Айзидә иртән иртүк Мөнәүвәрәнең өй эшләрен бетереп, йөгереп эшенә килде. Кичләрен өйгә очып кайтып, аннан-моннан капкалап, клубка ашыкты.

Менә бүген дә Айзидә, эшеннән кайтып, сеткасыннан ипи-сөтен кәбәркә (кухня) өстәленә куйды. Ашыга-ашыга юынды, киенде.

– Кайттыңмы?

Мөнәүвәрәнең кискен соравыннан кыз сискәнеп китте.

– Әйе.

Хатын, ризасызлыгын белдереп, шап-шоп табак-савыт кузгаткан булды. Анысын алды, монысын куйды. Кашык шалтыратты. Капкачларны ачып япты. Мөнәүвәрәне мондый халәттә күргәне булмаганга, кызга башта карчыкның кыланышы мәзәгрәк тә тоелды.

– Мине бүген репетициягә чакырдылар, беләсезме, – дип, сүзне нәкъ кирәкмәгән җирдән башлап җибәрде ул. – Мин бит җырлыйм, Мөнәүвәрә апа. Кичә клубка алып кереп җырлатып карадылар да, әйбәт җырлыйсың, әйдә кил безгә, тиздән концерт була, диделәр. Миңа репертуар әзерлибез, диделәр.

Мөнәүвәрә шаккатты. Шушы гана җитми тора иде. Карчык кызның сүзеннән шартлардай булды.

– Кичке мәктәбеңә дә йөр, репетицияңә дә өлгер... Теләкләрең зурдан икән. Өйдәге эшне кем эшли? – дип, кинәт кенә алпавытбикә образына керде дә куйды Мөнәүвәрә. – Әнә, тәрәзәләрне юарга кирәк.

Мөнәүвәрә кулына кайдандыр килеп эләккән пычак сабы белән тишәрдәй итеп тәрәзә пыяласына төртте.

– Тимерханның урын-җирен алыштырып юарга кирәк. Эш өйдә дә күп. Җырлап йөрү нәрсә инде ул? Әнә, бакчада да эш бетмәгән, бик тик торасың килмәсә?

Мөнәүвәрә тимерне кызган чагында сугарга ниятләде.

– Сиңа, миңа калса, бу хәлеңдә җыр турында түгел, кияүгә чыгу турында уйларга кирәк. Квартирант булып озак яшәргә җыенасыңмы?

– Мин яшь бит әле, Мөнәүвәрә апа. Чыгасым килми минем кияүгә. Әле концертларда җырлыйсым бар бит. Бәлки, җырчы да булып китәрмен.

Айзидә, сабыйлыгы белән баштарак, гомер иткән карчыкның мәкерен аңламады.

– Тәрәзәләрне иртәгә, ял көне юармын. Хәзер соң ич инде. Ә Тимерханның урын-җирен хәзер дә алыштырып өлгерәм. Аларны да иртәгә юармын.

Мөнәүвәрәнең үзенә төбәлгән ризасыз йөзен күреп, Айзидә кинәт туктап калды. Үзен гаепле хис итеп, нишләптер акланырга тотынды:

– Мөнәүвәрә апа, мин сезгә чиксез рәхмәтле. Акча алгач, әйттем бит, барсы өчен дә түләрмен. Сез әниемнән дә киңрәк күңелле, чынлап.

Авызыннан ялгыш очкан сүздән кызның тамагына төер тыгылды. Үз әнисе белән чагыштыра аламы соң бу карчыкны? Алуын аладыр, ләкин тиешме? Әни – изге бит ул. Ә аның әнисе изгеме? Әллә үзе шундый игелексезме? Нишләп йөри ул монда? Нигә шушы чит-ят кешеләр арасында кимсенеп ята? Кем төшерде аны шушы көнгә? Тискәрелегеме, әллә тәкъдиреме?

– Аннары, тулай торак та бирәбез, диделәр. Мин тиздән анда күчәм. Күчсәм дә, сезгә килеп йөрермен, булышырмын, яме. Борчылмагыз, – дип, әллә әйтте, әллә әйтмәде Айзидә. – Мин барыйм инде бүген репетициягә, Мөнәүвәрә апа, яме. Җибәрегез инде. Минем, чынлап, сәхнәгә чыгып җырлап карыйсым килә. Зинһар, җибәрегез?!

Кызның үртәлүдән хәле бетеп, күз аллары караңгылангандай булды һәм инде каядыр бару теләге сүнде. Бары тик әлеге хакыйкатьтән тизрәк качасы килде.

– Бер чыгып ычкынгач, бик нык булышырсың инде син. Беләм сезнең кебек кылкойрыкларны. Койрыгыгызны тоттырмыйсыз инде сез аннары, – дип, һаман үз туксанын туксан итәргә тырышып мыгырданды Мөнәүвәрә карчык.

Айзидә алдындагы ипи валчыгын өстәлдән кулы белән генә сыпырып төшерде дә эндәшми генә шешәсен алып куйды. Аннары яшь тулы күзләрен карчыкка күрсәтмәскә тырышып, бүлмәдән чыгып китте. Тик Мөнәүвәрә генә һаман тынычлана алмады.

– Минем ачыгавыз өлгергәнче, чыгып та качар бу. Эзлә син аннары клублар,

концертлардан. – Мөнәүвәрә карчык канын суырып алгандай хис итеп, Айзидә, аякларын чак сөйрәп, Тимерхан бүлмәсенең ишеге янына килде. Тупсасыннан атлап кермичә генә, ишек яңагына сөялеп, бүлмә эченә күз салды. Бүлмә зур түгел иде. Тар гына кысан бүлмәгә киң тимер карават, аркалы агач урындык, ике ишекле шкаф сыйган. Берданбер кечкенә тәрәзә, әйтерсең, шушы күңелсез күренешне күрәсе килмичә, йөзен кояш нурында уңып, ашалып беткән чаршау белән каплаган. Кыз бу күңелсез эштән котылырга теләп, тиз генә юрган-мендәр тышларын салдырды да чирканудан борынын җыерып, бүлмәдән тизрәк чыгып китмәкче булды. Ләкин көтмәгәндә юлында «үсеп чыккан» Тимерханга бәрелеп, туктап калды.

Тимерханның нидер сиздерәсе, ниндидер мөһим сүз әйтәсе килеп йөргәнен Айзидә күптән сизенә иде. Шуңа күрә ул аның юлында очрамаска, күзләренә туры карамаска, кирәк-кирәкмәгәнгә сүз катмаска тырышты. Бүген ычкына алмас, ахры. Кыз үзен караклыкта тотылган кешедәй хис итеп, кызарынып башын иде. Ишек катында сүзне кайдан башларга белми аптыраган Тимерхан бер – артында сүз тыңларга торган анасына, бер – каршында куркудан куырылган Айзидәгә борылып карады.

– Айзидә, тукта, ашыкма әле. Сөйләшик, – диде ул, инде беркая да ашыкмаган кызны аптыратып.

Айзидә дә, кайдадыр кереп качасы, яшеренәсе килгән сабый баладай, як-ягына каранды. Бүлмәдә ул качардай урын юк. Хәтта кечкенә тәрәзәләргә дә, көн яктысын каплап, күзгә караңгылык сыланган иде.

– Нәрсә турында сөйләшәбез, Тимерхан абый, вакыт соң бит инде.

– Әни әйтә, тулай торакка китәргә җыена, ди. Чынлапмы?

Тимерхан бераз тынычланып түргә узды да, Мөнәүвәрәнең ачуын чыгарып һәм Айзидәне тәмам куркуга салып, бүлмә ишеген ябып куйды.

– Мәңгегә монда кала алмыйм бит инде мин, Тимерхан абый, – дип, ялварулы карады кыз. – Мин бит сезгә чит кеше. Болай да рәхмәт. Сез булмасагыз, белмим, кая барган булыр идем?

Вак-вак адымнар белән, Айзидә читләтеп кенә ишеккә якынлашырга маташты.

– Ашыкма, Айзидә. Китәргә ашыкма, дим. Без сиңа инде чит кеше түгел, бер-беребезгә ияләнергә өлгердек.

Тимерхан, бүлмәдән чыгып качарга маташкан Айзидәне, беләгеннән эләктереп алып, үзенә тартты. Бу хәлдән тәмам куркуга төшкән кыз, читлектәге җанвар шикелле ыргылып, ишеккә ташланды.

– Юк инде, китәргә кирәк. Кешедән оят, – диде Айзидә, ишек toткасына ябышып. – Болай да инде кызлар кемең соң ул синең Тимерхан, ирең мәллә, дип теңкәне корыталар. Минем танышларым, дигәнгә ышанмыйлар. Алайса таныштыр, диләр. Сез кызларга ошыйсыз, Тимерхан абый.

Айзидә бу сүзләрне махсус, аның үзеннән күңелен төшерү, хисләре булган очракта аларны суыту өчен әйтте, әлбәттә.

– Әгәр ирең булсам, начар булыр идемени? Миңа, син ошыйсың, Айзидә.

Тимерхан, хисләренә бирелеп, кызга тагын якын килмәкче булды. Тик Айзидә, кыр кәҗәсе кебек җитез генә икенче якка сикереп чыкты да, Тимерханның берүзен генә калдырып, бүлмәнең ишеген ябып куйды.

– Ни сөйлисез сез, Тимерхан абый? Акылдан шаштыгыз мәллә? – дип кычкырды Айзидә ябык бүлмә ишеге аша.

Беразга тынлык урнашты.

– Тимерхан абый, зинһар, бу турыда сөйләшмик. Сез бит олы кеше, – дип кычкырды ул ишек артыннан янә.

– Булса соң, олы булса? – Тимерханның да бирешәсе килмәде. – Мин сине кулларымда күтәреп йөртермен, Айзидә, – диде Тимерхан, бар көче белән ишекне этеп. – Синнән дә бәхетле кеше булмас. Телисеңме, мин сине диңгезгә алып барам, киләсе җәйгә, телисеңме...

Тимерхан бу сүзләрен ихлас күңелдән, кызны чынлап бәхетле итәсе, аны тормышның аяусыз җил-яңгырыннан саклыйсы, яклыйсы килгәннән әйтте. Аның таянычы, терәге буласы килгәннән.

Тик Айзидә аны ишетергә дә, күрергә дә теләмәде.

– Нәрсә турында сөйлисез сез, ни дигән кияүгә чыгу? Нинди диңгез? Чыга алмыйм мин сезгә кияүгә, аңлыйсызмы? Чыга алмыйм. Сезгә бит башка, олы хатын кирәк. Мин бит сезнең балагыз кебек. Аннары, әни мине бәреп үтерә, – дип, кычкырып, үкси-үкси еларга ук тотынды.

Әлеге хәлдән Мөнәүвәрәнең коты чыкты. «Карале, тымызык күл кортлы була, дигәндәй. Усаллаша башлады бит бу!» – дип уйлады карчык. Аннары, күрше-фәлән ишетмәсен, дип, йөгерә-йөгерә, ишек-тәрәзәләрне ябарга тотынды.

Тимерхан да бүлмәдә тынып калды.

– Нинди әни турында сөйлисең син? Бармы соң ул синең? Булса да, кирәкме син аңа? Барлыгыңны да белгәне юк бит, Айзидә, – диде бераздан Тимерхан, үз-үзе белән сөйләшкән кешедәй, тыныч кына. Сулкылдавы аша да ишетте аның сүзләрен Айзидә. Чөнки ул сүзләрне күптән, Тимерханның яисә Мөнәүвәрәнең авызыннан бер чыгачак, дип көткән иде.

– Сүз тидермә минем әнигә. Гадел кеше ул. Минем монда икәнне белми генә. Белсә, әллә кайчан йолкып алып кайтып киткән булыр иде.

Бу җавапны да Айзидә инде күптән әзерләп куйган иде. Тик шушы әйтелгәннәргә башка бер сүз дә өсти алмады.

Тимерхан тагын бераз тын торды. Аннары ишекне үзе сыярлык кына этеп ачып, кысылып чыкты да ишек төбендәге элгечтән алып пәлтәсен киде, баш киемен кулына тотты.

– Курыкма миннән, Айзидә. Мин сиңа дошман түгел. Мин дә тере кеше бит. Сине яраткач, нишлим инде...

Айзидә, сулкылдавын басарга теләп, Тимерханның караватыннан салдырып алган мендәр тышлыгы белән юеш битен сөртте, яшенә чыланган чәчләрен җыеп баш артына урады. Аннары матур чәчәкле чаршау яшергән үзе йоклый торган караватка барып утырды.

– Тимерхан абый, мин сезне бик хөрмәт итәм. Ләкин, мин сезгә кияүгә чыкмыйм. Үпкәләмәгез.

Айзидәнең соңгы сүзе шушы иде.

– Әйдә, – диде Тимерхан, киенгән килеш ишек төбендә таптанып. – Синең бит бүген клубка барасың килгән иде. Әйдә, киен, киттек. Әни борчылмасын өчен, үзем илтеп куям.

Айзидә, дөрес ишеттемме соң дигәндәй, җәлт итеп чаршауны тартып, Тимерханга карады.

– Әйдә, барсаң. Борын мышкылдатып утырма, киен. Мин чыга торам. Озак торма, – дип, ачык ишектән тышка атлады ир-егет.

## 6

Алар мәдәният йортына килеп кергәндә, репетиция тәмамланып, җырчы-баянчылар таралыша башлаган иде инде. Айзидәнең ишектән керүен әллә кайдан күреп алган сәнгать җитәкчесе Ирек, кулын болгап, аны үз янына чакырды. Айзидә канатланып аның янына йөгерде. Тимерхан ишек төбендә бераз уңайсызланып торганнан соң, тамашалар залының иң соңгы рәтенә барып утырды. Үзешчән түгәрәк кызлары, кайтырга җыенуларын да онытып, сәхнә пәрдәсе артыннан бер-бер артлы башларын чыгарып карый-карый, чышын-пышын аны энә күзе аша үткәрергә тотынганнар иде инде. Озын буйлы, кап-кара пәлтәдән, башында килешле киң кырыйлы эшләпә, үз бәһасен белеп кенә атлаулары – сокланмаслык та түгел шул. Тик Тимерханның башкаларда кайгысы юк иде. Аның бөтен теләге – Айзидәне үзенеке итү. Шул теләк бөтен эчен яндырды, әллә нинди планнар кордырып башын катырды. Монда ул аяк атлаган булыр идеме, әгәр Айзидә теләмәсә? Үзе дә бит гармунда начар уйнамый. Өйдә генә уйнап утырыр иде. Туйганчы җырлатыр иде. Юк, кызга бит сәхнәгә менеп, кеше алдына чыгып җырларга кирәк. Матурлыгын кешегә күрсәтергә, җырын ишеттерергә кирәк! Шуларны уйлап, Ирекнең Айзидә тирәсендә кулларын болгый-болгый бөтерелгәнен карап үртәлеп утырды Тимерхан.

– Изумительно! Гаҗәеп. Кайдан беләсең син бу җырларны? Афәрин, афәрин. Булдырдың. Тә-ә-әк, иртәгәдән репетициягә. Аңлашылдымы? Иртәгәдән. Шушы вакытка, яме. Соң түгелме?

– Юктыр, соң түгел.

Айзидә, куркынып, карашын Тимерханга күчерде.

– Синең әтиең мәллә ул? – дип сорады Ирек, хәлнең нидә икәненә төшенеп.

Кыз уңайсызланып, ни әйтергә белми, җилкәләрен генә җыерды.

– Ну, ярый. Тик, зинһар, иртәгә соңга калмагыз, яме, – диде Ирек, тирәнгә кереп тормый гына, Тимерхан ягына дустанә ишарәләп.

Тимерхан Ирекнең ни әйткәнен ишетмәсә дә, күзе үткер иде. «Бусы ярый, минем кебек карт тәресе куркыныч түгел. Әнә теге яшь баянчысы Айзидәдән күзен дә алмый, денсез», дип үртәлде ул. Аңа калса, денен чәчәргә дә күп сорамас... Тик Айзидәгә генә ошамас аның баянчыны кыйнаганы. Аннары, кызлар өчен гомерендә сугышып йөргәне булмады Тимерханның. Киресенчә, кызлар аны үзләре бүлеште.

Эчендә янган уттан көеп, Тимерхан олы учлары белән алгы рәттәге урындык аркасын шап-шоп какты. Үтереп тәмәке тартасы килде. Ачуыннан иртларын чәйнәде. Тик һич кенә дә, Айзидәнең үзен генә залда калдырып, урамга тәмәке тартырга чыгып китәсе килмәде. Турысын гына әйткәндә, кызны – үзе табып алып кайткан хәзинәне – беркем белән дә бүлешергә теләмәде.

Айзидә, тизгә генә дип, дус кызлары белән саубуллашырга теләп, сәхнә артына чыкты. Шуны гына көтеп торган кызлар, аны корт кебек сырып алып: «Кем ул синең таинственный кавалерың», – дип теңкәсен корытырга керештеләр.

Менә шушы вакытта Айзидә үзен яшәештәге иң бәхетсез кеше, дип санар иде, әгәр дә сәхнәнең икенче башында уктай төбәлгән ягымлы бер карашны тотып алмаса, шул караш хәнҗәр булып йөрәгенә кадалмаса! Шул кадалудан йөрәге гармун күреге кебек кысмаса! Ул караштан үзен көчкә йолкып-аерып, тар коридор буйлап чыгу юлына ашыкты Айзидә. Ләкин күз нурлары өзелергә теләми, шул

карашка баткан килеш калды, гүя. Шул караштан аңа әллә нинди илаһи көч иңде, иңнәренә канатлар үсте, сүнгән өметләренә җан өрелде. Аның аяклары җиргә тимәде. Кая барганын да аңламый йөгерде Айзидә. Хәтта Тимерханның артыннан чак җитешеп шапын-шопын чабып кайтуын да сизмәде. «Ярый әле килгәнмен бу шәһәргә. Ярый әле килгәнмен», – дип, шатланып уйлады кыз.

**7**

Һаваларда оча ике аккош,
Еракларга китә моңнары.
Киләчәккә аккош юлы булып
Китсен безнең яшьлек еллары...

Шушы җырны алар бигрәк тә яратып кабатладылар. Газиз, киң канатларын киереп җилпи-җилпи очкан һавадагы бөркет шикелле каерылып, гармунын тартты. Йөзенә күтәрелеп карарга кыймаса да, үзенең хисләрен гармун күрегеннән өзелеп чыккан һәр авазга, аларны әллә нинди бизәкләргә төреп, кыз күңеленә җиткерергә тырышты. Шул бизәкләр Айзидә күңеленең әллә нинди нечкә кылларына барып бәрелә дә, аларның кайтавазы булып, гаҗәеп матур тавышына үрелеп, сихри моңга әйләнеп, фанилыкка тарала иде. Алар шушы җыр эчендә тәүге кат серле хисләрне тойдылар, кичерешләреннән ләззәт алдылар, яшьлектә генә була торган беренче мәхәббәтнең иң саф ноктасына күтәрелеп, бәхет тәмен татыдылар.

Еш йөри алмады Айзидә мәдәният йортына. Тимерхан белмәгәндә качып-посып, белгән чагында берничә минутка гына эләгә алды ул монда. Ләкин шушы кыска гына вакыт эчендә гел бергә булырга, моң дөньясына китеп, яшәештәге проблемаларны онытып, хисләре белән яшәргә тырыштылар. Бер-берсенә булган яшерен кичерешләрен әйтеп бирү түгел, күзләренә тутырып карарга да кыймадылар.

Газиз: «Соңга калдың бит, әйдә, озатып куйыйм», – дип, сәбәп тапкан булып, Айзидәне озата барганда да, баштарак юлның икесе ике ягыннан атладылар. Кыз капка төбенә кайтып җиткәч кенә, кулларын кысышып саубуллаштылар.

Тимерхан, Айзидәнең һәр хәрәкәтен күзәтү астында тотарга тырышса да, артыгын булдыра алмады – йә эшеннән соң кайтты, йә бөтенләй командировкага китеп барды. Айзидә дә ул өйдә вакытта соңга калып кайтмаска,яисә бөтенләй өйдә генә утырырга тырышты. Ләкин, без капчыкта озак ятмаган кебек, әлеге хәл дә капчыкны тишеп чыкты да, Тимерханны чыгырыннан чыгарды.

Ул көнне мәдәният йортында репетиция соң бетте. Караңгыга калынды. Тимерханның өйдә икәнен белсә дә, Айзидә Газизнең озатып кую тәкъдименнән баш тарта алмады. Чөнки вакыт соң иде. Икенчедән, караңгы да, Тимерхан берни дә күрмәс, дип уйлады.

Ике гашыйк җитәкләшеп төнге тын урамның уртасыннан атладылар. Сөйләшмәделәр, бары тик пышылдап кына яраткан җырларын көйләделәр.

Айзидә яшәгән өй тирәсендәге тал төбенә басып саубуллаштылар. «Сау бул», – дип, Газиз оялып кына Айзидәнең иңнәренә кагылды. «Ярар, сау бул», – дип, кыз да, оялып кына, керфекләрен аска төшерде. Гаеп итәрлек берни дә кылмадылар югыйсә.

Ләкин кинәт өермәдәй кайдандыр күтәрелеп чыккан Тимерханны күреп котлары очты.

– Менә ничек, җыр кабатлап йөрисең икән син, Айзидә.

Тимерхан зур авырлык белән булса да кыз алдында ярсуын тыярга тырышты.

– Тимерхан абый, мин үзем Газизнең озатып куюын сорадым.

– Марш өйгә! – дип, җөмләсен теш арасыннан кысып чыгарды Тимерхан.

Айзидә, куркынган мәче баласыдай, капкага ташланды. Ләкин ачык капкадан йөгереп кереп, капка баганасы артына яшеренде дә, тын гына, бу икәүне капка ярыгыннан күзәтеп тора башлады.

– Мин синең белән озак сөйләшеп тормам, яме, молокосос. Тагын бер тапкыр Айзидә янында күрәм икән, үтерәм, белдеңме?! Кара аны, малай! – Тимерхан Газизнең борыны төбендә кулындагы авыр күсәген уйнатты.

– Үтереп кара. Кем соң син, карт җүләр?! Кеше баласына хуҗа булдыңмы?

Газиз дә ир-ат белән ир-атча булып, бирешергә теләмәде.

– Әх, син, молокосос. Телең дә озынмы әле синең?! Якын килмә, аңладыңмы?! Үтерәм!

– Синнән сорармын, карт ишәк!

Айзидәнең куркудан күз аллары караңгыланды, тәненә чымырдап салкын тир бәрде, башы әйләнеп китте. Егетләр сугыша иде. Ул, коты алынып, өйгә йөгереп керде дә, чишенергә дә онытып, юрганы астына башы белән кереп чумды. Кызый шулай томаланып күпме ятканын да, ничек йоклап киткәнен дә соңыннан хәтерләмәде.

**8**

– Сандугачың чыгып оча бит инде. Аңгыра сарык бәрәне кебек, авызыңны ачып йөрсәң, – диде Мөнәүвәрә кадала-чәнчелә чабып кайтып кергән Тимерханга, Айзидә почмагына ымлап.

– Әни, кит моннан, ачуымны китермә.

Башкача сүз куертып торырга теләмичә, егет анасы ягына кулын гына селтәде. Аннары, кыз ягына борылып бер-ике адым атлады да, ары табан ни кылырга, ни әйтергә белми аптырап, төртелеп калды.

– Ашыкма әле, Айзидә, ашыкма. Сөйләшәсе сүз бар.

– Минем сезнең белән сөйләшер бер сүзем дә юк, Тимерхан абый. Мин тулай торакка күчәм.

Кызның бу сүзләреннән егетнең башы тумар белән суккан кебек зыңлап китте, кинәт кенә тыны кысылып, каерылган канатлардай ике як иңе салынып төште, аяклары йомшарды. Шыбыр тиргә баткан башыннан кипкесен салып дымлы учларында әвәләргә тотынды Тимерхан. Ни әйтсен соң ул? Ничек алып кала алсын аны бу адымыннан? Хет бикләп куй! Башыннан андый уй да узган иде егетнең. Тик болай да тормышта дөнья яктылыгы күрмәгән Айзидәне кызганды. Аны елатасы, рәнҗетәсе килмәде.

– Айзидә, сиңа ярдәм кирәк булганда, без ярдәм иттек. Әни белән, – дип, алдан әзерләп куйган соңгы чарасына күчте егет. – Хәзер безгә синең ярдәм кирәк.

– Сөйләгез, – диде Айзидә, борылып та карамый, Тимерхан ягыннан үзенә карата бернинди куркыныч та янамасына ышанып.

Ике арада тынлык урнашты. Кыз, битараф йөз белән, һаман әйберләрен төреп чемоданына тутыра бирде. Егет, сүзен ничек башларга белми изаланды.

– Син бит күрәсең, без иске, тузып беткән йортта яшибез, бернинди уңайлыклар юк, – дип башлады егет, үзен дә ышандырмаган, әллә нинди

ялган интонация белән. – Тиздән безгә фатир бирергә тиешләр. Менә шул. Син аңлыйсың бит, мин әнине ташлап калдыра алмыйм, берничек тә. Ул карт, авыру. Әгәр дә мин өйләнсәм... миңа зуррак фатир бирәчәкләр, Айзидә. Яңа фатир! Анда син хуҗа булачаксың!

Тимерхан әлеге сүзләрне тиз-тиз генә әйтеп салды да, Айзидәнең шушы яңалыкка мөнәсәбәтен күрүдән куркып, күзләрен йомды.

Ике адым гына читтә кәбәркә стенасы артына качып бу икәүнең сөйләшүен тыңлап торган Мөнәүвәрә, улының сүзләреннән авып китә язды. Менә сиңа мә! Вәт шпиун, ичмасам, улы! Нинди матур хәйлә уйлап чыгарган! Улының тапкырлыгы белән горурланып та куйды.

– Сез зур яңа фатир алсын өчен мин сезгә кияүгә чыгарга тиешме? Мин бит сезне яратмыйм. Башкага өйләнегез, Тимерхан абый. Сезне яраткан кызлар күп бит.

– Әйе, өйләнешергә. Һәм безгә фатир бирәләр. Син йә миңа чыгасың, йә башкача беркемгә дә кияүгә чыкмаячаксың, менә шул!

Үз колакларына үзе ышанмый торган Айзидә егеткә борылып карады. Бу юлы Тимерханның йөзендә үзенә карата бернинди дә мәрхәмәт чаткысы күрмәде. Җитди сүз сөйли түгелме соң бу кеше?!

Куркудан, кулына тоткан чемоданы кинәт шапылдап идәнгә төште дә, сатлык рәвешендә капкачын киереп ачып, кызның хәстәрләп җыйган әйберләрен кире идәнгә чәчте. Шушы мизгел Айзидәнең йөрәгенә хәнҗәр булып кадалды. Егет сөйләгән сүзләрнең җитди булуына, үзенең мәкер пәрәвезенә килеп эләккәненә инанды.

– Ә аннан соң карарсың. Теләсәң – аерылышырсың.

Айзидә егетне ишетмәде. Аның моңа тиклем булган бар тормышы кинолента сыман, күз алдыннан йөгереп узды да Тимерханның әле генә сөйләгән сүзләренә килеп бәрелеп туктап калды. Нәрсә соң бу?! Нишләп соң аның тормышында изгелек өчен һәрвакыт фаҗига, хәсрәт белән түләргә туры килә? «Әнинең рәнҗешедер», дип уйлады кыз.

– Мин бит алай булдыра алмыйм, Тимерхан абый, булдыра алмыйм. Мин бит сезне яратмаячакмын, – дип пышылдады кыз чарасызлыктан, өметсез, сүнгән тавыш белән. – Сез мине иреккә җибәрсен өчен, ни эшләргә соң миңа? Башка нәрсә сорагыз, зинһар.

– Шушы гына... безнең үтенеч.

«Үтенеч» сүзенә Тимерхан аеруча басым ясап әйтте. Көчләмиләр, үтенәләр генә, янәсе. Аннары, кызның хәсрәтле йөзен күрергә теләми, борылып ишеккә сөялеп басты. Йөрәге, шушы мәрхәмәтсезлеге өчен егетне тукмаган, кыйнаган кебек, бөтен тәнен, җанын дөрселдәтеп какты. Аһ, оятсыз! Ничек яшәр бу мәкере, ялганы белән? Яшәр, яшәр! Айзидә дә күнеп китәр. Ул бит әнә ничек матур итеп яшәде алар белән. Башта елар, аннары бу хәлгә ияләшеп, тагын алар белән бер гаилә булып яшәп китәр, дип, үзен-үзе юатты егет.

– Менә сиңа мә! Елап утыра тагын! Кыл изгелек – көт явызлык. Без бит моны, сиңа яхшы булсын, дип эшлибез, аңгыра кыз. Үскәч аңларсың. Ышанычлы кулга эләккәнең өчен, рәхмәт әйтерсең, игелексез.

Мөнәүвәрәнең бу сүзләре хөкем карарын тормышка ашыручы электр урындыгы белән тиң иде. Ул Айзидәнең тәнен түгел, җанын үтерде.

– Кит, әни! Кем кысылырга кушты сиңа, – дип җикерде Тимерхан.

Тик соң иде инде. Сүз бит улаткан ук кебек. Кире әйләнеп кайтмый. Барып кадала да җанны яралый.

## 9

Никах мәҗлесенә кеше күп чакырылмаган иде. Остабикәсе белән мулла һәм тагын якын туган дип аталган берничә пар гаилә килгән иде. Тар гына кысынкы бүлмә буйлап сузган өстәлнең түрен олы яшьтәге, күп ашаудан корсаклары салынып төшкән, кыска буйлы, бераз кәкре аяклы мулла белән юан, кызыл битле остабикәгә бирделәр. Алардан уң якка Тимерхан белән Айзидә, берничә ир-ат һәм каршы якта – калган хатын-кызлар утырды. Өстәл белән кәбәркә арасында авыр аякларын сөйрәп бары Мөнәүвәрә генә йөреп торды. Мулла абзый, гадәттәгечә бераз вәгазь сөйләде, аннары, йокымсыраудан авырайган башын өстәл өстендә чайкалдыра-чайкалдыра, иренеп кенә догасын укырга тотынды.

Айзидәгә бу хәл куркыныч төш кебек тоелды. Ул кимсенүдән кечерәеп калган бичара тәнен өстәл алдында хәрәкәтсез калдырып, күңеле белән әллә кайларга очты – әнисенә кайтып, аның үзе өчен бикле ишеген какты, Тимерхан белән сугышканнан бирле юкка чыккан Газизне эзләде. Иң мөһиме, үз аяклары белән шушы шәһәргә чыгып киткән көнен каргады.

– Атаң-анаң бармы соң, балам? – дип сорады мулла, сәер тын утырган кәләшкә сынаулы караш ташлап. Айзидә эндәшмәде. Ул аны хәтта, ишетмәде дә. – Килеп җитә алмадылармы? – дип, мулла сорау алуын дәвам итте. – Әйе, килә алмадылар, – диде Мөнәүвәрә, бу турыдагы сүзне шушы урында тәмамларга теләп. – Абый-апа, энекәш-сеңелләрең дә юкмы? Мулла абзыйның һаман нидер ачыклыйсы килде. Шуңа ул, каршында утырган бу сабыйның рәвешеннән сынаулы карашын алмады. Ул, күрәсең, өй эчендә торган атмосферадан ниндидер яшерен, серле нәрсәдер тойды, нидер чамалады. Айзидә җавап бирмәде. Сорау бирүнең мәгънәсе булмаганлыктан, ә башка кешеләрнең фикере кызыксындырмаганлыктан, мулла да тынып калды. Башкалар исә мулладан узып сүз катырга кыймый тик утыра бирделәр. Бу хәлгә Мөнәүвәрә белән Тимерхан гына шат иде.

– Беттеме? Миңа чыксам ярыймы? – дип телгә килде кинәт Айзидә. Кунаклар тәмам аптырашып бер-берсенә караштылар. – Әйе, әйе, киленкәем, аш чыгарыр вакыт җитте, – дип, хәлне төзәтергә ябышты Мөнәүвәрә.

– Башка беркайчан да миңа ул сүзне әйтмәгез! Мин сезнең киленегез түгел! – Айзидә, урыныннан торып, астындагы эскәмия аша атлап чыкты да, үзенең почмагына барып, чаршавын каплап утырды. Тимерхан әйтер сүз тапмады. Ул, урыныннан торып, кулларын югары күтәреп: «борчылмагыз, аның белән мондый хәлләр булгалый», дигәндәй, һавада ниндидер билгеләр ясап маташты. Кунаклар моны аңлагандырмы, билгесез. Тик беркем берни эндәшми, карашларын гына түбән төшерделәр. Өйдә авыр тынлык урнашты. Ара-тирә, чаршау артыннан Айзидәнең генә мышык-мышык борын тартканы ишетелде.

...Никах мәҗлесеннән соң Тимерхан берничә тапкыр Айзидәгә сүз катты. Ләкин, кыз тәкәббер кыр кәҗәсе кебек, йөзен дә бормады. Аерым ашады, аерым йоклады. Мөнәүвәрә һаман кысташканга, кызга һәммә ысулларны кулланып, ярарга да тырышып карады. Нәтиҗәсе булмады. Кыз, авызына су капкандай, ләм-мим бер сүз эндәшмәде.

Башка чарасы калмаган Тимерхан көннәрдән бер көнне яхшы гына исереп кайтып керде. Аякларын сөйрәп лаш-лош йөрүеннән, шапылдатып ишекләрне кагып ябуыннан ук салганы тәненә сеңеп бетмәгәнлеге билгеле иде. Ир, ишек

катында бераз туктап торганнан соң, өс киемнәрен салып чөйгә элмәкче булды. Тик элгән һәр нәрсәсе ишелеп идәнгә төшә торды. Аннары, шул коелган әйберләре аша сөрлегеп атлап чыкты да, туп-туры Айзидә йоклый торган почмакка юнәлде.

Кыз, тезләрен кочаклап, тәрәзә каршында уйланып утыра иде.

– Нихәл, бичәкәй, – диде Тимерхан, дорфа гына. – Аллаһ ризалык биреп кавыштырган ирең белән хәзер исәнләшмисең дәме? Аллаһтан курык.

Кыз эндәшмәде.

– Ярар, эндәшмә, эндәшәсе килгән чакларың булыр. Но, әле син минем хатын, онытып җибәрмә, – диде Тимерхан, бармагын һавада уйнатты.

Аннары чайкала-чайкала кызга якынлашты. Шушы гамәлне кылыргамы, әллә кылмаскамы, дип, үз-үзе белән көрәшеп килгәндә, нәфесе шулай да җиңде. Һәм ул кызны йолкып кочагына алды.

– Яратырсың, яратырсың. Беркая да бармассың. Яратырсың. Мин бит сине яратам, нык яратам, Айзидә, – дип, карышырга маташкан кызның иреннәренә үрелде.

– Тимәгез миңа, зинһар, Тимерхан абый. Зинһар, тотынмагыз.

– Юк, юк, җаныкаем, менә күрерсең, бар да яхшы булыр. Бар кешене көнләштереп яшәрбез әле. Алтыным, кошчыгым минем...

Бу хәлгә шаһит өй эче тын торды. Бары тик тышта, бүлмәнең зәгыйфь тәрәзәләренә бәрелә-бәрелә, көзге салкын җил улады...

**10**

Айзидә ул көнне Газизне очратырмын дип һич тә уйламаган иде. Сөткә, дип кенә чыкты. Яндагы кибеттә сөт беткәнлектән, аргы урамдагы ларёкка китте. Йөзенә җепшек март кары бәрелеп эреде. Инде йомрыланып килүче корсагын эченә сыйдырып бетерә алмаганга, урта төймәләрен ычкындырып җибәргән пәлтәсе аша язның елгыр, салкын җиле кереп, кызның җылы тәненә сыланып җылынды.

Мәдәният йорты яныннан узганда, нишләптер туктап, аның тәрәзәләренә карап торды. Кемнедер күреп алырга өмет иттеме? Әллә болай гына, сагынып кынамы? Бераз тын торганнан соң, Айзидә, авыр сөт шешәсе салынган сеткасын җирдән сөйрәтеп, ары китте. Үзе дә аңламады – әллә җырлыйсы, әллә елыйсы килде.

Һаваларда оча ике аккош,
Каурыйлары җиргә коела...

– Айзидә, исәнме, Айзидә?

Кинәт Газизнең тавышын ишетеп, Айзидә туктап калды.

– Исәнме, Газиз?

Газиз дә, үз чиратында, Айзидәнең хәйран үзгәргәнлеген күреп каушап төште.

– Син... син, – дип төртелеп торды ул. – Син... матурайгансың.

Кыз күзләрен дымлы керфекләре астына яшерде.

– Нишләдең инде син, Айзидә? Нигә ашыктың?

Газиз, әллә чабып килүдән тирләгән битен, әллә күз яшьләрен җиң очы белән сыпырып төшерде.

Айзидә җавап бирмәде. Аның бүгенге бәласендә Газиз үзе дә сәбәпче

икәнен әйтәсе, елый-елый ачуланасы килде. Тик түзде. Чираттагы җүләрлек кылып, тагын адәм көлкескенә калсынмы?! Бер тапкыр ышанып карады бит инде ул аңа.

– Шулай язгандыр инде, – диде ул сабыр гына, керфеген дә селкетмичә.

Газиз, атылып килеп, Айзидәне кочагына алды, карлы битләреннән үпте.

– Нишлисең, кеше күрер, Газиз.

– Күрсен. Булырның иң куркынычы булды. Куркырлык ни калды соң, Айзидә? Син нидән куркасың?

Ярсуыннан Газиз нишләргә белмәде – эре-эре атлап, үзе тирәли әйләнеп чыкты, учлары белән йомарлап йолкый-йолкый, чәчләрен сыпырды. Әйтерсең, менә хәзер кемнедер тотып алып дөмбәслисе, үч аласы килде.

– Ә син?

Алдында тораташ кебек катып торучы Айзидәдән Газиз башка нәрсә көткән иде. Шуңа ул сорауны бераз аңламый торды.

– Минем балам булачак, Газиз. ...Тимерханныкы.

Тирә-юньдәге тынлыкны бозмый, сиздерми генә бу икәүнең өстенә күк гөмбәзе ишелеп төште дә, кайчандыр бербөтен булырга омтылган әлеге ике җан арасына упкын булып ятты. Бер-берсен күрергә теләгән күзләр, бер-берсен күрми башлады, бер-берсенә сузыласы куллар бер-берсенә сузылмады. Аларны уратып алган орбитада сукыр һәм саңгырау тынлык иде. Тәкъдир әнә шундый икән ул. Үзе теләгән вакытта сукыр һәм саңгырау итә дә, язмыш куласасының астын өскә әйләндерә дә куя. Аның кануны шундый.

– Хәзер нишлибез инде, – диде Газиз, башка әйтер сүз таба алмыйча.

Айзидә, керфекләрен төшереп, авыз чите белән генә елмаеп куйды.

– Телисеңме, икәү качабыз моннан иртәгә. Балаңны да үз балам кебек яратырмын.

Айзидә эндәшмәде дә, шул ук вакытта борылып та китмәде. Ул Газиз белән бәйләп тоткан күңелендәге җепселнең тәмам өзелгәнен, үзен ычкындырганын көтте.

– Әйтмә бер сүз дә, Газиз. Сөйләмә юкны.

– Айзидә, әйдә качабыз. Качарга кирәк моннан. Качсаң гына котылып була бу җүләрләр йортыннан. Кил иртәгә шушы урынга, яме. Мин дә әзерләнеп киләм.

– Газиз, тукта, сөйләмә, димен юкны!

Әйтерсең, Газиз аны ишетмәде. Карашын һаман Айзидәнең ычкынган төймәләре аша йомрыланып торучы корсагына төбәп сөйләвен дәвам итте.

– Мин эштән китәм, бүген үк. Әйберләрне җыям. Машина сөйләшәм яисә вокзалдан автобус белән китәрбез. Юк, автобустан безне тотып алырга мөмкиннәр. Шуңа попуткага чыгарга кирәк...

– Газиз! – дип кычкырды кыз, паркны яңгыратып. – Җитте сиңа. Син тәмам акылдан язган! Хәзер үк тукта, алайса...

Айзидәнең кискен тавышыннан Газиз кинәт туктап калды. Аннары җүләрлек кризисыннан айнып киткән күзләрен кызның йөзенә күчерде. Айзидәнең йөзе ябык китап кебек буш иде. Ул аннан берни дә укый алмады.

– Чынлап, – диде егет, тәмам аптырап. – Кил иртәгә, Айзидә. Мин сине көтермен... безгә күптән, күптән качарга кирәк иде. Мин, кыйналганнан соң, ,хастаханәдә озак яттым, шуңа...

– Гази-и-из!

Айзидә бу хәлгә башка түзеп тора алмады. Ул, берни ишетергә теләмичә,

колакларын куллары белән каплады да, җирдә яткан сөт шешәсе салган сеткасын да алырга онытып, бозлы сукмактан кире йөгерде...

...Айзидә йөгереп капкадан килеп кергәндә, Тимерхан, киенеп, каршына чыккан иде инде.

– Син нәрсә? Кайда йөрисең?

Айзидә эндәшми генә узып китмәкче булды. Тик көнләшүдән күзләре кызарган Тимерханга хатынының дәшми генә узып китүе аз иде. Ул аның рәвешен дә, елаудан шешенгән күзләрен дә күрмәде. Әлеге хәл башкача кабатланмасын өчен, яхшылап дәрес бирәсе килде. Шуңа ул хатынны иңсәләреннән эләктереп алды да, өйгә җилтерәтеп алып кереп, бүлмәсенә таба этеп җибәрде. Идәнгә үк аумаса да, карават башына чак тотынып, корсагы белән җайсыз егылудан сакланып калды Айзидә.

– Чыгып киткәнеңә егерме биш минут? Кайда йөрдең? – дип ярсыды ир.

– Тимерхан абый, – диде Айзидә, бар көченә фикерен тупларга тырышып. – Мин кибеттә генә булдым.

– Алган әйберең кайда?

Бу сүздән коты чыгып, Айзидә, кабалана-кабалана, сеткасын эзли башлады, кая куйганлыгын исенә төшерергә тырышты. Эшнең нидә икәнлегенә төшенеп, ул ни дип җавап бирергә белмәде.

– Кибеттә сөт юк иде. Мин... икенче кибеткә бардым. Аннары...

– Алмагач, акчаң калгандыр бит? Кая, бир монда акчаңны.

Айзидә калтыранган куллары белән кесә турысын капшап куйды.

– Мин, Тимерхан абый, югалттым... акчаны. Гафу итегез.

– Абый түгел мин сиңа, соңгы тапкыр әйтәм. Алдашасың бит, кызыкай. – Сугарга дип кизәнеп килгән җиреннән Тимерхан чак тыелып туктап калды.

– Мин бары тик сөткә бардым, Тимерхан абый.

«Абый» сүзеннән үртәлеп, ир йодрыгы белән шкаф ишегенең яңагына китереп бирде.

– Әйттемме сиңа, мин абый түгел, дип?

Инде шкаф ишеге дә беркеткән җиреннән кубып идәнгә авып төшкәч, ир артыгын кыланганын аңлап, чыгу юлына юнәлде.

– Тимерхан абый, сез нигә Газизне кыйнадыгыз?

Чыгып китәргә дип ишек тоткасына үрелгән ир, яшен суккандай, кинәт катып калды. Шушы бер мизгелдә барына да төшенде – җиңелде ул! Тамырсыз, ялган өстенә утырткан бәхетне нинди тирәү белән терәсәң дә, бер җимерелеп төшәсен белде. Тик әле болай тиз җимерелмәс, хатынының үзен яратуын өмет итмәсә дә, бәлки әле, вакыт барын да җайлар, яшәп тә кителер, дип ышанган иде. Ул сүнгән карашын Айзидәгә күчерде. Һәм хатынын танымады! Бу – үзенә төбәлгән усал йөз, нәфрәт һәм ут чәчеп торган караш Айзидәнеке түгел иде.

– Газизеңнең муенын борам, аңлашылдымы?! – диде Тимерхан, әллә нинди шомлы тавыш белән. – Тагын бер шуның исеме чыксын, авызыңны сугып җимерәм, белдеңме! Ә алай-болай аның белән очрашканыңны белсәмме, смотри, кызый.

Тимерхан хәлсезләнгән аякларын чак сөйрәп чыгып китте. Каерылып ачылган ишек, кире ябылмыйча, җавaптан өметен җуйган сорау билгеседәй, яңакларына асылынып тынып калды.

Ачык ишектән җылы тупса аша, ашыга-кабалана, боз салкыны шуышты.

## 11

Төшендә бүген Иделдән боз киткәнен күрде Айзидә. Шаулап аккан боз арасында ялгыз йөзеп баручы паром ярга якыная, имеш. Шул паром эченнән аны кемдер дәшә, чакыра. Кем икәнен аера алмый, тик ниндидер таныш тавышны гына ишетә, имеш.

Айзидә күзләрен ачып бераз тын гына ятты. Өйдә хәрәкәт ишетелмәде. Аннары торып, сак кына барып, шкафны ачты, аннан ниндидер кәгазьләр алып, җәһәт кенә ястыгы астына тыгып куйды. Шкаф, карават, урындык башларына элгән киемнәрен җыеп, аларны да юрган астына тыкты. Аяк очларына басып үрелеп, шкаф өстеннән чемоданын алды, юрган астыннан әйберләрен, берәмберәм чыгарып, шунда тутырырга кереште.

Аннары, чемоданын караваты астына этеп куеп, берни булмаган кыяфәттә кухня ягына узды.

Шулай көтелмәгәндә килене килеп чыгудан, иркенләп чәй эчеп утыручы Мөнәүвәрәнең коты очты.

– Миннән качырып шикәр белән чәй эчәсезме? – диде Айзидә, шаяру катыш, саран каенанасына төрттереп. – Баллы чәй эчәсем килә, дигәч, шикәр алырга да акча җиткерә алмыйм, дигән идегез бит.

Мөнәүвәрәнең авызына капканы кире коелып төшә язды.

– Нәрсә, гомер булмаганны болай таң тишегеннән тордың әле? – дип мыгырданды үз чиратында каенана.

– Миңа бүген икенче сменага. Бухгалтериягә барып кайтам. Тиздән бәбиләр вакытым җитә. Сугылып чыгарга кирәк. Озак тормыйм.

– Тимерхан беләме? – дип, килененең бу ниятенә ризасызлыгын белдерде Мөнәүвәрә. – Әйтмичә китәсең дә, ирең ачулана башласа, үксеп еларга керешәсең. Төне буе йокы мазасы бирмисең. Әле сәгать ничә?

– Белмим.

Айзидә, вакыт күпме икәнен белсә дә, юри әйтмәде.

– Бар, дөньяңны онытып йөрмә. Ярты сәгатьтән өйдә бул. Идәнең юылмаган, кереoriginalоң сасып ята, әнә.

– Идән минеке түгел. Тимерхан да минем ир түгел. Керләр дә минеке түгел. Бары да сезнеке. Теләсәң нәрсә эшләгез.

Килененең көтелмәгән бу кыланмышыннан Мөнәүвәрәнең кулыннан кайнар чәй тулы бокалы төшеп китә язды.

– Карале моны, ничегрәк сөйләшә башлаган. Ярар, Тимерханга сөйләп бирермен. Өйдә кем хуҗа икәнен ул аңлатыр.

– Мөнәүвәрә апа?!

– Әни, диген, агач тел.

– Нишләп сез мине шулай мыскыл иттегез? Алдаладыгыз! Фатирны да тәки бирмәделәр сезгә. Булмагандыр да әле ул.

Мөнәүвәрә эндәшми генә шакмак шикәрен шатыр-шотыр тешләп, өрә-өрә чәй эчүен дәвам итте. Кызга җавап бирергә уйламады да кебек. Аның өчен дә, Мөнәүвәрәнең үзе өчен дә ябык тема иде бу. Күкрәк читлегенең кайсыдыр почмагында калтыраган вөҗдан газабын кузгатасы килми иде сыман.

Айзидә дә каенанасы җавап бирер дип өмет итмәде. Аның, бары тик, эшнең нидә икәнлегенә төшенгәнлеген генә белдерәсе килде. Ул яраның һаман исән икәнен, онытылмаган, кичерелмәгән, һаман сулкылдап авыртып торганлыгын сиздерәсе килде.

– Озак йөрисе булма! Исеңә төшермәсәң, үз башыңа килмәс – хезмәт хакыңны алуга кайтарып бирергә онытма, алай шикәр белән чәй эчәсең килгәч. Син чүбек баштан барын да көтәргә була.

Каенананың сүзләрендә хаклык бар иде. Яшьлеге, җүләрлеге белән килененең нindидер акылсызлык эшләп ташларга сәләтле икәнен белә иде Мөнәүвәрә. Авылыннан качып, Тимерханга ияреп үзе килеп керде бит. Ләкин, ничек килеп керсә, шулай ук чыгып та китә алыр, дип, уена да китермәде.

Мөнәүвәрә, исенә килеп, шушы сүзләрне әйтеп калырга ашыкканда, Айзидә, яшереп куйган чемоданын күтәреп, өйдән чыгып киткән иде инде.

**12**

Зур чемоданын күтәреп, каядыр ашыгучы йөкле яшь хатынның каршысына очраучылар туктап, аңа юл бирделәр дә карашлары белән озатып калдылар.

Айзидәгә барыбер иде. Менә, бу көн тиз генә узар да, иртәгесен ул бәхетле, ирекле булып уяныр. Аның өчен бәхет көне туар. Бар да әйбәт, яхшы булыр. Тимерхан да үзенә тиңен табар. Мөнәүвәрә дә ялганы өчен җан газабы кичермәс. Бүген ул бу шәһәрдән китәр дә, шәһәр аны онытыр. Моның шулай булуын тели иде ул.

Менә ул – матур мәдәният сарайлары, гармунчы Газиз, хис-кичерешләре һәм башкалары белән әллә ниләр вәгъдә итсә дә, үзен бер тамчы да бәхетлерәк итә алмаган шушы шәһәрдән ашыга-ашыга китеп бара. Язмышы аны шулай тиз-тиз генә җыендырып, төенчеген кулына тоттырды да, ашыктыра-ашыктыра, этә-төртә, чираттагы тукталышына озата. Инде ничәнче тапкыр! Тик бер тукталышында да бәхет көткәне юк әле.

Әнисе исенә төшүгә, Айзидәнең йөрәген ут биләде. Ничек кайтып күзенә күренер? Мәңге кайтмам, дип киткән иде бит. Әллә никадәр зур, еракtan елкылдап, тылсым көче белән үзенә тартып торучы шәһәрләрдән кача алса да, әнисеннән һәм үзеннән кача алмас шул. Менә ул, бумеранг шикелле, йөгерә-йөгерә, чыгып очкан оясына кире кайтып бара. Башкача очып төшәр җире дә юк икән!

Әнисе аның монда икәнен белмидер дә. Кызының шушы хәлдә булуы башына да килмидер. Гомере буе аннан качып йөрмәс бит инде. Барыбер бер кайтырга кирәк булачак.

Бу хәлне Айзидәгә күз алдына китерүе дә авыр иде. Төннәрен керфекләрен йомган саен күз алдында һәрчак анасының усал, хәсрәтле карашы торды. Ни генә кылмасын – ятса да, торса да, кайгырса да, шатланса да, шул караш аны ычкындырмады. Һәм ул караш белән күзгә-күз очрашуны аның җаны кыямәт көнен көткән кебек көтте.

Кайвакыт аның тизрәк кайтып, ана хөкемен кабул итеп, ниһаять, бу газаплардан котылып, бушанып каласы килде. Ни әйтсә дә түзәр иде ул хәзер, әнисе күрмәгәндә генә артыннан килеп кочаклар һәм, кычкырса да, еласа да, каны, йөрәге, җаны җылынганчыга кадәр озак итеп кочагыннан ычкындырмас иде.

Ул хәзер анасының нигә шулкадәр кырыс, сөюгә саран булганлыгын аңлады, чөнки анасы һич тә бастырырга теләмәгән тырма башына үз теләге белән китереп басты.

Менә ул, тиз-тиз атлап, кайчандыр үзенә бәхет йорты булып тоелган мәдәният сарае яныннан узды. Әйләнеп карамады. Алай да кичә Газиз үзен

куып тоткан җирдә адымнарын бераз акрынайтты. Газизнең эзләре өстенә аякларын куеп атлап чыкты. Аннары, шул эзләрдән ниндидер этәргеч алган кебек ыргылып, алга китте. Әйтерсең, Газизнең дә качу теләге кушылды да икеләтә көч белән киләчәккә әйдәде.

Айзидә олы юлга түгел, ә паркка кушылган урман аша боз кичүенә чыгарга булды. Бу сукмак аңа таныш. Җәй башында төзелештәге кызларга ияреп су коенырга төшкәне булды. Ашыкмый гына барса, кичкә барып җитәчәк. Ул вакытта инде анда кеше-фәлән дә, җигүле атлар да, машиналар да булмаячак. Бу турыда аның абыйларыннан ишеткәне һәм аларның шулай кичкә калып кайталмаган чаклары турында сөйләгәннәре бар иде. Айзидә бу куе булмаган агачлык арасыннан боргаланып сузылган, инде кары купшакланган ышанычсыз сукмак өстеннән кичүгә таба атлады. Урманга килеп керүгә, бераз ирек, урман һавасы тоеп, кызга сулышлары киңәеп киткән, кар яктысыннан карашлары яктырып киткән сыман тоелды. Йөрәгендә чаң каккандай: «Куркыныч! Куркыныч бит! Курыкмыйча, нәрсә кылып йөрисең син?!» дигән хис бераз сүрелгәндәй булды. Ул инде күкрәк читлеген алай авырттырмады. Киресенчә, бер адым ясаган саен, Тимерханның өеннән ераклашкан саен, ул хис үзенең куәтен югалта, тәэсирен киметә барган сыман тоелды. Чөнки кунакка үз кагыйдәләрең белән килмиләр. Беренче адымнар ясауга ук, урман сине «чишендереп» ата да үзенең көчле дулкыннарына тәнеңне төрә, җаныңа тула да үзенең бер өлешенә, кисәгенә әйләндерә. Урман тере, җанлы ул! Айзидә аны күңеле белән тоя һәм, әллә нинди эчке тоемнарын эшкә җигеп, урман белән сихри элемтәгә керә белә иде. Монда аның җаны ял итте, сырхау, борчуларына дәва тапты. Менә хәзер дә бөтен хәсрәтен, куркуларын онытып, иркен сулап, юлыннан атлады.

Берникадәр барганнан соң туктап, агач төбенә утырып, чемоданыннан ипи кисәге чыгарып тамак ялгады, аннары нарат кәүсәсенә аркасын терәп, бераз черем итте.

Айзидә күзләрен ачып җибәргәндә, кояш нурлары сүрәнәеп, агач араларына караңгылык иңә башлаган иде инде. Урман да тынып калган. Кайдадыр бик еракта узып баручы поезд тавышы ишетелде. Кыз уйлавынча, барып җитәргә озак калмаган. Тимер юлның боз кичүеннән нинди ераклыкта икәнен бераз чамалый иде. Ул зур авырлык белән аякларына торып басты. Аяклары авырайган, көн буе чемодан күтәреп барып, тәне арыган, буыннары катып киткән. Атларга кирәк. Кичүгә җитәсе бар. Аннары гына аргы яктагы авылга кереп, берәрсендә кунып чыгарга сорарга була. Абыйларының шулай кунып чыкканы бар. Айзидә хәтта ул кешеләрнең исемнәрен дә белә иде. Изгелекнең исеме була һәрвакыт.

Караңгылык куерганчы, урманнан чыгып калу теләге белән, туктамыйча бата– чума бара торгач, кызның тәмам хәле калмады. Тирә-якта күз күреме начарланды. Күңелен тагын курку яулый башлады. Аякларын чак сөйрәп, ул ауган каен агачы өстенә килеп утырды. Күзләрен йомды. Нидер эшләргә кирәк иде. Төнгелеккә урманда кала алмый бит инде ул. Ерак та кителде кебек, тик урман һаман бетмәде.

Иң беренче – куркуын басарга, аннары – булган бар көчен җыеп, тагын атларга!

Кинәт ул кайдадыр якында гына ниндидер кыштырдау ишетте. Юк, агач та сынмады, кош та очмады, ә артыннан кемдер килә сыман... Айзидә тавыш килгән якка башын борды. Тик шикләнерлек бернәрсә дә күзенә эленмәсә дә,

куркынычның кайдадыр якында гына сулыш алуын, үтәли карашын тойды. Кыз урыныннан торды да тавыш килгән якка йөзен борып карады, үзе сак адымнар белән атлап китте. Берникадәр ара киткәннән соң, колагына кеше тавышлары да ишетелгән сыман тоелды. Бу хәл аның күңеленә бераз өмет кертсә дә, шиген дә арттырды. Кем булмас урманда?! Менә бераздан, агач арасыннан аңа учак яктысы да күренде. Урап узарга кирәк, дип уйлады кыз. Тик, барган саен, сукмак учакка якынайды. Һәм, күп тә үтми, ул аны кечкенә генә аланга алып чыкты.

Учак тирәсендә берничә ир-ат кайнаша иде. Учактан ерак түгел ярым җимерек алачык шәүләсе күренде. «Урман кисүчеләрдер», дип уйлады Айзидә.

Ут яктысында, алан башында кинәт пәйда булган яшь хатынны күреп, учак янындагылар беравык аптырап калдылар. Убырлымы, сихерчеме, әллә өрәкме? Ир-атлар, ни уйларга белмичә, бер-берсенә карангаладылар.

Айзидә торапаш кебек катты. Йөгерергә түгел – бер атларга да хәле юк иде. Тик учак янында торган ирләрнең йөзләренә чыккан курку, камалышта калган кебек нидәндер шикләнеп, сак кына хәрәкәт итүләре аны бераз аптырашта калдырды.

Ул да булмады, Айзидә, янында ниндидер җылы дулкын тоеп, бу ирләр алдында үзе генә түгел, ә аларның күңелләренә шом салырдай гайрәтле ниндидер көч иясе торганлыгын аңлады.

Җиңелчә генә ырылдау яңгырады. Шушы әмерне генә көткәндәй, ир-атлар дәррәү килеп артка чигенделәр.

Бу – бүре иде. Айзидә яхшы белә. Әнә ул, башын горур күтәреп, яшь хатынга игътибар да итми, учакка таба ике-өч адым ясады. Ут чәчеп торган усал, үткен карашы белән ир-атларның һәр хәрәкәтен күзәтте.

Алар тавыш-тынсыз чигенә-чигенә, берәм-берәм, ярым җимерек каралты эченә кереп шылуга, бүре ишегалдына килеп арт аякларына утырды да тулган ай кебек матур йөзен Айзидәгә борды.

Бер мизгел бүре белән яшь хатын күзгә-күз карашып тордылар. Җанвар амбразурага күкрәген куйган батыр кебек, урыныннан кымшанмады. Нәрсәдер аңлатырга теләгән бүре, сыртын кабартып, кыска гына итеп улап алды.

Хатын сискәнеп китте.

Менә хәзер, аның күкрәк читлеген ертып, кечкенә генә, инде бетәм, менә бетәм, дип калтыранып көн итүче җанын тартып чыгарырлар да, «бар, яшә», дип, күккә алып чөярләр кебек тоелды. Бер елга сузылып, аны әллә нинди түбәнчелекләргә төшереп елата-елата, җанын кыйный-кыйный яшәеш дәресе биргән, җитлектергән киеренкелек үзенең чишелешен табарга дип алып чыгып киткән икән аны бу юлга.

Айзидәнең бар үткәне, тузып кирәксезгә чыккан иске кием кебек, шушы урман авызындагы сукмак башында калды.

Җанының бичара булмавы, үлмәве аның үзе өчен генә түгел, тагын кемдер өчен мөһим булуын аңлады. Ул, Айзидә, карар итүче дә, хәл итүче дә, тудыручы да, үтерүче дә түгел! Ул – бары тик яралучы, абынучы, ялгышучы, төзәлүче, үсүче. Ул – кемдер тудырган яшәеш барышы. Аны сакларга утыртылган бүре дә «Айзидәнең тормышы» дип аталган зур дөньяның мөһим бер элементы – этәргече иде.

Айзидә юлын дәвам итте. Ул инде курыкмады. Әнә, урманнан чыгарга да күп калмаган. Агач аралары яктырып, аксыл күккә тоташкан. Алда, өстендәге

искергән бозны алып ату өчен көч, гайрәт туплап, яз килүен сабыр гына көтеп ятучы Иделе иде.

Менә бит. Килеп җитте! Инде авылына да озак калмады. Урман авызыннан Иделгә төшәсе дә кичкелеккә катып киткән боз сукмагыннан икенче ярга чыгасы. Иң мөһиме – икенче ярга чыгасы!

**13**

Кинәт ишек шакудан Гөлҗамал дертләп китте.

Соңгы вакытта ул һәр тавышка сискәнде, һәр кергән кешене шикле, сынаулы караш белән каршы алды.

Хәбәр көтте!

Кешеләр барын да беләләрдер, бары аңа әйтергә генә банзат итмиләрдер, дип уйлады.

Изгесен өмет итсә дә, хәбәрнең явыз булырына да әзер иде.

Ул барына да әзер иде! Тик башы гына исән булсын Айзидәсенең! Барын күтәрергә дә риза.

Бу бәланең оеткысын да үзе ясап салган, күпертүчесе дә ул, гомер бирүчесе дә.

Шушы бер ел эчендә Гөлҗамал гомеренең һәр көнен энә күзе аша үткәрде. Һәр мизгелен бизмәнгә салды.

Өстендәге киеменә түгел, тәненә кадалып, авырттырып-сызлатып, тәкъдире күлмәген тегүче энәнең җеп башын эзләде.

Менә, шакыдылар. Кем булыр? Таң белән явыз хәбәр йөридер?!

Гөлҗамал урыныннан кузгала алмады.

Ул күптәннән инде күбрәк урын өстендә ята. Хәл белүчеләр дә, керүчеләр дә сирәк иде. Гөлҗамал аларны үзе яратмады. Күрергә дә, ишетергә дә теләмәде. Ярдәмнәрен дә кабул итмәде.

Үзе теләп, үзен үзе хөкем өстәленә салды.

Менә тагын шакыдылар!

Кем булыр?!

Түрдәге, бүкәне җиргә тиеп туктап калган сәгатьнең теле кузгалып, текелдәргә тотынды түгелме? Тоелды гынамы?

Менә ягылмаган өйнең туң ишеге ачылыр да, аннан урам салкыны бөркелер.

Урам салкыны белән ул көткән хәбәр керер. Ул хәбәр аны кызганмас!

Тагын шакыдылар!

– Әни!

Инде ничәнче көн урын-җиреннән тора алмаган Гөлҗамал кинәт торып утырды.

Ишетелдеме?

Теге яктан ишекне тарттылар. Ишек ачылмады. Тупсасына боз каткан.

Кемдер ишеккә китереп типте. Ишек бозыннан кубып ачылып китте.

Ишек катында торган Айзидәсен күрүгә, Гөлҗамал аңлады – ...хәбәр, чынлап та, аны кызганырга килмәгән! Сынарга килгән!

– Кызыкаем, – диде Гөлҗамал.

Анасының хөкемен көткән Айзидәгә Раббы үз хөкемен әзерләгән иде. Ул, куркынып, караватның икенче башына чүгәләде.

Аның кинәт кисеп эче авыртып китте. Ул ухылдап, ике куллап корсагына ябышты. Авыртуга түзәрлек түгел иде. Хатын курку тулы яшьле күзләрен анасына күтәрде.

Барын да аңлады Гөлҗамал.

Вакыты елап ята торган түгел иде.

Шуңа Гөлҗамал акрын гына урыныннан торды, үрелеп, карават башыннан шәлен алып башына каплады, өстенә сырмасын элде.

– Ят, – диде ул, үзе әле генә бушаткан урынына төртеп. – Курыкма.

Гөлҗамал үзенең җылы урынына кереп йомарланган кызының өстенә юрганын каплады. Калтыранган кытыршы куллары белән битләрен, кулларын сыпырды.

– Курыкма. Әле куркырлык бер нәрсә дә юк, – диде, кулларын Айзидәнең корсагына күчереп.

Кинәт ишек тагын ачылып китте һәм аннан ир-ат шәүләсе күренде. Ир кеше бер көлтә салкынны өй эченә уздырды да, үзе дә тупса аша эчкә атлады.

Ишек катында кинәт, арыган-талган, йончыган Тимерханны күрү Айзидәгә авыр да, бераз куркыныч та иде. Ул курку тулы өнсез карашын иренең борчулы йөзенә күтәрде.

Ә Газиз кайда соң? Нигә ул эзләп килмәгән?

Хатын үзен, ачы җилләргә чыдый алмый, менә өзеләм-өзеләм, дип калтыранып торучы яфрак кебек хис итте.

Өзелеп, кай тарафка төшсә дә, череп туфракка әйләнеп юк булачагы көн кебек ачык иде.

Аның яфракка хас җанын ычкындырмый, җир һәм күк белән тоташтырып торучы ныклы агач кирәк иде.

Чөнки яфрак бер өзелеп төшсә, яфрак та, аны яшәтүче агач та үзенең дөньяви бурычын, мәгънәсен югалтачак. Агачсыз яфрак, яфраксыз агач – нигә?

Андый агач – Газиз булырга тиеш иде кебек.

Бөкре агачта да яфрак була. Бөкре булса да, яфрак ярырга сәләтле агачта, кайчан да бер төзәеп, гайрәтләнеп үсеп, болытларга күтәрелер, дигән өмет бар.

– Ярар, – диде кинәт Тимерхан, телгә килеп. – Тәрәзәләребезгә кадәр боз каткан. Мич ягарга утыныгыз бармы?

Гөлҗамал бу сүздән дертләп китте.

– Бар. Каралтыда.

Тимерхан карашын тагын бер кат Айзидәгә ташлап алды да, олы күн бияләе белән бүреген янәшәдәге сәкегә ташлап, өйдән чыгып китте.

Гөлҗамал беравык сүз кату түгел, селкенергә кыймый торды.

Ул Айзидәнең нидер әйткәнен, аңлатканын көтте. Тик кызы ләм-мим бер сүз эндәшми, яшьле күзләрен бозлы тәрәзәгә төбәгән килеш ята бирде.

– Ярар, – диде Гөлҗамал, үз гомерендә беренче тапкыр ары табан ни кылырга белми коелып төшеп.

Аннары, ябык ишеккә таба бераз карап торганнан соң, урыныннан кузгалды да:

– Өй тулы кунак, самавыр куярга кирәктер, – дия-дия, аякларын чак кымшатып, мич артына узды...



*Тукай туган көн – Казанда шигырь бәйрәме.*
*Сулдан уңга: Аяз Гыйләҗев, Ринат Мөхәммәдиев,*
*Мөхәммәт Мәһдиев һәм Туфан Миңнуллин.*
*1990 ел.*



*Татарстан Язучылар берлеге каршындагы бакчага Гомәр Бәширов һәм Әмирхан Еники, безне хәтерләтеп мәңге яшәсеннәр, дип, имәннәр утырткан. Ни кызганыч, ул имәннәр юк инде бүген… 1994 ел, сентябрьнең соңгы көннәре.*



*Беренче рәттә сулдан уңга: Рифкать Исрафилов (режиссёр), Муса Гали, Равил Галимуллин (Башкортстанның Чишмә районы җитәкчесе), Ренат Харис, Рауль Мир-Хәйдәров; икенче рәттә: Ринат Мөхәммәдиев, Мостай Кәрим, Рәсүл Гамзатов, Гариф Ахунов, Хәйдәр Бигичев. 1994 ел.*



*Россия Федерациясе гимны авторы Сергей Михалков белән. Фото 1993 елның мартында Советлар йортының колонналы залында төшереп алынган.*



*Илдар Юзеев, Аяз Гыйләҗев, Гариф Ахунов, Шәүкәт Галиев белән.*



*Легендар һәм фидакяр, милләт җанлы Ренат Акчурин белән аның эш кабинетында. Әле генә операция ясап чыккан чагы. Фоторәсем 2017 елда шагыйрь Наил Касыймов тарафыннан төшерелде. Мәскәү шәһәре.*


*Курт Воннегут (1922-2007) – күренекле Америка әдибе.*

*Үзендә сатира, «кара юмор» һәм фәнни фантастика элементларын берләштергән «Песи бишеге» (1963), «Бишенче номерлы терлек сую бинасы, яки Балаларның Хач явы» (1969) һәм «Чемпионнар өчен иртәнге аш» (1973) кебек күләмле әсәрләре аны XX гасырда бөтен дөньяга танытты.*

*Шуңа өстәп, Воннегут – мавыктыргыч вакыйгаларга корылган һәм, гадәттә, көтелмәгәнчә тәмамланган кызыклы, кызык, ә урыны-урыны белән кызганычрак та тоелган хикәяләр авторы да әле.*

*Арадан икесен сайлап алып, хөрмәтле журнал укучылары, хөкемегезгә тапшырырга рөхсәт итегез. (Бер уңайдан, әлеге эшкә алынуымны аклап, искәрмә ясап үтим: мине бу юлда кичә-бүген чит илләрдә иҗат ителгән яңа әсәрләрне татар укучысына үз ана телебездә җиткерәсе килү теләге генә йөртә...) Кайсыдыр китабына керештә язганча, тәкъдим ителгән хикәяләрнең беренчесенә карата автор үзе артык зур фикердә булмый. Аның каравы, икенче хикәясенә карата тәрҗемәче башкача уйлый. Сез дә битараф калмассыз дип ышанам.*

**Тәрҗемәчедән**



Курт
Воннегут

# ХИКӘЯЛӘР

## ГОМЕРЛЕК СӘЙРАН

Алар кырларга, агачларга һәм бакчаларга терәлеп торган шәһәр читендәге күрше йортларда үсте. Ерак түгел сукырлар мәктәбе урнашкан иде.

Хәзер икесе дә егерме яшьтә, бер-берсен елдан артык күргәннәре юк. Ике арада һәрдаим җылылык саклануга карамастан, аларның беркайчан да мәхәббәт турында сөйләшкәне булмады.

Егет Ньют исемле иде. Кыз – Катарина. Кояш кичкә авышкач, Ньют Катарина яшәгән өйнең ишеген шакыды.

Катарина, кәләшләргә багышлап чыгарылган калын, ялтыравыклы журналын кулдан төшермичә, тоткага үрелде һәм, гаҗәпләнүдән:

– Ньют! – дип кычкырып җибәрде.

– Әйдә, йөреп кайтабыз, – диде Ньют. Ул оялчан иде. Хәтта Катаринадан да ояла иде. Оялчанлыгын яшерер өчен, таркау сөйләшергә тырышты – әйтерсең, аны чын-чынлап борчыган мәсьәләләр әллә кайда калган, әйтерсең, ул берәр шымчы һәм хәзер аның матур, буй җитмәслек, дәһшәтле вакыйгалардан

арынып, ял итеп торган чагы. Беркайчан да, мәсьәлә турыдан-туры үзенә кагылганда да, Ньют сөйләм рәвешен үзгәртмәде.

– Йөреп кайтабызмы? – дип сорады Катарина.

– Бер адым, ике адым, – диде Ньют. – Яфраклар таптап, басмалар кичеп.

– Син шәһәрдәмени?

– Берәр сәгать кенә әле.

– Болай... һаман сафта, алайса?

– Җиде ай калды. – Ул артиллериядә беренче класс рядовое булып хезмәт итә иде. Формасы бөгәрләнгән. Ботинкасы тузанлы. Үзе кырынмаган. Журналга үрелде:

– Матур китабыңны карыйм әле.

– Мин кияүгә чыгам, Ньют.

– Беләм, – диде ул. – Әйдә, йөреп кайтабыз.

– Кырык якта кырык эшем ята, Ньют, ә туйга бер атна вакыт калды.

– Саф һавада йөзең алланыр... Алсу йөзле кәләш булырсың. – Ул журнал битләрен әйләндерде: – Менә аның кебек, аның кебек, аның кебек. – Ньют алсу йөзле кәләшләргә төртеп күрсәтте.

Алсу йөзле кәләшләргә карап, Катарина да алсуланды.

– Генри Стюарт Чезенска бүләгем булыр, – диде Ньют. – Сәйраннан мин аңа алсу йөзле кәләш алып кайтырмын.

– Исемен дә беләсең?

– Әнкәй хат салды, – диде ул. – Питтсбургтан бит?

– Әйе, – диде Катарина. – Ул синең күңеленә хуш киләчәк.

– Бәлки.

– Син туйга... килә алырсыңмы, Ньют?

– Белмим шул.

– Ялга ничә көнгә кайттың соң?

– Ялга? – дип кабаттан сорады Ньют. Ул куш биттә сурәтләнгән көмеш сувенирлардан күзен алмый иде. – Мин ялга кайтмадым.

– О?

– Бездә аны «самоволка» диләр.

– Булмаганны!

– Әйе шул, – диде ул, яңадан журналга текәлеп. – Һәдия эзлим. – Ул журналдагы исем-атамаларны укып китте. – Альбемарль? Вереск? Легенда? Роза? – Катаринага бакты. Елмайды. – Икегезгә дә калак бүләк итсәм, ничек?

– Ньют, Ньют, чынлап әйт әле...

– Минем йөреп кайтасым килә.

Катарина, борчылып, учын кысты:

– Хәрби хезмәтеңне ташлап качу турында шаярдың гына бит?

Ньют, кашларын сикертеп, сак кына, полиция машинасына охшаган тавыш чыгарды.

– Кайдан... Кайдан качтың?

– Форт Брег, – диде Ньют.

– Төньяк Каролина?

– Әйе, – дип җавап бирде ул. – Скарлет О'Хара мәктәпкә йөргән Фаетвилль тирәсеннән.

– Монда ничек килеп чыктың?

Ул, юлаучы машиналарның тукталуын сорагандай, баш бармагын өскә күтәргән килеш кул селкеде:

– Ике көн.

– Әниең беләме?

– Мин аның янына кайтмадым.

– Кем янына кайттың?

– Синең янга.

– Ни өчен?

– Чөнки мин сине яратам, – диде ул. – Әйдә, йөреп кайтабыз? Бер адым, ике адым, яфраклар таптап, басмалар кичеп...

Озакламый алар көрән төс сеңгән яфраклар келәме буйлап агачлар арасына узды.

Катарина ачулы, ярсулы иде. Еламыйча көчкә тыелып:

– Ньют, – диде, – ахмаклык бит бу.

– Нәрсә?

– Хәзер менә яратам дип әйтүең. Моңарчы ул турыда сүз кушканың булмады. – Кыз туктаган урынында басып калды.

– Киттек, – диде Ньют.

– Юк, ары бармыйбыз. Гомумән, сиңа иярәсе калмаган, – диде Катарина.

– Иярдең бит инде.

– Өйдән читкәрәк алып китәсе килде, – диде ул. – Кем дә кем туйга бер атна кала синең миңа әйткән сүзләреңне ишетсә...

– Ни булыр иде?

– Сине тилергән дип уйлар иде.

– Ник алай? – дип сорады ул.

Катарина көрсенеп куйды.

– Әйткән ахмаклыгың миңа бик ошады, күңелемне нечкәртте. Ләкин... хәрби хезмәттән качып кайтуыңа ышанып җитә алмыйм. Бәлки бу, чыннан да, шулайдыр. Мине яратуыңа да ышанып җитә алмыйм. Бәлки, бу да, чыннан да, шулайдыр. Ләкин...

– Бу чыннан да шулай.

– Яхшы. Рәхмәт, алайса, – диде Катарина. – Дустым буларак, Ньют, мин дә сине бик нык яратам. Ләкин... Мондый вакыйгалар кичерер өчен шактый соңга калдык без. – Катарина Ньюттан читләште. – Синең беркайчан да мине үпкәнең булмады. – Ул йөзен каплады. – Хәзер үбәргә кирәк, димим. Барысы да, ничектер, көтелмәгәнчә килеп чыкты. Мин ни әйтергә дә белмим.

– Әйдә, сәйранда йөри бирик. Шул гына, – диде ул. – Җаның ял итсен. – Алар янә кузгалды.

– Син миннән нәрсә көттең соң?! – дип сорады Катарина.

– Нәрсә көткәнемне кайдан белим инде? – диде Ньют. – Минем беркайчан да болай эшләгәнем юк иде әле.

– Кочагыңа ташланырмын дип уйладыңмы?

– Бәлки.

– Өметеңне өзгәнгә гафу ит.

– Өметем өзелмәде, – диде ул. – Мин бернигә дә өметләнмәдем. Шәп йөрибез бит?

Катарина тагын тукталды.

– Хәзер ни буласын беләсеңме?

– Уема да китермим.

– Без бер-беребезнең кулын кысышабыз, – диде Катарина. – Бер-беребезнең кулын кысышабыз да, дуслар булып, ике якка таралышабыз. Менә ни булачак.

Ньют башын чайкады.

– Яхшы. Вакыт-вакыт искә төшер мине. Сине дөньядан артык күреп яратуымны искә төшер.

Катарина үзе теләмәстән елап җибәрде. Ул Ньютка аркасын куеп басты, иге-чиге күренмәгән агачлар буена күз текте.

– Ни бу? – дип сорады Ньют.

– Чиксез ачу, – диде Катарина. – Синең хакың юк иде...

– Мин белергә тиеш идем, – диде ул.

– Мин сине яратсам, алдан ук белдерер идем.

– Белдерер идеңме? – дип кабатлап сорады ул.

– Әйе, – диде Катарина. Ньютка борылып карады. Аның йөзе ут яна иде.

– Үзең күрер идең, – диде Катарина.

– Ничек?

– Күрер идең, – дип кабатлады ул. – Мондый хисне яшерер өчен хатын-кызның акылы җитми.

Ньют игътибар белән кызның йөзенә бакты. Әле генә әйткән сүзләренең хакыйкать булуыннан Катарина үзе дертләп китте: әйе, хатын-кыз мәхәббәтне яшереп тота белми шул.

Ньют ул мәхәббәтне күреп өлгергән иде.

Ул күңеле кушкан адымга барды. Катаринаны суырып үпте.

– Сиңа ярап булмый! – диде Катарина, егетнең кочагыннан котылгач.

– Чынлапмы?

– Кирәкми иде.

– Ошамадыммы?

– Син нәрсә көттең? Кыргый дәртем ташып чыгар, дипме?

– Мин күрәзәче түгел.

– Саубуллашыйк, – диде Катарина. Ньют кашын чак кына җыерып алды. Аннары:

– Ярар, – диде.

Катарина яңадан сүз катты:

– Үбешүебезгә тамчы да үкенмим. Миңа бик тә, бик тә рәхәт булды. Безгә иртәрәк үбешә башлыйсы иде. Аралар якынрак чакта. Мин сине һәрвакыт хәтерләрмен, Ньют... Бәхетле бул.

– Син дә, – диде ул.

– Рәхмәт, Ньют.

– Утыз көн, – диде ул.

– Нәрсә? – дип аңышмыйча калды Катарина.

– Гауптвахтада утыз көн, – диде ул. – Шушы үбешүнең бәһасе...

– Гафу ит, – диде Катарина. – Мин сине качып китәргә кыстамадым.

– Беләм.

– Батырлык түгел бу. Бүләкләү көтмә.

– Батыр булу шәптер, – диде Ньют. – Генри Стюарт Чезенс батырмы соң?

– Очрагы туры килсә, – диде Катарина. Алар, саубуллашуны онытып, яңадан сәфәргә кузгалган иде. Бу хәлне аңлаудан Катаринага эсселе-суыклы булып китте.

– Син аны, чыннан да, яратасыңмы? – дип сорады Ньют.

– Әлбәттә, яратам! – диде Катарина, кайнар сулышын бөркеп. – Яратмасам, кияүгә чыгар идеммени?

– Кай ягы белән ошый ул сиңа?

– Болай төпченүең белән син мине рәнҗетәсең, аңлыйсыңмы? Генриның яхшы яклары күп, бик күп. Мөгаен, начар яклары да күп, бик күптер. Ләкин бу – синең эш түгел. Мин аны яратам һәм холык-фигылен синең хозурыңда тикшерергә җыенмыйм.

– Гафу ит, – диде Ньют.

– Шаккатарсың! – диде Катарина. Ньют аны яңадан үбеп алды. Аңа Катарина үзен үбүен сорый сыман тоелды.

Алар диңгез булып җәйрәгән җиләк-җимеш бакчасына килеп керүләрен сизмәделәр.

– Ничек шулкадәр ераклаштык без? – дип сорады Катарина.

– Бер адым, ике адым, яфраклар таптап, басмалар кичеп, – диде Ньют.

Сукырлар мәктәбенең чиркәү манарасында чаң кагу ишетелде.

– Сукырлар мәктәбе, – диде Ньют.

– Сукырлар мәктәбе, – дип кабатлады Катарина. Ул, гүя йокы исереклеге аша, башын чайкады: – Мин өйгә кайтырга тиеш бит!

– Саубуллашыйк, – диде Ньют.

– Мин саубуллашырга теләп авыз ачуга, син үбешә башлыйсың, – диде Катарина.

Ньют алмагач астында чабылган печән өстенә сузылды:

– Әйдә, утырып торабыз.

– Юк, – диде Катарина.

– Мин сиңа кагылмыйм.

– Ышанмыйм, – диде Катарина.

Ул, Ньюттан егерме адым читкәрәк китеп, үзгә агач астына сыенды. Һәм күзен йомды.

– Төшеңә Генри Стюарт Чезенс керсен, – диде Ньют.

– Кем?

– Төшеңдә сөекле киявеңне күр, – диде Ньют.

– Күрермен дә! – диде Катарина һәм, булачак ирен күз алдына китерергә теләп, чытырдатып күзен йомды.

Ньют иснәде.

Яфрак арасында бал кортлары гүелдәде, һәм Катарина чак кына мәрткә китми калды. Керфекләрен күтәргәч, Ньютның, чыннан да, йокыга талганын күрде. Ньют ара-тирә гырлап та алгалый иде.

Бер сәгать буе Катарина Ньютны уятырга базмады. Бер сәгать буе җаныннан артык яратып аның йокысын саклады. Алмагачларның шәүләсе көнчыгышка авышты. Сукырлар мәктәбендәге чиркәү манарасы яңадан аваз бирде. Песнәк:

– Чик-а ди-ди-ди, – дип җыр сузды. Еракта-еракта машина бырылдый башлады, ләкин, күпмедер эшләгәч, тавышын басты. Аннары яңадан бырылдый башлады һәм, тавышын баса-баса, ниһаять, бөтенләй тынды.

Катарина Ньют алдына тезләнә төште:

– Ньют!

– Нәрсә? – диде егет, күзен ачып.

– Соң инде!

– Сәлам, Катарина!

– Сәлам, Ньют! – диде Катарина.

– Мин сине яратам, – диде егет.

– Беләм, – диде Катарина.

– Соң инде, – диде Ньют.

– Соң инде, – дип кабатлады Катарина. Ньют урыныннан торды, тамагын кырып алды, тураеп басты.

– Шәп йөрдек, – диде ул.

– Килешәм, – диде Катарина.

– Саубуллашабызмы? – дип сорады Ньют.

– Син нишлисең? – дип сорады Катарина.

– Шәһәргә җитүгә, үземне җитәкчелек кулына тапшырам, – диде егет.

– Уңышлар! – диде Катарина.

– Сиңа да, – диде Ньют. – Миңа кияүгә чыгасыңмы?

– Юк.

Ньютның ирен чите тартылып куйды, ул игътибар белән Катаринага карап торды, аннары, кызу-кызу атлап, ары китте.

Катарина аның ерагайган саен кечерәя баруын, бихисап шәүләләр, агачлар арасында югалып-югалып алуын күрде һәм бөтен җаны-тәне, һәр күзәнәге белән һич икеләнмичә белеп торды: борылып эндәшсен генә, ул, хисләрен тыя алмыйча, егетнең кочагына томырылачак. Аның шулай итми чарасы калмаячак.

Күпмедер баргач, Ньют туктады, әйләнеп карады. Изрәп утырган кызыл яфракларны сискәндереп, бакча аркылы гайрәтле өн узды:

– Катарина!

## СӘЛАМ, ҖИРӘН!

Кояш күпер артына тәгәрәде. Аның торыкларыннан төшкән алагаем зур күләгә елга тамагына тыгылган авылны шомлы караңгылыкка күмде. Якында гына урнашкан ашханәнең әйләнмәле урындыгына Җирән Мейо – күпернең яңа механигы арт төрткән иде. Каһвә белән гамбургер алып янә урынына утыруга, урындык авыр ыңгырашып өн салды. Җирән – үтерүче чырайлы егерме сигез яшьлек сөмсез егет иде.

Йолкыш сатучы һәм сатып алучы өч ир-ат – барысы да – аны дустанә игътибар белән күзәтте: ул борылып карап, ым каксын гына, дүртесе дә май кояшыдай балкый башларга әзер иде.

Ым кагучы булмады. Карашлар очрашуга, Җирән пошкырып куйды һәм яңадан тәгаме өстенә авышты. Аның йомрандай мускуллары уйнаклап торды, мәхәббәткә һәм канга сусауны белдереп, беләгендә кисешкән хәнҗәр белән йөрәк сурәте ялтырап-ялтырап алды.

Иптәшләренең хуплавына буйсынып, сатучы үтә итагатьле төстә Җирәнгә дәште:

– Кичерегез, сэр, сез, чыннан да, Җирән Мейомы?

– Кем булсам – шул, – дип җавап кайтарды ул, сатучыга күтәрелеп тә карамыйча.

Барысы җиңел сулап куйды. Аннары канәгать пышылдашу ишетелде. Өч кеше:

– Мин уйлаган идем, бу... фаразлавымча, бу... кем булса – шул, – дип гөжләп алды.

– Син мине хәтерлисеңме, Җирән? – дип сорады сатучы. – Слим Корби?

– Әйе, мин сине хәтерлим, – дип коры гына җаваплады Җирән.

– Мине хәтерлисеңме соң, Җирән? – дип өметләнеп бакты арада иң карты. – Джордж Мотт?

– Сәлам, – диде Җирән.

Мотт:

– Әти-әниең үлеп китте, бик кызганыч. Күпме сулар акты. Сине шуннан бирле күргән булмады. Яхшы кешеләр иде. Чын кешеләр, – дип тезеп киткән иде, ләкин Җирәннең карашында салкын битарафлык күргәч, беркадәр икеләнеп калды. – Син мине хәтерлисеңме, Җирән? Джордж Мотт?

– Хәтерлим, – диде Җирән һәм янына җыелып өлгергән башкаларга төртте. – Бусы Гарри Чилдс, бусы Стен Вест.

Халык яңадан:

– Ул хәтерли... Әлбәттә, хәтерли... Ничек онытсын? – дип гөжләп алды һәм Җирәнне сәламләвен дәвам итте.

– Менә, ичмасам! – дип кычкырып җибәрде Слим, сатучы. – Болай очрашуыбызны күз алдыма да китермәс идем. Кайтмас, мөгаен, дип ышандым.

– Ялгышкансың, – диде Җирән. – Булгалый.

– Киткәнеңә ничә ел? – дип сорады Слим. – Сигез? Тугыз?

– Сигез.

– Син һаман сәүдә флотындамы? – дип сорады Мотт.

– Күпер механигы.

– Кайда? – дип сорады Слим.

– Монда, – дип тәрәзәгә ишарәләде Җирән.

– Һә-ә-әй, ишеттегезме? – дип кычкырды Слим. Ул, итагатен онытып, Җирәннең иңенә кагылырга талпынса да, вакытында тыелып калды. – Җирән – күперебезнең механигы!

– Төкле аягың белән... Яхшы эш... Шәп бит? – дип гөжләде халык.

– Күптәннәнме? – дип сорады Мотт.

– Ике көн.

Барысы да таң калды.

– Ишетмәдек тә… Анда кем утыра икән дигән фикер дә килеп карамады... Ике көн! Ә без сизмәгәнбез, – дип гөжләде халык.

– Мин күпер аша көненә дүрт тапкыр узам, – диде Слим. – Ник бер дә хәл сорашмадың? Без, ярар инде, механикны күпернең бер өлеше итеп кенә беләбез. Ләкин син, ихтимал, минем дә, Гарриның, Стенның, мистер Моттның, Эдди Скуддерның, башкаларның да янәшә узганын күргәнсеңдер, ник эндәшмәдең?

– Әзерлегем җитмәде. Аңарчы бер кеше белән сөйләшеп аласым бар иде.

– Аһ, – дип көрсенде Слим, агара төшеп. Ул иптәшләренә сораулы караш ташлады, әмма тегеләр җилкә кагудан узмады. Слим, маңгайга бәреп сорарлык форсат булуга карамастан, кул хәрәкәтләре белән генә һаваны ботарларга керешге.

– Кирәкми, – диде ачуы кузгалган Җирән.

– Нәрсә кирәкми? – дип сорады Слим.

– Кем белән сөйләшүемне ачыкларга теләп маймылланма.

– Билләһи, тел төбеңне аңламыйм, Җирән, – дип җаваплады Слим. – Күпме гомер узды. Кем белән очрашырга теләвеңне кем белсен?

– Күпме кеше килеп китте... Күпер астыннан күпме сулар акты... Элекке дус-ишләрең олпатланды, акыл утыртты, – дип гөжләде халык.

Җирән астыртын елмайды гына. Алай да, бераздан:

– Кыз, – диде. – Миңа бер кыз белән сөйләшергә кирәк иде.

– О-о-һо, – диде Слим, оятсызларча елмаеп. – Син, ата эт, карт диңгезче! Туган туфрагыңның берәр чибәркәендә сыену урыны эзләдеңме? – Җирәннең үтәли тишеп каравыннан соң, Слим елмаймый башлады.

– Йә, күңелсезләнмә, – диде Җирән, усал гына. – Синең якынча биш минут вакытың бар әле. Эдди Скуддер килгәнче.

– Эдди? – дип кабатлап сорады Слим. Аның Җирән әйткән сүзләрне бербөтенгә оештыра алмавы йөзенә чыккан иде.

Халык тынып калды. Җирән аларның дуслыгын кабул итмәде. Ул аларны куркытты һәм тәмам бутады гына.

Җирән ләззәтләнеп иренен кысты.

– Һич төшенерлек түгел: Җирән Мейога Эдди Скуддер нигә кирәк булды икән? – диде ул, тавышын сузып. Тирә-юньнең самимилеге аны чыгырыннан чыгарды. – Мин бу авылны бөтенләй онытканмын. Илаһым, барысы да акылга сыймаслык ялган сөйли. – Ул йодрыгы белән сатучыга төртеп алды. – Хәтта туган-тумача, минем каным, минем тәнем – берсе-бер хәбәр салмаган!

Халык шыпырт кына почмакка сеңде һәм Слим куркыныч җирән ир-ат белән япа-ялгызы калды.

– Нинди ялган? – диде ул, калтыраган тавышын баса төшеп.

– Нинди ялган, нинди ялган, – диде Җирән, әңгәмәдәшен үртәгәндәй. – Шулкадәр дөнья гизеп тә мине шаккатырыр нәрсә калган икән әле. Күзем маңгайга менде.

Слим үзенең:

– Нинди нәрсә? – дип сораганын сизмәде дә.

– Көньяк Африкада шундый елан бар, ишеткәнең юкмы?.. Ул бала урларга ярата. Урлый да аны үзенеке итеп тәрбияләп үстерә. Шуышырга өйрәтә. Күпмедер вакыттан соң башка еланнар да сабыйны үзише итеп күрә башлый.

– Ишеткәнем юк... Чын әйтәсеңме? Башка сыймаслык. – Почмактагы шау-шу пышылдауга әверелде.

– Без бу хакта Эддидан сорарбыз, килеп җитсен инде. Ул җәнлекләр дөньясыннан да, табигать белеменнән дә хәбәрдар кеше, – диде Җирән һәм, әңгәмәнең төкәнүен искәртеп, гамбургер чәйнәргә кереште. – Эдди тоткарлана, – дип өстәде аннары, сүзен авыз тулы ризык аша көчкә чыгарып. – Хәбәремне алгандыр, шәт.

Җирән үзенең «илчесе» турында уйлады. Карашын аска төбәгән килеш, ияген уйната-уйната, төш турысындагы очрашуны хәтерендә яңартты.

Корыч һәм пыяладан эшләнеп, юлдан ике метр өстә асылынып торган оя-будкада утырганда, Җирән үзен авылның хуҗасы итеп тойды. Болытлар гына аннан биегрәк йөзде.

Күпернең авызын ачып-ябу кодрәтенә ия рычаг күп дигәндә ярты сантиметрга күчә иде. Шулай да, бу ара авыл белән идарә итәргә бик җитте. Аңа үзе дә, әйләнә-тирә дөнья да туктаусыз хәрәкәттә, астагы елга гына мәңгегә тынып-тукталып калгандай тоелды. Ул тугыз ел буе диңгезләр кичте. Ә күпер механигы булуына нибары ике көн иде.

Төш вакыты җиткәнен белдереп яңгыраган гудокны ишеткәч, Җирән эшен читкә куйды һәм күзәтү торбасы аша аска, Эдди Скуддерның соры алачыгына бакты. Җил катырак иссә ишелергә әзер бу алачык елга тамагында күкрәк киереп торган алагаем зур, затлы йортлар янында мескеннәрчә боегып утыра. Тозлак ярларга ике сыгылмалы такта сузылган. Алачык янындагы су төбен устрица* кабырчыклары каплаган. Алар кояш нурында җем-җем килә.

Эддиның сигез яшьлек кызы – Ненси – алачыктан чыгып, такталар өстендә

* Устрица – диңгез моллюскасы.

сикереп уйнады. Кояшка тутырып карады. Аннары, сикерүдән туктап, тыйнаклана төште.

Җирән бу эшкә аны күрер өчен генә урнашкан иде. Ул аның гаять тыйнак булуын белә. Ир-ат, кларнетта уйнагандай, бармаклары белән күзәтү торбасына сугып алды.

– Сәлам, Җирән, – дип пышылдады.

Ненси һаман-һаман бакыр чәчләренең шарлавыгын тарады. Аның күзләре йомылган иде. Кулының һәр хәрәкәте искиткеч ләззәт бирә иде кебек.

Озакламый чәч белән әвәрә килү дә туйдырды. Ул каш җыерып кына тозлак басу аша үтте, аннары, текә ярга күтәрелеп, күпергә илткән юлга чыкты. Ненси көн саен бу вакытта, күпер янындагы ашханәгә килеп, әтисе белән үзенә кайнар аш алып кайта иде.

Ике ара кими төшкәч, Җирән аңа карап елмайды.

Кыз чәчләрен төзәтеп куйды.

– Урынында, – диде Җирән.

– Нәрсә урынында? – дип сорады Ненси.

– Чәчләрең, Җирән.

– Минем исемем Җирән түгел, дидем бит инде. Мин – Ненси.

– Сине авыл халкы Җирән дип атый ласа.

– Синең исем ул.

– Теләсәм, сиңа да куша алам. Моңа тулы хакым бар.

– Мин сөйләшеп тора алмыйм, – диде кыз, шатлыгын тыеп. Аңа Җирәнне үртәү рәхәт тоелды. Ненси бу иргә тулысынча ышана иде. Аларның һәр очрашуы чын әкияткә тиң, һәм кыз өчен Җирән – билгесез берәү түгел, ә күпер кадәр күперне күчерә алган чын тылсымчы булды. Һәм ул тылсымчы, ни гаҗәп, нәни кызчык турында кирәгеннән артыгын белә иде.

– Синең кебек, мин дә монда туып үстем, бу хакта сөйләдем бит инде, – дип куйды Җирән. – Әти-әниең белән бергә укыдык. Сөйләдем бит инде? Ышанмыйсыңмыни?

– Ышанам, – дип җаваплады Ненси, – ләкин әни кечкенә кызларга таныш булмаган кешеләр белән сөйләшергә ярамый, ди торган иде.

– Бигрәк тәүфикълы бала, – диде Җирән, авыз чите белән. – Әйе, әниең кечкенә кызларның, кечкенә малайларның тәртипле булырга тиешлеген яхшы аңлый иде. Әйе-е-е, Виолет әдәпле иде. Аның авызыннан беркайчан да әшәке сүз чыкмады.

– Бөтен кеше шулай дип сөйли, – диде Ненси, горур басып. – Әле әти белән миннән кала да.

– Әти? Әтиме? – дип үчекләде Җирән. – Әти, әти, әти, батыр әтием – Эдди Скуддер, – ул сак кына башын күтәрде. – Минем монда булуымны әйтмәдеңме?

– Мин вәгъдәмне бозмыйм. – Ненси нахак яладан кызарып чыкты.

– Күпме гомердән соң башына ишелеп төшим әле, ә? Күзе маңгаена менмәсме?

– Әни, беркайчан да вәгъдәңне бозма, дип кабатлап үлде.

– Әниең җитди кеше иде шул, – дип куйды Җирән. Аның тавышына ихтирам хисе үтеп кергән иде. – Мәктәпне бетергәндә, кызларның барысы да, диярлек, кәеф-сафа корырга, күңел ачып калырга теләде. Виолет кына үзгә иде. Әйе. Мин тәүге сәяхәтемдә бер ел йөреп кайттым. Ә ул инде Эддига кияүгә чыккан. Син дә бар идең. Чәчең генә юк иде әле.

– Мин этигә төшке аш алып кайтырга тиеш.

– Әти, эти, эти. «Мин этигә алай итәргә тиеш, мин этигә болай итәргә тиеш». Синең кебек сөйкемле һәм акыллы кызың булу шәптер. «Әти, эти». Әтиеңнән чәчең турында сораштыңмы соң? Ник төсе җирән икән?

– Дөньяда төрле хәлләр була, диде. Кайвакыт тиктомалдан да җирәнләнеп чыгарга мөмкин алар. Менә, минеке сыман, – диде кыз, чәчләрен сыйпап.

– Урынында.

– Нәрсә урынында?

– Чәчләрең, – дип хахылдап җибәрде Җирән. – Ант итәм: аларга ул-бу булган көнне үк син, кибеп-корып, җил белән очып китәчәксең. Тиктомалдан, диме? Эдди шулай диме? – Җирән җитди генә ияк какты. – Ул әйтсә белеп әйтер. Син тугач та Эдди җирән төс турында күп уйлагандыр. Инде сүземә колак сал: әгәр дә минем бала җирән булмаса, авыл, умарта күчедәй, гөж килер иде. Башка сыймаслык хәл! Чөнки безнең нәселдә буыннан буынга җирәннәр генә туган.

– Кызык.

– Түбәнә төшеп уйласаң, тагын да кызыграк ул. Син, мин, эти картлач. Бу авылда бездән башка бер җирәннең дә булганы юк. Билләһи. Хәзер эти мәрхүм инде. Синең белән икәү генә калдык.

– Ух, сау бул, – Ненсиның исе китмәде.

– Сау бул, Җирән.

Кыз урыныннан кузгалуга, Җирән күзәтү торбасы аша Эддиның соры алачыгына текәлде. Йорт эчендәге эңгер-меңгер аша ул хуҗаның зәңгәрсу-соры шәүләсен абайлады. Эдди кыска буйлы һәм зарлы уйлар тулы зур башлы ир-ат иде. Әйтерсең, яшь Әйюпнең башы иде аңарда.

– Сәлам, – дип пышылдады Җирән, – өйдә кем бар?

Ненси җылы һәм калын кәгазь пакет тотып кайтканда, Җирән аны яңадан туктатты.

– Әйт ә-ә-әле, – диде ул, – Эдди картлачны шулай тырышып карагач, синең, бәлки, шәфкать туташы буласың киләдер? Мин яткан хастаханәдә дә табибәләр синдәй сөйкемле иде.

– Син хастаханәдә яттыңмы? – дип, шунда ук сагышланды Ненси.

– Өч ай буе, Җирән, Ливерпульдә. Дус-ишсез, туган-тумачасыз. Хәлемне белүче дә, открытка юллаучы да булмады, – дип боега төште ир. – Кызык инде, Җирән, аңарчы үземнең шулкадәр ялгыз икәнемне уйлап карамый идем. Башка беркайчан да диңгезгә чыкмаячагымны аңлап ятакта ятканчы, – дип, иренен ялап куйды. – Тормышым мизгел эчендә үзгәрде. – Ул бармак шартлатты. – Кинәт миңа үз йортым җитми башлады, – дип дәвам итте аннары, – хәлемне белүче, кайгыртучы кеше тансыкланды. Ярты учка сыйган юллама кәгазеннән башка һичнәрсәм юк иде, Җирән. Сыңар аякта калганда, андый кәгазьдән файда юк шул.

– Синең бер аягың юкмы? – дип, күзләрен шарландырды Ненси.

– Бәйдән ычкынган шайтан баласы идем, мине монда һәркем хәтерли иде, – диде Җирән, куллары белән бөтен авылны колачларга тырышып. – Күп тә үтмәде, карт, бик карт кеше булып янә кайтып аудым.

– Хатының йә әниең бардыр бит? Сине кем карый соң? – диде Ненси, аның кайгысын уртаклашып, һәм күкрәгенә сукты: ул, тәртипле кыз буларак, хәленнән килгән ярдәмне хәзер үк күрсәтергә әзер иде.

– Үлеп беттеләр, – дип баш какты Җирән. – Әни дә үлде, мин яраткан

бердәнбер хатын-кыз да үлде. Ә башкалары... Үзең сөймәгәч, алар беркайчан да сиңа тугрылык сакламаячак. Өрәккә гашыйк булсаң гына.

Җирән сөйләгән тормыш ачысы Ненсиның алсу йөзендә чагылды.

– Нигә, алайса, агым буенча өстә яшисең? – дип сорады ул. – Нигә син күптәнге дусларың белән бергә түгел?

– Дуслар, имеш. – Җирән кашын җыерды. – Виолет җирән чәчле кыз тапты, дип хәбәр дә салмагач, шәп дуслар инде... Туганнар да сиздермәде, ичмасам!

Җил куәтләнә төште. Ул Ненсиның тавышын әллә кайлардан әйләндереп китергәндәй тоелды.

– Әтинең ашы суына, – диде кыз, китәргә кузгалып.

– Җирән!

Кыз Җирәнгә аркасы белән баскан килеш туктап калды. Чәченә орынды.

Җирән аның борылуын теләп Илаһка ялварды.

– Минем Эдди белән сөйләшәсем килә. Син аңа шул хакта әйт әле, яме? Эштән соң, алтынчы ун минутта аны ашханәдә көтәрмен.

Саф һәм тыныч тавыш белән:

– Ярар, – диде кыз.

– Вәгъдәме?

– Вәгъдә, – диде кыз, янә китәргә җыенып.

– Җирән!

Ул чәчләренә орынды, ләкин адымын киметмәде.

Җирән аны торба аша күзәтте. Кыз, шулай буласын белеп, йөзен күрсәтмәс өчен, башын читкә борды. Йөгерә-уйный алачыкка барып җитте.

Җирән алачык эчендә ниләр кылынганын күрмәде. Алай да, кояш баер алдыннан, Эдди, урамга чыгып, күзгә чалынып алды. Җәһәт кенә күпергә бакты. Ләкин ул да йөзен күрсәтмәде.

...Урындык шыгырдавы Җирәнне яңадан чынбарлыкка кайтарды. Ул, күз кысып шәфәкъкә караганда, күпердән атлаучы Эдди Скуддерның шәүләсен чамалады. Кәкре аякларында зур башын чайпалдырып килүче бу кеше кулына кәгазь пакет тоткан иде.

Җирән ишеккә аркасын борды, пинжәгенең кесәсендә актарынып, алдына бер төргәк хат чыгарып салды. Аннары учы белән аларның өстенә сукты.

– Әнә ул, яңа көн батыры, – диде.

Халык дәшмәде.

Эдди шактый кыю адымнар белән ашханәгә керде, коры гына исәнләшкәндәй итте, иң ахырдан Җирәнне сәламләде. Аның тавышы гаять тирән һәм мәгънәле булып тоелды.

– Саумы, Җирән, – диде ул. – Күрешәсең килгән икән. Ненси әйтте.

– Нәкъ шулай. Нәрсә әйтергә теләвемне кем белә икән?

– Ненси да аптырады, – диде Эдди, һич үпкәләмичә.

– Аннары төшенеп җиттеме соң?

– Сигез яшьлек бала төшенә алган кадәренә төшенде, – Эдди янәшәдәге урындыкка утырды, кулындагы пакетны өстәлгә, хатлар янына куйды. Хатлардагы хәрефләрнең язылышын танып, беркадәр гаҗәпләнде. Һәм гаҗәпләнүен яшермәде.

– Слим, каһвә китерче, – диде.

– Бәлки, аулак урын табарбыз? – дип сорады Җирән. Эддиның чиктән тыш тынычлыгы аны каушата төште. Ул танышын тилемсә шамакай итеп хәтерли иде.

– Нигә? Барыбер Илаһ һәммәсен күрә.

Җирән әңгәмәгә Илаһның да килеп керәсен көтмәде. Хастаханәдә чакта ул бу мизгелне, гомумән, үзгәчә күз алдына китерә иде. Һәр яктан хаклы булуына ышанып ятты: һичшиксез, үз канын, үз дәвамын кайтарыр өчен аның тулы хакы бар! Җирән, җитдилеген һәм көндәшеннән өстенлеген ассызыкларга теләп:

– Беренчедән, – диде, авыр сулап, – бу очракта канунның нәрсә кушуы миңа барыбер. Вазгыять һичнинди кануннарга сыймый.

– Яхшы, – диде Эдди. – Бусын килештек. Мин дә шулай уйлыйм.

– Без бер сүз сөйлибезме? Баланың әтисе – мин, син түгел.

Эдди калагын кысып тоткан килеш каһвә болгатырга керешә:

– Без, чыннан да, бер сүз сөйлибез.

Слим да, калганнар да, битараф чырай ясап, тәрәзәгә текәлде.

Эдди калагын каһвә чынаягында әвәрә китерде:

– Дәвам ит, – диде.

Җирән югалып калды. Сөйләшү ул уйлаганнан тизрәк һәм башкача, бөтенләй башкача бара иде. Әңгәмәнең иң югары ноктасына җителде, югыйсә! Әмма чынбарлыкта берни үзгәрмәде, үзгәрергә уйламады да.

– Теләсә кемнән сора, алар минем сүзне раслаячак! – диде Җирән, ачулана башлап.

– Намуслы кешеләр, димәк.

Әйтелергә тиешле булып та әйтелә алмаган сүзләр Җирәннең башында кайнады.

– Чын әтисен ачыклар өчен, кан бирмәкче булам, ризалыкмы? – дип сорады ул.

– Бер-беребезне ышандырыр өчен, канга бату мәҗбүриме? Килешәм, дидем бит инде. Аның әтисе – син. Моны бөтен кеше белә. Моны күрмәс өчен, сукыр булырга кирәк.

– Аяксыз булуымны әйттеме?

– Әйе. Анысын күңеленә аерата якын алган. Шөбһәле хәбәр. Бигрәк тә сигез яшьтә.

Җирән үз чагылышын каһвә чәйнегендә күреп аһ итте: аның чырае кып-кызыл, ә күзләренә яшь тыгылган иде. Алай да, ул тынычланды. Сулышы тигезләнде. Сөйләме төзекләнде. Аның белән уйнап сөйләшергә ярамый иде.

– Эдди, ул минеке, һәм мин аны кайтарырга телим.

– Кызганыч, Җирән, ләкин бу мөмкин хәл түгел, – Эддиның беренче мәртәбә кулы калтырап китте, һәм калак чынаяк читенә бәрелде. – Мин сиңа китәргә киңәш итәм.

– Вак-төякме бу, синеңчә? Кеше, берни булмагандай, мондый хәлдән җиңел генә кача аламы? Газиз баласын калдырып? Яисә онытканга сабышып?

– Минем әти булып караган юк. Нәрсә кичерүеңне бик якынча гына чамалыйм.

– Көләсеңме?

– Көлмим, – диде Эдди, тынычлыгын саклап.

– Үзеңне әтирәк саныйсыңмы? Йомры сүзләрең артында шул фикер ятамы?

– Яткан фикерем ята торсын, – Эддиның кулы янә калтырап китте, һәм ул, өстәл читенә тотыныр өчен, калагын куярга мәҗбүр булды.

Җирән шулвакытта гына Эддиның никадәр куркынганын сизде. Аның моңарчы тыныч һәм тәкъва булып күренергә тырышуын, дөресе – кылануын фаш итте. Бәдәненә көч-куәт агып кергәнен сизде, күпме гомер хыялланган

гаделлек тантанасы җитүен тоюдан рухы-иманы ныгыды. Ул бер мизгелдә әңгәмәнең хуҗасына әверелде, бар уйлаганын әйтер өчен, ниһаять, аның чамадан тыш вакыты һәм бихисап сүзе барлыкка килде.

Эддиның алдарга, башын тәмам бутап, аяктан яздырырга теләвен, һәм әлеге теләгенә чак кына ирешми калуын аңлаудан Җирәннең җен ачуы чыкты. Бу ачуның үзәгендә җәһәннәм уты булып салкын һәм буш дөньяга карата нәфрәт хисе кайный иде. Хәзерге вакытта каршысында торган кечкенә кешене бөҗәк сыман сытып үтерергә әзер иде ул.

– Ул бала Виолет белән минеке. Виолет сине беркайчан да яратмады.

– Ә мин ябаткандыр дип ышанам, – диде Эдди, беркадәр тартынып.

– Ул мине кире кайтмаячак, дип уйлады, шуңа күрә генә сиңа чыкты! – Җирән төргәктәге иң өске хатны алып Эддига сузды. – Аның сүзе бу, менә, кара, бик тәфсилле язылган анда. Кара.

Эдди хатка күз дә төшермәде.

– Булган – беткән, Җирән. Аннан соң нәрсә генә үзгәрмәгәндер.

– Нәрсә үзгәрмәгәнен әйтимме соң? Аның миңа хат язуы, кире кайт, дип ялваруы үзгәрмәде. Беркайчан да!

– Беренче вакытта булса гына.

– Беренче вакытта? – ул хатларны учлап Эддиның борын төбендә җилфердәтте. – Син көне-сәгатенә кара! Кара, ник карамыйсың?

– Карыйсым килми. – Эдди урыныннан торды.

– Куркасың.

– Шулай, – диде Эдди, күзен йомып. – Кит, Җирән. Зинһар өчен, кит син.

– Бигайбә, Эдди, миңа хәзер кая да булса китүнең хаҗәте юк. Җирән үз өендә.

– Алайса, Илаһ ярдәменнән ташламасын, – диде Эдди, ишеккә юнәлеп.

– Син кәгазь пакетыңны оныттың, – Җирән үкчәсе белән идәнне төя иде.

– Сиңа ул. Ненси бирергә кушты. Бу – аның теләге, Илаһ шаһит: белсәм, тыеп калыр идем, – Эдди елап ук җибәрде.

Ул, караңгылыкны ерып, күпердән атлады.

Слим да, баягы өч кеше дә өнсез-тынсыз калдылар.

– Йа Хода! – дип кычкырды Җирән. – Ул минем тәнем, минем каным! Яшәвемнең мәгънәсе! Моннан китәргә нәрсә мәҗбүр итә ала мине?

Беркем дә җавап бирмәде.

Җирәннең кәефе тәмам кырылган иде. Ул, ярасын дәваларга теләгәндәй, кинәнеп уч төбен ялады:

– Слим, пакетта нәрсә? – дип сорады аннары.

Слим пакетның авызын ачты.

– Чәчләр, Җирән. Җирән чәчләр.

*Русчадан* **Рүзәл МӨХӘММӘТША** *тәрҗемәсе.*

# ӘКИЯТСЕЗ БАЛАЧАК

«Казан утлары» журналының быелгы 10 нчы санында «Яңа исемнәр» рубрикасында басылган «Әкиятсез балачак» повестен укый башлау белән, үз эченә бөтереп алып кереп китте дә, укып бетермичә «җибәрмәде». Нәрсәсе тотып торды соң: темасы яңа булумы, сюжет линиясеме, стиле, телеме? Анысын әйтеп тә булмый, укыла – беттекитте! Барысы да бардыр. Теле дә йөгерек, диалектлары да матур. Шулдыр инде ул язучының тумыштан килгән сәләте, ихласлыгы («талант» сүзенә тими торыйк, авторга «чир» йоктыруыбыз бар). Моңа кадәр 3-4 китабы чыккан, 3-4 телдә басылган әсәрләре булган 30 яшьлек Айгиз Баймөхәммәтов дигән авторның дөньяда барлыгын да белми йөргәнмен бит! Рәхмәт «Казан утлары»на, таныштырды.

Бу әсәр турында детдомда тәрбияләнгән кеше үз фикерен белдерсә, күпкә дөресрәк тә, отышлырак та булыр иде кебек, чөнки гап-гади гаиләдә үскән кеше буларак, икенче мохиттәге ул тормышны белмибез бит инде. Мәсьәләнең икенче ягы: сугыштан алдагы яки сугыштан соңгы еллардагы белән чагыштырганда, бүгенге көн детдомнары берберсеннән аерыламы? Аерылса, нәрсәсе белән? Балалар гына түгел, тәрбиячеләр дә башка буын вәкилләре бит. Тормыш шартлары да нык үзгәрде. Уйлана башласаң, бу тема фәнни тикшеренүләргә лаек (бәлки, андый хезмәтләр бардыр да). Ни генә булмасын, мин гади укучы буларак, фәкать үз фикеремне белдерә алам.

1950 елларда, ягъни 4-5 нче сыйныфларда укыганда, безне җәй саен пионер лагерьларына җибәрәләр иде. Ул лагерьларга сезонына ун-унике детдом баласы да килә. Алар гел бергәрәк булырга яраталар. Ул елларны лагерьга күбрәк район җитәкчелеге яки укытучы балалары җыела. Бер елны мин хәтта рәттән ике срок ял иттем. Начальник кызлары матуррак киенә, кылтыграк та. Беренче көннәрне, бертөрлерәк киенгән детдомныкыларга «өстәнрәк» карап, әлләни аралашу булмады. Ике-өч көннән болар, кулга-кул тотынып, җырлап әйләнә башлагач, әкрен-әкрен без дә боларга кызыгып кушыла башладык. Чегәннәр турындагы русча җырны мин әле дә хәтерлим. Дуслашып та киттек. Таралышып, укулар башлангач, бер кыз белән әле хатлар да языштык. Шул кыз сөйләгән иде: «Әйберне югалтырга ярамый, тузгач, аны сдавать итәсең дә, яңасын бирәләр», – дип. Лагерьда да ашханәдә дежур тору бар, график буенча. Кухняда, дежурдан соң, бер кызның чемоданында урланган конфет, печенье таптылар. Ул детдомныкы иде бугай, төгәл хәтерләмим. Линейкада, бөтен кеше алдында, елатканчы хурладылар, тиргәделәр дә, срогы беткәнче, әллә кайтарып җибәрделәр, әллә үзе качып китте, төгәле истә калмаган.

Повестьны укыгач, үземнең дә балачак бөтен детальләре белән күз алдыма килде. Миңа тугыз яшь чагында әни үлде; әти өйләнде, яратышып түгел, кирәк булган өчен, әнкәйнең егете сугышта үлгән иде, аңа инде 32 яшь. Әти – шактый кырыс кеше, мәктәп директоры. Футбол кыры кебек мәктәп – өй арасында без балалар бик күбәү. Бергә лагерьга йөрибез, бергә уйныйбыз, иң кызыгы шул: безнең арада акробатика ясамаган бер бала да юк. Уеннан керәбез дә әнкәйгә һөнәребезне күрсәтәбез. Аны да «шпагат», «мостик» ясарга, «чатлы багана» эшләргә өйрәтәсе килә. Ул эче катып көлә. Яраттык без бу апаны. Апам белән икебезгә, пардан бумази күлмәк тегеп киертте, чәчләрне тарады, юындырды. Тик... үзенең баласы тугач, үзгәрде дә куйды. Шуңа күрә әсәрдәге детдом директоры Мәүлидә Нургалиевнаның, тәрбияче Рәйфә һәм Тәгъзимә апаларның кыланышлары, тупаслыклары, балаларга кул күтәрүләре, хурлаулары – барысы да таныш миңа.

Повестьның азагы шәп! Сугышка киткәндә, әти безне нәнәйләрдә (дәү әнине бездә «нәнәй» яки «картый» диләр) калдырды. Йокларга җыелышып, сәке өстендә түшәк, ястыкларга чумабыз да нәнәй әкият сөйли. Кайчакта яңасын, кайчакта бер үк такмакны кич саен кабатлый, барыбер тыңлыйбыз. Болары да бүгенгедәй күз алдымда.

**Руфина ФӘТТАХОВА,**
*Казан*

# ХУҖА БӘДИГЫЙ ҺӘМ АНЫҢ НӘСЕЛ-НӘСӘБЕ ТУРЫНДА ЯҢА ТАБЫШЛАР



Хуҗа Бәдигый Казан губернасы Мамадыш өязе Түбән Сон волостена караган Югары Кыерлы авылында 1887 елның 24 декабрендә указлы мулла Габделгазизов Габделбәдыйк (1832-1899) гаиләсендә туган. Хуҗа Бәдигыйның нәсел чыгышы, ата-бабаларының туган җире турында әлегәчә төгәл билгеле түгел иде. Аңа багышлап чыгарылган китапта язылган «Габделгазиз улы Габделбадыйк Мичәннән чыккан» дигән хәбәр дөрес булмады. Мишә елгасы бассейнында Мичәнбаш, Яңа һәм Иске Мичән авыллары бар, ләкин Хуҗа Бәдигыйның әтисе әлеге авылларның кайсында вакытлыча муллалык итүе әле ачыкланмаган. Моны төгәл билгеләү – вакыт эше.

Габделбәдыйк мулла үзе Югары Кыерлыда өске мәчеттә имамлык иткәндә, «Ишаннар йорты»нда гомер кичергән. Бу йорт Бәлхия һәм Нурсабах апалар арасында булып, бүгенге көндә юкка чыккан. Элекке елларда мәрхүм Исмәгыйлев Наил абыйдан сорашканда, ул: «Хуҗа Бәдигыйның кызы сугыштан соң Югары Кыерлыга кайтып киткән, зиратларга барып, әрвахлар рухына дога кылып йөргән», – дип сөйләгән иде. Шушы очракны авылдашыбыз Фәрит абый Сәйфетдинов та раслады. Кыямов Габделхәй абыйлар астында, буа янәшәсендә өч бүлмәдән торган башлангыч мәктәп бар иде. Безнең буын шунда гыйлем алды. Муллалар һәм башка «кулаклар йорты сүтелеп, шул бүрәнәләрдән салынган бина икәнен өлкәннәр хәтерли әле. Ишаннар пуҗымы бетерелгәч, аның җирләрен ике күрше үзара бүлешкәннәр.

Габдессәламов Габделгазизнең нәселе ревизия кенәгәләре буенча төбәкнең данлыклы шәхесе Әҗикә[1] бабайга һәм, аннан да тирәнрәк китсәк, тарихта билгеле «Кара бик» шәҗәрәсенә тоташа[2]. Әҗикә улы Габдессәлам Әбдекәев (1753-1820) Пугач полковнигы, Бәхтияр Канкаевның аркадашы Сөбханкул Әҗекәев (Ичкаев, Аскин[3]) белән бертуган.

Хуҗа Бәдигыйның бабасы Габдессәламов Габделгазизнең өч хатынга унбер улы, ике кызы булган. Авыл тарихында дин хезмәткәрләре буларак мәгълүм уллары[4]: Габделмәүлә 1856 елда (100 сум хезмәт хакы алып) мулла, Габделлатыйф 1864, Габделфәттах 1865 елда азанчылар вазифасын Югары Кыерлы мәчетендә намус белән башкаралар[5]. 1891-1892 еллар тирәсендә Габделгазизнең дүртенче улы Габделбәдыйк

---

[1] Әхмәтҗанов М.И. Татар шәҗәрәләре. – Казан: Татар.кит.нәшр., 1995, 12-15 бб. Әҗекәй морза (Ю.Кыерлы). «Главный сотник дер. Верхнего Берсута».

[2] Шунда ук. Карабик нәселенең бер тармагы, ревизия кенәгәләре буенча Габдессәлам Әбдекәев белән туры килә. Кара бәк шәҗәрәсенең ике дистәдән артык варианты бар. Шәҗәрәләр һәм аларга аңлатмалар урыс тарихчысы Пётр Рычков, татар тарихчылары Сәет Вахиди, Миркасыйм Госманов һ.б. тарафыннан да бирелә. Шәҗәрәләрнең вариантлары архивларда саклана. «Караби – яйло» – Туристическая карта. «Крым», 1984. Карабик нәселенең бер тармагы, үз нәселе белән туры килүе сәбәпле, чыганаклар Рәис Шаһи тарафыннан шәрехләнде.

[3] РГАДА. Фонд 350. 2 тасв., 1084 эш. 1719 ел. 1-610 бб. Азыкачка Дусым – Пугачёв явында катнашкан Югары Кыерлы кешесе Әҗикә (Әҗкә) Сөбәй Аскинның (Сөбханкол Азиков) бабалары. «Чабаталы» морза.

[4] ТР МА. 3 фонд, 2 тасв., 69 эш кенәгәсе. 1818-1834 еллар арасы; ТР МА. 3 фонд, 2 тасв., 224 эш кенәгәсе. 1834-1850 еллар арасы. 7-9 ревизия кенәгәләре.

[5] Казан губернасындагы мәхәллә-мәчетләрнең һәм шунда хезмәт кылучы дини җитәкчеләрнең исемлеге. Мамадыш өязе буенча мәгълүмат. ТР МА, 2 фонд, 2 тасв., 8 эш кенәгәсе, 1866 ел; ТР МА. 2 фонд, 2 тасв., 273 эш кенәгәсе, 1872 ел.

мулла гаиләсе белән Арча районындагы Түбән Курса авылына күчеп киткәндә, Хуҗага нибары дүрт-биш яшь кенә булган. Габделбәдыйк гаиләсе күченеп киткәч, Югары Кыерлыда, 1913 елның 17 маенда, мәчеткә имам-хатыйп итеп Мөхәммәтфазылов Габделкотдүс хәзрәт сайлана. Габделгазизнең бишенче улы Әхмәтгариф (1840) егерме яшендә хәзерге Теләче районындагы Айдар авылына китә[6] , һәм аның улы Әхмәтвагыйз (1866-1920) Баскан авылына мулла булып кайта. Әхмәтгарифның икенче улы Габдулла Гарифов та 1893 елда шушы авылга мулла итеп билгеләнә.

Югарыдан күренгәнчә, Габдессәлам улы Габделгазиз – муллалар династиясенең башлангычы. Беренче Бөтендөнья, Гражданнар һәм Совет-Герман сугышлары ветераны Гарифулла бабай Нәдершин (1890), үзенең истәлекләрендә юкка гына: «Алар нәселеннән җиде мулла чыккан, алар безгә агай-эне булып чыга», – димәгәндер.

Югарыда искә алуыбызча, Хуҗа Бәдигыйның мулла бабасы Габдессәлам улы Габделгазиз чыгышы белән хәзерге Югары Кыерлы авылыннан. Бу хәбәр ревизия кенәгәләре белән дә раслана. Югары Кыерлы авылы зиратында галим Хуҗа Бәдигыйның бабасы Габделгазизгә, әбисе Шәрифҗамалга куелган кабер ташлары бар. Әтисенең абыйсы Габделфәттах Габделгазизовка (1926 елда 72 яшендә вафат булган) һәм аның хатыны Бибикамәриягә куелган кабер ташлары да табылды[7] . Аларның башка нәселдәшләренең дә күбесе әлеге зиратта җирләнгән.

Якташ-авылдашыбыз Хуҗа Бәдигый юбилеена багышлап басылган китапта[8] күренекле галим Рәшит Ягъфәров үзенең эзләнүләрендә Хуҗа Бәдигыйның нәсел-ыруын ачыкларга тырыша. Ул истәлекләрендә Хуҗага кардәш тиешле (Хуҗаның бертуган абыйсы Хәсәннең оныгы) Халитов Әсфәндияр Касыйм улыннан язып алган хәбәрләргә таяна. Андагы хәбәр буенча Галия Хәсән кызы: «Безнең нәсел тамырыбыз, мин белгәнчә, Мичән авылында яшәгән Габделгазиз бабабыздан башлана. Аның улы, безнең дәү әти Габделбәдыйк шул авылда туган. Соңыннанмы, Курса авылында мулла булган, ди. (Ул аның Югары Кыерлыда яшәгән чорыннан хәбәрдар булмый.) Истәлекләрдә: «Минем әтием Хәсән, нәселебездә беренче булып, Казанга килеп урнашкан, 1888 елда Садыйк Галикәев дигән татар баена ялланган. Бай аны яраткан, приказчик итеп Мәкәрҗәгә алып йөргән. Әтине бай өйләндергән, тормышы рәтләнеп киткән. Аннан соң әти туганнарын – Әхмәтне, Хуҗаны, Хөсәенне дә үз янына укырга чакыртып алган. Хәтерлим, әни аларны кунак итә иде, ял көннәрендә бергәләшеп безнең өйгә киләләр иде. Хуҗа абый 1918 елда гына өйләнде, җиңгәбез 1887 елда туган, Зәйнәп исемле иде. Роза исемле кызлары бар иде, Флүрә исемле асрау кыз алдылар. Абый «Мөхәммәдия»дә укыды, аның Гали Хәбиб исемле укытучысы бар иде. Бергә тордылар. Аннан шуны хәтерлим: 1920 елның 6 июнендә, төнге сәгать уникедә Хуҗа абыйларның өе янды (15 минут эчендә аның халыктан 13 ел буе җыйган әдәби җәүһәрләре көлгә әверелә). Ул вакытта алар «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенең ишегалдында торалар иде... Зәкия апа Рәсүлева – Хуҗа абыйның бертуганы Әхмәт абыйның кызы, язучы Атилла Расихның хатыны».

Гаделбәдыйк Габделгазизовның җиде баласы туа: Сабирҗан, Мәхмүзә, Хәсән, Мөхәммәтвафа, Әхмәт, Хуҗа, Хөсәен. Мәхмүзәдән кала, һәркайсының балалары, оныклары булган. Габделбадыйкның улы, Хуҗа Бәдигыйның абыйсы Мөхәммәтвафа хәзрәт Югары Кыерлы авылы мәчетендә имамлык итеп яшәгән. Ул турыдагы мәгълүматлар Татарстан Милли архивында саклана[9]. Әлеге язмалардан күренгәнчә,

---

6 Яңа табылган, әмма әлегә өйрәнелмәгән документлар: НАРТ. 2 фонд, 2 тасв., 4425 эш кенәгәсе. 1892 ел. Дело о переводе муллы д.Новые Мичени Мамадышского уезда Абдулгазизова Абдула муллою в деревне Нижняя Корса Казанского уезда. На 20 стр.; НА РТ. 2 фонд, 2 тасв., 5577 эш кенәгәсе. 1897 ел. Дело об определении крестьянина д.Верхнего Берсута Мамадышского уезда Гарифова Ахметсабирзяна муэдзином соборной мечети в деревне Айдарово Мамадышского уезда. На 15 стр.

7 Гариф Н.Г., Шаһиев Р.Г. Югары Кыерлы (Югары Бөрсет) авылы тарихы. – Казан: ТФА Тарих институты басмаханәсе, 2013. – 178-179 бб. Югары Кыерлы авылы зиратындагы кабер ташларындагы язулар Галимҗан Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының өлкән фәнни хезмәткәре, археограф, филология фәннәре кандидаты Раиф Мәрданов һәм Татарстан Милли китапханәсенең фәнни эшләр буенча директор урынбасары, тарих фәннәре кандидаты Ирек Һадиев тарафыннан укылды.

8 Хуҗа Бәдигый: Тел галиме, фольклорчы, педагог. – Казан, 2008.

9 НА РТ. Ф.2, оп.7, д.6417. На 24 лл. Дело Казанского Губернского Правления по ходатайству кр.дер.Нижней Корса, Казанского уезда, об определении к их мечети 2 муллою кр.Мамадышского уезда, дер.Верхнего Берсута Мухамета-Вафи Абдулбадигова. 1901 г.

берничә ел алдан Түбән Курса авылына килеп төпләнгән Бәдыйк хәзрәт Кыерлыдагы улы Мөхәммәтвафаны үз урынына калдырып, муллалык итүне аңа тапшыра. Мөхәммәтвафа Габделбәдыйгов 1909 елда да Югары Кыерлыда үзенең дини вазифаларын үтәвен дәвам итә[10]. Аның хәрби хезмәттә булуы, Чокырча авылындагы училищеда курслар тәмамлавы, урыс телен яхшы үзләштерүе архив документларыннан билгеле. Мәрхүм булып, мондагы зиратта күмелүе бик тә ихтимал. Шәкерт энесе Хуҗа, җәй айларында абыйсы янына авылга кайтып, хуҗалык эшләрендә аңа булышуы турында автобиографиясендә язып калдырган. Мөхәммәтвафаның улы Әхмәтхуҗа 1935 елның 28 декабрендә, мәчетне яптырмаска көрәшеп, курыкмыйча, тәнкыйтьнамәгә әби-бабайларыбыз белән бергә имзасын салган[11]. Мөхәммәтвафаның туганы Саҗидәбану, Югары Кыерлыдан китеп, Күки мулласына кияүгә чыга, остабикә буларак, анда кызларга дини сабак бирә.

Алгарак китеп, Хуҗа Бәдигый кызының язмышын да ачыклап китик әле. Роза Казан музыка училищесын тәмамлап, Ленинград консерваториясендә белем алуын дәвам иткән һәм шунда калып, озак еллар буена студентларга итальян телен укыткан. Аның уллары Антон һәм Алексей Бәдыйговлар Санкт-Петербург телевидениесендә эшләгәннәр. Соңрак Роза ханым уллары белән чит илгә киткән дигән хәбәр дә бар.

Түбән Курсада әтисеннән белем алган Хуҗа 1900 елда Казанның атаклы «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе шәкерте була, анда сигез ел укый. Әтисе вафатыннан соң, финанс кытлыгы кичерә башлый. Укуын ташламас өчен, җәйге айларда акча туплый: Югары Кыерлыга кайтып, абыйсына булыша, Әхмәт Хөсәеновның сукно фабрикасында кара эшче һөнәрен башкара, Галикәев дигән байның мануфактура кибетендә эшли, Мәкәрҗә ярминкәсендә «малайка» сыйфатында да хезмәт куя, төрле сезонлы эшләрнең берсеннән дә тартынмый. Милләтпәрвәр шәкерт 1905 елгы революция вакытында сәяси хәрәкәткә тартыла. Габдрахман Мостафин дигән студент белән прокламацияләр язып, аларны коймаларга ябыштырып таратуда актив катнаша. «Әл-Ислах» гәҗитендә мәдрәсә тормышы турында кыю мәкаләләр бастыра.

1906 елда чуваш һәм татар халык авыз иҗатын өйрәнү максатыннан, Казанга Венгриянең мәркәзе Будапешт шәһәре Көнчыгыш университетының гыйльми хезмәткәре, тюрколог, этнограф-ориенталисты Дюла (Юлий) Мессарош килә. Мәдрәсә укытучысы (бер елдан соң Төркиягә эмиграциягә киткән дәүләт һәм сәясәт эшлеклесе) Йосыф Акчура аңа ярдәмче итеп алдынгы карашлы шәкерт Хуҗа Бәдигыйны тәкъдим итә. Венгр галиме белән бергәләп, алар Казан арты авылларында фольклор әсәрләре җыю эшенә чумалар. Биш ай эчендә халык арасында йөреп, гаять зур хәзинә туплана. Хуҗа бу изге эшне соңрак та дәвам итә. 1908 елның көзендә «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе укытучылар советы аны мөгаллим итеп сайлый. Ул 1912-1914 елларда тупланган халык әсәрләрен төрләргә һәм жанрларга аерып, «Халык әдәбияты» дигән гомуми исем астында «Мәкальләр», «Табышмаклар, такмаклар, такмазалар», «Бәетләр», «Җырлар» дигән җыентыкларын бастыра һәм татар дөньясында киң танылу ала. 1918 елга кадәр мәдрәсәдә татар теле һәм әдәбияты, гарәп теле, гомуми тарих, урыс тарихы, география, математика фәннәреннән шәкертләргә белем бирә. 1909 елда, сәламәтлеге какшау сәбәпле, хәрби хезмәткә яраксыз дип табыла. Укыту дәверендә үзлегеннән урыс теленнән белем алып, учитель дәрәҗәсенә ирешү өчен, Казан губернаторына прошение язса да, сәяси яктан ышанычсызлыкта билгеләнеп, аның бу үтенече кире кагыла. 1917 елгы революция давыллары күтәрелгәндә, ул туберкулёз белән авыруы сәбәпле, урын өстендә ятарга мәҗбүр була. Яз көне, кымыз белән дәвалану максатыннан, хәзерге Башкортстан якларына юл тота. 1921 елның июнь-июль айларында ул яңадан,

[10] Башкортстан Республикасы үзәк архивы. И-295 фонд, 5 тасв., 6149 нчы эш кенәгәсе. Югары Бөрсет (Кыерлы) авылы. М.Габделбәдыйговның ислам дине кануннарын белүен тикшерү һәм аңа дини дәрәҗә бирү турында. 1909 ел.

[11] НА РТ. 732 фонд, 6 тасв., 222 эш кенәгәсе. 1937 ел. Югары Кыерлы авылы мәчетен ябу турында (1 нче мәхәллә мәчете) 24 бит.; НА РТ. 732 фонд, 6 тасв., 357 эш кенәгәсе. 1937 ел. Югары Бөрсет авылы мәчетен ябу турында (2 нче мәхәллә мәчете). 47 бит.

фольклор әсәрләрен җыю өчен, Бөре, Бәләбәй өязләренә сәяхәт кыла. Күрмәнкәй, Калмак, Борай, Сәйтәк дигән татар-типтәр авылларында җирле халык белән якыннан аралаша. Иске Балтач, Югары Тәтешле, Оса кебек татар районнарын да иңләп чыга. Биниһая бай материаллар туплый.

Үзе тарафыннан тупланган мәгълүматларга таянып, Хуҗа Бәдигый дистәләрчә хезмәтләр яза, зур дәрәҗә яулый һәм галим буларак таныла. Хуҗа Бәдигый Г.Тукай, Г.Ибраһимов, Җ.Вәлиди, Г.Газиз, Г.Әхмәров, Г.Алпаров, Г.Рәхим, Г.Ходаяров, Ф.Сәйфи-Казанлы, Х.Ярми, М.Фазлуллин, М.Гайнуллин, М.Җәләй кебек күренекле шәхесләр белән якыннан аралашкан. Тик бу дусларының күбесенең гомере (дәүләт эшлеклеләре, әдипләр, тарихчы һәм тел-әдәбият галимнәре) репрессия кампаниясендә өзелә. Татар зыялылары каймагын юкка чыгарганда, Хуҗаны да читтә калдырмыйлар, билгеле... Автономия кысаларында чикләнгән Татарстан җөмһүриятенең үсешен, күтәрелешен җаны-тәне белән яклаган гадел профессорны шәхес культы тегермәне он итеп тарттырырга була. Бәдигыйны «Буржуаз Идел-Урал штаты төзүдә катнашкан һәм режимга каршы хыянәтчел төркем оештыру»да гаепләп, 1938 елның 29 июнендә НКВД җәлладлары кулга ала[12]. Ул Пләтән төрмәсендә ябып тотыла. Туганнары аңа ашарына илтеп торалар. Хуҗа Бәдигый 1940 елның 22 июнендә акланып, әмма зинданнарда кыйналып, рухы сындырылу сәбәпле, бетәшеп, хәлсезләнеп төрмәдән кайта. Саулыгы беткән каһарман-галим, берничә генә ай яшәгәннән соң, 1940 елның 17 ноябрендә дөнья куя. Арча (кыры) зиратында җирләнә. Кабере Н.Лобачевский кабереннән ерак түгел, диләр...

***

Шунысы сөенечле: татар тарихында зур мирас калдырган якташыбыз онытылмый. 2008 елның 18 мартында Хуҗа Бәдигыйның тууына 120 ел тулу уңае белән, туган авылы Югары Кыерлы мәдәният йортында Мамадыш муниципаль районы хакимияте һәм ТР Фәннәр академиясенең Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты галимнәре катнашында үткәрелгән Республика фәнни-гамәли конференцияне зур вакыйга дип танырга тиешбез. Бу җыенда Мамадыш шәһәренең бер урамына, Югары Кыерлы мәктәбенә галимнең исемен бирү турында карар кабул ителде һәм әлеге башлангыч идея тормышка ашмас хыял гына булып калды. Кызганычка каршы, «оптимальләштерү»не сәбәп итеп, башлангычка гына калган мәктәп 2015 елда бөтенләй ябылды. Бәлки авылның бер урамын Хуҗа Бәдигый исеме ярдәмендә мәңгеләштерү кирәктер. Аның әби-бабасының каберләрен чардуган белән әйләндереп алып, хәзерге язмада истәлек тактасы кую да мәслихәт булыр иде. Барыбызга да мәгълүм бит – үз тарихын белмәгәннең киләчәге юк.

**Рәис ШАҺИЕВ,**
**Нурулла ГАРИФ**

[12] Бадыгов Ходжа Бадыгович (Бадиги). 1887 года рождения. Место рождения: Мамадышский район, с.Верхний Берсут. Татарин. Доцент. Преподаватель татарского языка. Казанский государственный пединститут. Место проживания: г.Казань. Арест: 29.06.1938. Осуждён 04.04.1939 г. Судебной коллегией Верховного суда ТАССР. Обвинён по статье 58-2, 58-10 ч. («Участник буржуазно-националистической организации «Идел-Урал»). Приговор: 10 лет лишения свободы, поражён в правах на 5 лет. Судебной коллегией Верховного суда ТАССР 2.06.1940 г. оправдан. (КПРТ).

# ТИТАННАР ГАСЫРЫ

Г.Камал театры. Бөек режиссёр Марсель Сәлимҗанов дәвере... Шул чор турында сөйләшү вакытында миңа Шәүкәт Биктимеров биреп калдырган фотолар бу. (Безнең ул диалог – «Әни... күп театрларга килде» исемендә 2010 елда «Казан утлары»ның 12 нче санында басылып чыкты.)



***Шәүкәт БИКТИМЕРОВ:*** *«Хәзрәтләр нәселеннән бит инде мин. Программаны кулыма алу белән, әүвәл аның өстенә «Аллага тапшырдым», дип язып куям. Шуннан соң гына, Бисмилла әйтеп, ролемне өйрәнергә тотынам. Рольләремнең авыр бирелүен хәтерләмим мин».*



*«Ташкыннар» (Таҗи Гыйззәт) спектакленнән күренеш. Гөлниса ролендә – Галимә Ибраһимова, Биктимер ролендә – Шәүкәт Биктимеров. 1977 ел.*

*Гасырлар узгач, әйтсеннәр иде:*
*Татар Дәүләт академия театрында*
*нинди титаннар эшләгән!..*

Марсель Сәлимҗанов




*Г.Камал исемендәге Татар Дәүләт академия театры артистлары. Сулдан уңга: Шәүкәт Биктимеров, Асия Галиева, Габдулла Шамуков, Рауза Хәйретдинова, Ринат Таҗетдинов, Вера Минкина, Галимә Ибраһимова, Фуат Халитов, Марсель Сәлимҗанов, Рәшидә Җиһаншина. 15 декабрь, 1976 ел. Мидхәт Шакирҗанов фотосы.*

**Рәйсә ЮСУПОВА** *әзерләде.*

# МИЛЛИ ЯҢГЫРАШ

Моннан хәтсез еллар элек кирилл алфавиты, яңалифне алыштыру белән канәгатьләнмичә, хәзерге графикага парлы хәрефләрне (я, ё, ю, е) ияртеп керде, авазларның үз хәрефләрен кысрыклап, шулар урынына урнаштырды. Югыйсә моңа ихтыяҗ юк иде. Җанлы сөйләшебездә аларга ярардай куш авазлар юк бит. Парлылар, билгеле, шунда ук эшкә керешеп китә алмады. Чөнки татар һәм рус телләре икесе ике системага карый. Милли сүз кабул итсен өчен, әлеге куш билгеләрне бераз каккалап-суккалап, нечкәртергә-калынайтырга, өстәмә чаралар күрергә туры килә иде.

Парлы хәрефләрнең туган туфрагы – рус әлифбасы. Алар шуңа җайлашкан. Яңа мохиттә исә алар милли авазларның яңгырашына яраклашырга тиеш була. Рус һәм татар телләрендә бер үк хәрефләр белән билгеләнгән сүз төрлечә яңгырый. Менә «он» кәлимәсе. Шуны рус телендәге «ул» мәгънәсендә әйтеп карагыз. Шуннан соң «мука» мәгънәсендәге татарча сүзне әйтерсез. Ике төрле яңгырашны тойдыгызмы? Аерма шактый бит. Язуда парлы хәреф милли яңгыраш ала.

Менә «якын» сүзе. Биредә тәүге иҗеге дә, татар сүзе дә калын авазлардан тора. Тышкы яктан парлы хәреф үзгәрми. Үзгәреш эчке якта хасил була: «я» иҗеге үз яңгырашын югалта, милли яңгырашны кабул итә. Кабул итмәсә, язылганча гына укылса, сүзнең яме югала.

Нечкә әйтелешле кәлимәдә үзгәреш арта төшә. Әйтик, «яшел» сүзендә «я» иҗеге нечкәрә, моңа тулаем сүзнең нечкәлеге йогынты ясый. Шуңа тиң яңгыраш барлыкка килә. Бүтән төрле яңгыраш була алмый.

Күп кенә сүзләрдә үзгәреш тагын да катлауланa. Менә «ямьле» кәлимәсе. Биредә «йәм» иҗеген нечкәртү өчен нечкәлек билгесе «ь» өстәлә. Парлы хәрефнең үз яңгырашы югала, «йәм» иҗегенең аһәңе пәйда була.

Шул рәвешчә, яраклаша торган сүзләр белән эш итеп, авазларның яңгырашын игә китердек ди. Алга таба исә үтә үзсүзле кәлимәләр белән очрашабыз. Язу-сызу гамәле гүя бетон стенага барып төртелә. Әйтик, «йозак», «йөзек» ише сүзләргә куш хәрефне берничек тә урнаштыру, янәшә китерү мөмкин түгел. Бердәм милли яңгыраш хасил булмый. Татар лексикасында алар шактый калын катламны тәшкил итә. Язу-сызу эше Миңлебикә кодагыйның чуар тавыгы хәлендә кала. Менә ул, кырт-кырт килеп, үзе утырып чыгарган үрдәк бәбкәләренең сүзен тыңлап, күл буена төшә, җәйрәп яткан суга карап бергәләп хозурланырга ниятли. Ләкин сары йомгаклар аны-моны уйламый, килгән шәпкә йөзеп кереп китәләр. Әниләре зур хафага төшә, «кермәгез, кермә, батасыз бит» дип арлы-бирле йөгереп йөри, ярдәм итмәкче була, ләкин суга керә алмый. «Әле ничек батмадыгыз?» дип аптырый.

Каз-үрдәк моның хикмәтен яхшы белә. Шуңа күрә суга кергәнче һәм йөзеп чыккач, каурый төбендәге биздән томшыгы белән май алып, каурыен, мамыгын мул итеп майлый. Каурый белән мамык арасында әле һава да була. Шуңа күрә бу кошлар суда батмый. Тавыкта суга мондый җайлашу юк.

Шуның кебек, теге «йозак», «йөзек» ише үҗәт кәлимәләрдә парлы хәреф авазының русча яңгырашы үзгәрми. Шуңа мондый сүзләргә парлы хәреф кушыла алмый. Табигате белән ул моңа җайланмаган. Кушыйм дисәң, «ёлдыз», «ёгән» килеп чыга.

Сорау туа: әгәр читтән кергән өстәмә парлылар милли лөгатькә тулысынча хезмәт итә алмыйлар, өлешчә генә хезмәт күрсәтәләр икән, алайса аларны әлифбага кертү нәрсәгә кирәк булды соң? Алардан башка да хәрефләр җитәрлек иде бит. Сөаль, әлбәттә, җавапсыз кала.

Инде теге үҗәт сүзләр язмышына килсәк, әлегә кадәр кулланылган чаралар монда бармый. Галимнәр аларны бары тик үз хәрефләре белән генә язарга мөмкин, дигән нәтиҗәгә киләләр. Бу фикерне әлеге сүзләр шатланып, колач җәеп каршы ала. Шул ук вакытта ул тәкъдим башка авазлар массасында көнләшү, ризасызлык тудыра: нишләп алар гына үз билгеләре, үз “киемнәре” белән йөри? Нишләп безне дә үз хәрефләребез белән язмыйсыз? Язуның табигыйлеге, төгәллеге, күркәмлеге җәһәтеннән, аннан да ышанычлырак, әйбәтрәк юл юк бит, диләр күк. Бу эштә яңаларны уйлап чыгарасы да түгел. Алар бар һәм җитәрлек күләмдә.

Заманында Q, G, Wларның әлифбага сыймавын алфавитның бик нык ишәюе белән аңлаталар иде. Артык үрчү әлеге парлы билгеләрнең басып керүе хисабына барлыкка килде. Димәк, нормаль хәлгә кайту өчен шулардан арыну фарыз. Әмма мантыйк буенча эш ителми. Парлылар урыннарыннан кымшанмыйлар да, кирәкле, әһәмиятле хәрефләр әлифбадан читтә кала бирә. Безнең графика мәгыйшәтендә логикасызлык, эзлексезлек бик күп булды. Инде, акыл белән эш итеп, артык билгеләрне әлифбадан чыгару, файдалы, ләкин үгисетелгән хәрефләргә закон көче бирү таләп ителә. Мондый гамәл парлы хәрефләрне һич тә кимсетмәс, алар үзләренең туган туфрагында гомер кичерер, ә милли әлифба тулыланып, төзекләнеп калыр.

**Фәрит ХАТИПОВ,**
*филология фәннәре докторы,*
*профессор*



*Ак җилкән*

Балачак белән яшьлек арасындагы гүзәл дөньяда яшәүчеләр, бу – безнең сәхифә!

*Бәләкәйләр*

# ПРӘНИКЛЕ ТӨШЛӘРЕМ...

Ул чакта мин үземне инде үсеп җиткән малай итеп хис итә идем. Алтыдамы, әллә җиде яшьтә булдыммы икән, тәгаен хәтерләмим. Әмма әтиемнең ике сүзнең берендә: «Әнә, нинди зур үскән минем улым» яисә «Бу малайның кулы нык булырга охшаган, пычкыны әйбәт тарта. Кар көрәсә – буран уйната», – дип, җай чыккан саен үземне мактап, туганнарым алдында салпы якка салам кыстырып, очындырып торганнарын һич онытасым юк.

Табигый инде, мактагач, бермә-бер тырышыбрак эшлисең. Тырышкач – тагы мактау эләгә. Шулай очынып йөргән көннәрнең берендә, ишле гаилә кичке чәй табыны әйләнәсенә җыелгачтын, әти җитди сүз башлап җибәрде.

– Сыерны сатарга туры килер инде, әнисе, – диде, тирән көрсенеп.

Әти ни дисә, шулай була иде безнең өйдә. Аның белән бәхәскә керүче булмады. Хәер, бәхәскә керердәй сүз сөйләми торган иде ул.

– Берни эшләр хәл юк, тагы кысыр калган шул, балаларга сөт кирәк. Гомер иткән сыердан аерылу авыр булса да, нишлисең, әтисе, – дип, килешүен белдерде әни.

– Бүген төнлә Өчиле базарына юлга чыгам. Малайларның кайсын алырга икән, әнисе, син ничек уйлыйсың, – дип, тагын әнигә мөрәҗәгать итте ул.

Йөрәк җилкенеп куйды, «мине ал, әти, мине», дип кычкырудан чак тыеп калдым үземне. Абыйлар бар, энеләрем... Алар да, әнә, әтинең күзенә текәлгәннәр. Өчиле базарына кемнең барасы килми инде. Анда ак икмәк саталар ди, келиндер, прәник… Базарның бай чагына туры килсәң, хәтта шакмаклы шикәр дә китерәләр икән... Шикәрен дә ашамый түзәр идең әле, шул базар дигәннәрен бер барып күрәсе килә иде бит. Сыер саткан чакта да эләкмәсә, тагы кайчан тәтер соң ул.

– Олыларын алырсың инде, йә Рәшитне, йә Рифатны, – дип әйтеп куймасынмы шунда әни. Һәм өстәп тә җибәрде әле. – Шултикле ерак юлга бала-чага ияртеп йөрмәссең лә...

«Ах, әни! Ни әйтеп ташладың син, әни... Нигә инде миңа җиткәч туктап калдың!» Башкаларның хәлен белмим, минем күзләрем камашып куйды, бугазыма каты төер килеп тыгылды. Борынны еш-еш тартып кына күз яшьләремне тыеп кала алдым.

Соңгы сүзне әти әйтә иде бит әле.

– Рәшит белән Рифатның өйгә бирелгән эшләре бардыр, дәресләрен әзерләсеннәр. Юл да озын, сибереп тә тора, әнә, буран чыгуы ихтимал. Көнен барып кайта алмасак, дәрестән калырлар. Яхшы булмас... – дип фикер йөртте ул. Гел шулай алдын-артын уйлап, үлчәп сөйләшә торган иде шул безнең әти.

Сүзләрең сүз генә түгел, алтын бәясенә тиң бит, әти. Әйткән һәр сүзең йөрәгемә сары май булып ягыла бара. Дөрес хәл итәсең, дөрес, карарыңны гына чыгар, сузма, зинһар, дип, зарыгып көттем аның соңгы сүзләрен.

– Ринатны гына алырмын, – диде, ниһаять, шактый көттерә төшеп. – Мәктәпкә дә барасы юк. Үзе үсеп тә җиткән, ни йомыш кушсаң – шуңа ярый инде ул хәзер.

Абыйларның, энекәшләрнең кәефе кырылгандыр инде, ансыз гына булмас. Әмма әти үзе хәл итте бит, минем гаебем юк, мин катышмадым. Барыбер әти әйткәнчә булачак, елашучы яисә каршы килүче булмады.

– Бар, улым, итекләреңне мич башына җылыга куй да йокларга ят, – дип, башымнан сыйпап куйды әни. – Юлга бик иртә чыгачаксыз.

Мин нәкъ әни кушканча эшләдем. Ишегалдына җәһәт кенә чыгып кердем дә, итекләремне мич башына куеп, түр яктагы идәнгә җәелгән зур түшәкнең бер почмагына кереп чумдым. Алты малай, алты туганга җитәрлек түшәк иде ул. Юрганны башыма ук тартып куйдым. Тавыш-фәлән ишетелмәсен, янәсе, йокларга кирәк. Ә үзем алгы якта пышылдап әйтелгән һәр сүзне эләктереп кенә алам. Кызык ич... Аннан, мин юлга чыгасы кеше – белеп тә торырга тиеш.

– Иртәнге өчтән дә калу ярамас, әнисе...

– Юл ерак, иртәрәк чыгу хәерле булыр, дөрес әйтәсең, этисе. – Кызык, әйтерсең, исемнәре юк, безнең эти белән әни гел шулай эндәшә торганнар иде бер-берсенә.

– Улым, Рифат, атка солы салырга онытма, яме. Сыерга да печәннең яхшырагын өстә.

– Ярый, эти.

– Чанага да бер-ике кочак салам салырга онытма.

– Салырмын, эти...

Ул арада Рифат абый ишегалдына, мал-туар янына чыгып китте. Каралты-кура тирәсендәге эшкә аңа җиткән кеше юк инде ул.

– Рәшит, улым, безнең теге бастырык тарттыра торган әйбәт бау кайда икән? Хәстәрләп куй әле шуны, сыерны бәйләргә кирәк булыр, дим.

– Ярый, эти, бауны чана түренә чыгарып куярмын. Бераздан тагы шапылдап ишек ябылды. Димәк, дәү абый да чыгып китте.

– Малайлар – Роберт, Рафаил, Рамил, барыгыз-бар, аяк астында чуалып йөрмәгез. Тышка чыгып, карны чылатып керегез дә түшәккә... Иртәгә иртән торып кар көрисегез булыр.

Ятып йоклагыз, дигән сүзне кем ярата инде. Әмма эти кушкач буйсынмыйча булмый, энекәшләр дә, уйный-көлешә, аякларына ни эләксә, шуны киеп, шәрә көе генә ишегалдын урап керделәр.

– Ашарыгызга ни тыгыйм икән, – дип, пышылдап кына сорады әни. – Пешкән ит белән ипекәй булыр инде?

– Ит белән ипи булгач, тагы ни кирәк, бик җиткән,– дип куйды эти.

Тагы ниләр киңәшкәннәрдер, хәтерләмим. Бер ягыма – Рамил, икенче ягыма Рафаил кереп ятты. Борыннары туңган, куллары суык иде аларның. Мине йоклый дип уйладылар бугай, дәшмәделәр, һәм мин чынлап та изрәп йокыга талганмын.

Йокыдан ни рәвешле торып, ничек киенгәнемне хәтерләмим. Мин ишегалдына чыкканда, ат җигелгән, сыерның мөгезеннән эләктерелгән бауны чана артына бәйләп куйганнар, олы капка киереп ачылган иде. Чана башындагы йомшак печән өстенә толыпка төреп утырттылар үземне. Күзләрем генә ачык калды. Әни аркамнан сөеп куйды шунда.

– Кара аны, этиеңне тыңла, улым, бик ерак юлга чыгасың, – диде.

– Әйдә, – дип, дилбегәне тартты эти.


Без кузгалдык. Авылны чыкканчы толып тишегеннән ике як урамны күзәтеп бардым. Төн караңгы булса да, кар көртләренә чумып утырган өйләр аермачык күренеп тора. Авыл йоклый иде әле. Ник бер өйдә ут чаткысы булсын, тәрәзәләр дөм караңгы. Минем белән уйный торган малайларның капка төбенә чыгып кул болгап озатып калуларын күрү кызык булыр иде дә бит. Юк шул, тәмле төшләр күреп йоклый әле алар.

Авыл капкасын чыккач та, сыер тагылган булгангадыр инде, атны атлатып кына барды эти. Сыер ат түгел, ул юырта белми шул. Юырту кая, атлар-атламас кына бара иде ул. Әллә авылдан бөтенләйгә китеп баруын аңлый иде, теләр-теләмәс кенә өстерәлеп бара шунда. Әледән-әле башын болгый, ераклаша барган авылга таба борылып, бер мөгрәп тә алды әле хәтта. Хушлашуы булдымы икән... Мин үземә калса, сыерны бер дә сатмас идем. Этигә дә сыерны сатарга ярамаганлыкны аңлатып караган булыр идем. Кыймадым, базарга барасы килүем бик көчле иде шул. Сыер сатасы булмаса, базарга да барып булмый. Дәшмәдем, түздем... Шундый уйлар белән толып эчендә май кебек эреп йокыга киткәнмен.

Өчиле базарында йөрибез, имеш. Монда бөтен кеше прәник сата икән. Эти белән прәник сайлыйбыз. Кайсы баллырак, кайсы нечкәрәк билле һәм кайсы алсурак – шундыен алдырасым килә этигә. Прәник сатучы апалар: «Монысын ал», – да, «Монысын ал», – дип, кулларын сузып торалар икән без килүгә. Эти көлә, миңа ишарәли: «Әнә, улым сайласын,

ул бик ярата прәникне», – ди. Прәник сатучы апалар мине кыстый ук башладылар, ниһаять: «Менә монысын авыз итеп кара әле, кара малай. Менә монысын», – ди-ди кыстыйлар. Кыстагач каршы килә алмыйм, үземә сузылган прәникләрен бер генә кабып карыйм да ары китәм. Янәшәдә кулын сузып торган икенче апаныкы тагы да тәмлерәктер төсле тоела. Әти дә бит, әнә, ашыктырмый. «Кабаланма, улым, ашыкма. Базарда ашыгырга ярамый, сайлап алырга кирәк әйберне. Өйгә кайткач кызарырга туры килмәслек булсын. «Кара инде, безнең абый прәник тә сайлый белми икән...» дип әйтерлек булмасын», – дип, акыл биреп йөри. Ашыктырмый, кәефе әйбәт, күңеле көр.

Һәр сатучыдан берәр прәник авыз итеп йөри-йөри, инде аяклар арыды, әмма тамак туймый икән һаман. Прәник сатучыларның очы-кырые юк, офыкка тикле тезелгәннәр. Барысы да минем исемне белә, барысы да прәник яратканлыгымны белә. «Алыгыз, ал...» – дип, һаман чакырып торалар. Ниһаять, чираттагы прәник сатучы янында тукталдык. Прәникләре чәчкә сыман алсу, әллә нинди тәмле хуш ис аңкып тора үзләреннән. Авызга капкан идем – эреде-китте, телемне йотканмын дип торам.



12 яшьләр чамасы, энекәшләр һәм сеңел белән туган нигездә.

– Әти, дим, әти, алыйк шунысын.

– Күпме алыйк икән соң? – ди әти.

– Күп итеп алыйк, әти. Күп итеп... Бөтен туганнарыма җитәрлек булсын. Күрше малайларына да берәрне бирербез, ярыймы, әти...

Әти елмая, аның кәефе яхшы. Минем сүзләремне хуплап, ярар да ярар гына дип тора...

Ах ул прәник! Мин андыйны күпме дөнья гизеп тә очратмадым. Әле дә эзлим, әле дә таба алганым юк андый прәникне.

– Улым, тор әле, тор, – дигән тавыш ишетелде шунда.

Аягүрә базар буйлап йөри идек бит, югыйсә. Ә монда «тор», дип дәшәләр. Кайсы чын иде дә, кайсы төш иде, озак кына аңыша алмый тордым.

– Тор инде, улым. Адаштык бугай без, тор әле.

Бусы әти тавышы иде инде. Күзләремне ачып җибәрсәм, мин бөтенләй Өчиле базарында түгел, чана башында толып астында йоклап ятам икән бит. Җил улый... Толып астыннан башымны чыгарган идем, йөземә кар өермәсе килеп сыланды. Ат туктаган. Чана да тик тора. Сыер чанага ук килеп терәлгән, башы минем аяк очымда гына. Яшьле күзләрен мөлдерәтеп, моңсу гына миңа карап тора. «Нинди ният белән йөрисез, кая алып киттегез инде сез мине...» – дип әйтүе идеме икән?!

– Әти... Әти, син кайда? Нәрсә булды? Без нигә туктап торабыз? – дип тавыш бирдем, саташу катыш курку белән. Җавап ишетелмәде. Мин торып ук бастым. Ян тарафтан китереп сылаган кар өермәсе һәм ачы җил чак аяктан бәреп екмады, чана үрәчәсенә генә тотынып калдым.

Ул арада шул өермә артыннан бер шәүлә төсмерләнде. Якыная төшкәч, мин шундук аны танып алдым, әти булып чыкты.

– Тордыңмы, улым? – диде ул, күз керфекләре һәм битенә сыланган ак карны күшеккән куллары белән сыпырып төшереп. – Күзачкысыз буран чыкты бит әле менә. Ат юлны югалтты.

«Юлны югалту» дигәннәрен ишеткәнем бар иде барын, әмма моның тәгаен ни аңлатканлыгын белеп бетерми идем.

– Нәрсә, без әллә адаштыкмы? – дип сорадым хәвефләнеп. Адашуның ни икәнлеген беләм. Кыш көннәрендә авыл җирләрендә бөтен хәвеф-хәтәр буранда адашуга бәйле була. Әле бер, әле икенче авылдан килеп тора иде андый хәбәрләр. Шул кышны гына да, Яңа елга каршы кичне, Урта Кирмән белән Норма авыллары арасында ике кыз адашып, суыктан катып үлгәннәр иде. Бөтен тирә-як кызганып сөйләде үзләрен.

Хәер, безнең эти алай җиңел генә бирешә торган кеше түгел. Гомумән, борын салындырган чагын хәтерләмим мин аның.

– Адашуын адашмадык, улым. Әмма юлны табарга кирәк, – диде ул. – Юкса, ат бара алмый. Кар тирән. Күрәсеңме, әнә, билдән көрткә чумган.

Шунда гына абайладым, атның, чынлап та, ботлары күренми иде диярлек, ул минем биеклектә генә калган, бил тиңентен карга чумган. Сыер да шундый ук хәлдә.

– Өчиле базарына еракмы икән соң әле, без кай тирәдәрәк икән, эти?

– Яке урманын чыгып, бер чакрымнар киткәнбездер. Өчилегә ерак әле, улым. Иң элек Кече Сонга барып җитәргә кирәк.

Аннан тагы бер урман кичеп барасыбыз бар.

– Базарга соңга калмабызмы соң, эти?

– Белеп булмый, улым. Мондый буран чыгар дип кем уйлаган бит аны.

– Буран узар әле, кичегә төшсәк тә барыйк инде, ярыймы, эти. Прәник сатучы апалар кичкә тикле эшлиләрме икән, белмисеңме, эти?

– Улым, әйдә, иң элек юлны табыйк әле...

Килешми хәл юк, килештем. Юлны тапмый торып, Өчиле дә юк, базар да юк – аны гына аңлыйм.



*Якын туганнары белән.*

– Ә ничек табарга соң ул юлны? – дип, эти ни кушса, шуңа әзер булуымны белгертеп, чанадан ук сикереп төштем һәм тез тиңентен көрткә кереп чумдым.

– Юлның маяклары да булырга тиеш иде, улым. Ат юлының уң ягына һәр кырык-илле метр саен, кышкы бураннарда юлчы адашмасын өчен, маяк итеп таяклар кадап чыгалар. Ләкин без ул юлдан тайпылдык. Бураны да басылырга уйламый, котырганнан котыра бит, әнә. Маяк түгел, каршыңда үсеп утырган агачны күрерлек түгел.

Чанадан төшкәч кенә хәлебезнең шактый ук мөшкел икәнлеген аңладым мин. Аяк карга чуммаган булса, билләһи дим, җил, кар өермәсе белән бергә, мине дә очыртып китәсе икән. Йолкып ыргытырдай булып исә, башны күтәрерлек түгел. Ат һәм сыер, бичаралар, кар өстендә басып түгел, түшләрендә ятып торалар икән ләбаса. Икесе дә, хәвеф сизепме, еш-еш сулыш ала, авыз-борын тишекләре ап-ак бәскә баткан.

– Йә, эти, куш бер йомыш, ни эшлим? Ничек ярдәм итим? – дидем шунда, төшенкелеккә бирелергә теләмичә.

– Син, улым, колагыңа киртләп куй, чанадан бер адым да читкә китәсе булма, яме, – диде ул, ике уйларга урын калдырмаслык итеп. – Синең өчен иң җитди эш шул әлегә. Ә мин тагы бер кат, уңга-сулга йөреп, юлны эзләп килим. Ул еракта түгел, монда, якында гына булырга тиеш.

Ике-өч адым ара китәргә өлгердеме-юкмы, аның шәүләсе күздән үк югалды. Эти югалды, һәм мин аны шундук көтә дә башладым. Ул китеп югалган тарафка карап, унга тикле санадым башта. Аннан бераз туктап тордым һәм тагы унга кадәр санадым. Биш мәртәбә кабатладым шулай. Эти юк та юк... Читен булып китте... Елар идең, еларга да оят. Әнә ич, ат белән сыерның хәлләре минекеннән дә авыррак, алар түзә.

Бераздан гел мин көтмәгән тарафтан килеп чыкты эти. Еш-еш сулыш алганын ишеттем иң элек, олтанлы дәү итекләрен кар көртеннән авырлык белән генә йолкып ала иде. Каеры тун өстеннән кигән кожаны ап-ак кар төсенә кергән.

– Тапмадыңмы, эти? – дидем, аны күрү шатлыгын яшерә алмый.

– Юк, улым, тапмадым әлегә. Ат түгел, кеше узарлык түгел шул бу кар өстеннән, тирән салган.

– Әти дим, әллә үзем эзләп карыйммы соң юлны?

– Белмим шул, – диде әти. Бу аның ризалашуы, рөхсәт бирүе иде инде.

Мин шундук икенче тарафка ыргылдым. Кар көрте нәрсә ул минем өчен, авылда чакта да юлдан түгел, көрт ерып кына йөрергә күнеккән ич без.

– Тукта, – дигән тавыш кына тыеп калды үземне. – Тукта, кая ашыгасың? Кереп киткән җиреңнән бар дип көтәргәме сине, юк дипме... Ашыкма, сабыр ит бераз.

Әти кырыслана төшкән иде. Мин карышмадым. Ул ипле генә ат янына барып, дилбегәнең бер ягын ычкындырып килде. Дилбегәнең бушаган очына тагы икенче бер озын бау өстәде. Төенен кат-кат тартып тикшереп карагачтын бауны минем билгә кысып бәйләп куйды.

– Мине тыңла, улым, – диде, ниһаять. – Мин кушканча гына эшлисең, ярыймы?! Бауның буе җиткән кадәрле, иң элек, туп-туры менә бу тарафка – җилгә аркаң белән барырсың. Бау тартылгач, көчәнмә. Баугa да кулың белән кагыласың булма. Шул тартылган бау ераклыгында чана тирәли бер әйләнеп чыгарсың. Катырак юлга килеп чыксаң, шундук тукта һәм мине чакырырсың. Җилгә каршы барып, кычкырганыңны ишетмәсәм, бауны бушата төшәрсең бераз. Мин үзем аңлап, бау буйлап яныңа килермен. Инде аңладыңмы?

– Аңладым, – дидем. – Тартылган бау белән, циркуль кебек, чана тирәли бер түгәрәк ясап чыгам. Каты җиргә килеп юлыксам, сине чакырам.

– Бар, улым, – диде әти, аркамнан кагып. – Тапсаң син генә табасың инде ул юлны.

Эчкә җылы кереп китте. Мактау – кайда да рәхәт икән ул. Борынны бер-ике тартып алдым да, бүрек колакчыннарымны башыма тагы да тарта төшеп, туп-туры әти күрсәткән якка кереп ыргылдым.

– Ашыкма, кая ашыгасың алай, ипләбрәк йөр, – дип, артымнан кычкырып калды әти.

Ипле генә барам югыйсә, ә җил, аркадан этеп, үзе йөгертә. Җилнең көченә түзәрлек түгел. Ярый әле аяклар бил тиңентен карга чума, юкса гел очыртып алып китәр иде. Бераз баргач, артыма борылып караган идем, ат та юк, сыер да, берни күренми. Кая ул, күзне ачарлык түгел. Әти дә мине күздән югалткандыр инде. Әмма тизрәк барып җитәсе, бауның тартылганын аңарга да хәбәр итәсе иде бит. Туктап хәл алу кая инде ул. Егылып, йөзтүбән карга чумдым, әмма туктап калмадым, үрмәләсәм-үрмәләдем, барыбер кире тордым һәм алга ыргылдым. Кар көрте итегемне йолкып алды. Ә мин югалып калмадым, кулларым белән казып чыгарып, итегемне алып кидем дә яңадан алга омтылдым. Бау тартылды, ниһаять. Шунда гына карга арка белән сузылып ятып бераз хәл алдым, аякларымны югары күтәреп, итек кунычларыма шыплап тулган карны төшердем.

Ниһаять, эшнең иң җаваплы өлеше башланды. Бауны җиңелчә генә тарттыра төшеп, зур әйләнә ясарга керештем. Җил аркадан искәндәге бару түгел инде бу, һәр адым, һәр сулыш өчен көрәшергә туры килә. Барам да барам, кар һаман да йомшак, атлаган саен бот тиңентен көрткә чумам. Көрткә чумган аякны тартып алу бер авыр булса, шул аякка торып басарга тырышу тагы да авыррак. Гәүдәне турайтырга өлгермисең, тагы бил тиңентен карга төшеп чумасың.

Туктап ял итәсе, хәл аласы килә һаман. Әмма анда әти бар. Ул миннән хәбәр көтә. Юлны таптым, дигән хәбәр... Юлны табу гына түгел, базарга да кичекмичә барып җитәргә кирәк бит әле. Юкса, якын-тирәдәге авыллардан килгән малайлар прәникне алып бетерергә мөмкин. Болар нинди ерак юл узып, буранлы юллар аша күпме газаплар чигеп килгәннәр, аларга да калсын инде бераз прәник, дип тормаслар. Аякларыма әллә каян көч һәм гайрәт килеп тулды шунда. Мин тагы да ашкыныбрак алга ыргылдым. Атлап түгел, йөгереп китәсем килә. Йөгереп булмый, бата-чума гына кар көртләре өстеннән йөзеп бара башлыйм. Ә юл һаман юк та юк. Әти дә көтә-көтә көтек булып беткәндер инде. Бер-ике мәртәбә бауны тартып, бу исәнме-юкмы дигәндәй, тикшереп тә карады бугай. Ә мин һаман барам да барам. Бу адымда булмаса, чираттагы адымым каты карга китереп чыгарыр кебек тоела иде.

Чү, рәттән ике-өч адым җиңел генә атлап үттем түгелме соң?! Кире борылдым. Яңадан арлы-бирле үтеп карадым – юл ич, юл иде бу. Ат юлы! Әнә, ике-өч адым ераклыкта гына карга кадап куйган озын куак таягы да җилдә бер ялгызы атынып тора.

Шунда ничек шатланганымны, күңелгә нинди кайнар дулкын бәреп кергәнлеген белсәгез икән. Үзегез дә утырган җирегездән сикереп куяр идегез.

– Таптым... Ур-ра, таптым... Юлны таптым, әти, – дип, җан-фәрман кычкырып, башымдагы колакчынлы бүрегемне салып, югары чөеп җибәргәнмен.

Әти дә тоемлады ахрысы минем тавышны. Ерактан ук бауга тотынып, аның миңа таба дәү-дәү адымнар белән якынлашып килүен абайладым.

– Нигә кычкырасың, улым? – диде ул, килә-килешкә.

– Юлны таптым, әти. Әнә, маягы да бар. Бу инде чын юл, туп-туры базарга, прәникле Өчилегә илтә торганы...

Үзе дә каты карга чыгып баскач, биегән сыман итеп, куанычыннан олтанлы зур итекләре белән шап-шоп тыпырданып алды.

– Маладис, улым, булдырдың, – дип мактады үземне. – Тапсаң син генә табарсың дип уйлаган идем аны...

– Бар, әти, атны алып кил. Мин монда көтеп торам, – дигәнмен шунда, эреләнә төшеп. Миңа ни, юл табылгач, юыртып китеп барасы гына калгандыр төсле тоелган инде.

– Эшнең иң зурысы алда әле, улым. Атны туарырга туры килер, шунсыз юлга алып чыгып булмас үзен, – диде ул, мине хафага салып. Күңелем белән юлда, юлда гынамы соң, базарга ук җитеп килә идем бит инде мин.

Әти килгән юлдан без икәүләп ат янына әйләнеп кайттык. Безне күргәчтен дә, куанычыннанмы икән, ат пошкырып куйды. Аның яллары, ап-ак төскә кереп, буранга уралган иде инде. Аркасыннан сизелер-сизелмәс кенә җылы пар бөркелеп тора.

Аркалыкны күтәрә төште әти. Аннан дилбегә очларын эләктереп куйды.

– Син, улым, йөгән очыннан тартып, атны юлга таба әйдәрсең, ә мин тәртәләреннән күтәреп ярдәм итәргә тырышырмын, – диде ул. Әмма ат, ике-өч мәртәбә кузгалырга теләп талпынып караса да, кузгала алмады, гөрселдәп кире карга чумды.

Әти дәшми генә атны туарырга кереште. Хәер, туару дип, бөтенләй үк туармады инде. Камыт һәм ыңгырчаклары атның үзендә калды, түбән тартып торган чана тәртәләреннән аерды ул аны.

– Әйдә, малкай, тагы бер көчәнеп карыйк, – диде, ниһаять, йөгән очын үз кулына алып. Ат, әле очарга гына өйрәнеп килгән кош баласыдай, җан-фәрман алга тартылды. Әмма аяклары кар көртеннән ничек килеп чыккан булса, шундый ук тизлектә кире кар астына кереп югалалар.

– Әйдә, бахбай, әйдә, – ди-ди тартты аны әти. Ул тагы ыргылды һәм тагы көрткә чумды. Тагы ыргылды...

Атның, ялларын җилгә таратып, болын сукмагыннан чабып барганын кем генә сокланып, хәйран калып күзәтмәгән икән бу дөньяда. Камиллек, җитезлек һәм сылулыкның үрнәге бит ул башын бераз артка ташлап, койрыгын дуга сыман күтәрә төшеп чабып барган аргамак. Ат чабар өчен, җилдәй җилдерер өчен яратылган. Кар көрте өстеннән тырмаша-тырмаша үрмәләү өчен түгел. Әмма бу очракта башка чарасы юк иде бахбайның. Көрт өстеннән үрмәләү дип әйтү дөрес булгандырмы ул очрак өчен, йөзеп бару дип әйтүме... Ни итсә итте, өч-дүрт мәртәбә туктап хәл ала-ала, тояклары белән йомшак кар көртләрен ишеп, юлга чыгып җитте ул, ниһаять, һәм аяк астындагы юлны тоюдан, бар тәне белән калтыранып, өстенә ябышкан карны кагып алды. Шатлыгыннанмы, пошкырып кешнәп үк җибәрде. Буран артыннан чана янәшәсендә бер ялгызы калган сыер мөгрәп җавап кайтарды үзенә. Хайван диген инде син аларны, әнә ич, нинди акыллылар.

Атны миңа калдырып, чана белән сыер янына китеп барды әти. Ул кушканча, йөгән очын кулыма урап тоттым да аның кире кайтуын көтә башладым. Башыма һич сыймый, күз алдыма китерә алмый азапландым – атсыз калган чана белән сыерны ни эшләтә, ничек алып килә инде ул хәзер.

Бахбай да шул хакта уйлана иде булса кирәк. Моңсу гына миңа карап тора. Буранда юл югалтуда, һәм безнең шул тикле тоткарланып изалануыбызда ул иң элек үзен гаепле саный иде булса кирәк.

«Син гаепле түгел, малкай, бу буранда юлны табу түгел, маңгаең белән килеп төртелми торып, маякны да күрерлек түгел бит, әнә», – дип әйтәсем килде аңа.

Әти киткәнгә инде байтак гомер узды, ә ул юк та юк, һаман күренми. Пошаманга төштем, нигә шулай озак тора икән ул, бер-бер тавыш-хәбәр бирсә икән. Каршы да

барып булмый, чөнки атны кулдан ычкындырырга ярамый. Бер урында селкенмичә торгангадыр, аяк-кулларга да суык үтә башлады инде.

– Әти, син кайда? – дип кычкырдым. Җавап ишетелмәде.

Атның яңакларын, борын очларын сыйпап тордым. Ул түзә, көтә бит әнә, мин дә сабыр итәргә тиеш, дип, үз-үземне тынычландырдым.

– Улым, – дигән тавыш ишетелде, ниһаять. Тавыш килгән яктан тонык кына булып әтинең шәүләсе шәйләнде бераздан. Ике тәртә арасына кереп, бата-чума ат чанасын өстерәп килүе икән аның. Үз аякларың белән атлау мөмкин түгел, ә ул анда ат чанасын өстерәп килә, әнә. Тавыш биреп, аны ашыктырганым өчен кыен булып китте, уңайсызландым. Әтинең колакчынлы күн бүреге астыннан пар бөркелә иде.

Чананы юлга тартып чыгаргач та, тәртә арасыннан чыгып, үзе урынына җәт кенә атны җигеп куйды ул. Шундук буран эченнән озын-озын итеп сузып ике мәртәбә сыер мөгрәгәне ишетелде. Ә мин сыер хакында бөтенләй оныткан да идем инде.

– Сыер үзе генә калдымы, әти? Ул анда ничек торыр, – дидем борчылып.

– Кая китсен, улым. Көрткә баткан сыер суга чумган балта кебек ул...

Чана өстендә яткан кожан торыпшаны алып, ул кире борылды.

– Ә монысы нигә? – дип кызыксындым, иске соры торыпшага күрсәтеп.

– Сыер ат түгел, улым, аны торыпша өстенә менгезеп булса, шуның белән өстерәп килми чара юк.

Аңлагандай баш кактым. Әти китеп барды. Ә вакыт үтә, буран да басылмый. Көннең кай вакыты икән инде хәзер? Өчиледә базар башланды микән?.. Тарала гына күрмәсен инде. Без килеп җиткәнче көтсәләр ярый ла... Ат та тынгысызлана башлады, басып торган җирендә аякларын тупырдатып, өстенә сарылган карны кагып алды. Ә минем күз әти киткән якта, ак буран эченнән чираттагы мәртәбә аның шәүләсе күренгәнне көтәм.

Шәүләдән элек, аның авыр сулап уфылдаганы ишетелде бу юлы. Аннары – кар көрте өстеннән өстерәлгән кожан торыпша шыгырдавы. Унга кадәр санаем да көтәм, унга кадәр санаем да көтәм... Шулай санагачтын, алар якыная төсле иде. Һәм, ниһаять, су өстендәге көймәдә йөзеп килгән кебек, торыпша өстенә яткан сыер да шуып килеп җитте.

Яңадан җылы толып эченә төреп, чана түрендәге ышык урынга утыртты мине әти. Аякларым чираган, авыз-борыннарым күшеккәнлеген шунда гына аңладым. Юлыбызны дәвам иттек. Үзебез юлда булсак та, күңелем белән инде Өчиле базарында идем мин. Прәник сатучы апалар янында...

Әтинең «трр» дип, ат туктаткан тавышына уянып киттем бу юлы. Ул кем беләндер сөйләшергә керешә. Мин толып эчендә изрәп оеган көе, күзләремне ачарга иренеп, ятуымны дәвам итәм.

– Заһидулла абый, исәннәрме? – дип, күптәнге танышын очраткандай, җылы итеп күреште әти.

– Мөхәмәтсафа, син түгелме? Бу кара буранда нинди җилләр ташлады үзегезне? Ничек җөрьәт итеп юлга чыктыгыз? – дип җавап кайтардылар аңа. Бераз карлыга төшсә дә, гаҗәеп тыныч, җанга үтеп керә торган ипле тавыш иде ул кешедә.

– Авылдан чыкканда, буранның заты да юк иде. Сезнең урманны чыккач кына башланды ул. Иң элек кар ява башлады, аннан җил кузгалды. Күзачкысыз буранга эләгербез, дип, кем уйлаган бит аны.

– Сыер да таккансыз икән. Җитмәсә, бер ялгызың. Син дөнья күргән кеше бит инде, Мөхәмәтсафа, кышкы көнгә ышанып буламыни...

– Мин үзем генә түгел, әнә, үсеп җиткән улым бар. Ул булмаса, эшләр харап иде әле... – дип, мине мактап алды әти.

Рәхәт булып китте. Кемнән-кемнән, әтидән мактау сүзләре ишетү еш тәтеми бит ул. Заһидулла абзый дигән кеше белән сөйләшә-сөйләшә, алар алгарак үттеләр. Тавышлары тоныклана төшеп, ишетелер-ишетелмәс булды.

Бераздан әтинең үземне күтәреп алганын хәтерлим. Әмма күзләремне ачарга ирендем, җылы һәм рәхәт иде. Толыбым-нием белән мич башына кертеп салганнар үземне. Күземне ачканда, өйдә ут алганнар иде инде. Өлкәннәр җиделе лампа яктысында чәй эчеп утыра.

Башына яшел бизәкле ак яулык, өстенә шундый ук ак алъяпкыч япкан апа уятты үземне.

– Улым, тор инде, төшәсеңме? Кайнар коймак белән чәй эчәрсең, – дип дәште ул миңа. Үз әнием тавышы дип торам, ул да шулай яратып, «улым» дип, тәмле ризыклар белән кызыктырып уята бит мине йокыдан. «Тор-тордан хәбәр килгән, торыгыз, улларым, торыгыз...» ди-ди такмаклап уята. Ә кайнар коймак минем иң яраткан ашым, «кайнар коймак», дисәләр, төн уртасында да сикереп торырга әзер мин.

– Рәхмәт, апа, – дидем, тартынып кына. – Бераз гына ятыйм да төшәрмен.

– Кәнифә... Кәнифә, дим. Бала-чаганың бар рәхәте йокыда бит аның. Ятсын, ник уятасың, йокысы туйгач торыр әле, – диде Заһидулла абый, хатынына эндәшеп.

– Ярар, атасы, ярар. Коймакны җылы чакта ашасын, эченә җылы керер, дип кенә әйткән идем. Ятып торсын алай булгач, – диде ак алъяпкычлы апа.

Бу уянмады дип уйладылармы, мине оныттылар.

– Базарга өлгермәдек инде, хәерлегә булсын, – дип, көрсенеп алды шунда әти.

«Ничек өлгермәдек?! Без бит базарга дип чыккан кеше. Өчиледә түгелмени без?» – дип кычкырып җибәрә яздым кинәт.

– Әти, без кайда, Өчиледә түгелмени? – дип сорарга җөрьәт иттем шулай да.

– Улым торган икән бит, – дип, башын күтәрде әти. Сизеп торам, кәефе үзенең дә бик шәптән түгел.

Аның өчен Заһидулла абый җавап бирде.

– Базар булмагандыр бүген. Мондый буранда җүнле хуҗа этен дә урамга чыгармый бит. Аннан, Мөхәмәтсафа, соңгы араларда базары да бик бәләкәйләнде, ярлыланды аның. Әүвәл заманнарда урамнарга сыймый торган иде Өчиле базары, мал сатучылар әллә кайлардан килә торганнар иде. Хәзер алыйм дисәң, малы юк, сатыйм дисәң – алучысы. Бетеп бара базар.

– Ә прәник... прәник бармы соң, абый? – дип аваз салдым мич башыннан.

Әмма җавап бирүче булмады. Әллә ишетмәделәр...

– И-и, Заһидулла абый, ул Өчиле базарын әйтеп-сөйләп бетерерлек түгел иде бит, – дип, офтанып куйды әти. – Мин үзем әле колхозлашу башланганчы ук хәтерлим ул базарларны. Ни генә булмый торган иде ул чактагы базарларда. Булмаса, шул кош сөте генә булмагандыр.

– Ул чаклар белән чагыштырырлыкмы? Һәр кешенең бер һөнәре яисә шөгыле бар иде ул елларда! – дип өстәде Заһидулла абый.

Өйдә бераз тынлык утырып торды. Мич каршында әвәрә килгән ак алъяпкычлы апа бүлде ул тынлыкны. Тәмле пар бөркеп торган бер коштабак бәрәңге китереп утыртты ул өстәлгә.

– Заһидулла абый, – дип, өй хуҗасына мут кына елмаеп күзен кысып алды әти. – Минем чана башында бер чәкүшкә булырга тиеш, тамак чылатып алмыйбызмы?

– Анысы качмас, – диде Заһидулла абый. – Синең бит әле иң элек мал сатасың бар, Мөхәмәтсафа. Шуны хәл итик башта. Кәнифә, әнисе... карале, теге түбән очның Мөхәммәтҗан Газизҗаны, Кәти Газизҗанын әйтәм, сугымга мал эзли дип ишеткән идем, таптылар микән?

– Белмим шул, Заһидулла, – дигән җавап ишетелде. – Әнә, Мирсәет кайтты бугай, капка шыгырдады. Бәлки, ул белә торгандыр. Кайчан карама, шуларның Фазылҗаны белән бит ул. Бүген дә бергәләп тауда чаңгы шудылар.

Ялт кына ишегалдына чыгып керде Кәнифә апа.

– Әтисе, – диде, сүзен дәвам итеп. – Мирсәетне төшереп җибәрдем. Хәзер белеп менәр, боерган булса.

– Рәхмәт инде, Заһидулла абый, сезгә мәшәкать тудырдым бит әле, – диде әти, итагатьлек күрсәтеп.

– Безнең Мирсәет үземә охшаган, җиңел аяклы, хәзер менеп җитәр, – диде Заһидулла абый, шаярган атлы итеп. – Синең бәхетең булса, Газизҗан үзе дә менәр әле. Малайларына атап ясаткан гармуны бар иде, аны да аласы бар.

Мирсәет дигән малайлары озак көттермәде, кайтып та керде. «Малай» дигәч тә, мин аны үзем кебек бер юеш борын дип уйлаган идем, ә ул буй җиткергән егет икән. Чандыр гына үзе, озынча. Бит алмалары, борын очлары кызарып тора, ә авызы ерык.

– Газизҗан абый хәзер менеп җитәм диде, – дип хәбәр салды малайлары. Аннан, карга манчылып юешләнеп беткән киез итек һәм йон оекларын мич башына куярга дип килгәч, мине күреп алды.

Иң элек борынын җыерып, сүзсез генә, үземне үчекләп алды.

– Мич башында бер бәләкәй малай да утыра икән бит әле, – диде, авызын ерып.

«Бәләкәй» дигән була. Нинди бәләкәй булыйм инде мин...

Янган мич каршысына барып, кул-аякларын җылытып торды ул бераз. Миңа карап елмайды һәм күзен кысып тагы бер кат мине үчекләп алды.

Бу юлы инде мин дә югалып калмадым, әти янда гына бит, бияләй кадәрле телемне чыгарып күрсәттем үзенә.

Бераздан өйгә, Фазылҗан атлы дәү малаен ияртеп, башын кыңгыр салып, әзмәвердәй дәү гәүдәле, Газизҗан абый килеп керде. Тыйнак кына авыл өе кеше белән тулды, ул хәтта кысан булып китте.

Безнең әтинең белмәгән кешесе юк. Газизҗан атлы абзый белән дә күптәнге танышлардай күреште алар.

– Синмени әле бу, Мөхәмәтсафа?! – диде ул аңа, ике кулын сузып.

– Исәнме, Газизҗан абый. Саулармы?..

Хәл-әхвәл белештеләр беравык. Аннан Газизҗан абый дигәне безнең авыл кешеләрен сораштыра башлады. Дөнья кадәр икән таныш-белешләре. Туган-тумачалары да бар икән, берәвен җизни, икенчеләрен кода-кодагый дип искә алды. Миңа рәхәт, мич башыннан башны сузып, тик тыңлап утырам олылар сүзен.

Әтинең ни йомыш белән килеп чыгуын ачыкладылар. Шундый күзачкысыз буранда юлга чыгып, исән-аман килеп җитүебезгә гаҗәпләнде Газизҗан абзый. Сүз иярә сүз чыгып, сыерга да килеп җиттеләр, һәм шунда капылт кына өстәл артыннан торып, җилкәләренә туннарын салып, бер-бер артлы өчесе дә ишегалдына чыгып киттеләр.

Ак алъяпкычлы Кәнифә апа табын тирәсендә мәш килде. Ә теге ике малай – Мирсәет белән Фазылҗан – түрдәге шкаф каршына килеп, аның киштәләрендә торган гармуннар белән кайнаша башлады. Мине искә дә алмыйлар, әйтерсең, мин бөтенләй юк.

– Менә бу гармунны әтигә Салих Сәйдәшев бүләк иткән, – диде Мирсәет, бер горурлык белән.

Мактанчык, дип уйлап куйдым үзалдыма. Сәйдәшевнең кем икәнлеген мин каян белим әле ул вакытта?! Ә Фазылҗан белә икән.

– Кит аннан, – дип куйды, соклануын яшермичә. – Кая, тотып кына карыйм әле, малай. Салих Сәйдәш үзе бүләк иткән, дисеңме?

– Теләсәң, мә, уйнап кара, – дип, гармунны дустына сузды Мирсәет.

Фазылҗанның бәхете, эченә сыешмыйча, эчкерсез елмаю булып, авызына, күзләренә бәреп чыкты. Теге, яшел күн белән чигелгән гармунны кулына алды да елкылдап торган телләренә, бакаларына басып-басып тарткаларга кереште.

Мин аны кычкыртып кына карый торгандыр дип уйлаган идем, ә ул уйный да белә икән. Ничек кенә уйный икән әле. Читтән карап торсаң, үзен бер дә гармунчы димәссең...

– Мал хуҗасына охшый, диләр. Бу гармун үзе уйный икән, малай, – диде Фазылҗан, бәхетеннән авызын җыеп ала алмыйча.

Ул гармунны Мирсәет ни рәвешле ипле генә кулына алган булса, шундый ук кадер белән кире урынына куйды.

– Монысы Вараксин, – диде, янәшәдә торган икенче гармунга күрсәтеп. – Әтигә аны Вараксин үзе бүләк иткән...

Гаҗәпләнүен яшерә алмый, тел шартлатып, башын чайкап куйды Фазылҗан. Ихластан сокланып күзәтте ул бу гармунны да.

Ә Мирсәет һаман гармуннарын күрсәтә. Каян хәтерләп бетергән ул аларның исемнәрен. «Бусы – баян, монысы – ике рәтле хромка. Монысы – тальян...» Кайдан алынган һәм кем бүләге икәнлекләрен бәйнә-бәйнә сөйләп барды.

Иң соңыннан гына шкафларының аскы ишеген ачып җибәрде – анда да гармуннар икән, малай. Минем үз гомеремдә ул кадәр күп гармун күргәнем юк иде, безнең бөтен авылда булмагандыр алай. «Болар, нәрсә, шул тикле черегән байлар микәнни...» – дип уйлап куйдым. Алай дисәң, өйләре гади генә, әллә ни зур да түгел. Бу хәл минем башка сыймады. Мин ул гармуннарны санарга керешеп карадым. Унга тулды тулуын, әмма аннан ары санын бутаганмын.

Минем дә, идәнгә төшеп, шул шкаф янына барасым, гармуннарны тотып-тотып карыйсым килә иде. Җиз бакаларына, елкылдап торган көмеш телләренә басып карыйсым килде. Мин басканда да чыгар идеме икән алардан шундый ук матур тавыш?! Ләкин кыймадым, мин бит монда кунак кына. Аннары бит әле чакыручы да юк.

Шул рәвешле, теге малайларга кызыгып, алардан көнләшеп утырганда, шау-гөр килеп, күтәренке күңел белән өйгә әтиләр килеп керде. Өс-башларын чишенгән арада миңа дәште әти:

– Төш, улым, күпме йокларга була, – дип, күтәреп идәнгә төшереп бастырды. – Сыерны саттык, буран да басылырга охшаган. Юллар уңды болай булгач, – дип, уч төпләрен бер-беренә сыпырып куйды.

– Мөхәмәтсафа, – дип, әтине өстәл янына дәштеләр шунда. – Сыер сату, сыер алу көн дә булмый. Авыл кешесе өчен ул бик зур эш. Бераз гына чеметеп алыйк булмаса...

Бу – Заһидулла абый тавышы. Аның ипле, моңлы тавышын мин инде таный башлаган идем.

Газизҗан абый дигәннәре дә алыш-бирештән канәгать иде, күрәсең.

– Бирәм дигән колына – чыгарып куяр юлына, – дип әйтеп куйды ул көр тавышы белән. – Киләсе базарга барырга дип тора идем әле. Әйбәт булды бу сыер, әйбәт... Балалар ишле, бәрәңге белән генә торып булмый шул.

– Йә, Мөхәмәтсафа, чәкинең хуҗасы син. Үзең үк ачып та җибәрәсеңме әллә, – диде хуҗа кеше.

Өйгә яңа пешкән итле аш исе таралды. Әтиләр теге чәкүшкәне өстәл уртасына утыртып, өч ир-ат кич буе, шау-гөр килеп, дөнья хәлләрен сөйләшеп утырдылар.

Ак алъяпкычлы Кәнифә апа безгә аш-суны мич каршысындагы сәкегә әзерләде. Мирсәет белән Фазылҗан ике яклап сәкедән аякларын асылындырып утырдылар, ә мин, аякларымны матур гына бөкләп, түргә менеп кунакладым. Тамак та ачкан, аш та тәмле иде. Ә иң мөһиме, мин бит, аларга тиң булып, ике олы малай белән бер табын артында утырам. Алар мине үртәмиләр дә инде хәзер.

– Мирсәет, улым, әллә «бер матурның балдагын йә калфагын» тартып җибәрәсеңме соң? Күңелле булып китте бит әле. Буран булса да – бәйрәм булсын инде, – дип, Заһидулла абый улына эндәште шунда.

Минем дә күңелгә шатлык тулды. Баядан бирле шул гармуннар турында хыялланып, сүз катарга кыймый утыра идем.

Мирсәет абый ялындырып тормады, кулына туры килгән беренче гармунны алды да, йоласын килештереп, иң элек бер-ике теленә, бакаларына баскалап алды. Аннан сыздырып уйнап җибәрде. «Шахта» көе булды бугай. Ул уйнап җибәргәч тә, җанга шундый рәхәт булып китте. Әтиләр дә онытылып тыңлый иде үзен. Фазылҗан булып, ул да, ачыла төшкән авызын йомарга онытып, бер почмакка текәлгән, әнә. Күзләрен челт-мелт йомып ала, аңа да бик моңсу иде, ахры.

– Инде хәзер, Фазылҗан, син уйна, улым, – диде Газизҗан абый, Мирсәет уйнап туктагач. Аның да үз малаеның гармунчы икәнлеген күрсәтеп, ул уйнаганда бер горурлык кичереп утырасы килгәндер...

Фазылҗан абый, үзенә күрә түгел, гармунның да, әнә, кыңгыраулысын, яшелен сайлап алды. Ишеткәнем бар, кыңгыраулы гармунда уйнау бермә-бер катлаулырак, диләр. Безнең авылда бит кыңгыраулы гармунда бер шәһәр Рәфәгате генә уйный белә. Ул да шул бию көе – «Чабата»ны гына оста чыгара. Фазылҗан, икеләнеп тә тормады әнә, шул гармунны алып тез өстенә куйды да, башын кыңгыр салып, «Баламишкин»ны сайратырга кереште.

«Баламишкин»ны ишеткәч, йөрәк җилкенеп куйды. Безнең авылда да җәйге кичләрдә су буйлары, бакча башлары тарафыннан еш ишетелә иде ул көй. Гармунга кушылып, бер-ике егет кычкырып җырлап җибәрсә, яткан җиреңнән ничек сикереп торганыңны да сизми каласың. Фазылҗан да, әнә, шул безнең авыл яшьләре кебек, юри кычкыртып, сузып-сузып уйный ул көйне. Үз улының уенына сокланып утырган Газизҗан абый да түзмәде, ирексездән, кушылып җырлап җибәрде. Тора-бара, Заһидулла абый белән минем әти дә кушылып киттеләр үзенә.

Сыздырыпмы-сыздыра Фазылҗан, гармунының кыңгыравы, тарткан саен аваз биреп, йөрәккә кагыла – йөрәкне җилкендерә. Фазылҗан абый уйный, әтиләр җырлый.

Мирсәет абый да, әнә, авызын бөреп кенә утырса да, җыр белән бергә талпына, онытылып, җыр дулкынында тибрәнә. Ә аның әнисе, башындагы яулык чите белән авызын каплап, чаршау артыннан исе китеп карап тора.

Мин җырга кушылмадым. Хәтта урынымнан кымшанмадым. Берни булмагандай, тик тыңлап кына утыра идем бит, югыйсә. Ә күзләремә, тамак төбемә кайнар яшь тамчылары килеп буылган. Җырлый да алмыйм, көлә дә алмыйм. Җырлыйм дип авызым ачсам, хәтта кымшансам да, күзләремә тулган шул кайнар тамчылар мөлдерәп тышка бәреп чыгачак...

– Мөхәмәтсафа, синең малай да уйнамый торгандыр ич? – дип сорап куйды шунда Заһидулла абый.

Миңа читен һәм уңайсыз булып китте. Үзем түзәр идем әле, әтием өчен уңайсыз иде. Ул ничек дип җавап бирер?.. Уйнау түгел, минем бит кулыма гармун да тотып караганым юк.

– Минем улым уйный белми әлегә, – диде әти, һич кенә дә уңайсызлану кичермичә. – Менә, Заһидулла абый, әллә үзенә бер-бер гармун алып биримме икән дип уйлап утыра идем әле.

«Ай әти, шул мизгелдә минем ни турында хыялланганымны кайдан белдең син!..» Кеше янында булмасак, үзеңне йөгереп барып кочып алган булыр идем.

Җыйнак гәүдәле, җиңел хәрәкәтле Заһидулла абый, өстәл артыннан торып, минем янга килде шунда. Һәм кулын биреп, сәке өстеннән төшерде. Үзенә әллә кайчан тартып, яктылыгы белән күзләремне, күзләремне генә түгел, бар җанымны җәлеп итеп торган шкаф янына җитәкләп алып килде. Аның урта шүрлегенә берсеннән-берсе матуррак булып бизәлгән өр-яңа өч гармун тезеп куйды.

– Ал, кайсын ошатасың – шунысы синеке! – диде.

Мин бер гармунга карыйм, бер әтигә күз төшереп алам. Сыер саткан акчага ни алырга җыенганнарын белә идем чөнки. Җиде балалы йортта гармун кайгысы түгел иде әле.

– Кыюрак бул, улым, тартынма, ошаганын сайлап ал. Акча бар бит менә, – диде әти, сер бирмәде.

– Акча малы түгел, үзем ясаган гармуннар, – диде Заһидулла абый.

Барысы да матур, кайсын алырга белмәссең. Уртадагысына кулымны сузганмын.

– Ал, – диде Заһидулла абый, шул гармунны минем кулыма тоттырып. – Миннән бүләк булыр үзеңә. Зур булып үсәрсең һәм шул чакны, яхшылык белән, мине дә искә төшерерсең, ал.

Әтинең «юк-юк, сатып алабыз...» дигән ай-вайларына колак та салмады Заһидулла абый.

– Үзем ясаган гармун, малаеңа миннән бүләк булсын, – дип, бәхәсләргә урын калдырмаслык итеп бастырып куйды сүзен.

***

Шул еллардан соң күпме гомер узып, күпме сулар аккандыр. Үсеп буйга җиткәнче, Кече Сонда башкача булырга туры килмәде миңа. Заһидулла абый дигәнебез – мәшһүр композитор Заһид Яруллин булганлыгын мин ул чакта белмәгәнмен. Хәзер беләм. Әмма Заһидулла абый инде күптән башка дөньяда. Газизҗан абыйны да шул көннән соң күрергә язмаган булып чыкты. Әтине югалтканыма да байтак гомер. Заһидулла абый да юк, Газизҗан абый да... Минем әтием дә... Хәтта гармун да юк.

Ул гармунны тыңлата алмадым мин үземә. Әллә гармун миңа буйсынмады, әллә мин гармунга – әйтә алмыйм. Гармунчы чыкмады үземнән.

Әмма еллар үткән саен кайтып-кайтып, гомеремнең иң истәлекле бер көне сыман хәтергә уелып калган, Өчиле базарына чыккан җирдән юл таба алмый адашып йөргән буранлы иртәне сагынам. Шул чакта күпме хыялланып һәм омтылып та барып җитә алмаган, гомеремдә бер күрергә насыйп булмаган Өчиле базарын сагынам. Прәникле төшләремне... Кече Сон авылындагы җылы мич башын. Әтине... Заһидулла абыйны... Газизҗан абыйны... Һәм, ни өчендер, күпме үҗәтләнеп тә өйрәнә алмаган, үземә буйсынырга теләмәгән, киребеткән шул гармунны сагынам.

**Ринат МӨХӘММӘДИЕВ**

Печән Базары

*Сатирик әсәрләр*

# ТУКСАНЫНЧЫ ЕЛЛАР КӨНДӘЛЕГЕННӘН

### Яшәсен талон

Талонга күчү тәмам күтәрде бәндәне. Кесәңдә талоның булмаса, сине кешегә санаучы да юк. Ансыз кибеткә керү турында уйлыйсы да юк. Сатучы синең тарафка күтәрелеп тә карамаячак. Әгәр талоннарың булса – син бай кеше! Кибеткә керү генә түгел, төрледән-төрле ризыклар тезелгән киштәләрне карап, миллионер кыяфәте чыгарып йөрергә мөмкинсең.

Кечкенә генә булса да талон дигән кәгазь кисәге хәзер күңелгә шундый якын тоела башлады, талонсыз бирелгән әйберне сатып аласы да килми хәтта.

Беркөнне урамда иске танышымны очраттым. Шартын китереп исәнләшкәч, әлбәттә, хәл-әхвәлләрне белешә башладык. «Тазалыгың ничек?» – дип сорыйсы урынга: «Талоның ничек?» – дигән сүзнең авыздан чыгып очуын үзем дә шәйләми калдым. Шушының белән генә бетсә бер хәл иде, тагын саташып ташлаганмын.

– Бабай булырга торам, кызны ярәшергә сорап килделәр, – дип, танышым үзенең шатлыгы белән уртаклашкан иде.

– Кияү нindирәк? – дим.

– Ярыйсы күренә.

– Талоны бармы соң?.. – Тфү-тфү... Тагын ычкынды, тәре! Саташтыра башлады, ахрысы, бу талон. Югыйсә: «Ата-анасы бармы?» – дип сорамакчы идем бит.

Танышым карашын читкә борды. Миңа гына түгел, аңа да кыен булып китте бугай. Бу бәндә саташа башлаган, ахры, дип шикләнгәндер дә әле.

Ничек уйласа да урынлы. Талон мәсьәләсе тәмам миемә сеңде. Аны ничек һәм кайда куллану, аерым тармакларга гамәлгә кертүдән нинди уңай нәтиҗәләргә ирешеп булачагы турында баш ватам хәзер.

Әйтик, аерылышу, кат-кат өйләнешү илдә киң таралган. Балаларны ятим итмәс өчен, талон тәртибе кертергә кирәк. Гаиләне ташлап китүченең талонын алып, бала калган якка бирү, аңа башкача талонның духын да күрсәтмәү аерылышуларны киметергә тиеш.

Бала табучыларга да талон кертү заури. Югыйсә, халык үрчи дә үрчи, ә ашау ягын җиткерер хәл юк...

Төрле дәрәҗәдәге түрәләрне дә талонга калдыру отышлы булыр. Үз кул астындагы туган-тумачаларын мактаган саен, аларның талонын кисәргә кирәк. Телен дә, кулын да тыя алмаган түрәләрне гел талонсыз калдыру урынлы булыр. Бәлки, билләре нечкәрер, дөресрәге, бил урыннары сизелә башлар иде.

Талон кирәк. Талонсыз яшәү – файдасыз яшәү. Әнә, туксан яшен күптән уздырган Хәмит ага да Газраилне кире борган.

– Бездә талонсыз җан түгел, конфет та бирмиләр, – дип, талон белән килергә кушып җибәргән.

Талон безне озын гомерле итә икән бит. Яшәсен талон!

*Декабрь, 1990 ел*

## Тыңлаучан кеше

Минем алдан тартучым да, арттан этүчем дә булмады. Салмак кына, үз көемә эшләп йөрдем. Каршы дәшмәдем, ни кушсалар, шуны үтәдем, эшкә соңга калмадым, алдан килмәдем, хуҗаның теләген алдан сиземләдем. Фәкать үз тырышлыгым, үз көчем белән генә күтәрелә алдым, инде урынбасар иттеләр.

Бәндә дигәнең тиз дә үзгәрә икән, җен алыштырып куйдымыни?! Сөйләшү, йөрү, күз карашым, кыяфәтем, тавышым – бары да үзгәрде. Акрын гына эндәшәм, кычкырып көлмим, җыелышларда ахырдан гына сөйлим. Хәтта хатын да, миндә үзгәреш сизеп, иртән ашарга әзерли башлады...

«Галстук» астына «сам» белән икәү генә җибәрәбез. Өч кеше булса, кем «сатканын» белеп булмый, ди хуҗа.

Мин сатмыйм. Тырышып эшлим. Ял көне дип тормыйм, эш урыныма барып, газета-журналлар булса да укып кайтам.

Күрделәр. Хуҗа итеп күчерделәр.

Шәхси тормышны җайга салмыйча, тыныч күңел белән яшәп булмый: йортын да, машинасын да яңарттым. Башка вак-төякләрен әйтеп тә тормыйм.

Көнләштеләр, сөйләделәр, тикшерделәр. Кесәләрне бутагансың, дип, икенче хуҗалыкка күчерделәр. Мин каршы килмәдем.

Тора-бара дөньялар тагын көйләнде. Поши атарга дәүләт машинасы белән йөрим. Халык арасында сүз чыккан: имеш, минем малай мәктәпкә импортный кием белән йөри; имеш, хатын кунакка иномаркада...

Сөйләсеннәр. Хәзер демократия. Кеше сөйли дип, минем япон телевизоры күрсәтүдән, магнитофон уйнаудан туктамас, аларның озын-озак гарантиясе бар.

Әлбәттә, нәфсенең чиге юк. Тик нәфсене чикли торган оешмаларда эшләүчеләрнең дә нәфесе барын онытмаска кирәк. Алар арасында тамагы бик туймаганнары да була – әнә бит, мине тагын тикшерә башладылар.

Тикшереп нигә вакыт әрәм итәргә? Һич аңламыйм! Нервыда уйнамыйча гына, туп-туры әйтсеннәр! Мин бит өченче хуҗалыкка күчәргә дә риза...

*Апрель, 1991 ел*

## Яшәсен – Мин!

Җитәкче урыннарда эшләү өчен миңа әлләни акыл да, белем дә кирәк булмады. Гәүдәгә накыслык* та карьерага зыян сала алмады. Иң мөһиме, усал кыяфәткә кереп үтәли карау, тавышның калын һәм көчле булуы, кирәкле сүзне урынында һәм кешесенә карап әйтә белүем адым саен файда китерде.

Безнең халыкта «Сакланганны саклармын», дигән гыйбарә бар бит. Мин моны бервакытта да онытмадым, сакландым: салкын аракы, бозлы сөт эчмәдем. Тамакка даими күнегүләр ясадым. Аның гади юлы шул: кул астында эшләүчеләрне кабинетка җыям да сәгатьләр буе нотык тотам. Бу – минем төп эшем. Дөньяның буталган чагы, ни сөйләсәң дә ярый. Соңгы вакытта хөкүмәтнең тетмәсен тетәм. Хәзер кемнең дөреслеген берәү дә төшенми, белергә дә теләми.

*Накыс (*диал.*) – кече.

Чыгышны иплəп, йомшак кына итеп башлыйм. Тавышны шундук көчәйтсәм, карлыгуы ихтимал. Тамак җылынгач кына, полный ходка җибәрәм. Үзебезнең оешма эчендәге кимчелекләрдән башлыйм да чит илнекеләрне искә алганда, тавыш үзеннән-үзе кабарып, калынаеп, көчәеп китә. Шөкер, белем җәмгыятенең шәрәфле лекторы дигән таныклык тоттырдылар.

Кайбер исәрләрнең икешәр дипломы бар. Акыллы кешегә аның берсе дә җитә...

Гомеремнең иң рәхәт көннәре колхоз рәисе булып эшләгән чакка туры килде. Сәкинә әбинең өй түбәсен шифер белән яптырып, тәрәзәләренә пыяла куйдырган идем, алдан планлаштырып эшләгәнчә килеп чыкты. Озак та тормыйча, карчык гүр иясе булды. Аның өен балалар бакчасы иттек. Минем бу хезмәтемне билгеләп, «Атказанган укытучы» исеме бирделәр.

Клубның түшәменә терәү куйдырып, сарык торагы төзүдән калган вак-төяк белән сипләп, тыштан буяткан идем... Бу хезмәтем дә игътибардан читтә калмады. «Атказанган мәдәният хезмәткәре» исеме белән зурладылар.

Авылны төзекләндерүгә дә игътибар бирдем. Үземә алты почмаклы йорт, мунча, гараж салдырдым. Ике катлы итеп идарә бинасы төзеттем. Алдына тимер-бетон плитәләр җәйдердем, идарәгә килү сукмагының як-якларына агачлар утырттырдым... «Атказанган төзүче» исемен алдым...

Сыер тотудан да уңмадык, ни итләре, ни сөтләре юк ул хайваннарның. Терлекләр өчен әзерләнгән азыкның иң күбе шуларга китә югыйсә. Дуңгызлары да киребеткән чучка булып чыкты. Үз балаларын да рәтләп карамыйлар, кешегә салыналар. Сарыклар да ышанычны акламады. Җәй буе кәнтәйләнеп йөрсәләр дә, без көткән үрчемне бирмәделәр. Тавыклар да тибенүдән башканы белмиләр. Хет берәрсе йомырка салу турында уйласа иде. Чолыкчылыкка күчәрбез – «Атказанган умартачы» исемен аласым килә...

Шулай өметләнеп тора идем. Дөньяның асты өскә килде. Үзгәртеп корулар башланды. Мине дә үзгәртерләр, дип, бик нык хафаландым. Әмма борчылуларым юкка булды. Әнә, абзагызны район хакимиятенә чакырталар! Үземне ни көткәнен беләм... Икенең берсе булыр: йә үстерәләр, йә хуҗалыкка күчерәләр...

*Июль, 1993 ел*

## Эш кирәк иде бит

Мине эшсез калдырдылар. Кыскартуга эләктем. Базар мөнәсәбәтләренә күчү заманасы бит. Гаҗәпләнәсе юк – илдә ничәмә-ничә завод-фабрика туктап калган, хәзер эшсезләр белән дөнья тулы.

Ә шулай да эшләргә кирәк. Пенсиягә чыгу өчен стаж туплыйсы бар. Оешмадан-оешмага чабулыйм, үземнең дипломлы белгеч икәнлегемне дә җиткерәм, хезмәткә намуслы карау галәмәтенең канга сеңгәнлеген дә әйтәм, тәртип ягының да үрнәк дәрәҗәдә икәнлеген сөйлим. Тыңлыйлар. Минем борчуны аңлаганнар да кебек, хәлгә керәселәре дә килгәндәй тоела, тик ярдәм кулы сузучы юк. Кайсы ишекне шакыма: «Синең белгечлек буенча бездә урын юк», – дип кырт кистерәләр.

Элек бергә эшләгән якын танышымны очраткан идем, минем хәлгә керергә теләп, үз киңәшен бирде:

– Син белгечлегең буенча беркая урнаша алмассың хәзер. Андый штатларны тутырып бетергәннәр инде... – дип сүз башлаган иде, мин шундук бүлдердем:

– Ничек тутырсыннар? Минем һөнәрдәге кешеләр районда санаулы гына.
– Санаулы булсагыз да урын юк. Хәзер дипломлылар урынын тулыр-тулмас урта белемле туган-тумача, дус-иш белән шыплап тутыралар.
– Минем кебекләргә нишләргә кала инде?
– Иң кулае – каравылга урнашу. Анда хезмәт хакы инженерныкыннан да күбрәк. Мин капка каравылчысы кирәк, дигән бер контораны беләм, шунда сугылып кара, – дип киңәш итте танышым. – Директорын бюрократның бюрократы, диләр, артыңны-алдыңны уйлап сөйләш, – дип тә өстәде.
Ярый, мин әйтәм, бюрократлык галәмәте коммунистлар арасында да, капиталистлар арасында да киң таралган күренеш. Күнеккән инде без аңа. Капка каравылчысына бюрократның сөрәсе[**] әлләни тимәс, дип киттем танышым әйткән конторага.
Гариза язып керттем. Кадрлар бүлегендә утыручы кызлар мәсьәләне тиз хәл иттеләр. Гаризага кул куйдырып чыктылар да, приказ язып, мөһер суктыргач кына, директорга керергә куштылар.
– Абзый, эшкә алындыгыз, хәзер директор сезнең белән әңгәмә үткәрергә тели, – диделәр.
Менә әкәмәт! Капка каравылчысын да санлыйлар икән бираедә! Түрә үзе аның белән гәп кора. Кердем кабул итү бүлмәсенә. Чират көтәм секретарь янында – сокланырлык чибәр кыз. Сайлый беләләр түрәләр матурларны. Модный журнал тышына төшерелгән гүзәлкәйләргә биргесез бу бала.
Кызга сокланып озак утырырга туры килмәде, телефон шалтырады. Секретарь төрепкәне тыңлагач, миңа директор кабинеты ишегенә таба ымлады.
Кердем эчкә. Бюрократ дигәннәре ыспай кыяфәттәге яшь кеше булып чыкты. Мөлаем гына каршы алып, урындыкка таба күрсәтте.
– Озак сөйләшеп тормабыз, эшнең тыгыз чагы. Шулай да иң мөһим мәсьәләләр буенча фикер уртаклашмыйча булмас. Синең төп бурычыңны төшендерәсем килә. Каравылчы ул, үзең беләсең, сакчы дигән сүз. Дефицит әйберләр күп бездә. Шуңа күрә каравылчыдан уяулык таләп ителә. Кергән-чыккан машиналарны контрольдә тотарга кирәк булачак. Рөхсәтсез әйбер алып чыгучыларны тикшерергә туры килер. Тик минем машина исәпкә керми. Баш инженерныкын да тикшереп торасы юк, минем урынбасарның, бүлек җитәкчеләренең машиналарын да туктатмассың. Склад мөдире Гатифә апа намазлы кеше, хилаф юлга басмый. Баш механик белән баш энергетикны да тикшереп торма.
– Ничек инде ул алай, – дим. – Тикшерергә машиналар калмый түгелме соң?
– Бигрәк әйбәт, сиңа эш җиңеләер, – ди ул, көлеп.
– Алай булмый, мин эшләмичә ашарга күнекмәгән, – дим.
– Менә нәрсә, әфәнде, – ди директор, җитди тонга күчеп, – кулың бик кычытып тора икән, мин сиңа йөк төяүче булып урнашырга киңәш итәм. Башка предприятиегә, әлбәттә, – дип көлеп куйды түрә үзенең тапкырлыгыннан канәгатьләнеп.
Һәм приказ белән гаризаны бөгәрләп, аяк астындагы кәрҗингә ыргытты.
Мин дә көлгәндәй иттем.

*Октябрь, 1995 ел*

**Зәет МОТАЛЛАПОВ,**
*Актаныш*

[**] Сөрә: сөрә карау (*диал.*) – караңгы чырайлы булу, маңгай астыннан карау.



# УЕНЫ-ЧЫНЫ БЕРГӘ

**Туфан МИҢНУЛЛИН**

## Минһаҗ маҗаралары

Рәсәйнең яңадан-яңа гимнын тикшереп утырабыз. Юк, безгә аның ничек язылганы, безнең өчен ярыймы-юкмысы кирәкми. Безгә ни җырласалар да барыбер.

Шулай да тикшерәбез. Бөтенесе дә тикшергәч, без генә кырыйда кала алмыйбыз, нәрсәне дә булса тикшерергә кирәк ич инде. Пенсияләрне дә тикшереп арыдык, президентларны да энәсеннән җебенә тиклем тикшердек, колхозны әйтеп тә торасы юк.

Гимн мәсьәләсен әлеге дә баягы Вәлиәхмәт абый башлады.

– Нигә атна саен гимн алыштырып торалар икән? – ди.– Хатын-кызның гына бүген әйткән сүзе иртәгә ярамый. Хөкүмәттә чүтеки ир-атлар утыра бит, – ди.

Тотындык инде шуннан тикшерергә. Барысы да үз белгәнен сөйли. Барысы да белә. Хәтта Садретдин да сүзнең ни турында барганын аңлады:

– Гимнның элеккесендә «нарушение» дигән сүз бар иде. Нигә ул сүз булды икән? Нарушение ул – тәртип бозу дигәнне аңлата бугай. Бригадир Нурәхмәт тә, берәр нәрсәне ул кушканча эшләмәсәң, фәләнеңне фәлән итим, нигә нарушение ясадың,– ди.

– Нинди нарушение? «Нарушение» дигән сүз югые элеккеге гимнда,– диде Вәлиәхмәт абый.

– Булмады ди сиңа «Саюз нарушение» дип җырлаганнарын сәгать алты саен үзем тыңлый идем.

Тәгәри-тәгәри, буыла-буыла, эчне уа-уа көлдек.

– Алла колы, гомерең буе урыс арасында яшәп урысча белмисең, – дидек Садретдинга. – «Саюз нарушение» түгел ул, «Союз нерушимый»! Мәңге җимерелми торган Союзны аңлата ул, мокыт.

Садретдин да бирешмәде:

– Мәңге җимерелми торган булгач, нигә җимерелде соң? Нарушение булганга җимерелгәндер бит, – диде.

Тагын көлештек. Минһаҗ абзый гына көлмәде.

– Маладис, Садретдин. Төп башына утырттың наданнарны, – диде. – Җимерелде шул менә, җимерелде. Нарушение булды шул, булды. Хәзер генә ялгышканымны аңладым. Хәзер менә үкенәм җимерешкәнемә.

– Нәрсәне җимерештең, Минһаҗ абзый, бер дә кыек эшеңне күргәнебез булмады, – дидек.

– Андый эшне күрсәтеп эшлиләрмени аны, – диде Минһаҗ абзый. – Харап итештем шул СыСыСыР дигән илне. Хәзер менә терсәк якын, тешләп булмый. Ташкенттагы дустым Кәримов янына, казакътагы ахирием Назарбаев янына да бара алмыйм. Юллар ябылды. Булды шул гаебем, булды.

– Бер дә сөйләгәнең булмады, Минһаҗ абзый, – диештек.

– Булмаса, сәбәбе булгандыр. Бөтен нәрсәне дә урамга чыгып кычкырып булмый бит. Мин бит сөйләмәскә сүз бирдем, кыягазга кул куйдым. Хәзер инде сөйләсәң дә ярый. Елсин дә юк, Кыраучык та юк, Шүшкәвич тә юк. Ә бит бергәләп җимердек СыСыСыРны.

*(Дәвамы бар)*

**БАТУЛЛА**

## Ачы торма

Ренат Харисны, «Казан утлары» журналыннан алып, обкомга эшкә күчерәләр. «Казан утлары»ның баш мөхәррире итеп Равил Фәйзуллин сайлана.

– Җә, Батулла агай, – ди Җәүдәт Миңнуллин. – Журналдагы үзгәрешләргә ничек карыйсың?

– Керән ачы тормадан баллырак булмый, – ди Батулла.

## Тәкъва

Бервакыт Батулла яшь хатыны Рузия ханым белән Аяз Гыйләҗев өенә кунакка килә. Чишенеп, түргә узгач, Батулла:

– Ягез, йортка бер фатиха, – дип дога кыла.

Шуннан соң Аяз Гыйләҗев дус-ишләренә болай дип әйткән, имеш:

– Батулла, ак оекбаш киеп, тәсбих тартып йөри башлаган. Унсигез ел марҗа әвәләп яткан димәссең, валлаһи, парин!

## Батулла керәшен икән

Батулла керәшеннәр турында язылган бер әсәреннән өзек укыган. Фәрит Җәләй белән Мөдәррис Әгъләм моны игътибар белән тыңлаганнар да, авторны хуплап, кулын кысканнар.

– Керәшен турында керәшен үзе дә болай матур язалмый, – дигән Фәрит Җәләй.

Мөдәррис исә:

– Син, Батулла, керәшен булып тугансың, керәшен булып язасың, керәшен булып үләрсең, ахрысы! – дип чыгып китә.

**Морад ДУСАЙ**

## Ләбиб Леронга

Бер дошманы юк – никадәр
Төртмә сүзләр, сатира,
Пародия язып та!

Кайбер шагыйрьләрнең имди
Нәкъ аның аркасында
Калуы бар тарихта.

Бер дошманы юк – никадәр
Ачы булса да сүзе.
Юк! –
Бар ич дошманы Ләбибнең!
Кем, дисезме? –
Ул... үзе!

*Сәхифәне* **Марсель ГАЛИЕВ** *әзерләде.*

# 2019 елда дини бәйрәмнәр һәм истәлекле көннәр

## МӨСЕЛМАН АЙ КАЛЕНДАРЕ БУЕНЧА 1440-1441 ҺИҖРИ ЕЛЛАР

**8 март** – Рәҗәб аеның беренче җомгасына каршы кич – Рәгаиб кичәсе дип атала. Мөхәммәд пәйгамбәрнең әти-әнисе Габдуллаһ һәм Әминәнең бергә кушылуын искә алу кичәсе дә.

**3 апрель** – Мигъраҗ кичәсе. Мөхәммәд пәйгамбәрнең Мәккә шәһәреннән Иерусалимга һәм аннан җиде кат күккә – Аллаһы Тәгаләнең тәхете янына кылган могҗизалы сәяхәте. Мигъраҗ уразасы 100 төн ураза тотуга тиңләнә.

**20 апрель** – Бәраәт кичәсе, ягъни «ләйләтул-Бәраәт». Бәхет һәм һәртөрле уңышлар, изгелекләр иңә торган изге көн. Нәкъ шушы төнне Аллаһы Тәгалә, һәркемнең изге гамәле һәм догаларында ялварып сораган үтенечләрен исәпкә алып, кешеләрнең язмышы турында карар кабул итә.

**5 май** – изге Рамазан ае һәм Ураза башланган көн.

**21 май** – Идел Болгарстанында Ислам динен рәсми рәвештә кабул иткән көн (310 нчы һиҗри, 922 нче милади ел).

**4, 5, 6 июнь** – Гайдел-фитыр. Ураза бәйрәме.

**10 август** – Гарәфә көне. Хаҗ кылучылар тарафыннан Мәккә янындагы Гарәфә тавына бару һәм тау итәгендә намаз уку көне.

**11 август** – Гайдел-Әдъхә, Корбан гаете. Мөселманнарның иң зур бәйрәме. Ураза тәмамлангач, нәкъ 70 көннән соң башлана торган Корбан чалу бәйрәме, ул 3 көн дәвам итә. Бу көн Татарстан Җөмһүриятендәге барлык календарьларда кызыл төс белән билгеләнгән.

**12, 13 август** – Тәшрикъ көннәре. Әлеге көннәрдә мөселманнар, фарыз намазларын укыганнан соң, Аллаһы Тәгаләне мактап, махсус сүзләр әйтәләр.

**30 август** – 1441 ел, яңа мөселман елы һәм Мөхәррәм ае башланган көн. Бу айда күп итеп хәер (зәкят) бирелә, изге гамәлләр кылына.

**9 сентябрь** – Гашура бәйрәме. Сөнниләр – Аллаһы Тәгаләнең ун пәйгамбәренә күндерелгән изгелекләре хөрмәтенә, ә шигыйлар, Мөхәммәд пәйгамбәрнең оныгы Гали хәлифәнең улы Хөсәенне (626-680) җәзалап үтерү көнен мөбарәк, изге вә хөрмәтле санап, ураза тота.

**26 октябрь** – Сәфәр ае башланган көн.

**8 ноябрь** – Мәүлид бәйрәме. Иң зур бәйрәмнәрнең берсе – Мөхәммәд пәйгамбәрнең туган көне. Әлеге изге бәйрәм нәкъ бер ай дәвам итә. Бу вакытта мәчетләрдә вәгазьләр укыла, хәер, садака (зәкят) өләшенә. Күп кенә мөселман илләрендә факеллар һәм фонарьлар кабызып, тантаналы мәрәсимнәр уздырыла.

*Төзүче-мөхәррир –*
**Хаҗи Абдулла ДУБИН**

## «Татмедиа» акционерлык җәмгыятенең филиалы» «Казан утлары» журналы редакциясе ТАССРның 100 еллыгына багышлап иң яхшы әдәби очеркка конкурс игълан итә

Конкурсның темасы – «Татарстан. Тарих. Шәхесләр».

Конкурсның максаты – очерк жанрын үстерү, рухи кыйммәтләрне, патриотизм хисләрен пропагандалау, республикабызда телләрне саклау һәм үстерү, яңа авторларны табу, алар белән хезмәттәшлек итү.

Конкурс **2019 елның 1 гыйнварыннан 2019 елның 15 декабренә кадәр** үткәрелә. Татар телендә язылган, моңарчы беркайда басылмаган очерклар гына кабул ителә. Аларның күләме А4 форматында 15 биттән дә артмаска тиеш.

Конкурста катнашучылар үзләренең эшләрен электрон почта аша җибәрергә яки «Казан утлары» журналы редакциясенә электрон вариантын китерергә тиеш.

Очерклар 10 баллы система белән бәяләнә, аларның әдәби һәм сәнгатьчә эшләнеше, сюжет, өслүб үзенчәлеге, композиция төзү осталыгы исәпкә алына.

Конкурста җиңүчеләр «Казан утлары» журналының баш мөхәррире раслаган жюри әгъзалары тарафыннан 2019 елның 20 декабрендә игълан ителә. Җиңүчеләргә – премия:

**I урын – 15 000 сум (бер премия).**

**II урын – 10 000 сум (бер премия).**

**III урын – 7 000 сум (бер премия).**

**Кызыксындыру премияләре – 3 000 сум (өч премия).**

Җиңүчеләргә дипломнар бирелә.

Яхшы әсәрләр «Казан утлары» журналында басылачак.

Конкурс турында мәгълүматлар – «Казан утлары» сайтында: www. kazanutlary. ru; «В контакте»: vk.com/feed#qazanutlari

# ХУШЛАШУ СҮЗЕ



Сәкинә гарәпчәдән «тынычлык», «сабыр холыклы» дип тәрҗемә ителә. Төрек телендә дә шул мәгънәгә якын бер сүз бар – «сакын», «сак бул» дигәнне аңлата ул. Чыннан да, Сәкинәнең ата-анасы, исем кушканда, кызларының сабыр холыклы, тыныч хәрәкәтле булуын теләгәннәрдер. Исеме җисеменә туры килә.

Кыз кешенең гомер сызыгы менә шуннан гыйбарәт ки: сабый кыз, йөргән кыз, кәләш, килен, хатын, ана, каенана, әби. Кыз булып дөньяга килгән җан иясе әлеге дәрәҗәләрне намус белән узарга тиеш.

Дөресе шулдыр ки: Сәкинә ханым сабый чакта тәртипле, итагатьле кыз булган. Ул «матур кәләш» сынавын да узды. «Яхшы килен» дә булды, тугры хатын йоласын да җиренә җиткезеп яшәде. Каенана буларак та киленнәренә ярдәмчел, киңәшче була белде. Әби дәрәҗәсенә җитте, анысын да намус белән башкара килде. Сәкинә ханым чын татар кызы, чын татар хатыны, чын татар әбисе икәнен бөтен халык алдында исбат итте.

Бөтен хатын-кызларга да: «Менә, татар хатыны нинди булырга тиеш! Сәкинә ханым күпләргә үрнәк», – дип әйтсәсе килә. Ул татар халкының сөенече, бәхете иде. Шөкер! Сәкинә ханымга чиксез рәхмәтләребез!

Җәмәгать урыннарында күренсә, Сәкинә ханымны халык сырып ала, театрның тамаша залына килеп керүгә үк, тамашачы аягүрә баса, аны озак алкышлый торган иде. Ихлас ханымга ихлас алкышлар иде ул кул чабулар.

Берәү дә Сәкинәне: син олы урында утыра торган кешенең хатыны булачаксың, дип тәрбия кылмагандыр. Президент хатыннары кеше алдында үзен ничек тотарга тиеш, дигән дәресләр дә алмагандыр ул, әмма Сәкинә ханым Илбашы хатыны була белде. Тыйнаклыгы, иреннән алда сүз башламавы, мөлаем елмаюы, үзенә килешеп тора торган нечкә зәвык белән киенүе бөтен дөнья президентлары хатыннарына үрнәк булып тора иде.

Каян килә бу мәгънә?! Казанда туса да, Сәкинә авылда халкыбызның йолаларында тәрбия алган. Ул, һәр форсат чыккан саен, ата-анасының туган авылына – Шәлегә кайта торган иде. Авыл кызларына кушылып эшләү, бәйрәмнәргә авылча киенеп чыгу, җырлар-такмаклар башкару, печән чабу, җиләк җыю – боларның барысы да күзәтүчән кызның колагына, күңеленә, зиһененә сеңеп калган. Сабый чактагы бу күренешләр гомер буена сузылып бара, ул тәрбия искерми дә, тонокланмый да.

Сәкинә ханым белән Минтимер әфәнденең икесенең дә күңел күзләре ачык булганга, бер-берсен табышкан да инде. Табышканнар да үрнәк гаилә корганнар!

Кызганыч ки, Сәкинә ханым күптән түгел якты дөньядан китте. Барыгызның да, бигрәк тә Минтимер аганың һәм аның гаиләсенең кайгысын уртаклашам!

Авыр туфрагың җиңел булсын, Сәкинә ханым! Урының җәннәттән әйләсен!

**Рабит БАТУЛЛА**
*2018, 23 ноябрь*

**Редакциядән:**
Хатыны Сәкинә Шакир кызының вафат булуы сәбәпле, Татарстан Республикасының Беренче Президенты, Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәрип улы Шәймиевнең һәм аның якыннарының авыр кайгысын уртаклашабыз.

# 2018 елда «Казан утлары» журналында басылган әсәрләр исемлеге


**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЛАРЫ**

Шиһабетдин Мәрҗанинең тууына 200 ел тулуны бәйрәм итү турында. №1

2018 елда Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләкләрен бирү турында. №5

**БАШ МӨХӘРРИР СҮЗЕ**

Ибраһимов И. Яңа 2018 ел белән! №1

**ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР**

Ахир. Кыргый алмагач. *Повесть*. №11

Әмирханов М. Зиннәтулла хәзрәт. *Бәян*. №4

Әхмәтгалиева А. Ак читек. *Бәян*. №№2, 3

Батулла Р. Китек күңел. *Бәян*. №3

Бәдигый Х. Җиләк чиләге. *Маҗаралы бәян*. №1

Бәйрәмова Ф. Гөләйза. *Тарихи роман*. №№7-9

Булатова Д. Соң түгел! *Повесть*. №4

Вәлиева Р. *Хикәяләр*. №6

Галиуллин Т. Татар әреме. *Хикәя*. №5

Горький М. Лев Толстой. *Язмалар. (М.Галиев тәрҗемәсе)*. №3

Гыйльманов Г. Алтын басуы. *Хикәя*. №7

Гыйльметдинова Ф. *Хикәяләр*. №7

Гыйматдинова Н. *Хикәяләр*. №6

Даутов Г. Генерал. *Хикәя*. №5

Җамалетдинова Ф. Адаштырма, буран... *Повесть*. №8

Зыятдинов Ф. Әгәр дә бу кеше вафат булса... *Новелла*. №9

Ибраһимова Л. Айзидә. *Хикәя*. №12

Исмәгыйлев Х. Әфган тауларын кичеп... *Повесть*. №7

Камал Х. Каһәр. *Роман*. №№5, 6

Кара К. Депрессия. *Фәлсәфи повесть*. №4

Маликова М. Татлы гыйшык җимеше. *Хикәя*. №9

Мөхәммәдиев Р. Аязучан болытлы һава... *Хикәя*. №3

Нуриев В. Кышның озын бер төне. *Сатирик бәян*. №1

Нуриев В. *Хикәяләр*. №8

Хәлим А. Читтә. *Хикәя*. №4

Хәмзин А. Шәрәфи – «хи-хи» түгел... *Кинаяле тамаша*. №12

Хуҗи Р. Карт кыз. *Юмористик хикәя*. №5

Хуҗин Ф. Сугыш күләгәсендә. *Повесть*. №5

Шәмси С. Кендек каным тамган йорт... *Бәян*. №2

Юныс М. Кыпчак кызы Аксанә. *Роман*. (*Р.Рахманиның кереш сүзе белән)*. №№10-12

**ШИГЪРИЯТ**

Аймәт Р. Ятлар салган юлдан бармадым мин... *Шигырьләр*. №10

Әхмәтҗанова С. Татар кыйтгасының сагында. *Шигырьләр*. №1

Батталова Г. Рәшә иде ерак дәвердән. *Шигырьләр*. №3

Бәйрәмова Г. Моң ул бездә тумыштан. *Шигырьләр*. №2

Бәшәр Р. Алда – биек тау түбәсе... *Шигырьләр*. №6

Булатова К. Төзәтәсе иде дөньясын. *Шигырьләр*. №1

Габделхакова Р. Җыйдым бәхет тамчысын... *Шигырьләр*. №6

Габдерәхим Ф. Намуска тимәсеннәр. *Шигырьләр*. №1

Газизова Л. Сөенүләрен телим. *Шигырьләр*. *(И.Иксанова тәрҗемәсе)*. №2

Галиев М. Мәңгелекнең бер мизгеле... *Шигырьләр*. №6

Гарифуллина Р. Ай нурында энҗе яна. *Шигырьләр*. №4

Гәрәева С. Каныбызда – ана телебез... *Шигырьләр*. №11

Гыйбадуллина Л. Аннары – мәңгелек сагыну... *Шигырьләр*. №5

Гыйләҗев Ф. Ефәк юлы чатында. *(Төркестан дәфтәреннән). Шигырь*. №7

Идиятуллин Р. Дөньялыкта кылган сәфәрем... *Шигырьләр*. №9

Иксанова И. Таулар миңа – йөрәк ярасы... *Шигырьләр*. №12

Иматдинов Ш. Үкенерлек яшәмәдек бугай... *Шигырьләр. (Р.Зәйдулланың кереш сүзе белән)*. №12

Латыйп Х. Иделгә таулар да иелә... *Шигырьләр*. №8

Миңнуллин Р. Бар иде гаярь заманнар... *Шигырьләр*. №8

Мирза М. Бакы – кубарык җил. *Поэма*. №5

Морат Г. Гел үткелдән үтеп йөрмешебез... *Шигырьләр*. №10

Мостафин Ш. Үлемсезлек җыры өзелмәс. *«Багышлаулар» дәфтәреннән. Шигырьләр*. №2

Мөдәррисова Х. Галәмнәргә чаклы агыла. *Шигырьләр*. №4

Мөхәммәтша Р. Актарыла тарих, хатирәләр... *Шигырьләр*. №8

Низами Р. Безнең Тукай. *Шигырь*. №4

Рахман Р. Очар кошлар холкы миндә... *Шигырьләр*. №8

Рәхим Г. Мин – мине югалттым... *Шигырьләр*. №9

Сабиров И. Без – милләтнең ерак илчеләре... *Шигырьләр*. №7

Сәлах Р. Җилләр исә кыйбла ягыннан... *Шигырьләр*. №6

Солтан Ф. Тоясы килә яңгыр тамчысын... *Шигырьләр*. №9

Сөләйман Ж. Кояш нурларына сыена. *Шигырьләр*. №3

Суфиянов А. Өзелмәсме милли шәҗәрә? *Шигырьләр*. №3

Тукай Г. Алла гыйшкына. *Шигырь*. №7

Фатыйхов В. Булу кирәк бергә үзәктә. *Шигырьләр*. №1

Фәйзуллин Р. *Публицистик шигырьләр*. №2

Фәттахова Л. мәсәлләрдән гөләндәм. №10

Хәйруллин Д. Бер төзегән гомер буе төзер... *Шигырьләр*. №12

Хисамов Н. Һәр акыллы җанда чыңлыйдыр саз... *Шигырьләр*. №11

Шәех Л. Тынычлыкка сусау. *Шигырь*. №5

Шәмсуаров Т. Җыры барның – чиксез гомере! *Шигырьләр*. №5

Шәрипов Р. Эт урамы. *Поэма*. №4

Шәрифуллина Э. Сүз – әҗәлгә дару да... *Дүртьюллыклар*. №10

Якупова С. Карашымда хөрлек чагыла... *Шигырьләр*. №7

Яруллин Ф. Яңа елга иске теләк. *Шигырь*. №1

**ДРАМА ӘСӘРЛӘРЕ**

Салихов Д. Мөхәммәт. *Драма*. №10

Хәким З. Тәрәзәдә һаман ут яна. *Бер пәрдәле драма*. №3

**ПУБЛИЦИСТИКА**

Әхмәтгалиева Г. Туган җирдә – канатлылар... *Очерк*. №1

Гарипов А. Язмыш сынауларына бирешмичә. №5

Имамиева А. Гамәлләрендә – кылыч ныклыгы. №7

Мирза М. Җаннан бүленгән кыйтга. *Эссе*. №1

**«ХӘЗИНӘ» ӘДӘБИ КОНКУРСЫ**

Абдуллин Ф. Кемгә сөйлим серләремне... *Повесть*. №11

Бәдретдинов И. Кыргыч. *Хикәя*. №8

Галиуллин Т. Ник керәсең төшләремә? *Хакыйкый бәян*. №7

Гәрәева-Акчура А. Төркиянең беренче нефтьчесе – татар. *Документаль бәян*. №10

Зарипов Ә. Күпер. *Повесть*. №9

Рәхим Г. Тау хуҗасы. *Хикәя*. №8

Солтанова Г. Факел. *Хикәя*. №5

Хәсәнов А. Кәҗәкәй – матур бәләкәй. *Хикәя*. №10

Шаһиев Р. Аяк ялы. *Хикәя*. №6

Яхин Ф. Яз яме белән бергә. *Повесть*. №12

**«ИҢ ШӘП ХИКӘЯ» КОНКУРСЫНА**

Җамалетдинова Ф. Кирлемән. *Хикәя*. №2

**ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ**

Галимуллин Ф. Гафур Коләхмәтовка ике төрле караш. №4

З а һ и д у л л и н а  Д. «Бүркем икәү...» *(«Поляк-татар» әдәбияты турында уйланулар)*. №3

М а н с у р о в  З. Йөрәккә сыйган дөнья. №6

М а н с у р о в  З. Җанны көйгә салу. №9

Х ә м и д у л л и н  Л. Туплар гөрселдәгәндә туган шигырьләр *(Мәхмүт Хөсәеннең тууына 95 ел)*. №6

**ТАРИХ**

Әхмәдһади Максуди мәкаләләре *(Ленар Гобәйдуллинның кереш сүзе белән)*. №9

Г ы й л ә җ е в  И. XX йөз башында татарларның Европага карашы: яңа перспектива эзләү. №8

**СӘНГАТЬ**

З а р и п о в  Ә. Иркә иркәләми шул... №8

И м а м и е в а  А. «Милли үзаң булмаса, үсеш тә юк» *(Татарстанның халык, Россиянең атказанган артисты Айдар Хафизов белән әңгәмә)*. №5

*Редакция котлавы:* Рауза Хәйретдиновага 90 яшь; Ринат Тажетдиновка 80 яшь; Нәҗибә Ихсановага 80 яшь. №1

**ЯҢА ИСЕМНӘР**

А й д а р о в а  Ф. Мин очышка әзер... *Шигырьләр*. №11

Ә г ъ л ә м е т д и н о в  Р. Чат. *Хикәя*. №9

Б а й м ө х ә м м ә т о в  А. Әкиятсез балачак. *Повесть*. №10

В ә л и ш и н а  Л. Җиңү язы килгәндә... *Хикәя*. №6

Г а л и е в а  А. Киләчәккә атап. *Фантастик хикәя. (М.Закирның кереш сүзе белән)*. №4

Г а н и е в  Н. Ил бетмәсә, бетмәс телем дә... *Шигырьләр*. №12

Л а т ы й п о в  Р. Кытай елгасы. *Хикәя*. №8

С а б и т о в а  З. Таныш кешем. *Хикәя*. №11

Т и м е р г а л и е в  З. Сәмига. *Бәян*. №1

Х и с а м и е в а  А. Кайтаваз кабатлый үткәннән. *Шигырьләр*. №3

Ш ә й д у л л и н а - М у р а т  Р. Күзләрдән юату эзләмә... *Шигырьләр*. №9

**ҖӘҺӘТ ТӘНКЫЙТЬ**

Айгөл Әхмәтгалиева. «Ак читек». №3

Дилбәр Булатова. «Соң түгел». №4

Лилия Гыйбадуллина. Шигърият. №5

Рифат Сәлах шигырьләре. №6

Фәнил Гыйләҗев. Шигърият. №7

Рүзәл Мөхәмммәтша шигырьләре. №8

Райнур Әгъләметдинов. «Чат». №9

Лилия Фәттахова. Мәсәлләр. №10

Зилә Сабитова. «Таныш кешем». №11

Нурлан Ганиев. Шигърият. №12

*(Сәхифәне Д. З а һ и д у л л и н а  алып бара.)*

**ТУКАЙ ҺӘМ ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ**

Р а х м а н  Р. Тормышыма Тукай килеп керде... №4

Р а х м а н  Р. «Ил капкасын кагам...». №11

**ГАБДУЛЛА ТУКАЙ ИСЕМЕНДӘГЕ ДӘҮЛӘТ ПРЕМИЯСЕНӘ КАНДИДАТЛАР**

Ә х м ә т г а л и е в а  А. «Кеше бәясен халкы билгели...». *Очерк*. №4

Г а ф ф а р  Ә. Киләчәктән кайтып килешли. *Хикәя*. №4

Х а н н а н о в  Р. «Яшәлгәнен яза торам...». №3

**ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ – ДӨНЬЯ КИҢЛЕГЕНДӘ**

Дөнья – иксез-чиксез симфония... *(Н.Измайлова, А.Нургатина, К.Таңгалычев, И.Биектаулы, Ш.Шахмаев, Ф.Дәүләтгәрәева, Р.Насыйбуллин, Ә.Әскәров, Р.Шәфигуллин, Э.Кәримова, Г.Исхакова шигырьләре)*. №7

**ДӨНЬЯ ХАЛЫКЛАРЫ ӘДӘБИЯТЫ**

Г а л г о ц и  А. Язга таба. *Хикәя*. *(Р.Зәйдулла тәрҗемәсе)*. №3

В о н н е г у т  К. Гомерлек сәйран. Сәлам, Җирән! *Хикәяләр*. *(Р.Мөхәмммәтша тәрҗемәсе)*. №12

**КАРДӘШ ХАЛЫКЛАР ӘДӘБИЯТЫ**

Д о д у е в  Ә. Таш сыртында бүген утырам мин... *Шигырьләр*. №11

И с к ә н д ә р  Ф. Әтәч. *Хикәя*. *(Р.Бәшәр тәрҗемәсе)*. №8

Х а р л а м п ь е в а  Н. Җан яктысын яудыра. *Шигырьләр*. *(Якутчадан Л.Шәех тәрҗемәсе)*. №5

Якут риваятьләре.*(М.Вәлиев тәрҗемәсе)*. №4

**ӘДӘБИ ХӘЗИНӘЛӘРЕБЕЗ**

А л и ш  А. Тоткынлыктан кайткан шигырьләр. №9

М ө х ә м м ә т җ а н о в а  Л. Дастаннар ватаны син, Себер! №7

**ТОРМЫШ ЯЗГАН ХИКӘЯЛӘР**

Нуриев В. Хикәяләр. №4

**ТАТАР ХИКӘЯЛӘРЕ ХӘЗИНӘСЕННӘН**

Латыйфи Ф. Аяклы каза. *(Камил Кәримовның кереш сүзе белән)*. №6

**ШИГЪРИ ХӘТЕР**

Галиев Ш. Саумысыз, арышларым! *Шигырьләр*. №11

Закиров Р. Безнең балачак. *Шигырьләр*. №6

Сафин Ф. Сез кемнәр? *Шигырьләр*. №6

**ГАМЬЛЕ ӘҢГӘМӘ**

Гомер буе укый укытучы... *(Арча педагогия көллияте директоры Гөлнара Гарипова белән Вакыйф Нуриев әңгәмәсе)*. №1

Кайда да йөрәктә *(Кентау шәһәрендәге «Татар-башкорт» милли оешмасының җитәкчесе Фәрит Әюпов белән Илфак Ибраһимов әңгәмәсе)*. №1

«Нәккаш – бизәк остасы ул...». *(Нәҗип Нәккаш белән Айсылу Имамиева әңгәмәсе)*. №7

**МӨГАЛЛИМ МӨНБӘРЕ**

Төхфәтуллина Ә. Язучы дәрес бирә. №1

Фәхретдинова А. Халык авыз иҗаты – миллилекнең башы. №3

**100 нче БИТ**

Ахунҗанова Р. Тукайның «Туган тел»е. *Шигырь*. №4

Батулла Р. ...биздергән дә тел! №3

Галиев М. Нинди язмышка дучар без? №2

Зәйдулла Р. Яңа ел бит! *Шигырь*. №1

**ЮБИЛЕЙЛАР**

ТАҖЕТДИН ЯЛЧЫГОЛНЫҢ ТУУЫНА – 255 ЕЛ

Гарифуллин Д. Табышмаклы гомер иясе. №7

ШИҺАБЕТДИН МӘРҖАНИНЕҢ ТУУЫНА 200 ЕЛ

Гобәйдуллин Л. Ташкичүнең олуг абызлары. №1

Дәминова Ф. Остазлар остазы. №1

Мәрҗани сабаклары. *Рабит Батулла тупламасыннан*. №1

ГАЗИЗӘ СӘМИТОВАНЫҢ ТУУЫНА 155 ЕЛ

Зәйдулла Р. Милләт Газизәсе. №2

МАКСИМ ГОРЬКИЙНЫҢ ТУУЫНА 150 ЕЛ

Галиев М. Бөек әдип. №3

ГАЯЗ ИСХАКЫЙНЫҢ ТУУЫНА 140 ЕЛ

Фазлетдинов И. Исхакыйның геройлар эволюциясе. *(Мәгърифәтчелек чоры)*. №2

ХУҖА БӘДИГЫЙНЫҢ ТУУЫНА 130 ЕЛ

Шаһиев Р., Гариф Н. Хуҗа Бәдигый һәм аның нәсел-нәсәбе турында яңа табышлар. №12

ФАТИХ ХӨСНИНЕҢ ТУУЫНА 110 ЕЛ

Диндаров И. Бер күрешү. №2

АЯЗ ГЫЙЛӘҖЕВНЕҢ ТУУЫНА 90 ЕЛ

Хәбетдинова М. Татар сәхнәсендә – Аяз Гыйләҗев прозасы. №1

ГӨЛШАТ ЗӘЙНАШЕВАНЫҢ ТУУЫНА 90 ЕЛ

Ханнанов Р. Китмә, сандугач!.. №1

НУРИХАН ФӘТТАХНЫҢ ТУУЫНА 90 ЕЛ

Имамов В. Татар илле Нурихан. №10

Фотоархив. Нурихан Фәттах тормышыннан мизгелләр. №10

РӘИС ДАУТОВНЫҢ ТУУЫНА 90 ЕЛ

Тарханова Ф. Мин аларга мең-мең рәхмәтле! №3

ШӘҮКӘТ ГАЛИЕВНЕҢ ТУУЫНА 90 ЕЛ

Фотоархив. Шәүкәт Галиев тормышыннан мизгелләр. №11

ШӘҮКӘТ БИКТИМЕРОВНЫҢ ТУУЫНА 90 ЕЛ

Фотоархив: Титаннар гасыры. *Рәйсә Юсупова әзерләде*. №12

БУЛАТ СӨЛӘЙМАНОВНЫҢ ТУУЫНА 80 ЕЛ

Сәйфуллина Ф. Туган як моңы... №5

ШАМИЛ МАННАПОВНЫҢ ТУУЫНА 80 ЕЛ

Вәлиев М. Кечкенә әзи – зур абыем. №1

ФӘНИС ЯРУЛЛИННЫҢ ТУУЫНА 80 ЕЛ

Гаташ Р. Халыкның сөекле шагыйре. №2

Миннекаева Д. Фәнис Яруллин драматургиясендә әхлак тәрбиясе. №2

Хәбипов Н. Яшәүгә мәдхия тудырган шәхес. №2

Хәкимова С. Әдип иҗатына бер караш. №2

Яруллин Ф. Анам теле – телләр теле. *Шигырьләр*. №2

**КОТЛЫЙБЫЗ!**

ЛОКМАН ЗАКИРГА 90 ЯШЬ

Рабит Батулла мәкаләсе. №2

МАРАТ ӘМИРХАНОВКА 85 ЯШЬ

Миңнегулов Х. Әдәбиятыбызның әмир-ханнарыннан берсе. №4

ХУҖИӘХМӘТ МӘХМҮТОВКА 85 ЯШЬ

Мөхәммәтҗанова Л. Сүзе хакның – йөзе ак. №2

ЗӨФӘР РӘМИЕВКӘ 80 ЯШЬ

Закирҗанов Ә. Хакыйкать эзләү юлында. №6

ИЛИДА БӘШИРОВАГА 80 ЯШЬ

Миңнуллин Б., Сәгъдиева Ф., Мирхаев Р. Фәнне галимнәр үстерә... №11

РАБИТ БАТУЛЛАГА 80 ЯШЬ

Ибраһимова С. Сокланам! Шаклар катам! №3

РҮЗӘЛ ЮСУПОВКА 80 ЯШЬ

Хуҗин Ф. Гали зат. №9

ТӘЛГАТ ГАЛИУЛЛИНГА 80 ЯШЬ

Заһидуллина Д. Әдәбиятның йөрәк тибешен тоеп... №7

РАВИЛ ФӘЙЗУЛЛИНГА 75 ЯШЬ

Фәйзуллин Р. Язсам гына, яшәвемне раслыйм... *Шигырьләр*. №8

Шигъриятле тормыш юлында. №8

Фотоархив. Равил Фәйзуллин тормышыннан мизгелләр. №8

РӘФИКЪ ЮНЫСКА 75 ЯШЬ

Юныс Р. Җитәрбез иң ерак чорларга. *Шигырьләр*. №3

Язмыш мизгелләре. Р.Юныс фотоархивыннан. №3

ИСЛАМ ӘХМӘТҖАНОВКА 70 ЯШЬ.

Әхмәтҗанов И. Әйткән сүз... №4

Вәлиев Р. Синең язмыш язга охшаган. *Шигырь*. №4

РОБЕРТ МИҢНУЛЛИНГА 70 ЯШЬ

Бикбаев Р. Тантанадан хәтер яңара. №8

РИНАТ МӨХӘММӘДИЕВКӘ 70 ЯШЬ

Фотоархив: Ринат Мөхәммәдиев тормышыннан мизгелләр. №12

ШАҺИНУР МОСТАФИНГА 70 ЯШЬ

Имамов В. Рәхмәтле каләмдәшем. №2

ВАКЫЙФ НУРИЕВКА 60 ЯШЬ

Ханнанов Р. Ни хәлең бар, Вакыйф абый?.. №8

ДАНИЛ САЛИХОВКА 60 ЯШЬ

Сәгъди Р. Каләм алса – уй салыр! №10

ФӘҮЗИЯ СОЛТАНГА 60 ЯШЬ

Хисамов Н. Хисләремдә ирекле мин... *(Фәүзия Солтан шигъриятенә күзәтү)*. №9

ХӘБИР ИБРАҺИМГА 60 ЯШЬ

Зәйдулла Р. Кызган күмер. №11

ГӨЛЗАДӘ БӘЙРӘМОВАГА 55 ЯШЬ

Шәрипов Р. Шигырьләре – гомер мизгелләре. №2

БУЛАТ ХӘМИДУЛЛИНГА 50 ЯШЬ

Имамов В. Тарихи каек иясе. №8

РӘМИС АЙМӘТКӘ 50 ЯШЬ

Заһидуллина Р. Йөрәге аша «дөнья уза шаулап...». №10

**ӘДӘБИ БЕРЛӘШМӘЛӘРДӘ**

«Каурый каләм» иҗат берләшмәсеннән: *Г.Шәрипова, Д.Нуриәхмәтов, М.Кашапов, Х.Фәйзрахманова шигырьләре; Г.Зәкиева хикәясе (Халидә Фәйзрахманованың кереш сүзе белән)*. №1

**АК ҖИЛКӘН**

Әгъләмова И. Уңтәпи, султәпи. *Әкият*. №8

Бикмуллина А. *Хикәяләр*. №9

Гыйльметдинова И., Миръякупова Ә., Ногманова Р. шигырьләре. №6

Глухова Э., Сәлахов И., Хәсәнова Г., Шәкертҗанов Ә. шигырьләре. №8

Дәүликамова Ю. Беләзек. *Хикәя*. №4

Насыйрова А. Әминә. *Хикәя*. №11

Нуждина Е. Әни. *Шигырь*. №11

Сафина Л., Сәетгәрәева Р., Фәррахова Р. шигырьләре. №4

Хәбибуллина А. Мизгел. *Хикәя*. №6

**БӘЛӘКӘЙЛӘР**

Галимуллин Ф. Бәләкәй Фоат. №8

М ө х ә м м ә д и е в  Р. Прәникле төшләрем... №12

КИТАП КҮЗӘТҮ

В ә л и е в  М . Мөбарәк тәсбихның бер төймәсе. №5

Г а л и у л л и н  Т. Тапкырлыкта – матурлык. *(Ринат Мәннан «кытыкларына» бер караш)*. №2

ХӘТЕР

М а к с и м о в  Г. Югалган моң. *Хәтердә калганнардан*. №11

ФИКЕР

Х а т и п о в  Ф . Милли яңгыраш. №12

ДИН ҺӘМ ТОРМЫШ

С а л и х җ а н  Х . Шагыйрьнең Коръәнгә мөнәсәбәте. №4

ҮТКӘННӘР САГЫНДЫРА

М и ң н у л л и н  Т. Энесе кем – абыйсы шул... №5

ИСТӘЛЕКЛӘР

Г а л и е в  Г. Кырынды авылы тарихыннан сәхифәләр. №№1, 2

ШӘХЕСЛӘР САГЫНДЫРА

Ш а к и р  С . Мәрхәмәтсезлек. №6

ШӘХЕСЛӘРЕБЕЗ

Г о м ә р  Г. Куш йөрәкле Хәләф. *Эссе*. №1

ӘДИПНЕҢ ТӘҮГЕ КИТАБЫННАН

Ф ә т т а х  Н . Безнең бабай. *Хикәя. (Р.Ханнановның кереш сүзе белән)*. №10

Х а н н а н о в  Р. Алты тиенлек шатлык. №2

Я р у л л и н  Ф . Ана чәчәкләр китерә. *Хикәя*. №2

БАЛАЛАР КИТАПХАНӘСЕ

Х ә й р у л л и н а  В . Йолдыз белән күк матур... *Шигырьләр*. №10

ТАБИГАТЬ ҺӘМ МИН

Г а р и п о в  А . Атларның да тугры җаны бар. №2

УКУЧЫ ФИКЕРЕ

Ф ә т т а х о в а  Л . «Җәһәт тәнкыйть»кә кайтаваз. №5

Ф ә т т а х о в а  Р. Әкиятсез балачак. №12

Ф и р г а л и е в  И . Максатчан әсәр. №5

КУЕН ДӘФТӘРЕННӘН

М и н һ а җ  Р. Ышанычлы иләк. №№2, 3

БЕЗНЕҢ КАЛЕНДАРЬ

Зариф Бәширинең тууына 130 ел. №5

Дәрҗия Аппакованың тууына 120 ел. №3

Әнәс Камалның тууына 110 ел. №3

Вера Минкинаның тууына 100 ел. №9

Айрат Арслановның тууына 90 ел. №4

Гөлчәчәк Галиеваның тууына 90 ел. №2

Нәҗип Мадьяровның тууына 90 ел. №3

Фәтхи Бурнашның тууына 90 ел. №1

Шамил Бикчуринның тууына 90 ел. №1

Шамил Анакның туына 90 ел. №11

Шәүкәт Биктимеровның тууына 90 ел. №10

Гакыйль Сәгыйревнең тууына 80 ел. №2

Ямаш Игәнәйнең тууына 80 ел. №1

ПЕЧӘН БАЗАРЫ

А р и ф у л л и н  Р. *Юморескалар*. №7

Ә х м ә т  Г. Кайткан! *Памфлет*. №3

Г ы й м а д и е в  А . Замана хикәяләре. №6

З а р и ф  Ф . Зарифизмнар. №7

М о т а л л а п о в  З . Туксанынчы еллар көндәлегеннән. №12

Т а җ и  Н . Мин. *Мәсәл*. №3

ЮМОР-САТИРА

«Афәрин, тагын әйт!» *(Равил Шәрәфиевкә 80 яшь)*. Р.Батулла тупламасыннан. №4

В ә л и - Б а р җ ы л ы  М . *Юморескалар*. №1

М и ң н у л л и н  Р. *Юморескалар*. №5

Х ә й р у л л и н  И . *Юморескалар*. №9

ШАЯН СӘХИФӘ

Уены-чыны бергә. *Сәхифәне Марсель Галиев әзерләде*. №№1, 2, 3 , 6, 7, 8, 9, 10, 11, 12

Сәфәрләр, очрашулар, тәэсирләр. №4

«Казан утлары» архивыннан. №№1-12

2019 елда дини бәйрәмнәр һәм истәлекле көннәр. №12

Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. №№1-12

Яңа китаплар. №№2-12

Хушлашу сүзе. С.Шәймиева. №12

# Ictimaği-mədəni tormışıbızdan
# Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан

## ҺӘЙКӘЛЛӘР АЧЫЛДЫ

Казанда галим, фәлсәфәче, тарихчы, мәгърифәтче Шиһабетдин Мәрҗанигә һәйкәл ачылды. Бакый Урманче проекты нигезендә сынчы Рамин Нәфыйков тарафыннан ак мәрмәрдән эшләнгән бу һәйкәл Кабан күле буендагы «Әл-Мәрҗани» мәчете янында урнашкан. Аны ачу тантанасында Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов, Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев, Татарстан мөселманнарының Диния нәзарәте рәисе, мөфти Камил Сәмигуллин, Мәрҗани оныгының оныгы Гөлзадә Мостафина һ.б. чыгыш ясады.

Рөстәм Миңнеханов һәйкәлдәге язуның бары тик рус телендә генә булуына игътибар итеп, ТР Мәдәният министрлыгына Мәрҗанинең исемен татар, инглиз һәм гарәп телләрендә дә язарга күрсәтмә бирде.

***

Казанда М.Җәлил исемендәге опера һәм балет академия театры скверында балет сәнгатендә дөньякүләм танылган биюче, «оча торган татар» Рудольф Нуриевка һәйкәл ачылды. Аны ачу тантанасында ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов, ТР Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев, Президент Аппараты Җитәкчесе Әсгать Сәфәров, мәдәният министры Ирада Әюпова, һәйкәлнең авторы, мәшһүр сынчы Зураб Церетели, иганәчесе Рөстәм Мәһдиев, күренекле әдәбият һәм сәнгать әһелләре катнашты.

## «ШАЯН ТВ»

«Татарстан – Яңа гасыр» телерадиокомпаниясендә «ШАЯН ТВ» дип аталган татрча беренче балалар каналы эшли башлады. «ШАЯН ТВ»ның эшли башлавы уңаеннан оештырылган тантаналы чарада ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов катнашты һәм чыгыш ясады. Аның сүзләренә караганда, яңа телеканалның төп максаты – татар телендә аралашу культурасын үстерү. «Уеннар, төрле кызыклы материаллар телне өйрәнүгә ярдәм итәчәк. Ата-аналар әлеге проектны уңай бәяләр, дип уйлыйм», – диде ул.

## «ГОМЕР КАЛЕЙДОСКОБЫ»

Казан Ратушасында шагыйрь һәм җәмәгать эшлеклесе Равил Фәйзуллинның 75 яшьлеге уңаеннан Татарстан китап нәшриятында татар һәм рус телләрендә басылып чыккан «Гомер калейдоскобы» – «Калейдоскоп жизни» дип аталган яңа китабын тәкъдим итү кичәсе булып узды. Китап шагыйрьнең тормыш юлындагы мөһим этапларны, замандашларының бәясен, фикерен, кабатланмас гомер мизгелләрен – 500ләп фотосурәтне колачлый. Татарстанның 100 еллыгына әзерлек алдыннан соңгы 50-60 елда әдәби-мәдәни хәрәкәтне объектив чагылдырган үзенчәлекле басма бу – китап-альбом.

Кичә Р.Фәйзуллинны 70 яшьлегендә Минтимер Шәймиев котлаган чыгышның видеоязмасы белән башланып китте. Бәйрәмдарны ТР Премьер-министр урынбасары – авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры Марат Әхмәтов котлады һәм аңа «Ватан алдындагы казанышлары өчен» ордены медален тапшырды. Кичәдә Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты рәисе Ренат Закиров, Татарстан Язучылар берлеге рәисе Данил Салихов, ТР Президентының мәдәният фонды башкарма директоры Нурия Һашимова, Татарстанның халык шагыйрьләре Ренат Харис, Рәдиф Гаташ, Татарстанның халык язучысы Гәрәй Рәхим, Башкортстанның халык шагыйре Равил Бикбаев һ.б. чыгыш ясады. Бәйрәмнең башыннан ахырына кадәр Рөстәм Абязов җитәкчелегендәге «La Primavera» оркестры уйнады. Котлауларга республикабызның сәнгать осталары Мөнир Якупов, Илдус Әхмәтҗанов, Резеда Шәрәфиева, Эльмир Низамов, Илүсә Хуҗина, Казан театр көллиятендә укучылар һ.б. чыгышлары кушылды. Кичәне Илдар Кыямов алып барды. Элек «Дворянское собрание» дип йөртелгән бу затлы бинада туган телебездә үткәрелгән беренче зур әдәби-музыкаль бәйрәм булып үтте бу кичә.

## ЗЫЯЛЫЛАРЫБЫЗ – ФИНЛЯНДИЯДӘ

Татарстанның бер төркем мәгариф, фән, әдәбият әһелләре (алар арасында ТР мәгариф һәм фән министрының беренче урынбасары Илсур Һадиуллин, Казан мәгариф идарәсе җитәкчесе Илнар Һидиятов, галимнәр Дания Заһидуллина, Искәндәр Гыйләҗев, Хатыйп Миңнегулов һ.б. бар) Финляндиядә өч көнлек сәфәрдә булып кайттылар. Алар Хельсинкидагы «Ислам җәмгыяте» йортында Шиһабетдин Мәрҗанинең тууына 200 ел тулуга багышланган конференциядә доклад-чыгышлар ясадылар, Россия Федерациясе илчелегендә, Хельсинки универси-

тетында, Лахти шәһәрендәге дөньякүләм атаклы ISKU корпорациясендә күпфункцияле мәктәптә булдылар, тарихи урыннарны карадылар, милләттәшләребез белән очраштылар.

### ДЕКАДА

Казанда Аяз Гыйләҗев әсәрләре буенча спектакльләр декадасы булды. Анда Г.Камал, К.Тинчурин исемендәге, Әлмәт, Түбән Кама, Әтнә татар дәүләт драма, хакас милли театрлары катнашты.

### ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ – МАГНИТОГОРСКИДА

Татарстан Язучылар берлеге әгъзалары, шагыйрьләр Газинур Морат, Рифат Җамал, Марат Закир Чиләбе өлкәсенең Магнитогорск каласында булып, сәяси репрессия корбаннарын искә алу чараларында катнаштылар һәм татар җәмәгатьчелеге белән очраштылар.

### «ИДЕЛЕМ АКЧАРЛАГЫ»

«Иделем акчарлагы» яшь язучылар бәйгесе тәмам. Быел ул унтугызынчы тапкыр үткәрелде. Бәйгедә дүрт номинациядә («Поэзия», «Проза», «Драма», «Балалар әдәбияты») 150 кеше катнашты. Шуларның 45е икенче турга үтте. Әсәрләргә Газинур Морат, Ләбиб Лерон, Илсөяр Иксанова, Марат Закир, Әлфәт Закирҗанов бәя бирде. Быелгы бәйгедә Гран-прига ике яшь иҗатчы лаек булды. Болар – Ләйлә Хәбибуллина, Миләүшә Гафурова (икесе дә шигърияттә).

### ГАРИФ АХУНОВ ПРЕМИЯЛӘРЕ ТАПШЫРЫЛДЫ

Арчада унынчы тапкыр Татарстанның халык язучысы Гариф Ахунов премияләре тапшырылды. Быел әдәби бүләккә сигез егет һәм кыз, өч иҗат коллективы ия булды. Аларга Г.Ахунов исемендәге премия лауреаты дипломы һәм сертификатлар бирелде. Лауреатларны Арча муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Рамил Гарифҗанов, Татарстан Язучылар берлеге рәисе Данил Салихов, шагыйрә, Гариф Ахуновның кызы Наилә Ахунова, язучы-прозаик, «Казан утлары» журналының баш мөхәррире Рөстәм Галиуллин, шушы басманың җаваплы сәркатибе, язучы-прозаик Вакыйф Нуриев котлады.

### ЮБИЛЕЙ

Татарстан Язучылар берлегенең Г.Тукай клубында язучы-прозаик, публицист, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, А.Алиш исемендәге әдәби премия лауреаты Вакыйф Нуриевка 60 яшь тулуга багышланган, «Җаннарны чайкыйсы бар» дип аталган әдәби-музыкаль кичә булды. Кунакларны Язучылар йортының вестибюлендә Арча әдәбият-сәнгать музее тарафыннан әзерләнгән, бәйрәмдарның иҗатын гәүдәләндергән махсус күргәзмә каршы алды. ТР мәдәният министры урынбасары Дамир Натфуллин ТР Президенты Рөстәм Миңнехановның Вакыйф Нуриевны «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләү турында Указын игълан итте. Юбилярны Татарстан Язучылар берлеге рәисе Данил Салихов, «Казан утлары» журналының баш мөхәррире Рөстәм Галиуллин, якташлары – Арча муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Рамил Гарифҗанов, мәдәният идарәсе җитәкчесе Рамил Мөхетдинов, «Казан арты» тарих-этнография музее директоры урынбасары Шәфигулла Гарипов, «Идел-пресс» нәшрият комплексы генераль директоры Әнәс Әскәров, якташ каләмдәшләре Хәнәфи Бәдигый, Гәүһәрия Мәһдиева-Хәсәнова, Наил Касыймов, Гүзәл Әдһәм, галим Фәрит Хуҗин котлады. Кичәдә язучының тормыш һәм иҗат юлы турында әдәбият галиме, «Казан утлары» журналының баш мөхәррир урынбасары Рамил Ханнанов сөйләде. Г.Камал театры артистлары Дания Нуруллина, Хәлим Җәләй, Фәннүр Мөхәммәтҗанов язучының әсәрләрен укыдылар, Казан театр көллияте укучылары скетчларын уйнап күрсәттеләр. Кичәдә Рафаэль Сәхәбиев, Рөстәм Закиров, Алмаз Хәмзин, Люция Мусина, Рафаэль Сафин, Земфира Гыйльметдинова башкаруында җырлар яңгырады. Кичәне язучы-сатирик Камил Кәримов алып барды.

### «ЯЗГЫ КӘРВАННАР» – ТӨРЕК ТЕЛЕНДӘ

Төркиядә Аяз Гыйләҗевның «Язгы кәрваннар» китабы басылып чыкты. Аны төрекчәгә Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы Фатих Кутлу тәрҗемә итте.

### ХЕЗМӘТЕНӘ КҮРӘ ХӨРМӘТЕ

Казан Кремлендә ТР Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин мәгариф, фән, сәламәтлек саклау, дәүләт идарәсе, мәдәният, машина төзү, авыл хуҗалыгы һәм башка өлкәләрдә уңыш казанган хезмәткәрләргә Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләрен тапшырды. Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы, шагыйрь, публицист, озак еллар «Казан утлары» журналы редакциясендә баш мөхәррир урынбасары булып эшләгән Рәфикъ Юныс улы Юнысов «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләнде.

***

Россиянең тарихи мирасын һәм каһарманнары истәлеген саклау эшенә керткән өлеше, югары әхлакый һәм гражданлык позициясе өчен «Татар солдаты» әсәре авторы Айдар Хәлим (Хәлимов Борис Нәҗметдин улы) «Александр Невский» Бөтенроссия тарихи-әдәби премиясе дипломы белән бүләкләнде.

## В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*«Проза и поэзия»: роман М.ЮНУСА «Кипчакская дочь Аксана»; повесть А.ХАМЗИНА «Шарафи»; рассказ Л.ИБРАГИМОВОЙ «Айзида»; стихи И.ИКСАНОВОЙ, Д.ХАЙРУЛЛИНА, Ш.ИМАТДИНОВА (с предисловием Р.ЗАЙДУЛЛЫ).*
*«Новые имена»: стихи Н.ГАНИЕВА.*
*«Актуальная критика»: рубрику ведёт Д.ЗАГИДУЛЛИНА.*
*Литературный конкурс «Достояние»: повесть Ф.ЯХИНА «С весенней красотой».*
*«Литература народов мира»: рассказы К.ВОННЕГУТ (перевод Р.МУХАМЕТШИНА).*
*«Мнение читателя»: Р.ФАТТАХОВА. «Детство без сказок».*
*«130 лет со дня рождения Х.БАДИГИ»: статья Р.ШАГИЕВА и Н.ГАРИФА, посвящённая Х.БАДИГИ.*
*«90 лет со дня рождения Ш.БИКТИМЕРОВА»: фотоархив подготовила Р.ЮСУПОВА.*
*«Мнение»: Ф.ХАТИПОВ. «Национальное звучание».*
*«Юбилеи»: фотографии Р.МУХАМАДИЕВА; Р.МУХАМАДИЕВ. «Сладкие сны».*
*«Сенной базар»: З.МУТАЛЛАПОВ. «Из дневника 90-х годов...»*
*«Страницы юмора»: рубрику ведёт М.ГАЛИЕВ.*
*Библиографический список произведений, опубликованных в 2018 году.*
*Дневник общественно-культурной жизни.*
*На наших обложках: «Татарка». Художник Анвар Сайфутдинов; писатель Лира Ибрагимова.*

## IN THIS ISSUE:

*«Prose and poetry»: novel by M.YUNUS «Kipchak daughter Aksana»; novel by A.KHAMZIN «Sharafi»; story by L.IBRAGIMOVA «Aysida»; poems by I.IKSANOVA, D.KHAIRULLIN, SH.IMATDINOV (with Preface by R.ZAYDULLA).*
*«New names»: poems by N.GANIEV.*
*«Actual critics»: section is conducted by D.ZAGIDULLINA.*
*Literary contest «Heritage»: story by F.YAKHIN «With the spring beauty».*
*«Literature of the peoples of the world»: stories by K.VONNEGUT (translated by R.MUKHAMETSHIN).*
*«130th anniversary of H.BADIGHI»: article by R.SHAGIEV and N.GARIF dedicated to H.BADIGHI.*
*«90th anniversary of SH.BIKTIMIROV»: the photo archive is prepared by R.YUSUPOVA.*
*«Opinion»: F.KHATIPOV. «National sounding».*
*Anniversary: photos by R.MUKHAMADIEV; R.MUHAMADIEV. «Sweet dreams».*
*«The opinion of the reader»: R.FATTAKHOV. «Childhood without fairy tales».*
*«Hay market»: Z.MUTALLAPOV. «From a diary of the 90s...»*
*«Pages of humor»: section is conducted by M.GALIEV.*
*Bibliographic list of works published in 2018.*
*Diary of social and cultural life.*
*On our covers: «Tatar girl». Artist Anvar Sayfutdinov; novelist Lyra Ibragimova.*

---

*Тышлыктагы сурәтләр*

*Тышлыкның беренче битендә:* «Татар кызы». *Әнвәр Сәйфетдинов картинасы.*

*Тышлыкның дүртенче битендә:* язучы Лира Ибраһимова.